ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

6.2012



# Татарстан Республикасы Президенты
# УКАЗЫ

## *2012 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген бирү турында*

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре комиссиясе тәкъдимен карап, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген, «Кол Шәриф мәчете» архитектура комплексын иҗат иткән өчен, **Зөфәр Шәйдулла улы Галиуллин, Андрей Вячеславович Головин, Альбина Кен кызы Даишева, Рөстәм Мөхәммәд улы Зәбиров, Зөфәр Мазһар улы Садыйков, Искәндәр Фуад улы Сәйфуллин, Айвар Гомәр улы Саттаров, Сергей Петрович Шәкүров** составындагы коллективка бирергә.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н.МИҢНЕХАНОВ**

*Казан, Кремль*
*2012 ел, 25 апрель №ПУ-269*



**Казан утлары**

**Qazan utlari**

2012

# 6

**(1076)**

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Камил Кәримов, Ләбиб Лерон, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

*420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир—562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары—562-10-38.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—562-11-53.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—562-11-53.*
*Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге—222-09-80.*
**Факс**—(843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

«Милли асылыбызны җаныбыз белән тойдык, акылыбыз белән аңладык» *(Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең шагыйрь Ленар Шәех белән әңгәмәсе)*. ........ 5

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Нур ӘХМӘДИЕВ. Шагыйрь күңеле — шаулы кара урман. *Шигырьләр*........ 22
Мидхәт МИНШИН. Кызыл диплом. *Бәян*........ 27
Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА. Очышта да күнел сына икән... *Шигырьләр*. ........ 86
Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА. Кояшлы мизгел. *Бәян*........ 89
Илүсә ИСМӘГЫЙЛЕВА. Йөрәк аша уза вакыт... *Шигырьләр*. ........ 111
Фарсель ЗЫЯТДИНОВ. Авылдашның авыр юл башы. *Документаль бәян*........ 114

Гавриил ДЕРЖАВИН. Сәхрәләргә чыга идек без... *Шигырьләр*. ........ 148

Котлаулар........ 150

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Фәридә ХӘСӘНОВА. Йөрәккә яшерелгән серләр *(Флера Тарханова иҗатында газәл жанры)*. . 156

**ТАРИХ**

Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Тукайның остазы һәм оста матбагачы. ........ 161

**ХӘТЕР**

Фәнис ЯРУЛЛИН. Хәтер төпләрендә утлы күмер. *Көндәлекләр*. ........ 166

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы........ 178

**ШАЯН СӘХИФӘ**

Әхәт ГАФФАР. Әкиятләр. ........ 181

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Рәфикъ ЮНЫС. Татар офыгын киңәйткән әдип *(Миргазиян Юныска 85 яшь)*. ........ 186

Юбилеебыз тантанасы мизгелләре........ 154, 184
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........ 186

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

Интервью Л.ШАЕХА с первым Президентом Республики Татарстан М.ШАЙМИЕВЫМ.
«Проза и поэзия»: повесть М.МИНШИНА «Красный диплом»;
повесть Ф.ЗИЯТДИНОВА «Трудный путь односельчанина»; рассказ
Р.ГАБДУЛХАКОВОЙ «Солнечное мгновение»; стихи Н.АХМАДИЕВА;
Э.ШАРИФУЛЛИНОЙ; И.ИСМАГИЛОВОЙ; Г.ДЕРЖАВИНА.
«Литературная критика»: статья Ф.ХАСАНОВОЙ о творчестве поэтессы Ф.Тархановой.
«История»: Л.ХАМИДУЛЛИН. «К.Мотыйги — духовный наставник Г.Тукая»
«Память»: дневниковые записи Ф. ЯРУЛЛИНА.
«Наука»: Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень».
«Наши юбиляры»: Р.ЮНУС. «Писатель, расширивший горизонт татар»;
«Юмор и сатира»: А.ГАФФАР. Сказки.
Фотокадры из юбилейного вечера журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Лето»; писатель Булат ХАМИДУЛЛИН.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

Interview of L.SHAEHA with first President of Tatarstan Republic Mintimer SHAIMIEV.
«Prose and poetry»: novel by M.MINSHIN «Red diploma»; novel by
F.ZIYATDINOV «Hard way of a villager»; story by R.GABDULHAKOVA
«Solar moment»; poems by N.AHMADIEV; E.SHARIFULLINA; I.ISMAGILOVA;
G.DERZHAVIN.
«Literary Criticism»: article by F.HASANOVA about work of poetess F.Tarhanova.
«History»: L.HAMIDULLIN. «K.Motiygi is a spiritual mentor of G.Tukay».
«Memory»: diaries by F. YARULLIN.
«Science»: F. GARIPOVA. «History of our villages».
«Humor and Satire»: A.GAFFAR. Tales.
Snapshots from anniversary of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Summer»; writer Bulat HAMIDULLIN.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 01.06.2012, график буенча 01.06.2012.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ 8155. Тираж 4040.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча
Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ТУ 16-00337.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе иркен.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2012 ел.

# «МИЛЛИ АСЫЛЫБЫЗНЫ ҖАНЫБЫЗ БЕЛӘН ТОЙДЫК, АКЫЛЫБЫЗ БЕЛӘН АҢЛАДЫК»

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ПРЕЗИДЕНТЫ
МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВНЕҢ
ШАГЫЙРЬ ЛЕНАР ШӘЕХ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘСЕ

*Беренче булу бервакытта да җиңел түгел. Шулай да нәкъ менә беренчеләр, кабатланмас булып, тарихта үз урыннарын алалар һәм милләт хәтерендә калалар. Төрки-татар дәүләтләрен төзегән Атилла, Кубрат хан, Казан ханлыгының нигез ташларын салучы Олуг Мөхәммәд... һәм, ниһаять, Минтимер Шәймиев — хәзерге Татарстан Республикасын оештыручы, аның Беренче Президенты, бөек тарихлы татар дигән милләтнең горур исемен дөнья күләмендә ишеттерүче. Безне хәзер таныйлар, фикерләребезгә колак салалар, исәпләшәләр. Без аяк терәп: «Мин — татар!..» дип горурланып әйтәбез, рәхәтләнеп туган телебездә аралаша алабыз.*



Татарстан
Республикасының
Беренче Президенты
Минтимер Шәрип улы
Шәймиев.

*Минтимер Шәрип улы — үзен бөтенләе белән туган милләтенә, республика халкына багышлаган шәхес. Бүген дә ул ватаныбызның киләчәге ышанычлы һәм якты булсын дип яши. Татарстан Республикасының Дәүләт Киңәшчесе буларак, «Яңарыш» фондын оештырып, борынгы Болгар, Зөя шәһәрләрен төзекләндерү кебек олы эшне башлап җибәрүе моны аермачык күрсәтеп тора...*

**— Минтимер Шәрипович, Болгарда һәм Зөядә барган үзгәрешләрне ишетеп, белеп, күреп торабыз. Узган ел ахырында мин Спас районында балалар әдибе Абдулла Алишка багышлап оештырылган чараларда катнаштым. Муниципаль район башлыгы Камил Нугаев безгә тарихи Болгар шәһәрлеген дә күрсәтте. Төзекләндерелгән биналарны, яңа төзелгән һәм сафка басып килгән корылмаларны күреп, күңелдә өмет чаткылары уянды, чөнки төзекләндерү эшләре башлангач, бирегә беренче мәртәбә килүем иде. Кыска гына вакыт аралыгында күпме эш башкарылып ята (922 елда Идел буе болгарларының ислам динен кабул итүенә багышланган бина, яңа Җәмигъ мәчете, Икмәк музее һ.б.). Якын арада нинди яңа корылмалар ачылачак, кайсыларына нигез салыначак, шуны беләсе килә?..**

— Сезнең белән килешәм, чыннан да, Болгардагы һәм Зөядәге тарихи ядкәрләрне торгызу буенча әлеге күләмле проект өчен ике ел — бик кыска вакыт. Шушы вакыт эчендә ул бөтенхалык эшенә әйләнде, аны гамәлгә ашыру бу борынгы шәһәрләрнең барлык тарихи объектларын үз эченә сыйдырган киң колачлы төзү-реставрация рәвешен алды. «Яңарыш» фонды эшчәнлегенең беренче көннәреннән үк, кешеләрне барыннан да бигрәк ниләр һәм ничек эшләнәчәге түгел, кайчан әзер булачагы кызыксындыра иде. Мин ул чакта: «Ике елдан без ике борынгы шәһәрне дә күренекле кыяфәткә китереп, эшебезнең беренче нәтиҗәләрен күрсәтә алачакбыз»,

— дигән идем. Әлбәттә, күпләр моңа шикләнеп карагандыр. Торгызылырга тиешле ядкәрләрнең һәм яңа корылмаларның без тәкъдим иткән эскиз-проектларын, матур макетларын карагач, мондый тиз, әкияти үзгәрешкә ышану кыен булгандыр, чөнки, үзегез беләсез, бу ядкәрләрне төзекләндерүнең зарурлыгы турында сүз гасырлар дәвамында барды. Бу нисбәттән, «Яңарыш» фонды оештырылуны мин кайсыдыр дәрәҗәдә закончалыклы күренеш дип саныйм. Димәк, кем әйтмешли, сәгате суккан, һәм без барыбыз да моңарчы күрелмәгән шушындый зур гамәл өчен өлгереп җиткәнбез. Шуңа күрә эш яхшы гына башланып китте. Ил һәм республика җитәкчеләренең, хәйрияче оешмаларның, тарихи мирасыбызның кадерен белгән игелекле кешеләрнең ярдәме нәтиҗәсендә беренче ике елга исәпләнгән эш күләмен уңышлы башкарып чыга алдык.

Иң беренче чиратта Болгарда да, Зөядә дә көнкүрешне тәртипкә салырга, кешеләрнең яшәү шартларын җайларга кирәк иде. Бүгенгә көнгә элек бөтенләй булмаган инфраструктура һәм коммуникация барлыкка килде, юллар төзелде, газ үткәрелде, чистарткыч корылмалар куелды, җылылык һәм электр энергиясе белән өзлексез тәэмин итү оештырылды. Биредә яшәүчеләрнең торак шартларын яхшыртуга ирештек. Мәсәлән, Болгарда 26 гаилә яңа фатирларга күчте, тагын 21 гаилә яңа фатирларны быел алачак. Ә 14 гаилә өчен шәхси йортлар салына. Зөядә исә ике ел эчендә яңа төзелгән йортлардагы фатирларга 81 гаилә күченде. Моңарчы алар монастырьлардагы кысан хөҗрәләрдә яшиләр иде. Болгарда — музей зонасында, Зөядә — тузган торакта яшәүчеләрне күчерү буенча куйган бурычларыбызны быел тулысынча үтәрбез дип уйлыйбыз.

Кыскача гына санап үтсәк, Зөя утравында 1552 елда салынган агач чиркәү — Троицкая чиркәве, казна корылмалары биналары, сәүдәгәр Каменев йорты, Богородице-Успенское монастыренең биналары, монастырь училищесы торгызылды. XX гасыр башына караган Җәмәгать бинасы төзекләндерелде, анда хәзер балалар өчен Мәгариф үзәге эшли. Елга вокзалы бинасы төзелеп куллануга тапшырылды. Успенье монастыре янында сәяси репрессия корбаннарына һәйкәл куелды. Хәзерге вакытта храмнарда иконаларны, уникаль фрескаларны реставрацияләү эше башланды. Бу, әлбәттә, бик төгәл, күп көч таләп итә торган эш, шуңа күрә ул озакка сузылачак. Зөя шәһәренең тарихи архитектурасын торгызу шулай ук бик күләмле һәм катлаулы эш, бу очракта тиз түгел, нәкъ менә җиренә җиткереп, бөртекләп эшләү зарур.

Болгарда узган ел ахырында булгансыз икән, димәк, безнең эшчәнлекнең беренче нәтиҗәләрен үз күзләрегез белән күреп кайткансыз. Узган елгы «Изге Болгар җыены» алдыннан Чатырлар лагере куллануга тапшырылды, Болгар шәһәрлегенең Көньяк капкасы торгызылды. Хәзерге вакытта биш катлы елга вокзалы төзелә. Аның причалына теләсә нинди зурлыктагы елга суднолары килеп туктый алачак. Ә өске катларында Болгар цивилизациясе музее урнашачак. «Болгар» мәчете һәм мәдрәсәсе комплексы төзелә. Сез искә алган Икмәк музеенда да эшләр ахырына якынлашып килә. Табиб йорты салына. Әлбәттә, Болгарның тиңсез хәзинәсе булган борынгы ядкәрләрне — Җәмигъ мәчетен, Төньяк һәм Көнчыгыш төрбәләрне, Ак, Кара һәм Көнчыгыш пулатларны, Ханнар төрбәсен, Кече манараны төзекләндерү-реставрацияләү эше дәвам итә.

Шушы төзү-төзекләндерү эшләре эчендә кайный-кайный мин инде үзем дә күпмедер дәрәҗәдә археолог, төзүче, архитектор булып җитәм бугай. Һәрхәлдә, тарихи мирас белән эш итүнең берничә кагыйдәсен яхшы үзләштердем. Мәсәлән, тарихи объект җир астыннан казып чыгарылып, ачып куела икән, аны саклау өчен барлык чараларны күрү мәҗбүри. Әгәр дә инде аны тиешенчә сакларга көчең җитмәсә, бөтенләй кагылмавың, җир өстенә чыгармавың хәерлерәк. Шуңа күрә археологлар тарафыннан чагыштырмача күптән түгел табылган Хан сараеның нигезе өстенә саклагыч корылма төзибез. Мең еллар буена сакланган әлеге уникаль истәлекнең кар-яңгыр астында таркалып юкка чыгуына юл куярга һич ярамый.

Быел июнь аенда — Идел буе болгарларының ислам динен кабул итү көнендә — әлеге вакыйга хөрмәтенә салынган яңа бинаны — Истәлек билгесен ачу күздә тотыла. Аның төп залына дөньяда иң зур басма Коръән куелачак. Залның диварына элү өчен Сезгә яхшы мәгълүм Ибн Фадлан илчелегенең Болгарга



*Изге Болгар җыены. 2011 ел, 18 июнь.*

килү юлы күрсәтелгән карта эшләнеп бетәчәк. Аскы залда исә болгарларның ислам динен кабул итү мизгелен сурәтләгән мозаик панно һәм Ибн Фадланның Идел буена сәяхәт турында язмасы татар, рус, инглиз һәм гарәп телләрендә басылып үзенең лаеклы урынын алачак. Якын киләчәккә ниятләр менә шундый.

**— Тарихи чыганаклар буенча, Болгар шәһәре 1236 елда Чыңгыз хан нәселенең дәвамчысы Батый хан тарафыннан яулап алына, яндырыла һәм озакламый янәдән сафка бастырыла. Ә бүгенге көндә әлеге тарихи шәһәрне өлешчә булса да торгызу мөмкинме? Болгарны уратып алган зур, калын, ак таш диварлар, данлыклы Агабазар, хан сарайлары һ.б. күз алдына килә.**

— Әгәр дә Сез бу очракта торгызу төшенчәсен Болгарны өлешчә булса да элеккеге хәленә китерү, ягъни янәдән төзү дип аңласагыз, бу мөмкин нәрсә түгел. Беренчедән, Сез беләсез, Болгар да, Зөя дә ЮНЕСКО оешмасының Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертү өчен әзерләнә. Шуна күрә без тарихи ядкәрләрне саклауның бөтен дөньяда кабул ителгән кагыйдәләре буенча эш итәбез. Алар буенча борынгы хәрабәләр (ә Болгар шундыйлар исәбенә керә) ничек бар — шулай сакланырга тиеш. Аларга реставрация ясарга, саклагыч корылмалар куелырга мөмкин, әмма нидер өстәп төзергә ярамый. Бу аңлашыла да: һәрбер тарихи ядкәр үзен ясаган останың кул җылысын, гасырлар эзен саклый, ул шуның белән кадерле дә. Югыйсә, дин кардәшләребез дөньяның әллә кайсы почмакларыннан килеп Болгардагы Җәмигъ мәчетенең әлегәчә сакланган диварлары янында дога кылып, борынгы ташларны сыйпап йөрмәсләр иде. Шуна күрә Болгар шәһәрлеге җирендә яна корылмалар төзү эшенә бик сак карала.

Шулай да, Болгар җирлегендәге кайбер борынгы истәлекле урыннарны билгеләү мөмкин. Узган ел Изге Болгар җыенында Болгарга ислам динен алып килгән сәхабәләрнең берсенең кабере өстендә шул сәхабәләргә багышлап һәйкәл куелды, хәзерге вакытта аларга бәйле тагын бер истәлекле урын — Габдрахман коесын төзекләндерү эше бара.

Сәхабәләр турында безнең көннәргә килеп җиткән риваять бик кызыклы. Ул, әйтик, Кара пулат легендасы кебек үк киң таралмаган. Шуңа күрә, аны сөйләп китү урынлы булыр дип уйлыйм. Мәгълүм ки, ислам динен кабул иткәнче үк Болгар күренекле шәһәр, сәүдә үзәге булган. Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең өч сәхабәсен ислам динен тарату максатында Болгарга җибәргән. Кулларына юл таягы, язу өчен кара савыты тоттырган һәм берсенә үз башыннан салып чалма кидергән. Бу исә исламның Болгарга тыныч юл белән керүе турында сөйли. Болгарга барыгыз, урамнарда йөрегез, кешеләр белән сөйләшегез, үзегезне Мәккә, Мәдинә табиблары дип тәкъдим итегез, дигән Мөхәммәд пәйгамбәр. Сәхабәләр Болгарга килгәннәр. Бу вакытта биредә Айдархан хакимлек иткән. Аның вәзире сәхабәләрне күреп алып, алар белән танышкан да Айдарханга хәбәр иткән. Ә ханның 20 яшьлек кызы Туйбикә каты авырый икән. Ул сәхабәләрдән кызын дәвалауларын үтенгән. Аның дәвасы — каен себеркесе, дигән табиблар. Бездә алар күп, дигән патша. Юк, безгә шушы таяктан үсеп чыкканы кирәк, дигән Габдрахман атлы сәхабә һәм үзенең юл таягын җиргә кадап дога укыган. Шул мизгелдә таяк кадалган урыннан су ургылган, күз алдында каен үсеп чыккан. Бу күренештән шаккатып калган Айдарханга шушы каеннан себерке ясап биреп, кызын мунчада чабарга кушканнар. Кыз чыннан да терелеп аякка баскан. Айдархан сәхабәләргә рәхмәтләр укып, моның өчен нәрсә

телисез дип сораган. Хак динне кабул итегез, дигәннәр алар. Һәм Болгар кешеләре әкренләп мөселманнарга әйләнгәннәр. Туйбикә исә сәхабәләрнең берсенә кияүгә чыккан, алар 25 ел тату гомер иткәннәр. Риваять буенча Кече манара янындагы мәгълүм кабер дә шул сәхабәнеке, чөнки сәхабәләрнең икесе кире үз илләренә кайтып киткән. Шул тылсымлы юл таягы кадалган урыннан бәреп чыккан чишмәне халык изге чишмә дип кабул иткән, кое ясап, аны изге Габдрахман коесы дип атаган. Аның суы чыннан да шифалы диләр.

Ә инде Сезнең күз алдыгызга килгән ак диварлар, Агабазарга килгәндә, аларны күреп соклану мөмкинлеге булыр дип уйлыйм. Хәзерге фән-техника, компьютерлар заманында бу тормышка ашмаслык нәрсә түгел. Казан (Идел буе) федераль университеты хезмәткәрләре безгә Болгарның космостан төшерелгән фотоларын тәкъдим иттеләр. Алар объектларны 10 см га кадәр төгәллек белән күрсәтә. Бу — археология өчен менә дигән нигез булып тора, яңа технологияләрне файдаланып, археологларга казу эшләрен алып бару өчен урыннарны төгәл билгеләп бирү мөмкинлеге бар дигән сүз. Хәзерге фәнни җайланмалар җир астындагы хәрабәләр буенча объектның 3D сурәтен дә ясап бирә ала. Димәк, Болгар җире астында ниләр ятканын ачыклап була. Шуна күрә хәзерге вакытта яшь галимнәр борынгы Болгар шәһәрлегенең макетын һәм виртуаль күренешен булдыру буенча эшлиләр.

**— Сез узган елның ноябрендә Италиядә булып кайттыгыз. Чит ил белгечләренең бездәге тарихи һәйкәлләр турында фикерләре ничек? Болгар белән Зөянең ЮНЕСКО канаты астына керүе Татарстанга нәрсәсе белән отышлы булачак?**

— Чит илләрдә йөреп гыйбрәт ал дигән татар халык мәкаленә ияреп, без Италиягә, Салерно провинциясенә, ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы объекты — Пестум шәһәрен карарга бардык. Безне анда Мәдәни хәзинәне саклау һәм реставрацияләү буенча халыкара тикшеренү үзәге (ICCROM) генераль директоры, «Яңарыш» фондының Белгечләр советы әгъзасы, фикердәшебез Мөнир Бушенаки чакырды. Нәкъ менә Пестумга баруыбыз очраклы хәл түгел. Аның борынгы истәлекләре безнең Болгар ядкәрләрен хәтерләтә, алар тарихлары буенча да бер-берсенә охшаш.



*ICCROMның генераль директоры Мөнир Бушенаки белән Болгарда. 2011 ел, май.*

Пестум (иң беренче исеме — Посейдония) шәһәренә безнең эрага кадәр VI гасырның беренче елларында шул тирәдә урнашкан грек каласы Сибаристан чыккан ахей кешеләре нигез салган, ул заманда шәһәр Лукания елгасының көнбатыш ярында (хәзерге Салернодан 35 км көньяк-көнчыгышта) урнашкан. Соңрак ул әлеге сазламык урыннан Бөек Грециянең эченәрәк күчерелгән.

Пестумның чәчәк аткан чоры безнең эрага кадәр 540нчы елларга һәм аннан соңгы унъеллыкларга туры килә. Безнең эрага кадәр V гасыр ахырынарак ул грек мәдәниятенә хас билгеләрен җуйган һәм гадәти шәһәргә әверелгән. Безнең эрага кадәр 274 елда Пестум латин колониясенә әйләнгән һәм шул чордан башлап үз әһәмиятен югалткан, соңгы елларда ул тирә-ягын тоташ әйләндереп алган роза чәчәкләре белән генә күренекле булган.

IX гасыр ахырында Пестум сарациннар тарафыннан таланган һәм ташландык хәлгә килгән. Биредә өч дорик храм бик яхшы сакланып калган. Аларның берсе Афина алиһәгә багышланган. Калган икесе Гера хөрмәтенә төзелгән һәм хәзер алар Гера храмы I һәм Гера храмы II дип атала. Шәһәр диварларының кинлеге

алты метрга кадәр җитә, периметры биш километрны тәшкил итә. Без ул храмнар тирәсендә шактый озак йөрдек.

Пестумның хәрабәләре ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә чагыштырмача күптән түгел — 1998 елда кертелгән. 1968 елда Пестумда «Суга чумучы төрбәсе» табылган. Аның эчендә безнең эрага кадәр якынча 470 елгы фрескалар сакланып калган. Бу классик чорга караган грек фреска сәнгатенең безнең заманга тулысынча диярлек килеп җиткән бердәнбер ансамбле икән. Диварга ясалган әлеге биш сурәт, башка антик табылдыклар белән беррәттән, җирле Милли археология музеена урнаштырылган. Бу кызыклы музейны карап чыгуыбыз да бик файдалы булды, музей эшләрен алып баруның яхшы үрнәген күрдек.

Чыннан да, Пестум шәһәре бүгенге көндә археологик объектларны реставрацияләүнең, консервацияләүнең һәм музейлаштыруның уникаль өлгесе булып тора. Мин итальяннарның үз тарихи мирасына карата кайгыртучан һәм сакчыл карашына сокландым. Аларның тәҗрибәсен без Болгардагы тарихи истәлекләрне саклау буенча эштә киң куллана алабыз. Без бит Болгарны ЮНЕСКО исемлегенә тарихи-археология комплексы буларак тәкъдим итәбез.

Пестум белән Болгарның охшашлыгын күреп мин шуны билгеләп үттем: Италия галимнәренең Пестумдагы кебек зур мәйданнарда археология объектларын реставрацияләү буенча тәҗрибәсен һәм технологияләрен гомумиләштерү безгә үзебезнең борынгы истәлекләребезне, атап әйткәндә, борынгы Болгар ядкәрләрен казып чыгару, консервацияләү, музейлаштыру буенча мәсьәләләрне хәл итүнең иң яхшы юлларын табарга мөмкинлек бирәчәк. Игътибарыгызны шуна юнәлтәсем килә: нәкъ менә зур мәйданнарда тарихи ядкәрләрне берәм-берәм янарту түгел, тарихи тирәлекне тулаем торгызу. Без Болгарда да, Зөя утравында да үзебез алдына шундый бурыч куйдык та.

Пестум дөньяда Археологик туристлыкның Урта диңгез биржасы белән дә киң танылган. Ул биредә 1998 елдан башлап үткәрелә. Бу — дөньяның байтак илләрен берләштерүче зур күргәзмә. Әлеге илләрнең һәрберсе үзенең тарихи истәлекләрен сакларга мөмкинлек бирә торган алымнарны һәм алдынгы технологияләрне тәкъдим итә. Без биржаның экспонатларын бөртекләп карап чыктык. Археологиядә кулланыла торган виртуаль чынбарлыкны һәм компьютер графикасын файдалануның иң яңа мисалларына аеруча игътибар иттек. Рим, Болония һәм башка университетлар тарафыннан күрсәтелгән виртуаль археология буенча инсталляция (фильм) проектлары бик кызыклы булып чыкты. Без аннан яңа идеяләр белән кайттык һәм аларны әкренләп гамәлгә ашыра барабыз. Сүз уңаеннан шуны әйтим: хәзерге вакытта Болгардагы Икмәк музеена кергән биналарда музейлаштыру эше бара һәм анда менә шушы алдынгы ысуллар кулланыла.

Без шулай ук Римда ICCROM — Мәдәни хәзинәне саклау һәм реставрацияләү буенча халыкара тикшеренү үзәгенең штаб-фатирында да булдык. Италия белгечләре, исемнәре бөтен дөньяга мәгълүм галимнәр белән сөйләштек. Алар киң күңелле кешеләр булып чыкты, безгә үзләренең серләрен чиштеләр, эшләү ысулларын күрсәттеләр, археологик объектларны реставрацияләү барышында ихтимал хаталар турында искәрттеләр. Дөресен әйтим, итальяннарның Болгарда һәм Зөядәге торгызу эшләре белән чынлап кызыксынулары безне гаҗәпләндерде дә, шатландырды да. Алар әйтүенчә, безнең Болгар һәм Зөя истәлекләрен реставрацияләү һәм музейлаштыру мәсьәләләрен җентекләп башкарып чыгарга омтылышыбыз аларда зур ихтирам уяткан икән.

Һичшиксез, дөньякүләм объектларны карап йөрү һәм халыкара дәрәҗәдәге реставраторлар-белгечләр, археологлар белән сөйләшү-киңәшү Болгар һәм Зөя тыюлыкларындагы эшне дөрес оештыру өчен бик мөһим. Әмма хикмәт монда гына түгел. Дөньякүләм тәҗрибә шуны раслый: үз халкыңның мәдәни һәм тарихи мирасын саклау — бөек тарихи үткәнне дөрес итеп, ничек бар — шулай ачып бирү мөмкинлеге ул.

ЮНЕСКО белән мөнәсәбәтләрдә дә уңышларыбыз бар. Хәзерге вакытта «Болгар тарихи-археология комплексы» һәм «Зөя тарихи-мәдәни һәм ландшафт комплексы» дигән номинацияләр, ягъни алар буенча бөтен документ тулысынча

әзерләнеп, ЮНЕСКО комиссиясенә тапшырылды. Быел ICCROMның халыкара белгечләре Болгарга һәм Зөягә килеп, аларның ЮНЕСКО таләпләренә туры килүен тикшерәчәкләр. Белгечләр фикеренчә, Болгар һәм Зөя турында документлар 2013 елда, ЮНЕСКОның чираттагы утырышында каралачак.

Сезнең сорауга җавап йөзеннән шуны әйтәсем килә: чыннан да, Болгар белән Зөяне ЮНЕСКО канаты астына кертү безнең өчен бик отышлы хәл.

Беренчедән, Бөтендөнья мирасы исемлегенә кергән тарихи истәлекләр ЮНЕСКО яклавы һәм күзәтчелеге астында була. Әйтик, ул истәлекләргә беркем дә кагыла алмый һәм, иң мөһиме, аларның торышы һәрдаим тикшерелеп тора, ягъни, телисеңме-теләмисеңме, аларны төзек һәм бөтен итеп саклауның барлык шартларын үтәргә тиешсең. Тарихи ядкәрләргә бер бөртек тә зыян килмәскә тиеш.

Икенчедән, бу вакыйга Татарстанның халыкара абруен күтәрәчәк. Без үз мирасының кадерен белә торган алдынгы, цивилизацияле республика буларак та танылачакбыз.

Өченчедән, барыбызга да мәгълүм ки, туристларның дөнья буенча төп агымы ЮНЕСКО исемлегендәге тарихи ядкәрләргә юнәлә. Димәк, Татарстан өчен халыкара туристлык хәрәкәтенә юл ачыла. Мәсәлән, Казан Кремле ЮНЕСКО исемлегенә кергәч, аны карарга килүче туристлар саны бермә-бер артты, узган ел миллионга житте. Туристларны кабул итү эшен оста итеп оештыра алсак, Казан, Болгар һәм Зөя Татарстанны дөньядагы мәшһүр туристлык үзәкләренең берсенә әйләндерә алачак.

**— Зөя утрау-шәһәренә Болгарга караганда шактый соңрак нигез салына һәм аны Явыз Иван Казан ханлыгын яулап алу өчен төзетә, шуңа андагы биналар яхшырак һәм күбрәк сакланып калган кебек... Бирелә алып барылган төзекләндерү эшләрен башка дин вәкилләре ничек кабул итә?**

— Зөя — Урта Иделдәге иң беренче православие шәһәре, аның Россия дәүләтен формалаштыруда үз роле бар. Ул заманнарда Зөядә булган вакыйгалар буыннан-буынга тапшырылып, Татарстанда яшәүче кешеләрдә төрле хисләр уята. Әйе, ул — Казанны яулап алу өчен төзелгән ныгытма. Безнең аны төзекләндерү эшенә тотынуыбызга сәяси яңгыраш бирергә тырышучылар да юк түгел. Әмма мин гел шуны әйтеп килэм: максатыбыз — фәнни-тарихи эзләнүләрне сәясәткә әйләндермичә, республикада яшәүче халыкларның матди мирасын торгызу. Әйтик, Зөя соборларының архитектурасын һәм андагы гаҗәеп фрескаларны сәясәтчеләр ясамаган ләбаса, бөек осталар иҗат иткән. Собор диварларында аларның кабатланмас эзе, аларның буяулары, аларның иҗаты калган. Гомумән, буыннан-буынга нәфрәт тапшыру — дөрес гамәл түгел. Безгә кагылышлы тарихка күз салсаң, татар-монгол гаскәрләренең Рәсәй җирләрен басып алу чорын бәяләү инде ничәмә-ничә гасыр бәхәсләр тудыра. Әгәр дә без алга киткән халык булырга телибез икән, катлаулы тарихыбызны белеп, аңлап, тиешле нәтиҗәләр ясап, киләчәк турында фикер йөртеп, туган җиребезгә хезмәт итәргә тиешбез. Кайбер галимнәр сүзендә үпкә төсмерләре ишетелә. Бу очракта мин Алман иле канцлеры Ангела Меркельның Мәскәүгә Бөек Җиңүнең 65 еллыгын бәйрәм итәргә килүен мисал итеп алам. Кызганыч, әмма сугышта союздаш булган илләрнең житәкчеләре юк иде анда. Ә җиңелгән як килде. Ана Кызыл мәйданга килеп басу җиңел булмагандыр



*Зөядә. 2011 ел, 30 июнь.*

дип уйлыйм. Менә бу — лаеклы гамәл. Димәк, алар фашизмнан катгый төстә баш тарталар, киләчәк буыннарны бу афәтнен эзеннән азат итәргә тырышалар дигән сүз. Бу очракта мин Мәскәү һәм Бөтен Русь патриархы Алексий II нен Явыз Иван турында әйткән фикерләре белән танышырга тәкъдим итәр идем.

Һәрбер халыкның үз язмышы, үз тарихы. Кемдер күп илләрне буйсындырып килеп, соныннан үзе кемгәдер буйсынган. Ошыймы ул безгә, юкмы, ул бит безнең үткәнебез. Минемчә, тарих ничек булган, шулай чагылырга тиеш. Шунысы куанычлы: бу юнәлештә уңай күренешләр әлеге проектны гамәлгә ашыру вакытында күзгә ташлана. Игътибар итсәгез, без төрле диннәргә караган ике изге шәһәрне торгызу өчен бер фонд оештырдык, моның да мәгънәсе тирән. Бу әлеге эшнең барыбыз өчен дә уртак булуын дәлилләп тора. Эш барышында төрле оешмалар, төрле диндәге хәйриячеләр арасында эшлекле, хәтта дустанә мөнәсәбәтләр урнашты. Гомумән, тарихта булган вакыйгаларда хәлиткеч рольне халыклар үзләре түгел, нигездә дәүләт житәкчеләре, аларның сәясәте уйнаган.

**— Агымдагы ел Россия Федерациясе күләмендә «Россия тарихы елы» дип игълан ителде. Бәхәссез, Россия тарихында татарларның роле әйтеп бетергесез зур. Моны (авырлык белән булса да) барыбер таныйлар. Чит илдә, мәсәлән, Польшаның Гданьск шәһәрендә татар сугышчысына һәйкәл куйдылар хәтта! Сезнеңчә, быел чын тарихны тану дәвам итәрме?**

— Гомумән, татарлар дөнья тарихында да шактый эз калдырганнар. Сүз уңаеннан, бер кызыклы факт: инглиз галиме, Кытай буенча танылган белгеч Эдуард Паркер, мәсәлән, кытайларның тарихын өйрәнү барышында татарлар турында шулкадәр күп мәгълүматка тап булган ки, хәтта татарлар турында «Бөек халык тарихы» дигән аерым бер китап язарга мәжбүр булган.

Ә татарларның Россия тарихындагы роле — ул үзе бер зур тема. Татарлар бүгенге көнгә кадәр Россиядә сан ягыннан икенче милләт булып тора икән, бу, әлбәттә, юктан бар булмаган. Россиянең үсешенә төрле заманнарда, төрле өлкәләрдә зур өлеш керткән шәхесләр арасында татар морзалары бик күп. Татар фамилияле рус эшлеклеләрен Сез үзегез дә яхшы беләсез, алар Россия тарихыннан һәркемгә мәгълүм. Россия дәүләтчелегенең тарихын ничә гасырлар буе «татар-монгол изүе»нә каршы көрәш рухында бәян итеп килделәр. Шуңа күрә безнең халык өчен иң авыр мәсьәлә — татар-монгол явы темасы иде. Җәмәгатьчелекнең безнең тарихка мөнәсәбәтен үзгәртү юнәлешендә иң беренче адымны Лев Гумилев ясаган дип саныйм. Аның коточкыч ябык совет елларында, җәмәгатьчелек фикеренә каршы килеп, татарлар турында дөреслекне язарга кыюлыгы җиткән. Мин аның әсәрләрен җентекләп укып чыктым: «Борынгы төркиләр», «Борынгы Русь һәм Бөек дала», «Русьтан Россиягә кадәр» һәм башкалар. Ул татарлар турында уйдырмаларны бик үткен итеп «кара легенда» дип атаган. Гумилев Россия дәүләтенең асылын төгәл билгеләп биргән: Россиянең ике чыганагы бар — славяннар һәм төркиләр, православие һәм ислам, Киев Русе һәм Алтын Урда, дигән ул. Лев Гумилев — татар халкының тирән ихтирамына лаек шәхес ул. Шуңа күрә без Казанның 1000 еллыгына шәһәрнең үзәгендә аңа һәйкәл куйдык. Игътибар итсәгез, анда аның сүзләре язылган: «Мин, рус кешесе, гомер буе татарларны яладан яклап киләм». Мин Сезгә аның татарлар турындагы бу фикерен тулысынча китерә алам: «Белегез, бу — горур исем! Ялган фәнни, сәяси яки нинди дә булса башка конъюнктура өчен түгел, дөреслек хакына мин, рус кешесе, гомер буе татарларны яладан яклап киләм. Алар — безнең канныбызда, тарихыбызда, телебездә, тирә-юньгә мөнәсәбәтебездә. Минә менә мондый күзаллау бик табигый тоела: чынбарлыкта руслардан аермалары нинди генә булмасын, татарлар — безнең янәбыздагы түгел, безнең эчебездәге халык ул». Минемчә, бүгенге вәзгыять менә шуны аңлауга, тануга таба юнәлтелергә тиеш. 2010 елның 25 ноябрендә Польшаның Гданьск шәһәрендә татар сугышчысына тантаналы төстә һәйкәл куелуны да моның бер чагылышы дип карарга кирәктер, мөгаен. Чыннан да, 600 ел элек Польша-Литва дәүләтенең Грюнвальд сугышында тарихи җиңүенә турыдан-туры татар гаскәриләре ярдәм иткән. Татарларга рәхмәт йөзеннән әлеге һәйкәлне кую — Польша хөкүмәтенең тәкъдиме булган бит. Тантанада аларның президентлары

пан Бронислав Комаровски катнашкан. Ул үзенең әнисе Ядвига белән һәйкәлгә чәчәкләр куйган. Пани Ядвига әтисе ягыннан булган татар тамырлары белән горурлануын сөйләгән. Бу хәл полякларның анда яшәгән татарларны килмешәк дип түгел, үз итеп кабул итүләрен аңлата түгелме? Польшада да татарлар белән поляклар язмышы бергә үрелгән. Минем Варшавада атаклы Юзеф Пилсудский музеенда булганым бар. Полякларның горурлыгы — күренекле маршал, 1918 елда яңадан торгызылган Польша дәүләтенең беренче җитәкчесе Юзеф Клеменс Гинятович Косьчеша Пилсудскийның исеме үк татарларга катнашы булганлыгын күрсәтеп тора. Юзеф — Йосыфтыр инде ул, Гинятович — Гыйниятович... Һәйкәл ачу тантанасында безнең Бөтендөнья Татар конгрессы, гомумән, башка төбәклардән дә татар оешмалары вәкилләре, Кырым татарлары да катнашкан. Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов, үзенең Польшадагы эшлекле сәфәре вакытында, ул һәйкәлгә чәчәкләр салган иде. Моңа Россия матбугатында бераз шаулап алдылар, ләкин бу вакыйганың асылына төшенә башласаң, әллә ниләр ачыклана. Әйтик, моннан алты йөз ел элек булган хәлиткеч сугышта (Поляк корольлеге белән Бөек Литва кенәзлеге — бер яктан, Тевтон ордены икенче яктан) полякларга Алтын Урдадан килгән татар гаскәрләре булышмаган булса, Тевтон ордены тагын да Көнчыгышкарак җәелер, бәлкем, Россия үзе дә бүген католик дәүләт булыр иде. Тарихи борылышлар кайчак бик кызыклы бит алар.

**— «Россия тарихы елы» буларак, быел Республикабызның Сез җитәкләгән «Яңарыш» фондына да сизелерлек ярдәм булырга тиеш кебек. Гомумән, Россия хөкүмәтенең «Болгар — Зөя» проектына карашы нинди? Хуплыйлармы, үз фикерләрен әйтәләрме, тәкъдимнәрен кертәләрме, финанс ягыннан ярдәм итәләрме?..**

— Болгар һәм Зөя калаларындагы тарихи ядкәрләр илкүләм әһәмияткә ия, шуңа күрә мондый зур эшне башкаруда Россия хөкүмәте дә житди ярдәм күрсәтә. Сүз уңаеннан, 1722 елда Идел буйлап Азовны алырга барганда, Петр I Болгарга кагылган, борынгы ташландык шәһәргә игътибар иткән, Казан губернаторына бу тарихи ядкәрләрнең исемлеген төзергә, аларны төзәтергә һәм сакларга кушып Указ язган. Бу Россиядә тарих һәм архитектура ядкәрләрен саклау турында беренче Указ булган.

Татарстан Республикасы Президенты вазифасыннан китәргә карар кылгач, 2009 елның декабрендә мин Мәскәүдә Россия Премьер-министры Владимир Путин белән Болгар һәм Зөяне торгызу эше турында махсус сөйләштем. Президент Дмитрий Медведевка бу турыда ул безнең республикага килгәч сүз кузгаткан идек. Мин ана Болгарны һәм Зөяне вертолеттан күрсәттем. Мин аларга бер генә сорау бирдем: «Сезгә Казан Кремле ошыймы?» «Ошый», — диделәр. «Алайса, әйдәгез, бездәге милләтара дуслыкның, диннәргә тигез карашның символы булган Казан Кремле үрнәген кинрәк манзарага — Идел ярларына чыгарыйк, әлеге борынгы шәһәрләрнең икесе дә Иделнең искиткеч матур ярларында урнашкан бит», — дидем. Алар бу идеяне хупладылар. Әлбәттә, алар хуплавының хикмәте, бер яктан, федераль мирас булып саналган тарихи ядкәрләребезне саклап калу, аларны дөньяга күрсәтү, туристлыкны үстерүдә булса, икенче яктан, Россия кебек күпмилләтле ил җитәкчеләре өчен диннәргә һәм милләтләргә тигез караш идеясен тарату мөмкинлегенең бүген аеруча мөһимлеген аңлау. Хәзер моңа бөтен дөнья мохтаҗ.

Шул рәвешчә, без, ил җитәкчеләренең фатихасын алып, Россия хөкүмәте тарафыннан ярдәм турында да килештек. Бу проектка финанс ярдәме федераль бюджеттан да, республика бюджетыннан да тигез өлешләрдә бүлеп биреләчәк дип сөйләштек. Узган ике елда сөйләшенгән сүз төгәл үтәлә. Шунысын да әйтергә кирәк: ил җитәкчеләре проектны гамәлгә ашыру барышы белән кызыксынып торалар. Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов бу проектны үз игътибарында тота, эзлекле рәвештә ярдәм итә.

**— «Яңарыш» фонды заказы белән Италиядә дөньядагы иң зур басма Коръән әзерләнде. Матбугат чаралары бу хакта күп язды. Башта безнеке зуррак диделәр, аннары Әфганстандагысы... Хәер, хикмәт анда гына да түгел. Коръән узган елның 17 ноябрендә Казанга кайтарылды һәм быел Болгарда узачак чираттагы тантаналарга**

**кадәр Кол Шәриф мәчетенә куелды. Чыннан да, бу татар халкы өчен олы бүләк кенә түгел, ә Россия һәм дөнья дәрәҗәсендә зур мәртәбә. Җир шарында ислам дәүләтләре күп, аларның безгә караганда мөмкинлекләре дә күпкә зуррак. Сезнеңчә, ни өчен нәкъ менә Татарстан Республикасы бу эшне башкарды? Ислам дәүләтләре нинди караштa тора?**

— Сезнен мәгълүматыгызны бераз аныклау кирәк дип саныйм. «Янарыш» фонды эшләткән Коръән ул хәзер дә дөньядагы иң зур ***басма*** Коръән булып кала бирә. Күптән түгел безгә Гиннесс рекордлары китабыннан моны дәлилләүче сертификат та килеп иреште. Биредә «басма» дигән сүзне ассызыкларга кирәк, чөнки Әфганстандагы Коръән ул иң зур ***кульязма*** Коръән сыйфатында үзенчәлекле. Бу очракта хикмәт үлчәмнәрдә түгел.



*«Яңарыш» фонды заказы белән дөньяда иң зур басма Коръән эшләнде. 2011 ел, 17 ноябрь.*

Ни өчен мондый Коръәнне нәкъ менә Татарстан эшләде? Беренчедән, басма Коръәннәр тарихында Казанның үз урыны бар. 1803 елда Коръәннен иң беренче мөселман басмасы нәкъ менә Казан типографиясендә чыккан. Аны мөселман дөньясында «Казан басмасы» дип атыйлар һәм классик Коръән дип саныйлар. Ул заманнарда мөселман илләрендә нәшер ителгән Коръәннәр шушы Казан нөсхәсе нигезендә басылганнар. Без әнә шул традицияне дәвам иттек. Икенчедән, Болгар — хәзерге Россия территориясендә ислам динен иң беренче булып рәсми һәм ирекле рәвештә кабул иткән изге урын. Анда мәдәният хәзинәсе дип танылган үзенчәлекле Коръән урнаштыру, минем фикеремчә, татар халкының бөтендөнья мөселман мәдәниятендә тоткан урыны һәм ана керткән лаеклы өлеше булып тора.

Дөньядагы иң зур басма Коръән быел май аенда, Идел буе болгарларының ислам динен рәсми рәвештә кабул итүләре хөрмәтенә төзелгән Истәлек билгесе бинасына урнаштырылачак. Шул вакытта без Гиннесс рекордлары китабының сертификатын да халыкка күрсәтәчәкбез. Анда болай дип язылган: «Дөньядагы иң зур басма Коръән (буе — 2 м, иңе — 1,52 м, калынлыгы — 0,17 м), ARC Groups.r.l компаниясе (Италия) тарафыннан эшләнгән, Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика фонды (Россия) тарафыннан 2011 елның 17 ноябрендә Кол Шәриф мәчетенә (Казан, Татарстан Республикасы) тапшырылган».

**— Соңгы вакытта Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов башкалабыздагы тарихи урыннарны, биналарны карап йөри башлады. Дөрес, күп истәлекләребез сүтелә, җимерелә, яндырыла. Казаныбызның йөзе югала. Хәтта бөек Тукаебыз яшәгән «Болгар» кунакханәсе дә чыгарылма түгел. Данлыклы «Матбугат йорты» бушап калганга да биш ел... Бүген безгә Болгар шәһәрлеге, андагы тарихи биналар никадәр кадерле, аларның дөньякүләм әһәмияте никадәр зур булган кебек, киләчәктә Казанның архитектура истәлекләре дә шул дәрәҗәдә кыйммәтле булачак. Башкалабызның тарихи йөзе җуелып бетеп бара бит. Бу очракта нишләргә, нинди чыгу юлларын табарга? «Яңарыш» фонды башка тарихи һәйкәлләрне торгызуны да максат итеп куймыймы (Казан, Алабуга һ.б.)? Быел Татарстанда да «Тарихи-мәдәни мирас елы» бит әле...**

— Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика фондын оештырганда ук Фондның максаты: Болгар тарих-архитектура музейтыюлыгын, «Зөя утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музеен,

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан башка тарихи һәм мәдәни истәлекләрне торгызуга һәм үстерүгә, Татарстан Республикасы күпмилләтле халкының тарихи, мәдәни һәм рухи традицияләрен саклап калуга һәм үстерүгә булышлыкны оештыру дип билгеләнгән иде.

Чыннан да, ныклап тикшерәсе, яңартасы, төзекләндерәсе тарихи ядкәрләребез күп әле безнең. Бу, бер яктан, безнең бай тарихлы халык икәнебезне күрсәтсә, икенче яктан — алдыбызга бик җитди бурычлар куя. Бу тарихи истәлекләрнең киләчәк буыннарга исән-имин барып җитүе өчен, чыннан да, без җаваплы бит. Татарстан тарихының үзенчәлеге шунда ки, тарихи урыннарны башлыча археологик документлар аша гына өйрәнү мөмкин. Географик яктан бик уңайлы җирдә урнашу сәбәпле, безнең аша бик күп халык узган, күп вакыйгалар, сугышлар, күченүләр булган, шуңа күрә бик күп язма документлар һәм истәлекләр юкка чыккан. Сез яхшы беләсез, безнең бик кадерле тарихи җәүһәрләребез — Биләр, Сувар, Тәтеш шәһәрләре бар. Алга таба археологлар, галимнәр, тарихчылар аларга игътибарларын күбрәк юнәлтергә тиеш, әлбәттә. Болгарда елга вокзалы төзү турында әйтеп киткән идем. Анда, причалдан бинага керә торган җирдә без төрле чорларда Болгар дәүләтенең башкалалары булып торган Биләрне һәм Суварны чагылдыручы ике портал куйдык.

Казан мәсьәләсенә килгәндә исә, Рөстәм Нургалиевичның Казандагы тарихи урыннарны саклауга турыдан-туры алынуын хуплыйм. Тора-бара Сез телгә алган архитектура истәлекләрен реставрацияләү, төзекләндерү эшләренең формасы, вакыты, күләме билгеләнер дип уйлыйм.

**— Безнең Актаныш районы гына милләтебезгә күпме асыл уллар һәм кызлар биргән! Шагыйрьләр, язучылар, җырчылар, биючеләр, галимнәр, спортчылар, сәясәтчеләр... Шулай да һәрбер кеше туган ягы, туган районының нинди дә үзенчәлеге бар дип исәплидер. Сезнеңчә, безнең якның төп үзенчәлеге нәрсәдә? (Мәсәлән, тарихи үзенчәлеге һ.б.?..)**

— Минемчә, иң элек Актаныш шуның белән үзенчәлекле: анда көн Татарстанның башка районнарына караганда иртәрәк туа, тормыш ике сәгатькә иртәрәк башлана. Без балачакта күрше Башкортстан радиосы буенча яши идек. Тугандаш башкорт халкы белән якынлык ул безнең сөйләм теленә дә кереп калган. Мин һәрвакыт әйтеп киләм: без башкорт җырларын тыңлап үстек. Авыл җирендә иртә торасың, мәктәпкә киткәнче йорт-кура арасында эшләп алырга да өлгерәсен. Ә бу вакытта Башкортстан радиосы инде сөйли, иртәнге концерт тыңлыйбыз. Ә Казан радиосы сөйли башлаганда инде өйдән чыгып киткән булабыз. Шул рәвешчә, без башкорт җырлары-моңнары тәэсирендә үстек. Мәдәниятебез, әдәбиятыбызның шулкадәр якын, шулкадәр үзара тыгыз үрелгән булуын, бер-берсен тулыландыруын, баетуын яшь чакта ук тоеп, белеп үстем.

Ә табигатебезнең матурлыгы! Иң матур елгалар ярында урнашкан бит безнең туган җир — Агыйдел, Кама, Ык, Сөн... Тагын бер үзенчәлек: бүген Актаныш районындагы 88 авылның икесе — Мари Суыксу һәм Терпеле — мари авыллары, Михайловка — татарлар белән катнаш рус авылы исәпләнә, калганнары — саф татар авыллары. Актаныш районында яшәүчеләрнең 98 проценты татар, шуңа күрә милли традицияләр, милли тәрбия, милли мәдәният көчле. Бу байлыкны саклау һәм тагын да үстерүдә Актаныш муниципаль районы башлыгы Энгель Фәттаховның хезмәте мактауга лаек.

Актанышның тарихы да гаять үзенчәлекле бит аның, мәсәлән, ул Татарстанның бер өлеше булып бары тик 1920 елдан гына исәпләнә. Аңа кадәр ул бер-бер артлы Казан, Оренбург, Уфа губерналары составында йөри.

Актанышлыларның тарихи тамырлары болгар бабаларыбызга барып тоташа. Галимнәр әйтүенчә, безнең җирлектә иң әүвәл күпчелек фин-угыр кабиләләре яшәгән. Археологик материаллар да шул хакта сөйли. Безнең эраның IV гасырыннан башлап күчмә кабиләләр, угырлар бу якларга үтеп кергәннәр. XI-XII гасырдан исә Ык һәм Агыйдел елгалары арасына Идел буе болгарлары күченгәннәр.

Актаныш татарларын типтәрләр дип атыйлар. Тарихчылар фикеренчә, XVIII

гасыр ахырында рус булмаган «җибәрелгән» кешеләрне татар дөньясында шулай дип йөртә башлыйлар. Нигездә, алар хәзерге Башкортстан һәм Урал алды җирләрендә яшәгәннәр. «Типтәр» атамасының барлыкка килүе һәм ясалышы турында төрле фикерләр бар. Галимнәр әйтүенчә, бу этноним татарлар арасында крестьяннар сословиесен аңлата. Типтәр сүзе – фарсы сүзеннән алынган — «дәфтәр» дигәнне белдерә, төрки-монгол сүзеннән күчкән. Башта мәгънәсе буенча законнар исемлеген аңлаткан. Алтын Урда чорында «ясак түләүне һәм суд карарларын язу дәфтәре» мәгънәсендә кулланылган. «Типтәр» дип нинди дә булса исемлеккә кертелеп, яки килешү нигезендә «законлы» рәвештә яшәүче кешеләрне атаганнар, ягъни алар дәфтәргә теркәлгән, дигән сүз. Мондый төркем кешеләре XVI гасырның икенче яртысында, Явыз Иван Казан ханлыгын басып алганнан соң, качаклардан формалаша.Чөнки Чиркәү рус булмаган бар халыкны чукындыру сәясәте алып бара, шуңа күрә безнең төбәккә качаклар күчеп килү көчәя.

Ирек сөюче Актаныш халкы патша Россиясе вакытындагы төрле баш күтәрүләрдә дә, узган гасырның 20нче елларындагы Гражданнар сугышында да актив катнаша...

Чынлап та, Актаныш районыннан бик күп күренекле шәхесләр чыккан. Мәсәлән, безнең Альберт Фәтхи, Мөхәммәтгали Арсланов, Леонид Арсланов, Габделхәй Әхәтов, Марс Вәлиев, Рамил Гәрәев, Рауис Госманов, Әлиф Зәйнәшев, Клара һәм Назыйф Зиннәтуллиннар, Наип Ләисов, Виктор Афанасьев, Камил Малов, Фәнис Нәбиев, Равил Хәертдинов, Фәрит Хатипов, Фарсель Зыятдинов һ.б. кебек танылган галимнәребез бар. Бөек Ватан сугышында катнашкан якташларыбыздан Баян Дәүләтов, Гатаулла Минаев, Хәсән Заманов, Гомәр Һадиммөхәммәтов, Илдар Мәннәпов, Гыймазетдин Вәҗетдинов — Советлар Союзы Герое исеменә, ә Польша партизаннары бригадасы командиры Александр Кузнецов — Польша Халык Республикасының Милли Герое исеменә лаек булганнар.

Сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклеләреннән Шәйгәрдән Шәймәрдәнов турында аерым әйтәсем килә. Ул 1924 елның декабреннән 1927 елгача Татарстан Үзәк башкарма комитеты рәисе, Халык Комиссарлары Советы рәисе вазифаларын башкарган. Безнең хәзерге Дәүләт Советы бинасында төрле елларда республиканың парламенты ролен үтәгән органнарны җитәкләгән шәхесләрнең рәсемнәре куелган, алар арасында безнең шушы атаклы якташыбызның да рәсеме бар.

Безнең як халкы иҗатка, сәнгатькә чын күңелдән гашыйк дип әйтер идем. Шуңа күрә танылган шагыйрь, язучыларыбыз шактый: Нур Баян, Риза Ишморат, Гамил Афзал, Рахмай Хисмәтуллин, Марат Әмирханов, Ләбиб Лерон... Санап карасаң, Актаныш төбәге татар әдәбиятына рәсми төстә танылган 40тан артык әдипне биргән.

Атаклы якташларыбыз — җырчылар: Салих Хөснияров, Әлфия Авзалова, Хәнәви Шәйдуллин, Асаф Вәлиев, Илгизәр Исламов, Газинур Фарукшин, Азат Тимершәех; композиторлар: Азат Хөсәенов, Рәис Нәгыймов, Инсаф Хәбибуллин, Илгиз Закиров, татарның беренче музыка профессоры Мансур Солтанов, музыкантлар: Иттакый Халитов, Фәнис Гыйльметдинов, Кирам Сатиев... Аларның барысын да санап чыгу мөмкин түгел, һәм без, Актаныш кешеләре, шуның белән бәхетле дә.

Иҗатның һәр өлкәсендә якташларың очрап тору — үзе бер горурлык бит ул. Мәсәлән, сынлы сәнгатьтә — Әсгать Сәфәргалин, Васил Маликов, Зилфәт Басыйров, Фаил Зиязов, цирк сәнгатендә — Замир Мостафин, театр сәхнәсендә — Мохтар Мутин, Нәсимә Җиһаншина, Роза Салихова, Ришат Гыйздәтуллин, Хафиз Хәммәтуллин һ.б. Безнең якташлар арасында халыкара дәрәҗәдәге спорт осталары — Лерон Сибгатуллин, Фирая Солтанова-Жданова, Фәрит Ганиев һәм башкаларны күрергә мөмкин. Атаклы шахматчыбыз, дөнья, Олимпия, ил чемпионы Алисә Галләмова исә даими рәвештә Актанышта үз исемендәге призга төбәкара ярышлар үткәрә...

Күрәсезме, Актаныш районы Сезнең кебек талантлы шәхесләрне биреп кенә тора! Менә әңгәмәбез алдыннан «Жылытасы килә дөньяны!..» дигән яңа китабыгыздагы шигырьләрегезне укыдым. Әсәрләрегез тирән фикерле, миңа бик нык ошады,

чынлап әйтәм. Мин бит шигырьләр яратам. Әле дәү әниегезгә багышланган шигырьләрегездән бер дүртьюллыкны язып та алдым: «Дәү әниемне уйлап...»дигән шигырьдән...

*Йомгагың тәгәри-тәгәри,*
*Сүтелә-сүтелә барды да...*
*Шул калын, шул ап-ак йомгактан*
*Бер чөмтем нечкә җеп калды да...*

Гаҗәп бит! Шулкадәр тирән мәгънәле, фәлсәфи юллар...

Җыеп кына әйткәндә, Актаныш кешеләре сәләтле, тыйнак, тырыш һәм эшчән, үз сүзендә нык тора, үз максатына ирешә торган халык. Мин үземнең туган ягым белән һәрвакыт горурланам.

**— Актаныш районы олы тарихка Татарстанның Беренче Президентын үстереп биргән як буларак керде. Һәрхәлдә, Сезнең биографиягез, димәк, Актаныш районының Әнәк авылында туган дигән мәгълүмат, бөтен дөньяга таралган. Туган ягыбыз Сезнең белән горурлана, Минтимер Шәрипович... Узган гасырның 90нчы еллары башында, СССР кебек зур дәүләт таркалган катлаулы чорда Сез Татарстан Республикасы Президенты вазифасын үз җилкәгезгә алдыгыз. Бу җитди тарихи адымны ясарга ничек тәвәккәлләдегез?**

— Бу — иң беренче чиратта язмыш эше. Татарстан Президенты дигән җаваплы вазифаны үз өстемә алырмын дип беркем дә алдан уйламый, әлбәттә. Дөресен генә әйткәндә, шулай килеп чыккан: шул чорда, шул вәзгыятьтә, шул урында мин туры килгәнмен.

90нчы елларга кадәр үк шактый җитди хезмәт юлы узган кеше идем инде. Институт тәмамлап, Мөслимгә, МТСка эшкә килеп, инженер булып мин берничә ай гына эшләдем, баш инженер итеп куйдылар. Шуннан китте: гел җитәкчелектә булдым. Аннан соң Минзәләдә районара «Сельхозтехника» берләшмәсе директорыннан мине КПССның Татарстан өлкә комитетына авыл хуҗалыгы бүлеге инструкторы итеп эшкә алдылар, бераздан бүлек мөдире урынбасары итеп күчерделәр. Ике ел эшләгәннән соң, 1969 елда, республиканың мелиорация һәм су хуҗалыгы министры итеп билгеләделәр. Яңа оештырылган министрлыкның эшчәнлеге нәтиҗәсендә республикада яңа тармак барлыкка килде, без хәтта ил күләмендә дан казануга ирештек, Казанда мелиорация буенча бөтенсоюз семинарлары уздырдык. Министр булып 1983 елга кадәр эшләдем. Аннары мине ТАССР Министрлар Советы рәисенең беренче урынбасары итеп куйдылар. Ул чагында Министрлар Советын Гомәр Исмәгыйлович Усманов җитәкли иде. Анда күп эшләмәдем, партия өлкә комитетына авыл хуҗалыгы буенча секретарь итеп алдылар. Соңыннан Министрлар Советына кире кайттым, бу юлы инде рәис булып. Ул вакытта Гомәр Исмәгыйлович партия өлкә комитетының беренче секретаре иде. Илдә үзгәртеп кору башлангач, ул Мәскәүгә, Үзәк комитетка китте һәм бездә, тарихта беренче мәртәбә, партия өлкә комитетының беренче секретарен альтернатив нигездә сайлау оештырылды. КПСС системасында мондый хәлнең гомергә булганы юк иде. Ике турда өч кандидат арасыннан минем кандидатура җиңеп чыкты. Бу урында да озак эшләмәдем, чөнки үзгәртеп кору инде бик куәтле юнәлеш алган иде. Ил күләмендә барган үзгәрешләрнең асылына төшенеп, мин барлык райком, горком секретарьларын киңәшкә җыйдым. «Ил буенча безгә «Бөтен власть Советларга!» дигән лозунг куелган, шуңа күрә мин Совет органнары системасына көчү зарур дип уйлыйм. Теләгән җитәкчеләргә күчү мөмкинлеге тудырылачак, уйлашыгыз, аннан үз фикерегезне әйтерсез. Партиянең киләчәге юк», — дидем. Мина, партия өлкә комитетының беренче секретарена, андый сүзләр әйтү бер дә җиңел түгел иде, әлбәттә. Әмма чынбарлык шундый иде. Берничә атна эчендә район-шәһәр партия җитәкчеләренең 70 проценты советларга күчте, алар урынына яңа секретарьлар сайланды. Шул рәвешчә без тәҗрибәле кадрларны, хуҗалык итә белә торган кешеләрне югалтмадык.

Шулай итеп, өлкә комитетының беренче секретаре булып бер ел эшләдем, 1990 елда мине Татарстан Югары Советы рәисе итеп сайладылар. Шуннан соң үзгәртеп кору эшләренә нык лап тотындык.

Боларны мин Сез әйткән тәвәккәллек темасына сөйлим. Яшь вакыттан ук җитәкче эштә булу кешене чыныктыра, ихтыяр көче, җаваплылык хисе тәрбияли һәм искиткеч зур тәҗрибә бирә. Әнә шундый тормыш мәктәбе узу алга таба миңа нык ярдәм итте. Гомумән, мин ил, республикалар, төбәкләр җитәкчелегендә башкарма хакимияттә уңышлы эшләгән кешеләр булырга тиеш дигән фикердә торам. Зур эшләргә тотынып өчен әнә шундый ныклы нигез кирәк.

Мәгълүм ки, СССРга кергән республикалар арасыннан Суверенитет турында декларацияне иң беренче Россия Федерациясе кабул итте. Чөнки аның СССР алдында хокуклары бик чикләнгән иде. Без дә, илебездәге милли республикалар, өлкәләр, крайлар арасында беренче булып Дәүләт суверенитеты турында декларация кабул иттек, чөнки автономияле республиканың СССР алдында да, РСФСР алдында да хокуклары юк чамасы иде. Күп тә үтмәде, Россия үзендә президентлык институты булдыру турында карар кабул итте, 1991 елның 12 июненә Россия Президентын сайлау көне билгеләнде. Шул чакта Татарстан Югары Советы, татар зыялылары, гомумән, халык үзебезнең Президентны булдыру мәсьәләсен күтәреп чыкты. Без дә Татарстан Президентын 1991 елның 12 июнендә сайларга булдык, чөнки җирле сайлауларны бөтенроссия сайлаулары белән бергә үткәрү тәртибе кергән иде. Сайлаучылар 12 июнь көнне ике бюллетень алды. Ельцинны — Россия Президенты, Шәймиевне Татарстан Президенты итеп сайлау турында. Татарстан халкына менә шундый мөмкинлек бирелде: кемне телисең — шуны сайла, теләсәң, икесен дә сайлый аласың. Безнең халык моннан үзенчә файдаланды: миңа 74 % кеше тавыш бирде, ә Россия Президентын сайлауда аз кеше катнашты һәм, закон буенча, Татарстанда Россия Президентын сайлау барып чыкмады. Президент булып менә шушындый вәзгыятьтә эшләп китәргә туры килде.

**— Моңа йөрәк тә, батырлык та кирәк бит әле?**

— Бик кызыклы сорау бу, тарихи китаплар укыганда, ул минем үземдә дә туа. Әмма шул мизгелдә, шул вакыйгаларның эчендә кайнаганда ул куркыныч кебек тоелмый: син бары тик көндәлек эшеңне башкарасың, җитәкче буларак, алдыңа килеп баскан мәсьәләне хәл итәсең кебек. Соңыннан искә төшергәндә генә, чыннан да, моңа йөрәк ничек җитте икән дип уйлап куйганым бар-барын... Президент булу — бик җаваплы, сүз дә юк. Бик катлаулы еллар кичердек. Әмма шуны әйтәсем килә: республикада Президент вазифасын булдыру — тормыш таләбе иде, шул вакытта язмыш кулы астына мин эләккәнмен, күрәсең. Президентлыкка адым менә шулай ясалды.

**— Татарстан Республикасы Президенты вазифасында егерме ел дәвам иткән эшчәнлегегезне үзегез ничек бәялисез? Эшләнеп бетмәгән эшләр, «их!..» дип куйган нәрсәләр юкмы?**

— Реаль күзлектән чыгып караганда, нигездә, юк дип саныйм. Буш вәгъдәләр бирмичә, зур күләмле күп кенә уңышлы программаларны гамәлгә ашырдык. Гадәтем шундый: булдырып чыга алырлык эшләргә тотынырга күнеккәнмен, чөнки чын тормышны белсән, үз-үзеңне, бигрәк тә кешеләрне алдый алмыйсың. Теләсә нинди сүзгә уңай җавап бирергә тырышучылар, тормышка ашмастай вәгъдәләр бирүче җитәкчеләр озак эшли алмый. Әйе, синнән гел яхшы сүз генә көтәләр. Әйтәсе дә килә бит аны! Телне дә тыю авыр кайчак. Бигрәк тә 90нчы еллар башындагы митингларда. Анда: «Азатлык! Азатлык!» — дип даулыйлар. «Шәймиев, син татармы?» «Дудаев ул — батыр! Ә син — камыр!» дигән лозунглар белән дә чыгалар иде. Ачу да килә. Алар әйтүен әйтә, ә алда нәрсә көтәсен белмиләр. Ул мәлдә гади чишелеш юк иде. Нәрсә генә әйтсәләр дә, ул чор өчен кулдан килгәннең барысын да эшләдек. Шуның нәтиҗәсе буларак, бүген республикабыз сәяси һәм икътисади яктан, башка төбәкләр белән чагыштырганда, нык сүзе һәм алга киткән икътисады белән аерылып тора.

Халык белән эшләү җиңел түгел, тик зарланырга да ярамый, чөнки син кайда

ПУБЛИКАСЫНЫҢ КИТАПХАНӘСЕ

эшләгәненне беләсең. Житәкче кеше хакимияткә үзе теләп килә, аны берәү дә мәжбүр итми. Шуңа күрә аңа беркем дә, берничек тә бурычлы түгел. Халык сина кылган гамәлләренә карап бәя бирә: вәгъдә биргәнсең икән — үтә, үти алмасаң, вәгъдә бирмә.

Президент вазифасыннан киткәч, мин шундый нәтижәгә килдем: республика житәкчесе булып егерме ел буе эшләвемнең иң зур казанышы — халкыбызның дәрәжәсен күтәрү, татар милләтенә тискәре карашны Рәсәй һәм дөнья күләмендә тамырдан үзгәртү булды.

Әлбәттә, моңа иң беренче адым — мөстәкыйльлек турында декларация кабул итеп, үз хокукларыбыз турында игълан итү булды. Ләкин ул вакытта без, күпләребез теләгәнчә, бәйсез дәүләт булып аерылып чыга алмый идек. Аның сәбәпләре бик житди. Безгә эшне, нигездә, радикаль формада алып барырга туры килде. Моның нечкәлекләренә артык тукталмыйча, минем шуны гына әйтәсем килә: 90нчы еллардагы тарихи вакыйгалар татарларның үзаңын үстерергә нык ярдәм итте. Ә бу бер дә жинел нәрсә түгел, моның өчен кешедә үз-үзенә ышаныч, үз-үзенә ихтирам тудырырга һәм халыкның тарихта тоткан урынын аңлар өчен шартлар булдырырга кирәк иде.

Сезнең буын, бәхеткә каршы, совет заманындагы кайбер хәлләрне белми, әлбәттә. Бар иде шундый заманнар, Казанда трамвайда, автобуста, урамда шәһәр кешеләре татарча сөйләшергә шикләнә иде, ул гына да түгел, кемнәрдер үзенең татар икәнен яшерә иде хәтта. Тик бу очракта беркемне дә гаепләп булмый. Вәзгыять шундый иде. Үзебезнең Казанда бердәнбер тулы булмаган татар мәктәбе калды. Мәктәп дәреслекләренә үк «татар-монгол изүе» дигән төшенчә кертеп, башка халыкларда кечкенәдән үк татарга карата нәфрәт тәрбияләнә иде. Үзгәртеп кору чорында сүз ирекке бирелгәч, без үз сүзебезне ныклап торып әйтә алдык. Әлбәттә, соңгы егерме ел эчендә без үзебезнең бай тарихлы, мәдәниятле, тырыш, ипле, тынычлык сөючән, башка халыкларга һәм диннәргә тигез карашлы халык булуыбызны сүз белән генә түгел, эшебез, олы казанышларыбыз белән дә исбат иттек. Татар булуыбыз белән горурлана башладык.



*Болгарда. 2011 ел, 1 июль.*

Соңгы елларда без милли асылыбызны жаныбыз белән тойдык, акылыбыз белән аңладык. Мөстәкыйль халык икәнебезне үзаныбызга салдык. Бу процесс Татарстанда гына түгел, ә бөтен Россиядә, БДБ илләрендә дә барды. Милли үзаң — ул кулга тотып карый торган әйбер түгел, ләкин шул ук вакытта без башкарган эшнең әһәмияте гажәеп зур һәм ул бик кирәк иде. Моның нәтижәләре хәзерге вакытта төрле яклап күренә. Мәсәлән, Россия хөкүмәтендә безнең милләт вәкилләре эшли. Мәдәният, сәнгать, мәгълүмат, спорт даирәләрендә бөтен дөньяга танылган милләттәшләребез күбәйде. Кызык бит, Казанга килгән мәшһүр кунаклар үз нәселләрендә татар табылса, моны бик сөенеп сөйлиләр. Шундый бер очракны мисал итеп китерәм: күптән түгел Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында Дмитрий Хворостовский чыгыш ясады, безнең журналистлар белән әңгәмәсендә ул әнисе ягыннан бабасының яртылаш Себер татары икәнлеген, аның Бөек Ватан сугышында һәлак булып калуы, аның белән горурлануы турында тәфсилләп сөйләде.

Болар барысы да татар милләтенә карата мөнәсәбәтнең тамырдан үзгәрүе турында сөйли. Безнең белән санлашмыйча мөмкин түгел хәзер. Мин боларны шушы заманда

үзем эшләгән өчен генә әйтмим, татарны дөнья күләмендә таныйлар. Моңа шатланам гына. Димәк, вакытны юкка уздырмаганбыз.

**— Мин Сезнең белән тулысынча килешәм. Без — Сез Президент булган чорда үскән, үз ана телебездә белем һәм тәрбия алган бәхетле буын...**

— Без дә татар мәктәбендә укыдык. Ләкин югары уку йортларына керү имтиханнарын рус телендә бирергә кирәк иде. Гел «бишле»гә укыган булсам да, институтка керәсе фәннәрне җәй буе русча өйрәнеп утырдым. Ничек итеп сөйләргә, ничек итеп аңлатырга дип баш ваттым.

1954 елда Казан авыл хуҗалыгы институтына керү имтиханнарын тапшырырга баргач, комиссиядә татар укытучылары да бар иде, әмма күбесе безнең халгә кермәделәр, мин үземнең ин яраткан фәнем — математикадан «дүртле» алдым. Рус телендә аңлатып бирә алмаганмындыр инде... Шуңа күрә хәзерге вакытта, ничек кенә зарлансак та, бүгенге кебек иреклнең монарчы булганы юк иде әле. Заманында республикада житештерелә торган эремчекнең майлылыгын да Мәскәү билгели иде. Бөтенесе үзәк күзәтчелегендә эшләнде.

**— Сезнең тормыш кагыйдәләренең берсе — тотрыклылык. Сез шуның өчен көрәштегез һәм уңышка ирештегез. Шул ук вакытта тормышта яңалык та кирәк. Сез Россия Федерациясендә яңалык кертү өчен дә шактый көч куйдыгыз. Тотрыклылык һәм яңалык — монда каршылык юкмы соң?**

— Минемчә, элек каршылыклар чагыштыргысыз күп иде. Бу — вәзгыятькә бәйле нәрсә. Мәсәлән, хәзерге чорда яңалык кертер өчен тотрыклылык, тәртип кирәк, ә яңалыкның эчтәлеге үзгәреп тора. Җәмгыять үзгәртеп корыла, социализмнан социаль-демократик дәүләт төзү юлына бастык. Болар — житди тарихи үзгәрешләр һәм, нигездә, уңай күренешләр. 90 нчы елларда республикадагы үзгәртеп корулар эволюцион юл белән узды. Күпләп кан кою булмады, әмма булырга мөмкин иде. Һәр халыкның, һәр дәүләтнең тарихында революцияләр ясала, ләкин аның нәтиҗәләрен ничек саклап калырга, тормышны ирешкән хокукларга тәңгәл итеп ничек көйләргә? Төп мәсьәлә шушы. Бу — барлык дәүләтләр һәм инкыйлаблар дилеммасы.

Россиядәге, Татарстандагы бүгенге процесслар — моның мисалы. Соңгы берничә елда икътисади реформалар белән күбрәк мавыгып, ил күләмендә сәяси реформалар сүлпәнләнгән булып чыкты. Ә алар бик кирәк бүген, чөнки яңа җәмгыять төзибез. Шуңа күрә халык сәяси үзгәрешләр таләп итеп митингларга чыкты. Ә 90нчы елларда, Горбачев, Ельцин вакытында, киресенчә — сәяси үзгәрешләр вакыт-вакыт чамадан тыш алга киткәләде. Халык икътисади реформалар даулый башлады. Совет чорында гел сугыш кораллары житештерүгә генә корылган икътисадны үзгәртү җиңел түгел иде. Үзгәрешләрнең икенче көнендә үк ничек башка товар чыгара башларга мөмкин? Әйткәнемчә, мондый хәлләр теләсә кайсы дәүләттә була ала.

Бүгенге көндә җәмгыятьнең сулышын тою мөһим, чөнки Россия халкының үзаңы көчәя. Бөтен дөньяны берләштерә торган массакүләм мәгълүмат чаралары бар, күпчелек йортларда компьютер куелган, интернет эшли. Безнең халык — йөз процент белемле халык ул, барысын да белә, аңлый, тыңлый, уйлый, нәтиҗә ясый. Шуңа күрә хакимияткә җәмгыятьнең халәтен тоеп, таләпләрен белеп, аларны исәпкә алып яшәргә һәм эшләргә кирәк. Әйтик, 2012 елгы Путин 2000 елдагы Путиннан нык аерыла, чөнки аның да үзгәрмичә хәле юк. Владимир Владимирович хәзер күп нәрсәләргә колак салачак. Ә гамәлгә яраклы таләпләрне тормышка ашырып, яңалыклар кертү өчен тотрыклылык булу шарт.

**— Сез сәнгатьне, әдәбиятны, бигрәк тә шигъриятне яратасыз... Нинди генә очрашуларда, мәдәни чараларда булмасын, халык белән турыдан-туры җанлы итеп аралаша беләсез, гамьле уйларга этәрәсез... Бу кешеләрне, үз ватаныңны, халкыңны яратудан киләме?**

— Минемчә, тәрбиядән, үз халкыңа һәм туган җиреңә бирелүдән килә. Язмыш шулай язган булган, күрәсең, яшь вакыттан ук зур эшләргә кереп киттем. Дөресен әйтим, Мәскәүгә эшкә күчәргә дә күп кенә тәкъдимнәр булды, ләкин бу хакта уйлап та караганым булмады. Ул тәкъдимнәрне һәрвакыт кире кага идем, чөнки минем

үз республикамда, үз мохитебездә яшисем һәм эшлисем килде. Яшь чакта, ике улым тугач, хыялым да шундый иде: ике йөзләп гектар җир алып, улларым белән шул җирдә хезмәт куеп яшәү. Каядыр башка якларга китеп урнашуны башыма да китермәдем. Бу яктан мин үземне бәхетле дип саныйм. Президентлыктан киткәч тә, үз Ватанымда лаеклы эш таптым — тарихи ядкәрләребезне торгызу белән шөгыльләнәм.

**— Әдәбият һәм сәнгать — күпләп табыш китерә торган өлкә түгел. Бу юнәлештә хезмәт куючы кешеләр — чын талантлар, фидакарь җаннар. Алар гасырларга калырлык, татарның милләт буларак үз йөзен ассызыклый торган бәһасез иҗат җимешләре тудыра, тудырырга тиеш тә. Димәк, әлеге өлкә кешеләре дәүләт ярдәменә мохтаҗ. Шул ук вакытта дәүләт контроле дә кирәк. Теләсә кем шагыйрь, җырчы, йә булмаса, композитор, рәссам була алмый бит. Моңа кадәр ярдәм һәм контроль мәсьәләсе ни дәрәҗәдә хәл ителде һәм бүгенге көндә ничек хәл ителә ала?**

— Безнең республикада әдәбият-сәнгать әһелләренә дәүләт тарафыннан ярдәм һәрвакыт күрсәтелеп килә. Аерым иҗтимагый оешмалар — Язучылар берлеге, Композиторлар берлеге, Рәссамнар берлеге, театрлар, иҗади коллективлар белән беррәттән, күренекле шәхесләребезгә генә түгел, яшь иҗатчыларыбызга да игътибар бирелә. Татарстан Президенты каршындагы Мәдәният үсешенә ярдәм итү фонды — бу юнәлештә эшли торган оешмаларның берсе. Ярдәмнең төрле формалары бар бит. Мәсәлән, республикада иң югары Дәүләт бүләге — Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясеннән тыш берничә дәрәҗәле премия бар. Дәүләт һәм төрле компанияләр, оешмалар тарафыннан бирелеп килә торган грантлар да иҗат кешеләренә алга таба үсеш өчен көч бирәләр дип саныйм.

Ә дәүләт контроле мәсьәләсенә килгәндә мин болай уйлыйм. Милли традицияләргә, рухи-әхлакый нормаларга яки юридик законнарга каршы килмәгән очракта, һәр иҗат — мактауга лаек гамәл ул. Әгәр кешеләр әдәбият, җыр-музыка яисә рәсем сәнгате дөньясына тартыла, нииндидер уңышларга ирешергә омтыла икән, шатланырга кирәк: һәрхәлдә, бу бит кирәкле шөгыль. Дөрес, теләсә кем шагыйрь яки җырчы була алмый. Ләкин һәр кешенең үз сәләтләрен сынап карау мөмкинлеге булырга тиеш. Дәүләтнең бурычы — күзәтчелек итү түгел, иҗат өчен тиешле шартлар тудырудан гыйбарәт дип уйлыйм. Кем шагыйрь яки җырчы, ә кем мондый дәрәҗәгә күтәрелә алмый — монысын тамашачы, укучы, ягъни халык үзе әйтә, үзе бәя бирә.

Бервакыт, илдә үзгәртеп кору башланган елларда, Бөгелмәгә баргач, миңа берничә рәссам белән очрашырга туры килде. Алар миңа шундый сорау бирделәр: «Социализм чорында безгә һәрвакыт төрле лозунглар язарга туры килә иде. Ул төп эшебезгә әйләнде. СССР таркалгач, заказлар юк. Безгә ничек яшәргә инде?..» Чыннан да, тормышта иҗат кешеләренең мондый проблемалары бар. Әлбәттә, зур таланты һәм төпле белеме булган рәссам ничек тә үз юлын таба ала. Әгәр дә лозунг язудан башкага талантың булмаса? Әчтән генә шуларны уйлап, мин аларга төгәл җавап бирә алмадым. Шәһәр хакимиятенә мөмкинлекләрегезгә карап ярдәм итегез, хәзер үткәрелә торган чараларга катнаштырыгыз дип киңәш иттем.

Аллага шөкер, татар театрлары яши, халык спектакльләргә йөри. Язучыларга исә әсәрләрен укучылар кирәк... Үзебезнең милләтне, телебезне саклап калу өчен, иҗат кешеләренә хөкүмәт тарафыннан ярдәм булдырырга кирәк дип саныйм. Моны шул ук грантлар аша да эшләргә була. Хәзер, әйткәнемчә, күп кенә күренекле иҗат берлекләренә — оркестрларга, театрларга һ.б. грантлар бирелә. Ул язучыларга да шул рәвештә булырга тиеш, минемчә. Яхшылабрак уйлап, үзебезнең милли иҗат әһелләренә ярдәм кулы сузу кирәк. Әлеге мәсьәләне республикабыз Президенты да, калганнарыбыз да аңлый. Бүгенге глобальләшү чорында, гореф-гадәтләребезне, телебезне саклап калу максатыннан чыгып, безнең татарча иҗат итә торган зыялыларыбыз булуы бик мөһим. Гонорар, премия күләмнәрен арттыру да күтәрелмәгән мәсьәләләр түгел. Моның уйланылган бер рәвешен генә табарга кирәк.

**— Җитмеш биш яшьлек Минтимер ага белән узган гасырның 90нчы елларындагы Минтимер Шәймиев арасында аерма бармы?**

— Бардыр, әлбәттә. Адәм баласы һәрдаим үсештә, үзгәрештә бит ул. Сәламәтлек ягыннан әйтсәк, зарланырлык түгел, яшемә карата яхшы, Аллага шөкер. Мин бик күп хәрәкәт итәм, җәяү дә, чаңгыда да йөрим, көн саен йөзәм. Хәрәкәттә — бәрәкәт, диләр бит. Яши-яши кайбер нәрсәләргә башкача карыйсың, кайбер фикерләр үзгәрә, яңа уйлар өстәлә... Ләкин иң мөһим максатым үзгәрешсез: һаман да халкыбызга, туган җиребезгә хезмәт итәсе килә. Өйдә кул кушырып утыра алмыйм. Сәкинә апагыз бераз ачулана инде, ул бит гомер буе минем эштән китүемне көтте, мине гел үзе янында булыр дип өметләнде. Аны да аңларга тырышам. Сүз дә юк, үземнең дә аның янында утырасым килә. Ләкин мин «эш җене кагылган» кеше булып чыктым, ахрысы. Үзегез күреп торасыз, өстәлемдә китаплар өелеп тора. Минем кабинетта беркайчан да моның кадәр китап булганы юк иде. Бик күп тарихи басмалар укыйм, архитектура, археология мәсьәләләрен карыйм. «Яңарыш» фондының эшен алып бару өчен гаять күп белем һәм мәгълүмат кирәк. Без бит тарихи ядкәрләребезне дөньякүләм таләпләргә, ЮНЕСКО кагыйдәләренә туры китереп торгызабыз. Бу — проектның төп үзенчәлеге. Шуңа күрә һәр адымыңны үлчәп, белеп, дөрес итеп атларга кирәк.



*Якташлар. Минтимер Шәймиев һәм Ленар Шәех. 2012 ел, 19 март.*

**— Татар халкының киләчәген ничек күзаллыйсыз? Безгә, киләчәк буынга, нинди әйтер сүзләрегез, бирер киңәшләрегез бар?**

— Үз милләтебезне сакларга һәм үстерергә, туган җирне яратырга. Бу — милләткә хезмәт итү дип атала. Бервакытта да шуны онытмаска кирәк: үзебезгә кирәген үзебез эшләргә тиеш, аны башкалар эшләмәячәк. Милләтебезне, телебезне саклау, аны үстерү, халкыбызның үзаңын киләчәктә дә югарыга үрләтү — ул без башкарырга тиешле гамәлләр. Ә без булдырабыз! Үзебезнең язмышны үз кулыбызга алып, соңгы елларда ирешкән уңышларыбыз моны дәлилләп тора.

**— Эчтәлекле әңгәмәгез өчен зур рәхмәт, Минтимер Шәрипович! Алла ярдәм биреп, сәламәт булып, тагын озак еллар республикабызның бүгенгесе һәм киләчәге өчен эшләргә язсын!**

— Рәхмәт.



Нур
Әхмәдиев

# ШАГЫЙРЬ КҮҢЕЛЕ — ШАУЛЫ КАРА УРМАН

## Тик, аңынчы...

*Кеше җиргә яшәр өчен туа...*

**Кеше җиргә үләр өчен килә,**
**Тик, аңынчы,**
**әнкәң күкрәгеннән**
**Кабатланмас шифа аласы бар;**
**Гаҗәпсенгән назлы караш белән**
**Күзләренә күпме багасы бар.**

**Кеше җиргә үләр өчен килә,**
**Тик, аңынчы,**
**башта аягына**
**Егылмаслык булып басасы бар;**
**Җырлар аша, әкиятләр аша**
**Үз-үзенә дөнья ачасы бар.**

**Кеше җиргә үләр өчен килә,**
**Тик, аңынчы,**
**дөньяларын онтып,**
**Көтмәгәндә гашыйк буласы бар;**
**Мәхәббәттән акылыннан шашып,**
**Хыянәттән Бүре булып уласы бар.**

**Кеше җиргә үләр өчен килә,**
**Тик, аңынчы,**
**дәвам калсын өчен**
**Үстерергә кирәк бала-чага.**

Нур ӘХМӘДИЕВ (1946) — *шагыйрь, прозаик; «Аһәң», «Амбирак», «Абага чәчәге» һ.б. китаплар, шул исәптән дүрт томлык «Сайланма әсәрләр» авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Әлмәттә яши.*

Бала — бала инде:
көн тудисә,
Мең мәшәкать синнән алда чаба.

Кеше җиргә үләр өчен килә,
Тик, аңынчы,
газиз оныкларның
Чыр-чуларын ишетәсе бар.
Озын юлда дуслар сирәкләнә,
Җиде ятны дус-иш итәсе бар.

Кеше җиргә үләр өчен килә,
Тик, аңынчы,
җирдә яшәгәндә
Күпме иләнәсе, илисе бар;
Шатлыклар да җиңел бирелмиләр:
Күз яшьләре белән түлисе бар.

Кеше җиргә үләр өчен килә,
Тик, аңынчы,
тормыш мәйданында
Үз-үзеңне ныклап табу кирәк.
Зилзиләләр кичерсә дә жаның,
Кеше булып җирдә калу кирәк.

***

Безнең сөю булмаган да кебек,
Көтмәгәндә кырау алдымы,
Яндырдымы ялкын, шул янунын
Бер чеметем көле калдымы?

Яндырырга бер карашың җитте,
Хәзер алар хәтта җылытмый.
Хәтер генә, хәтер генә һаман
Шашкын сөюләрне онытмый.

Киләчәкне кемнәр алдан белгән,
Бигрәк тә сөю язмышын.
Офыкларда гына күрәм хәзер
Сүрән мәхәббәтнең балкышын.

## Шагыйрь язмышы

Шагыйрь күңеле — шаулы кара урман,
Теләсә кем керә алмастыр.
Шагыйрьләрдә пәйгамбәрлек белән
Шайтанлык та булмый калмастыр.

Шагыйрь заты сабый балага да,
Хозыр Ильяска да охшаган.
Мин дөньяны асыл Шигърият
Яулап алырына ышанам.

Әй Илаһым, кодрәт, илһам бирче
Шагыйрь дигән атны акларлык.
Бир маһирлык, язганыңны халкың
Дога урынына ятларлык!

## Чатыр тавы

Болытларга башың тиядерме,
Синдәй таулар ләкин сирәктер.
Син — мәһабәт!
Моны аңлау өчен
Итәгеңдә туу кирәктер.

Таңда кояш әувәл сиңа төшә,
Якты нурлар бии түбәңдә.
Кылганнарга алтын өләшә дә
Ял итә ул, төшеп үзәнгә.

Тыңлап туярлыкмы иртәләрдә
Суырларның симфониясен.
Күңелләр киң безнең, алып барам,
Кемнәр тели — миңа иярсен!

Исле үләннәрнең исләреннән
Бераз гына башлар әйләнер.
Әй Чатырым, сиңа һәр кайтуым
Мәңге кабатланмас бәйрәмдер.

Үзенекен итми калмас еллар,
Нык торсак та әле иярдә.
Кайчандыр бер кайтасылар булыр
Соңгы тапкыр башны ияргә;
Балаң булып, бер шагыйрең булып:
— Хуш, бәхил бул, тавым! — дияргә...

***

Ашкынам мин бик еш болыннарга
Һәм йөгерәм чыгып кырларга.
Ни хозурлык!
Сүзләр таба алмыйм
Күңелдәге хисне җырларга.

Чәчәкләрнең таҗын үбеп йөрим,
Күбәләкләр куна иңемә.
Дөньядагы һәрбер җан иясе
Тартыла тик үзенең тиңенә.

Гөмбәләре сала эшләпәсен,
Җырлыйм, каеннарга сөялеп.
Анам карынында яралгандыр
Кырлар белән рухи бергәлек.

Бәхет өчен тагын ниләр җитми,
Күңеле җыр тулы балага?
Табигатьтән илһам алам да мин,
Ашкынып лар кайтам калага.

Каләмдәшләр көтеп тора анда
Һәм бәхәсләр — шигырь хакында.
Йөрәктә бит әле ут сүнмәгән,
Йөрәк дөрли, йөрәк ялкында.

**Шул ялкынны, мәңге сүрелдермә,**
**Шәфкатеңнән, Раббым, ташлама.**
**Иң зур бәхет Туган Җирнең сине**
**Якын итүеннән башлана.**

## Мәхәббәт шигыре

*Көнләшә, димәк, ярата.*
(Халык әйтеме)

**Син көнлисең.**
**Көнләсәң көнлә син мине:**
**шәфәкътагы кояш нурыннан,**
**нәҗәгайлар камчылаган иген кырыннан,**
**мәңге гашыйк былбыл җырыннан.**

**Көнләсәң көнлә син мине:**
**могҗизалы ап-ак кышлардан,**
**иңнәрендә баласын йөздергән аккошлардан,**
**нәни кояшка әверелгән көнбагышлардан.**

**Көнләсәң көнлә син мине:**
**сөю-наз өләшкән мәҗүси төннәрдән,**
**елмаеп, һушыңны алучы гөлләрдән,**
**тылсымлы көзгеле күлләрдән —**

**Мин аларга гашыйк, —**
**яшермим.**
**Ләкин син шуны бел:**
**Син — кайчысы**
**җанымның**
**җиденче тамырын парә-парә телгәләгән**
**Яшеннең.**

## Хәлләремне сорамагыз

**Тормыш сыный безне аямыйча,**
**Ашатмый ул гел-гел йөзем генә.**
**Йөзем кабып, әрем суы эчәм,**
**Хәлләремне беләм үзем генә.**

**Сикәлтәле тормыш юлларында**
**Адаштырмый, шөкер, күзем генә.**
**Тешем кысып, яңа үрләр яулыйм,**
**Хәлләремне беләм үзем генә.**

**Буыннарның ыңгырашкан чагы,**
**Аек калды фикер, сүзем генә.**
**Каләм тоткан кулым яза алмый,**
**Хәлләремне беләм үзем генә.**

**Салкын кышта шулай,**
**Яз, җәй шулай,**
**Җиңеләер микән көзен генә...**
**Җәрәхәтле Өмет яшен сөртә,**
**Хәлләремне беләм үзем генә.**

**Язмышыма язылганны шулай
Уздырырга кала түзем генә.
— Хәлең ничек? — диеп сорамагыз,
Хәлләремне беләм үзем генә...**

## Күптән әзер

**Җаным бүген әле җирдә минем
Килер бер көн: ашар күкләргә.
Көлеп яши идем,
Минем үлем
Гаҗәп тоелачак күпләргә.**

**Көлә-көлә, әйе, яшәдем мин,
Сәбәпсез дә авыз ерылды.
Минем гомер үч алуга түгел,
Гафу итүләргә корылды.**

**Гафу иттем кырын караганны,
Кайчагында хәтта дошманны.
Бу кылану түгел, курку түгел,
Үтәдем тик җаным кушканны.**

**Көлгәнне дә ала,
Бөлгәнне дә,
Җитсен көне, керсен сәгате.
Ришвәт бирер идең, алмаячак,
Юк Әҗәлнең андый гадәте.**

**Кем дә килми җиргә мәңгелеккә,
Белеп яши беркөн үләсен.
Мин дә әзер күптән,
Ләкин Әҗәл
Вакытыннан алда килмәсен.**

**Җаным әле бүген җирдә минем,
Килер бер көн — күккә ашармын.
Болыт аша сезгә елмаермын,
Сезне сагындым, дип дәшәрмен...**



Мидхәт Миншин

# КЫЗЫЛ ДИПЛОМ

БӘЯН

*Безнең гомер уен түгел, бәйрәм түгел...*
Г. Тукай.

Кимсенү — иң авыр газаптыр. Егерме ике яшенә җитеп, Нургаязның бер тапкыр да андый халәтне кичергәне юк иде. Мәктәптә беренче укучы булды, институтта мактаулы студент. Буй-сын килгән. Аңамы соң бу дөньяда кимсенеп яшәргә!.. Диплом алып, житмәсә әле кызыл диплом алып тормышка аяк атлыйм дигәндә маңгае белән таш кыяга бәрелгән кебек булды. Ничек йөрәге шартламагандыр?! Дәүләт имтиханнарын тапшырганчы ук эш мәсьәләсен хәл итәргә тырышып карады. Тик беркайда да көтеп тормыйлар шул...

Дөньяда үз-үзенә урын таба алмаганда, яну-көюләренне басардай бер әмәл дә булмаганда як-ягына карану да кешене бәладән коткара икән.

Жиде яшеннән үзе белән беренче класста укый башлаган дусларын берәм-берәм күз алдыннан уткәрде, алар белән ниләр генә булып бетмәгән. Хәтта япь-яшь килеш якты дөньядан китеп баручылар да бар, кайсыдыр төрмәдә утыра, кемдер сукбайлыкка чыккан. Алар белән рәттән куеп карасаң, Нургаяз буй җитмәслек биеклектә кебек. Үз-үзенне тынычландыру, үз-үзеңне кулга алу өчен як-ягына да, түбәнгә карау да кирәктер шул. Ә үзеңне табасың, хыялларың артыннан барасың килсә, югарыга караш ташла. Әле бит дөнья җимерелмәгән, аяк-кулларың үз урынында, күзең күрә, колагың ишетә — нишләп шулкадәр сыгылып төшәргә ди. Булсын, институтны кызыл диплом белән бетергән егет әлегә үзе теләгән эшкә урнаша да алмасын, әмма югары белем гомергә кала. Дипломы булмаса, урам чатында юл хәрәкәтен көйләп торучы якташы Инсаф та бөтенләй икенче төрле сөйләшер иде әле, ә ул ерактан ук сәлам биреп үз янына чакырып алды.

— Халык театрында эш юк дип аптырап йөрмә, — диде ул. — Халык театры режиссеры кемгә кирәк бүген?! Әле чын театрларның да хәле бик мөшкел диләр. Әйдә, үзебезнең янга алам сине...

Мидхәт МИНШИН (1936) — *шагыйрь, публицист; «Васыять», «Башаклар җырлый», «Каргыш» исемле китаплар авторы. Озак еллар «Татарстан» радиокомитетында эшләде. Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре. 2009 елда вафат.*

— Эшкәме?! — дип гаҗәпләнде Нургаяз. — Син шуны да булдырасыңмы?!

— Булдыра алмасам, әйтеп тә тормыйм мин, — диде Инсаф, уч төбе кадәр тимер таккан күкрәген алга киереп. — Сержант кына булсам да, сүз үтә минем. Кызыл диплом белән институт тәмамлаган дустымны да урнаштыра алмагач, кем булам инде мин?!

— Син чынлап сөйлисеңме соң?

— Чынлап булмыйча! Сезнең Мәдәният һәм сәнгать институтын тәмамлаучылар бездә шактый. Үзең дә беләсеңдер инде... Үз театрларын гына түгел, тәмәке киоскларын да ачкан «ас»лар бармак белән генә санарлык. Бер дә кайгырма, Нургаяз, үзеңнән бер дигән юхидист чыгар. Урамнарда, зур юлларда да режиссер булу кирәк. Иртәгә минем ял көне, сине үзебезнең нәчәлник янына алып барырмын, «беренче класстан бергә укыдык, ул безнең горурлыгыбыз», диярмен. Кызыл диплом алган кеше юләр булмый инде ул. Карап торышка да ничава күренәсең. Сөйләштек, иртәгә үзеңне алып барам. Киңәшем шул гына: нәчәлник белән сөйләшкәндә сәясәткә кереп китә күрмә. Ул чокырга төшсәң, исән чыгулары бик авыр.

— Син барысын да хәл итеп бетерДЕҢ, — диде Нургаяз, шаяру-чыны катыш. — Мин тагын төннәр йокламыйча кайгырып яткан булам, ә син кистең дә салдың.

— Безгә җебеп төшәргә ярамый, Нургаяз! Җебеп төшәргә ярамый! Юл хәрәкәтен көйләү уен эш түгел. Анда урнашуыңа үзең дә үкенмәссең. Син бит югары белемле, үсәргә перспективаң бар...

Әле кичә генә башка да кермәгән уйлар Нургаязны бөтереп алды. Аның язмышын профессорлар да, район үзәгендә халык театры ачарга вәгъдә биреп институтка кодалаган хакимият башлыгы да, әти-әнисе, туганнары да түгел, мәктәптә укыганда барлык контроль эшләрне Нургаяздан күчереп язган Инсаф хәл итмәкче. Кызыл диплом белән институт тәмамлаган өметле белгеч — «хәзерге буынның каймагы» — аның ярдәменә мохтаҗ булып чыкты. Инсаф, бәлки, Нургаязның «яхшылыкларын» — күчереп язарга бирүләрен онытмыйдыр, «яхшылыкка яхшылык» белән җавап кайтарырга телидер. Моның ни гаебе бар. Яхшылыкны онытмаган кешеләр белән уртак сүз табып була ул, аларга ышанырга мөмкин.

— Барып караганнан зыян булмас, — диде Нургаяз. — Ятып калганчы атып кал, диләр ич. Сайланып торыр чак түгел. Алда күз күрер, кирәге чыкса, тагын укырмын, бер диплом булгач, җиңел бара ул. Өчәр-дүртәр вуз бетерүчеләр дә бар.

— Шулай, шулай, — дип куәтләде Инсаф. — Бер эшләгән баш эшли инде ул. Беренче класстан гел «5»легә укыдың, синең «төтенең яхшы йөри», ЮХИДИда да югалып калмассың. Алайса, килештек. Көндезге сәгать 2 дә Чәчәкле мәйданында очрашырбыз.

— Рәхмәт! Рәхмәт, Инсаф!

Беркайчан да телгә кермәгән сүзләр үзеннән-үзе әйтелде. Уйламаганда очраган Инсаф сабакташының хәленә кереп, булышырга әзер булуын шундук әйтеп салды. Гүяки Нургаязга кирәге чыгуын үзе дә көтеп кенә торган. Тормыш аны да шактый ук шомарткан, хәзер сөйләшә дә, эш йөртә дә белә. Аңа ялынычы төшүчеләр дә хәттин ашкан. Тегесен дә, бусын да җайлый. Нишләп әле ул Нургаязны читкә этәрсен ди...

Инсаф урам чатында «кодрәтле таягын» уйнаткалап калды, Нургаяз шәһәр үзәгенә таба атлады. Барган көйгә аның башы түбән иелеп китте. Бу хәл тагын кабатланды. «Менә шулай егылып үләләрдер дә, — дип Нургаяз шомланып куйды. Әйтәләр бит, кемдер фәлән җирдә ауган, кемдер төгән җирдә сыгылып төшкән. Араларында бик танылган кешеләр дә очрый.

Адәм баласы үзе дә сизмичә дөньядан китеп бара. Үлем беркемнең яшенә дә, дәрәҗәсенә дә карамый...

Нургаяз Кипкән Күл бакчасына кереп бераз хәл алырга булды. Ышык урындагы эскәмиягә утырып та өлгермәде — тагын башы иелеп китте. Маңгаеннан салкын тир бәреп чыкты. Кесәсеннән кульяулык алып йөзен сөртте. Борчылулар, йокысыз төннәр артта калды, инде барысы да көйләнә дип иркенләп бер сулыш алырга җыенганда йөрәктәге көчәнеш тышка бәрде. Моңа гаҗәпләнергә дә кирәкмидер. Аның бөтен уй-хыяллары чәлпәрәмә килде бит. Кызыл диплом алырлык итеп укы-укы да урам чатында басып торучы бер сержант ярдәменә мохтаҗ булып кал инде... Беркая укырга керә алмаганнан гына ул ГАИга урнашты, шунда баш-күз алды, инде үзен шәһәр башлыгы сыман сизәме — ничек сөйләшә, аның канаты астына керүнең гарьлеген Нургаяз үзе генә белә. Кермәс иде дә — башка чарасы юк. Вакыт-вакыт телеграмм баганасына да сәлам бирәсең...

Нургаяз үзенә дүрт яшь тулганнан бирле ниләр булганын бик яхшы хәтерли, һәр елда берничә онытылмас вакыйга бар. Бүген ана Инсафның «эш тәкъдим итүе» дә шундыйлар рәтенә керер. Тәненнән җаны чыкканчы онытмас ул бу көнне...

Халык театры режиссерына укуы да тикмәгә түгел. Ул туып-үскән Ташлыяр каласында заманында колхоз-совхоз театры булган. Анда кемнәр генә уйнамаган. Аларны авылларда һәрчак көтеп торганнар. Нефтьчеләр башкаласы «чәчәк ата» башлагач, Ташлыяр театрын шунда күчерергә кирәк табалар. Янәсе, бер атуда берничә куянны әләктерәләр: СССРга танылып килүче нефтьчеләр төбәгенең үз театры ачыла, артистларга чын шәһәр шартларында — газлы, сулы фатирларда яшәргә мөмкинлекләр туа. Яңа калада иҗат көчләрен үстерүгә дә бик зур игътибар биреләсе икән, Язучылар союзының бүлеген дә ачачаклар, Ташлыярдан күчкән «колхоз-совхоз» театрының хәтта үз бинасы да булачак..

Ташлыярдан театр китә, әмма рухы кала. «Театр жененнән котыла алмаучылар» каян гына үсеп чыгадыр, хәтта Мәскәүдә укып кайталар да ин мәртәбәле театрларның да түренә менәләр. Халык бизә башлаган залларны шыгрым тутыралар. Ташлыярдан чыккан артистлар үзләре генә дә теләсә нинди спектакльне куярлык диләр.

Ничек инде Ташлыярның үзендә театрсыз яшәсеннәр. Башта халык театры ачып карарга, аннары дәүләт оешмалары алдында мәсьәләне кабыргасы белән куярга иде исәпләре. Талип Дәүләтовнең властька килүенә бу хыяллар да «иш янына куш» булды. Рухи азыкны онытып бетермәгән җитәкчегә өмет багладылар. Нургаязның мәдәният һәм сәнгать институтына укырга керүе дә нәкъ шушы «матур киләчәк» белән бәйле иде. Әмма могҗиза булмый калды. Кәнәфиенә утырып та өлгермәде, Талип Дәүләтов 180 градуска борылды, тегүчеләр клубын халык театрына көйлисе акчага хакимият йортын «европоча ремонтлатып» куйдырды, үзенең эш бүлмәсен футбол кыры кадәр итеп киңәйтте, ял бүлмәләрен җиһазлатты, коену кабинасына да нилләр генә куйдырмады. Боларны ул бик җиңел аңлатты: районның да, шәһәрнең дә читләр белән элемтәләре киңәя, килгән кунакларны адәмчә каршы алырлык шартлар да тудырылырга тиеш бит инде. Шундый «зур эшләргә» кечерәге дә килеп кушылды — башлыкка хан сараедай йорт та әтмәлләп бирделәр. Театр ачу турындагы хыяллар җилгә очкандай булды, авылларда мәктәпләрне, китапханәләрне кыскартуга йөз тотканда кем инде театр турында кайгыртсын ди! Институтта укып йөргән Нургаязның канатлары киселде. Инде менә сабакташы ЮХИДИга эшкә чакыра.

Хыялларының чәлпәрәмә килүе, бәлки, яхшыгадыр. Юк-бар артыннан

чабып гомер үткәргәнче, бәлки, тормыш юлына басканчы ук «акылга утыруың» хәерлерәктер. Әле төзәтә алмаслык хата ясалмаган. Алда барысы да үзеңнән тора.

* * *

Нургаяз яңа хәбәрне әти-әнисенә әйтми торырга булды. Әллә барып чыга, әллә юк, нигә аларны вакытыннан элек бимазаларга. Аларның борчулары болай да җитәрлек. Институт тәмамлаган малайлары өчен дә хәсрәтләнеп ятмасыннар әле. Вакыты җиткәч, ишетерләр, белерләр. Бәлки, театр тирәсендә кайнашмавына сөенерләр дә...

Шулай да моны берәүгә әйтмичә булмый, ул — Нурания. Университетның юридик факультетында укучы кыз. Нургаяз аның акыллы, бик төпле икәнен белә, карап торырга да чибәр. Тик араларында әлегә мең төрле билгесезлек. Нурания егетне бик якынга да, бик еракка да җибәрми. «Үзем сөймим, ятка бирмим» дип уйнаган шикелле дә түгел, тик хисләрнең шашып китүенә ирек бирми. Хикмәт нәрсәдә икәнен теле белән әйтеп бетермәсә дә, читләтеп, уенычыны белән сиздерә. «Көндәлек мәхәббәт» белән мавыгулардан кызык тапмаган Нурания ераккарак карап фикер йөртә: Нургаяз белән башы бәйләнсә, көнләшүләргә түзәргә көче җитәрме соң?! Режиссер тирәсендә хатын-кыз артисткалар бөтерелеп йөриячәк, калганы аңлашыла инде... «Бүген кайсы белән китте икән?» дип уйлый-уйлый акылдан язарсың. «Ир бирмәк — җан бирмәк» диләр, кайсы хатын ирен башкалар белән уртаклашырга теләсен. Нурания юристлыкка укый, судья булып сайлануы да ихтимал. Ул хаклык, гаделлек өчен көрәшүче зат булачак. Үз гаиләсен рәтләп кора алмаса, башкаларның хокукларын яклый алырмы?! Бу турыда ничек уйланмасын. «Йөгәнсезлекнең» ахыры ни белән беткәнен таныш-белешләренең күз яшьләре дә искәртеп тора. Исәп-хисап белән кияүгә чыгуларны, өйләнүләрне гаепләп сөйләүчеләр сөйләсен, язучылар язсын, әмма Нурания үзенчә уйлый, үзенчә фикер йөртә, үзенчә яшәргә омтыла, балачагыннан бирле бәхетле булырга хыяллана, шуның өчен укый, өй эшләренә өйрәнә, сафлыгына тап төшермичә яши, нишләп ул тормыш юлдашының кем булуы, нинди булуы турында уйланмаска тиеш ди әле! «Көндәлек мәхәббәт» кемнәрне генә яндырмаган да, кемнәрне генә көйдермәгән... Исәп-хисап белән өйләнешү ул малга, әти-әниләрнең зур урында булуына карап планлаштырыла. Кемдер фатирга кызыга...Нуранияның исәп-хисабы кешелек сыйфатларына нигезләнгән.

Егетләр үзләре дә ничек кенә сайлана әле. Сөеклесе матур да, тәртипле дә, эше дә кеше хөрмәт итәрлек булсын... Юньле егетләр юньле кызларны әллә каян таный. Ачык кендеклеләр — кендекбикәләр белән йөрергә, күңел ачарга рәхәттер дә, ә өйләнергә төпле акыллы кызлар кирәк. Нургаяз Нуранияның «салкынлыгы»на тикмәгә генә түзми. Өйләнер өчен аннан да кулай кызы юк... Бер елдан университет тәмамлый, ул арада Нургаяз бераз аякка басар, шулай итеп кавышып та куярлар.

Нургаяз урамның икенче ягына чыгарга аяк атлыйм дигәндә генә кесә телефоны җырлап җибәрде.

— Тыңлыйм. Үзем дә сиңа шалтыратырга җыенган идем әле, матурым.

— Җыенып кына калгансың шул...

— Мин озаграк җыенам шул.

— Дипломыңны кайчан күрсәтәсең?

— Бүген үк. Син хәзер кайда соң?

— Университет каршындагы бакчада.

— Мин Кипкән Күл бакчасыннан чыктым гына. Биш минуттан барып җитәрмен.

Нургаяз очып кына университет каршындагы бакчага килеп житте. Нурания аны күрүгә эскәмиядән сикереп торды да ике кулын сузды:

— Котлыйм! — диде ул. — Котлыйм! Кызыл диплом алу теләсә кемгә тәтеми. Гел «5»легә уку бик авыр бит ул, бик авыр. Үземнен дә көч житеп бетми, әле тегеләй, әле болай «4» леләр эләгә. Ә син тәки үзеннекен иттен... Нургаяз сүзне бөтенләй көтелмәгән якка борды:

— Минем сүзләрдән егылып китә күрмә, эскәмиягә утырыйк, — диде ул бик житди кыяфәт белән. — Безгә бүген гаять катлаулы мәсьәләне хәл итәргә кирәк. Син ничек җавап бирсән, шулай булачак...

Нурания сагаеп калды. «Бу режиссер нәстә мәтәштерә икән?» дигән кебек бик тә сәерсенеп Нургаязга төбәлде. «Әллә өйләнешү турында сүз кузгатамы? Башкача икәү бергә хәл итәрдәй нинди «гаять катлаулы мәсьәләсе» булсын ди?! Монарчы «артыгын кыланмаган» Нургаязны диплом алу белән алмаштырып куймаганнардыр ич?!»

Мондый чакта ашыкмау мәслихәт. Бер генә ялгыш сүз ычкындырсаң да, ахырдан үкенеп бетә алмассың. Нурания елмаеп, үз бәясен белеп кенә:

— Тынлыйм, — диде.

— Бүген бу дипломны икәүләп карап калыйк, аннары, аны онытырга туры килмәгәе, — диде Нургаяз.

— Аңламыйм. Бүген үк кадере беткәч, нинди кызыл диплом була инде ул?

— Була икән шул.

— Мин синнән кызыклырак сүз көткән идем. Бу — сүз түгел, чүбек.

— Шулай дисенме?! Беләсенме, шушы дипломны алып институттан чыккан гына идем, урам чатында якташым-сабакташым Инсаф очрады. Театр белән ботка пешмәсен әйткән идем — исе дә китмәде, «давай, безгә эшкә кил», дип тора. Үзем урнаштырам, ди. Мин режиссер түгел, юхидист булачакмын... Менә шулай Нурания иптәш!

— Шушы булдымы кызык сүз?!

— Кызык түгелмени?!

— Минемчә, шаяртырга урын юк. Барып чыкса, бер дә начар түгел. Йә, әйт! Театрга урнашсаң, нишләр идең?! Йомышчы малай рәтендә йөгертерләр иде. Яхшы дигәндә дә көтүче хәлендә калыр идең... Ә ЮХИДИда эшләп китсәң, әллә каян сәлам бирәчәкләр. «Мин мин микән, мин кем икән!» дип йөргән «бөекләрнең» дә сиңа йомышы төшәчәк. Берүк баш тарта күрмә. Студент чакта хыялда йөзәсең, диплом алгач, җиргә төшәсең.Тормышның бу законы күптән билгеле...

— Син барысын да бик оста китереп чыгардың әле. «Нурания — Нургаяз» дип кабатларга яратучылар «юхидист һәм юрист» дип тә өстәрләр инде.

Нургаяз беренче тапкыр күргән кебек Нуранияне сөзеп-сөзеп баштан аяк тикшереп чыкты. Кара син аны, әллә ниләр уйлап йөри икән. Хәер, аның һәрвакыт әйтер сүзе табыла. Ихлас күңелдән сөйли, шуңа ышандыра да... Нургаяз күңелендәге томанны да кодрәт иясе сыман таратты.

— Юхидига кайчан барасыз?

— Иртәгә.

— Мин дә сезнең белән барам. Чыкканыгызны көтеп торырмын. Сиңа тел ачкычы теләрмен. Андый жирдә эшләүчеләр мең катлы кәбестә кебек, берне әйтәләр, икенчене уйлыйлар, алар кешеләрне уңайсыз хәлдә калдырырга бик һәвәсләр, тегеләй дә кылыңны тартып карарлар, болай да тартып карарлар, син режиссер булырга укыдың, димәк, моннан кирәк чакта файдалана да белергә тиеш. Иртәгә тормышта «беренче спектакленне» куячаксың. Күрсәт, әйдә, осталыгыңны... Ә мин — синең илһам бирүчең... Ишеттеңме?!

— Ишеттем... ишеттем...

Нургаяз ишетте генә түгел, ә бөтен жаны-тәне белән Нуранияиең никадәр якын булуын тойды. Әйтәләр бит әле: «Аның белән разведкага барырга була» дип, димәк, Нурания белән «разведкага» да тәвәккәлләргә мөмкин...

— Сүз гел минем турыда, синең хәлеңне сорашкан да юк, — диде Нургаяз, гафу үтенгән сыман. — Син дә бит уйнап йөрмисең?

— Борчылырлык нәрсә юк, имтиханнар бетте, инде диплом эшенең дә темасы билгеләнде, каникулдан килү белән шуңа тотынам. Вакыт бар әле дип сузарга ярамас...

— Шулай, санаулы вакыт бик тиз уза ул, менә биш ел да үтте-китте, сизми дә калдык. Диплом темасы нинди инде?

— «Суд процессында катнашучы якларның тигез хокуклылыгы һәм үзара ярышы».

— Минем башка бик барып житмәде әле бу, ничек дисең?

— «Суд процессында катнашучы якларның тигез хокуклыгы һәм үзара ярышы».

— Үзең моның ни икәнен күз алдына китерәсеңме соң?

— Азрак чамалыйм. Безнең илдә ул кереп кенә бара. Алга киткән дәүләтләрдә ул гадәти хәл, демократия шунсыз үсә алмый, шунсыз бәйсез суд та була алмый.

— Судта якларның тигезлеген син була торган хәл, дип саныйсыңмы?

— Моны мин генә түгел, Конституция әйтә.

Нургаяз әллә ниләр әйтергә теләде, әмма ... Конституция белән ничек уйнауларын кем белми. Дәүләт башына килгәннәр аны бик жиңел генә үзләренә яраклаштырып куялар.

Нурания егетнең карашыннан ук бөтенесен абайлап алды:

— Теманы бик өнәп бетермисең мәллә?!

— Мин сезнең өлкәдә сай йөзәм. Нәрсә әйтсәм дә көләрсең генә. Үзең беләсеңдер, шулай да бер кызык тамаша күз алдына килә: зур корсаклы бер генералны чебеш кебек кенә бер солдат судка биргән ди. Солдат — дәгъвачы, генерал — жавап тотучы. Аларның судта тигез хокуклылыгын кем тәэмин итәр икән? Конституцияме?! Конституциядә булыр ул, ә менә судта?! Прокурор генералга каршы ничек тел күтәрер икән?! Солдатны якларга адвокат та табылыр микән әле?! Хәер, үзең беләсеңдер, кирәкмәгәнгә тотынмыйсыңдыр...

— Син мине уятып жибәрдең. Генерал белән солдатны рәттән куеп бөтенесен аңлаттың да бирдең... Чыннан да солдатны кыерсыткан өчен генералга жинаять эше ачып карасалар да, судка житкермиләр инде аны, йомып калу юлларын табалар. Әнә, бөтен илне тетрәндергән вакыйгалар турында ничек нәфрәтләнеп сөйлиләр. Армиягә яңа гына алынган яшьләр Ерак Көнчыгышка барганда туңып, өшеп бәлагә тарыдылар. Моның өчен кем судта жавап тотты да, кем җәзасын алды?! Тормыш без дигәнчә генә түгел шул. Шулай да рәхмәт, мине нинди сынаулар көтүен аңлаттың... Дипломымны язып, «5»легә якласам...

— Нишләтәсең инде?!

— Бусы сер.

— Мин ел буена шул сер турында уйлап йөрергә тиешме?!

— Бер ел гына да түгел...

— Гомерем буенамы?!

— !!!

— Әйтсәң, әйтеп карыйсың инде, Нурания! Юрист буласы кешеләр барысы да шундыймы икән?

— Сере булмаган кеше уенчык алма шикеллерәктер ул, тәме дә, исе дә юктыр...

— Ризык белән уйнарга ярамый, минем уенчык алманы Яңа ел чыршысында гына күргәнем бар, башка җирдә күргәнем юк әле...

— Димәк, серсез кешеләр дә бик сирәк...

...Менә ничә ел алар бер-берсен белә, тик беркайчан да үпкәләшкәннәре юк. Нуранияның «егет белән кыз хәрәкәтен» бик оста көйләве Нургаязны да билгеле бер кысада тота. Югыйсә ул да бик төшеп калмаган, кайбер кызларның «сәер шөгылен» дә белми түгел. «Мәхәббәт революциясе» җилләре ана да килеп суккалады. Нуранияне фәрештәләре саклап йөриме — аның белән булганда Нургаязны кемдер йөгәндә тота кебек. Мәхәббәт хакына берни белән исәпләшмәүчеләрнең мәхәббәте озак гомерле түгел, өлгерер-өлгермәс җиләкне өзү күп очракта үзәкләрне өзү белән тәмамлана. Кемнәрдер бүген үзләрен сакларга, кеше булып калырга тырышалар икән, бу гайре-табигый хәл түгел, бу — яшәеш кануны. Безнең татар кызлары арасында Нурания кебекләр булмаса, милләт ничек алга барсын, ничек үссен, ана телебез ничек гасырларны кичсен?! Режиссер булырга укыган Нургаязны борчымыйммы бу сораулар?! Безнең көчсезлек тә, бәхетсезлек тә шунда: без кемнәндер таләп итәбез, кемнәрнеңдер үзгәрүен телибез, ә үзебез «үзебезгә җайлы хәлдә» калырга булышабыз. Кызлар да безне яратсын, яратсын гына да түгел... Нургаязның да «ташып чыгардай» чаклары була, әмма Нурания «чиктән уздырмый», дәүләтләр арасындагы чикләр кагылгысыз булган кебек егетләр белән кызлар арасында да чикләр катгый.

Нураниягә мондый «ныклык» каян килгән, дип баш ватасы юк. Әнисе Гөлбаһар турында да хикәятләр йөри. Хәрби комиссариатта хезмәт иткән Каюмнурны Әфган сугышына җибәрергә фәрман килә. Шул ук көнне ул медицина институтының бишенче курсында укучы сөеклесе Гөлбаһарга өйләнмәкче була. Югыйсә бер-берсен яратышып-яратышып та бөтенләй кавышмыйча калырга мөмкин бит...

— Әле минем бер ел укыйсым бар, нигә ашыгырга?! — ди Гөлбаһар. - Өйләнешкәч, балабыз да туар, дәүләт имтиханнарын ничек тапшырырмын?! Укыганны юкка чыгара алмыйм бит инде. Янымда булсаң, ничек тә җаен табар идек, син бит сугышка китәсең...

Яраткан кешеңне шундый хәлдә калдыралармыни?!

— Син мине тыңла әле, — ди Каюмнур. — Без өйләнешик-язылышыйк, никах укытыйк, әмма ир белән хатын булып яши башламабыз. Мин сугыштан исән-сау кайтсам, бергә тормыш корып җибәрербез. Синең киләчәгең — ул минем дә киләчәк. Ул киләчәкне минем саклыйсым килә, язылышсак, икебезнең дә җаваплылык арта.

Тәки үзенекен итә Каюмнур. Аны, бәлки, шул мәхәббәте, матурлыкка, сафлыкка ышанычы саклап йөрткәндер дә. Ут капкан танк эчендә дә янмый кала — «интернациональ бурычын» үтәп кайта. Шуннан соң туй була, өйләнешүләренә бер ел тулганда ир белән хатын уртак түшәк ләззәтен татый. Нурания шул төн җимешедер.

* * *

Көндезгә сәгать ике тулганчы ук Нургаяз Чәчәкле мәйданына килеп житте. Бу — шәһәрнең бик тә матур, чиста урыны, һава да яхшырак. Монда кеше һәрвакыт күп була. Эскәмияләргә утырганнар да, арлы-бирле йөрүчеләр дә бихисап. Чәчәкләрдән ниләр генә ясамаганнар монда, хәтта аюларга кадәр бар. Бала-чага алар тирәсендә мәш килә. Нургаяз чәчәктән үрелгән болан баласы каршында басып тора иде, берәү арттан килеп ике кулы белән аның күзләрен каплады.

— Мин сине ун чакрымнан таныйм, катырак кыс әле, Нурания! — диде

Нургаяз, рәхәт мизгелләрен сузарга теләгәндәй. — Хәйлә белән иркәләнеп калыйм әле.

— И...и...җаным, сиңа наз җитмимени?! — дип Нурания дә кулларын алырга ашыкмады. Бераз шулай басып тордылар. — Инде булдымы?! — дип кыз бармакларын уйнаткалап алды.

— Шулай кичкә кадәр басып торырга да риза, тик хәзер Инсаф килеп җитәр. Безнең янга килергә куркып кире китмәсен тагын...

Чыннан да, килә-килешкә үк Инсаф Нургаязны шәйләп алган иде инде. Сүзгә дә кесәгә кереп маташмады:

— Шундый чибәр кызың булганын әйтмәден дә, Нургаяз! — дип шаярткан булды, барсы да бик табигый килеп чыкты, сүзләре дә үзеннән-үзе ялганып китте.

— Таныш бул, Нурания, — диде Нургаяз. — Университетның соңгы курсына күчте.

— Кайсы факультетта? — дип белеште Инсаф.

— Юридик факультетта.

— О...о... Молодец!

Аларны көмеш сыман «Мерседес» көтә иде. Инсаф шофер белән рәттән утырды, Нурания белән Нургаяз арттагы урыннарга чумдылар.

Юл буе сөйләшмичә бардылар. Монда «хуҗа» — Инсаф, ә ул машинада йөргәндә сүз белән артык мавыкмый. Юлларда болай да бик киеренке. Руль артына утыручыларга кесә телефоныннан сөйләшергә дә рөхсәт итмәс иде әле. Бөтен игътибарыңны юлга бирсәң дә, барулары бик авыр. Юл-транспорт фаҗигаләре күп очракта юл йөрү кагыйдәләрен санламау нәтиҗәсе.

Нурания белән Нургаяз да телләрен йоттылар. Майда йөзгән кебек кенә барган машинадан төшәсең дә килмәс. Шофер урамнарның һәр агымын яттан беләдер сыман. Машинасына канатлар куелган диярсең. Аның туктавы да сизелми калды.

— Килеп җиттек! — диде Инсаф. Үзе иң беренче булып машинадан чыкты. Аннары Нурания белән Нургаяз төште, һәркайсы шоферга аерым-аерым рәхмәт әйтте.

ЮХИДИ янында гадәттәгечә машиналар да, кешеләр дә күп. Инсаф Нуранияга эскәмия күрсәтте дә үзенчә шаяртып та алды:

— Безнең чыкканны шунда көтеп торырсың инде, сак бул, бер үк урлап китә күрмәсеннәр...

— Егетләр сүзе минем өчен закон, — диде Нурания, елмаеп. — Мин сезгә тел ачкычлары телим...

Инсаф белән Нургаяз дүрт катлы бинага кереп киттеләр.

Майор Солдатов бүлмәсе икенче катта коридор башында иде, баскычтан күтәрелделәр дә шунда юнәлделәр. Инсаф ишек шакуга «керегез» дигән җавап ишетелде.

Урта яшьләрдәге майор ике кулы белән ишарә ясап өстәле каршындагы урындыкларны күрсәтте.

— Утырышыгыз, — диде ул, башын күтәрмичә генә. Аннары әле Инсафка, әле Нургаязга карап алды. Янә бер кат Нургаязга сынаулы караш ташлады. «Шактый нык егет күренә» — дип үзенчә нәтиҗә дә чыгарып куйды. Шулай да майор егылып төшмәде. Сүзләрен дә санап кына әйткән кебек сөйләшә.

— Йә, сөйлә, сержант, ни йомыш?

— Иптәш майор, менә шушы егет инде ул Нургаяз. Минем классташ. Быел институт тәмамлады. Кызыл диплом белән.

— Кем булырга укыдыгыз? — диде тегесе, Нургаяз ягына борылып.

— Халык театры режиссерына укыткannar иде.
— Кем укыткан иде?
— Безнең районда халык театры ачмакчылар иде, мине укырга да җибәрделәр. Тик заманалар үзгәреп китте бит. Район хакимияте башлыгын да янадан сайламадылар. Мин кирәксез кеше булып калдым.
— Башка театрларда да урын юкмы?
— Миңа ошаганы табылмады. Инсаф сүзе белән киллем инде мин монда... Сезнең белән кинәшеп карарга булдык.
Нургаязнын «Сезнең белән кинәшеп карарга булдык» дигән сүзләре бик отышлы чыкты, күрәмсен, майор ирен чите белән генә елмаеп куйды. Анын каршында утырган егет төшеп калганнардан түгел. Сүзнең рәтен белә бу. Эш эзләп килсә дә, таралып китми. Мондыйлар кайда да үз юлын таба...
Инсаф сүзгә кушылмады. Ул күзен дә йоммыйча майорга карап тора. Эченнән генә уйлана: Нургаязны ошатты нәчәлник.. Болай барса, ботка пешәчәк...
— Безгә килергә телисеңме? — диде майор сүзне тәгаенләмәкче булып.
— Сез ничек кирәк тапсагыз, шулай була инде, — дип җөпләде Нургаяз. — Монда бит төрле һөнәр ияләре эшли. Бәлки, миңа да жай чыгар...
— Ә син ничек уйлыйсың, Инсаф?
— Нургаязга ышанмасам, сезнең янга алып та килмәс идем инде.
— Наркоман түгел, азып-тузып йөрми, дисең инде?..
— Бусы да хак. Ул балачактан тәртипле, бөтен классыбыз өчен үрнәк булды.
— Әти-әнисе, туганнары дамы?..
— Барысы да абруйлы, хөрмәтле.
Майор янәдән Нургаязга төбәлде. Юк, бу егеттә шик уятырдай сәбәпләр күренми. Аны кире борып җибәрү турында сүз дә була алмый. ЮХИДИга шундыйларны күбрәк тартырга кирәк әле. Күрер күзгә үк хөрмәт уятырлык, киләчәктә үсәргә сәләтлеләрне... Анда сәер бер кызыксыну туды:
— Режиссерлыкка укыгач, төрле тамашаларны үзең дә уйлап чыгара аласыңдыр инде? — диде ул.
— Нинди тамаша?
— Әйтик, безнең эшкә караганны.
Нургаяз урыныннан торды да, бүлмә читендәге сейф каршысына килеп басты. Ике аягын киң җәеп, ун кулын алга сузып тегене «боргычлый» башлады.
— Нигә документларың тәртиптә түгел?!
— Нинди документлар?
— Үзеңдә нинди документлар барлыгын белмисең дә мәллә?!
— Мин монда басып торганда хуҗам кырык тапкыр алмашынды, барысы да миңа нәрсәдер тутырды, аларның очына кем чыга алсын! Законнар да кырыкка төрләнде, кайсы дөрес, кайсы ялгыш икәнен дә белеп бетермәссең.
— Нигә менә бу кечкенә тартмаңны ачмыйсың?
Майор Солдатов иңбашларын җыерып куйды, сейф белән «булышу» аллә инде аның үзенә дә кагылды, ул тамашаны туктатырга ишарә ясады.
— Килештерәсең, беркетеп куйган сейфны да биеп китәрлек хәлгә җиткердең, — диде ул, үзенчә бер канәгатьләнү белән. — Теге кечкенә тартмасы да ачыла дип торам... Безнең хезмәткә турыдан-туры караган тагын берәр нәрсә уйлап тап инде.
Нургаяз шундук сейф янында гына басып торган шкафка «бәйләнде».
— Нигә «зебра»га кереп туктадың?!

— Кая, нинди «зебра» ул?

— Сиңа «зебра»ның нинди булуын да аңлатып торырга кирәкмени?!

— Юкны бар дип әйтә алмыйм бит инде.

— Ул боз астында гына калган!

— Боз астында нинләр барлыгын мин каян белим?!

— Нишләп белмисең? Белергә кирәк! Урам чатында «зебра» булырга тиешлеген син белергә тиеш!

— Гаеп миндә, онытылып киткәнмен.

— Уйлап кара, җәяүлеләр урам аша ничек чыксын!

— ???

— Кешеләр тормышына куркыныч тудыруны болай гына калдыра алмыйм, эшеңне судка юллыйм.

— Без бит инде адәм балалары, үзара гына килешеп булмыймы соң? Моннан соң боз астында гына түгел, җир астында нинләр барлыгын да уйлап йөрермен. ..Эшне зурга җибәрмәгез инде. Хатыным кичә генә малай тапты, шул бала хакына сорыйм...

— Син мине кемгә саныйсың?!

Нургаяз «гаепленең» бирде кирәген. Гүяки ул урам чатында бик җаваплы постта. Башлык та, Инсаф та сүзсез калдылар.

Шулай да хуҗа хуҗа инде, ул да үз эшенең «бүресе». Нургаяз кебекләрне күрмәгән түгел. Нинләр уйлавын йөзенә карап кына белә алмыйсың. Казна эшендәгеләр беркайчан да «капчыкны төбенә кадәр селкеп бетерергә» ашыкмыйлар. Аларның сүзләре дә, гамәлләре дә саналган. Бердәнбер «карарбыз» дигән сүзне генә кызганмыйлар, аны борчак урынына чәчәләр, «карарбыз» дип беркайчан да ялгышмыйсың...

Майор Инсафка әмер биргәндәй әйтеп куйды:

— Дустыңны кадровиклар янына алып кер, кирәкле документларны тутырсын, сынау шарты белән алты айга алып карыйк. Үзең алып килдең, үзең эшкә дә өйрәтерсең...

Аннары ул Нургаязга таба борылды.

— Бездә тәртип шундый инде, алты ай эчендә үзегезне уңай яктан күрсәтә алсагыз, аттестацияләү мәсьәләсен карарбыз. Искәртеп куям: бөтен яктан өйрәнәчәкбез. Яшерен-батырын түгел, җиз иләк аша үткәрәбез. Шулай да очраклы кешеләр дә арабызга килеп кергәли. Погон тагасың икән, аның дәрәҗәсен төшерергә ярамый. Аңладыгызмы? — диде ул, сүзгә нокта куйгандай.

— Сезгә бик зур рәхмәт! — дип Нургаяз урыныннан торды.

— Калганы үзегездән тора, үзегездән! — дип басым ясап әйтте майор.

* * *

Нәрсә, нәрсә кәгазь бездә һәрвакыт почетта. Нургаяз да нинди генә кәгазьләр тутырмады. Җиде бабаңны тикшерүләре кемгә кирәктер инде, моннан йөз ел элек дөнья куйганнарны нигә кузгатыргадыр. Хәзер урлашып төрмәдә утырып кайтканнар да, сугышка бармас өчен качып ятканнар да күкрәк киереп йөриләр. Әле дәгъвалары да буа буарлык. Янәсе, аларны нахакка рәнҗеткәннәр, шуларны дәүләт пенсияләргә өстәмәләр, төрле ташламалар белән кайтарырга тиеш икән... Нәрсә хаклы, нәрсә хаксыз икәнен ачыклавы да авыр хәзер. Заманалар үзгәрә, күп нәрсәгә караш үзгәрә, ә кемнедер эшкә алганда узган гасырдагы тәртипләр һаман әле үз көчендә. Анкеталардагы сорауларны да үзгәртмиләр ичмасам. Хәер, шулай булмаса, бюрократия ничек чәчәк атсын, коррупция ничек котырсын...

Нургаяз белән Инсаф эшләрне тәмамлап урамга чыкканда Нурания калын гына бер газетага «чумган» иде. Егетләрнең якынлашуларын да сизми калды.

— Нурания, бу без! — дип шаяртты Нургаяз. — Әллә безнең зур эшләр белән йөрүебезне онытып та җибәрденме?!

— «Зур эшләрегез» чыннан да зур булып чыкты, ахрысы, көтә-көтә көтек булып беттем. Юлыгыз уңдымы соң?

— Без көткәннән артык та, ким дә булмады, — диде Нургаяз. — Инсафка рәхмәт инде. Аның янында мина җил-янгыр тимәде.

— Сез дә мина бер яхшылык эшли аласыз, — диде Инсаф, хәйләкәр генә елмаеп.

— Нинди яхшылык? — диде Нурания, уйлап та тормыйча.

— Үзең кебек бер әйбәт кыз табып бирсәң, дөньям тәмам түгәрәкләнер иде.

— Әллә синең кызың юкмы?

— Бар белән юк арасында.

— Кызык...

— Андыйлар бер мин генә түгел, — диде Инсаф, балаларча беркатлылык белән. — Бүген бар, иртәгә — юк. Кайберәүләр бик тыйнак кына күренә, таныша башлагач, исләр китә...

— Сенлем булса, шатланып синең белән таныштырыр идем, — диде Нурания. — Кызганыч, сиңа безнең киявебез булырга язмаган шул. Кыз кемнәндер ишеткән шигъри юлларны да кабатлады:

Вәгъдә — иман, вәгъдә — иман —
Иманы булганнарга.
Пары кирәк кошларга да
Кыяга ояларга.

— Дуслар бер-берсенә һәрвакыт таяныч булырга тиешләр, — дип өстәде Нургаяз. — Гомерлек юлдашыңны табу җиңел түгелдер инде ул, мондый чакта бер-береңә белән киңәшүнең гаебе юк.

Инсаф кесә телефонын чыгарып үзләрен ЮХИДИга алып килгән шоферга хәбәр бирде.

— Борчып тормаска иде, — диде Нургаяз.

— Ул үз җаен үзе белә. Мин дә бит аны обижать итәргә ирек бирмим.

* * *

Алар Аккала үзәгенә юнәлделәр. Машина шулкадәр ипле бара, шоферның осталыгына таң калырлык. Кайберәүләр гомер буена машина йөртсәләр дә, юлны тоярга өйрәнмиләр, утын ташыган сыман аны-моны белештермичә чабалар. Ә бу... күз генә тия күрмәсен.

Үзәк мәйданда машинадан төштеләр. Инсаф шоферның колагына иелеп нидер әйтте. «Ярар, ярар»дип тегесе китеп тә барды.

— Бүген көне буе сүз белән сыйландык, — диде Нургаяз. — Тамак ялгап алсак та зыян итмәс иде. «Затлы ризык» йортына барсак, ничек булыр?

— Бик урынлы тәкъдим, — диде Нурания.

— Мин дә ике куллап риза,— дип шаяртты Инсаф. — Үз-үзебезне дә бераз хөрмәт итәргә хакыбыз бар.

Ремонттан соң «Затлы ризык» йорты бик нык үзгәргән. Хәзер мөмкинлекләр зур, акчаңны кызганмасаң, җәннәт ясарга да була. Нурания дә, Нургаяз да, Инсаф та яңарышларны әле күрмәгән дә булганнар, өчесенең күңеленә дә хуш килде яңа бизәкләр. Исемнәрен әйтеп тә булмаслык ризыклар белән баш катырмадылар, үзебезнең токмачлы аш, өчпочмак кебек нәрсәләрне алырга булдылар. Нургаяз үзенең кызыл дипломын юарга шампан шәрабен тәкъдим итте. Артык ыгы-зыгы куптармадылар, өчесенең

дә бик нык ашыйсы килгән иде, тәлинкәләрен тиз ялтыраттылар. Бераз шампан шәрабен дә татыгач, телләре ачыла төште. Сөйләшер сүзләре дә күп җыйналган икән.

— Моннан биш ел элек институтка керергә имтихан тапшырган көннәрем әле дә хәтердә, — диде Нургаяз. — Бүгенге көн дә безнең өчен бик истәлекле. Еллар узар, без аны кабат-кабат искә төшерербез, өчебезгә дә игелекле көн булсын иде.

— Бу тостмы? — диде Нурания елмаеп. — Әйе, өчебезгә дә игелекле булсын иде. Бүген мин Инсафны беренче тапкыр гына күрдем һәм Нургаязның шундый дуслары булуына сөендем. Кешенең кемлеген иптәшенә карап та белеп була.

— Шуңа күрә мин сездән кыз сайлауда булышуыгызны сорыйм да инде. Сезнең иптәшләрегез начар була алмас дип уйлыйм, — дип Инсаф ЮХИДИ янында башланган сүзне яңадан ялгап җибәрде. — Бу минем өчен мөһим мәсьәлә.

— Нишләп бик куырасың әле? — дип Нургаяз дустының «тузанын бастырырга» теләгән иде, тик Инсаф тагын да җитдиерәк дәлилләр китерде:

— Мин бабай белән әбине карыйм, икесе дә картлар, миңа фатирларын яздырдылар, Ходай биргән форсаттан файдаланмыйча булмый, әлегә миңа бик авыр, шуны анлый алырлык, киләчәк турында кайгыртып яшәрлек пар кирәк миңа. Сез инде яхшыны яманнан аерасыз, сезнең таныш-белешләр, дуслар да күп.

— Минем әни янында шәфкать туташы булып Солтания исемле кыз эшли,— диде Нурания, егетнең хәленә кереп — Әни аны мактап бетерә алмый. Чибәрлеккә дә бик чибәр. Авырулар да бик яраталар үзен. Әлбәттә, сез бик матур пар була алыр идегез.

— Киртә булырлык нәрсә бар соң?

— Киртә шул гына, ул бит районда, тик торганда гына аны эзләп бара алмыйсың.

— Нишләп бармаска! — диде Инсаф, очып китәрдәй булып. — ЮХИДИның бармаган җире юк аның. Командировкага барам. Район үзәк хастаханәсе тирәсендәге юлларны да «тикшереп» кайтырмын. Солтанияне күрергә дә җай табармын. Нургаяз, икәү бергә барырбыз. Без бит хәзер бергә эшләячәкбез. Нурания туган якларны күргәнең дә юктыр әле.

— Егетләр, бик кызып китмәгез, мине уңайсыз хәлгә куюыгыз бар. Әтиәни, туганнар, танышлар белсә, ни диярләр...

— Бу яктан кайгырма, Нургаязның режиссер икәнен онытма син, бүген нәчәлник бүлмәсендә сейф белән «театр уйнап» та шаккатырды, без инде сезнең районда да йөри белербез...

Нурания җитди ачыш ясаган шикелле Инсафка төбәлде. Кара, гади генә кебек иде үзе, нинди тәвәккәл икән... «Тәвәккәл таш яра» дию генә аздыр, тәвәккәллек — ир-егетләрнең ярты бәхетедер. Андыйлар белән хатын-кызлар дөньяның читенә дә барырга риза...

* * *

Майор Солдатовка гражданнардан кергән хатлар һәм жалобаларны контрольдә тоту да йөкләнгән, Ул халык фикеренә таянып эш йөртә. Үзен закон кысаларында яшәүче затлар рәтенә кертә, әмма «кеше кулы белән күмер көрәтергә» шактый ук остарып килә инде. Инсафның «тоткан җиреннән өзмичә туктамавын» яхшы белә, шуңа күрә аны үзенә «ияләштерә». Милиция академиясенә читтән торып укырга керергә ярдәм итәргә дә булды. Нургаязга да үз араларына юл ачачак. Анысы бик башлы күренә... Болардан күп нәрсә «эшләтергә» мөмкин...

Бу ике егет «бик житди операция» башкарачак. Солдатовның үзенә йорт салдырасы килә. Тик әлегә планнан башка бернәрсәсе дә юк. Бөтен өмет менә шушы ике егеттә. Алар жир алудан башлап түбә астына кертүгә кадәр барысын да закон кысаларында ерып чыгарга тиешләр. Режиссерлыкка укыган Нургаязның иҗади кодрәте бик тә ярап куячак монда. Зур-зур коттеджлар салучыларга да кемнеңдер «ярдәме» тигән инде. Югыйсә шундый йортлар житкерергә акчаны бассаң да житмәс иде. «Мич башыннан егылып төшүнең дә рәте бар» дигән шикелле барысын да жайлыйлар, көйлиләр. Беркем дә бәйләнә алмый.

Майор Солдатов эшне бик ашыктырмыйча гына алып бармакчы. Быел жәй жир алып, нигез салып «нольдән» чыга алсалар, бик житкән. Киләсе жәйдә түбә астына кертергә һәм эчтәге эшләрне башлап жибәрергә булыр... Егетләргә беренче «задание» — жир алу өчен юл ачу. Бу әлләни катлаулы да күренми: жир эшләре белән шөгыльләнүче абзыйның кызы бик шәп иномаркада йөри. Бик жилле кыз. Еш кына тизлекне дә арттырып жибәрә икән. Моңарчы аның белән «вакланмадылар», менә хәзер «акыл бирми» дә ярамас.

Икенче көнне үк майор Солдатов Инсафны үз бүлмәсенә чакыртты. Юлларда иминлек ае үткәрелү уңаеннан гражданнардан кергән хатлар, жалобалар турында сүз барды. Берничә машинаның маркасын, номерын атады. Берсен аерып күрсәтте.

— Бу машина хатларда бигрәк тә еш кабатлана. Үзең дә беләсең инде, менә шундыйлар аркасында яшел ут кабынгач та жәяүлеләр урамның икенче ягына чыга алмый аптырый. Яңгыр, юеш кар яуган чакларда бигрәк тә хәтәр. Кешеләр өстенә пычрак чәчрәтеп китүчеләр дә күпме. Ә бит жәяүлеләр чыкканны машиналар көтеп торырга тиеш. Бу кагыйдәне бар дип тә белмиләр. Моңа чик куярга вакыт. Светофорлар була торып күпме бәхетсезлек килеп чыга...

— Ана мин үзем дә игътибар иттем, — диде Инсаф. — Боргаланырга урын калмаслык итеп эләктерергә иде исәп. Ул бер кыз машинасы.

— Бик яхшы. Кыз кеше синең башны әйләндерергә дә маташыр, сүз белән артык мавыкма. Синең өстән жалоба кергән, диген.

— Үзләренә ике тиен бирмәссең, миллион торырлык машиналарда чабалар, — диде Инсаф, борчылуын белдергәндәй. — Иң күп кагыйдә бозучылар да — алар.

Майор Солдатов әйтеп бетермәсә дә, кызын якларга әтисе киләчәген чамалый иде. Ул бик яхшы белә: түрәләр балаларына жил-яңгыр тидермәс өчен утка да, су га да керергә әзер.

Бу «операция» кулдан килмәслек эш түгел иде, Инсаф тимерне кызу чагында сукты. Нургаяз сүзгә кушылмый, ул күзәтеп кенә — «мыекка чорнап кына йөри. Машинаның маршруты билгеле, аны бик тиз юл читенә терәделәр. Ике әби урам аша чыга алмыйча аптырап басып тора. Яшел ут кабынгач та кузгала алмый калдылар, теге машина юлларын кисте. Карчыклар бәладән чак кына котылдылар. Инсаф машинага тукталырга сигнал бирде. Кара төстәге «Форд» туктаырга мәжбүр булды. Джиплар арасында да бу иң зурысыдыр. Ана ике «Жигули» машинасы рәхәтләнеп сыярлык, һәм... ишекне киң ачып орчык кадәрле бер кыз килеп чыкты.

— Сержант Нуруллин, — диде Инсаф һәм тегенең документларын караштыра башлады:

— Бөтенесе тәртиптә, — диде кыз, елмаеп. — Без тәртип яратабыз.

— Тәртип яраткач, нигә жәяүлеләргә юл бирмисез?!

— Яшел ут кабынгач та кузгалмасак, без ничек йөрергә тиеш! Болай да «бөкедән» туйган.

Инсаф ашыкмыйча гына кәгазьләрен тартып чыгарды.

— Сез нәрсә?! — дип кыз аның терсәгенә тотынды. — Мин нәрсә эшләгән әле ул кадәрле?! Подумаешь?!

— Бу бит сезнең гадәткә кергән инде, машинагызның номерын язып хәтта жалоба җибәргәннәр, бүген монда, кичә тегендә җәяүлеләрне кыерсыткансыз. Берәүнең өстенә пычрак чәчрәтеп тә киткәнсез...

Кыз сагая калды. Ул үзе белә «маҗараларын»...

— Иртәгә әтиегез белән ЮХИДИга килегез.

— Әтинең вакыты булмаска мөмкин. Ул бит бик занятой. Бәлки, үзем генә барырмын. Уртак тел табарбыз...

— Мин сезнең турында кайгыртып сөйлим, кызы өчен борчылган ата вакытын тапмый калмас. Юлларда иминлек айлыгы бара, без җәза бирү өчен генә тырышмыйбыз. Безнең профилактика эшләрендә әтиегез дә катнашса, зыяны тимәс. Башкаларга да сабак булыр...

— Ярар, — диде кыз, күзен-кашын җимереп. — Все будет в порядке, товарищ сержант!

Ул китеп барды, ә теге әбиләр әле һаман урамның икенче ягына чыгып житә алмаганнар иде. Моңарчы барысын сүзсез генә күзәтеп торган Нургаяз киңәш бирде:

— Эшләр зурга китсә, кирәге чыгар, әбиләрнең кем булуларын, кайда яшәүләрен язып калыйк әле. — Кулда козырьлар күбрәк булган саен яхшырак. Бу кызның әтисе берәр түрәдер әле, әллә ниләр китереп чыгарулары бар. Бик кызып китсәләр, тынычландырыр өчен ярап куяр ул.

Урамның икенче ягында әбиләрне куып җиттеләр. Карчыклар сагаеп калдылар, Инсафның «бәйләнүенә» ризасызлык белдерделәр:

— Нигә безнең арттан киләсез, безгә юл бирмәгән кызның сабагын укытыгыз әнә.

— Безне дә шул борчый, авырыксынмасагыз, кем булуыгызны, кайда яшәвегезне әйтсәгез иде. Теге кызый кебекләргә профилактика ясау өчен кирәк бу...

— Гафу итегез, без сезгә дә ышанмыйбыз. Сезнең кебек тәти егетләрдән бөтенесен көтәргә мөмкин. Көн саен телевизордан кисәтеп торалар...Хәзер беркемгә ышаныч калмады.

Инсаф документларын күрсәтергә мәҗбүр булды. Кат-кат аңлаткач кына, карчыкларның күңеле йомшарды. Исем-фамилияләрен, телефон номерларын әйттеләр.

— Сәерсенеп карауларына үпкәләп тә булмый, Погонлылар арасында төрле кеше очрый, — дип нәтиҗә чыгарды Инсаф.

— Кызганыч, машинада йөрүчеләр дә, җәяүлеләр дә кагыйдәләрне адым саен бозалар, — диде Нургаяз. — Баксаң, бу һәркемнең үзе өчен кирәк... Һәркайсыбыз өчен кирәк...

* * *

Солдатов «кодрәте» белән икенче көнне үк тегермән канатлары әйләнә башлады. Теге кызның әтисе килеп тә житкән. Телевизор экраныннан төшмәүче затлар сыман бик килештереп киенгән. Костюмы да, галстугы да нәкъ Илбашныкы кебек.

Аның үз тактикасы. Ул кызының «төзәтә алмаслык гаебе» юклыгын Солдатовның үзенә төшендермәкче. Җинелчә кисәтүләргә аның исе китми. Үз дәрәҗәсен белеп кенә, дулкынланмый гына сөйләшеп «эшне» япмакчы.

— Кисәтү ясарлык сәбәп нәрсәдә инде? — диде кызның әтисе, әңгәмәнең дилбегәсен үз кулына алырга чамалап.

Солдатов та бүген генә тумаган. Белә ул кайчан ничек кысасын.

Мәйданга чыккан көрәшче сыман аяк чалырга да, кирәксә, баш аркылы җибәрергә дә күп сорамый.

— Сәбәп — халык фикере, — диде ул, кызның әтисе көтмәгән яктан һөҗүм ясап. — Менә хатлар, жалобалар. Алар сезнең кызыгыз дип язмаганнар, машинаның маркасын, номерын гына күрсәткәннәр. Хәтта кайберәүләрнең өстенә пычрак сиптереп тә киткән...

— Чынлыкка туры киләме соң алар? Хәзер үч итеп язучылар да табыла.

— Кызганыч, чынлыкка туры килә. Безнең хезмәткәрләр бу машинаны контрольдә тоттылар һәм жалобаларның дөреслеген исбатлаучы хәлләргә юлыкканнар, кызыгызны кисәткәннәр дә. Югыйсә сез монда килеп тә тормас идегез... Безнең бүген телевизордан айлык барышына багышлап «Турыдан-туры элемтә» үткәрелә, жалоба язучылар сорау бирергә дә мөмкиннәр...

Солдатов сүзен очлап бетермәде, нәрсә әйтер икән, дигән сыман әңгәмәдәшенә астыртын гына карап алды. Халык исеменнән сөйләү бик отышлы ул, һәрвакыт шулай булган. Заманында халык дошманы дигән сүз дә уйлап тапканнар, шушы тамга белән кемнәрнең генә башын ашамаганнар. «Халык дошманы» дигәч, судта карау да кирәк булмаган. Солдатов моның яңа вариантын уйлап тапты: ул «халык фикере» ди һәм моны телевизордан халыкның үзенә җиткерү белән яный. Милек һәм җир мәсьәләләре белән шөгыльләнүче абзый йомшара төште. Исемен бер телгә алсалар, аннары инде яхшылык көтмә...

Тәгаен генә әйтүе дә авыр, әллә кызның әтисе үзе, әллә Солдатов сүзне җир мәсьәләсенә күчерде, сүзләре ничек бәйләнгәндер, үзләре дә сизмәстән шактый ук тирәнгә кереп киттеләр. Бик тирәнгә кереп китсәләр дә, «җир патшасы» аннан чыгу юлын да тиз тапты. Ул кайларда кешеләргә җир бирелүен, нинди перспективалар булуын саный башлады. «Кайсы ошый?» дип теле белән әйтмәде генә. Солдатов та «балтадан аш пешергән солдаттан» ким түгел, ишарә ясый белде.

— Теләсәгез, ун көннән рәсмиләштерәбез.

— Пожалый, ярый да торгандыр, — диде Солдатов, артык исе китмәгән сыман.

— Мондый иркенлек озакка бармас, — диде кызның әтисе. — Бөтенесе кулга кереп беткәч, сырпаланудан мәгънә калмый. Кәгазьләр әзер булгач, мин сезгә үзем шалтыратырмын. Кызымны кисәтүгә килгәндә, монысы өчен рәхмәт. Ул-бу китереп чыгарганчы алдан профилактика ясау хәерле. Бала-чагага гел тукып торсаң да, бик таманга гына килә әле ул...

...Дипломатия шуның өчен туган да. Каршылыкларны акыл белән тыныч кына чишә бел. Майор Солдатов та, милек һәм җир мәсьәләләрен кулында тотучы түрә дә канәгать калды, икесе дә үз йомышын « хәл итте», закон да бозмадылар. Йорт салырга җыенган кеше җирне тапмый калмый, Солдатов үзенчә тапты. Кемдер айлап, еллап чаба, ә ул ярты сәгать эчендә «майлап куйгандай» итте. Моны «эш урыныннан явызларча файдалану» дип кем раслый ала?! Милек һәм җир мәсьәләләрен хәл итүче җаваплы зат законда каралмаганны эшләми, бу җир барыбер кемгәдер биреләчәк, Солдатовка ни дә, Сабировка ни... Аңа бүген Солдатов белән «дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыру» мөһим, киләчәктә дә кирәге чыгарга мөмкин аның. Шуңа да башы җитмәгәч, нинди түрә инде ул?! Кул-кулны, ике кул битне юа...

* * *

Инсаф белән Нургаяз бик затлы бер машинага игътибар юнәлттеләр. Ялт-йолт килә, чын көмеш төсендә. Нәрсәсе беләндер акчарлакка да охшаган сыман. Әйтерсең лә җирдә йөрергә түгел, ә күктә очарга көйләнгән.

Нимесләрнең «БМВ» машинасы, дөнья базарында бик абруйлы. Номеры Мәскәүнеке. Алай гына да түгел, махсус номерлы. Андый белән Кремльгә дә тоткарлыксыз керәләр, имеш. Инсаф кебек сержантларны алар бар дип тә белми. Шулай да Инсаф кичкә таба бу машинаны туктатып карарга булды. Аккалада ниләр майтарып йөри икән ул? Туктатырга җае да чыкты. Светофорда кызыл ут кабынгач, «зебра» өстенә керեп туктады бу. Җәяүлеләр машинаның алдыннан әйләнеп узалар. Берәү машина хуҗасына йодрык күрсәтеп тә китте.

Чатта басып торган Инсаф сигнал бирде, тоткарланырга ишарә ясады. Машинадан әзмәвердәй егет чыкты да Инсафка күзләрен акайтты:

— Син, нәрсә, неграмотный что ли?! — ди бу. — Мондый машиналарны ерактан танырга кирәк!

Читтәрәк торган Нургаязның якынлашуын күрдеме — бераз суына төште.

— Мәскәүдә дә мине туктатучы юк, сез бик смелый икән, — диде, шаяртткан булып.

— Алайса, танышып калыйк, — диде Инсаф та елмаеп.

Теге документларын чыгарды. Болар башкалардан аерылып тора. Махсус номер да, махсус документлар хуҗага шактый «иркенлекләр» бирә. Әмма өч көн буена Аккалада нишләп йөрергә тиеш әле ул?

— Гафу итегез, машинаның эчен дә, багажникны да карап чыгарга кирәк, — ди Инсаф. — Бездә юл хәрәкәте иминлеге айлыгы бара, теләсә кайсы машинаны тикшерергә безгә хокук бирелгән.

— Үзегезгә артык вәкаләтләр аласыз түгелме? Сез юл хәрәкәте иминлеген кайгыртыгыз, махсус машиналарны тикшереп вакыт әрәм итмәгез. Моның өчен җавап бирерсез.

— Без җавап бирергә өйрәнгән, анысы өчен борчылмагыз.

Машина иясе күреп тора: болардан җинел генә котылырмын димә. Тик ничек тә уртак тел табарга кирәк, «кыйммәтле йөкне» тапсалар, эш харап. Шулай да маркасын төшермәскә тырышып кына:

— Татар тотып карамыйча ышанмый инде, — дигән булды. — Карагыз, актарыгыз...

Инсафны өйрәтеп торасы юк. Ул мина эзләүчедән бер дә ким түгел. Машинаны үтәли күрә сыман. Күңеле белән дә сизә, тик зурдан кубып гаепләрлек нәрсә күренми.

Бала чакта берәр нәрсәне тапмый азаплансалар, «пәри» тап, тап, син тапмасаң, мин табам!» дип такмаклыйлар иде, ни хикмәт, шулай дигәч, «яшеренеп яткан» әйбер килеп чыга. Инсаф көлемсерәп шундый кызык хәлләрне дә исенә төшерде. Кулыннан ниндидер көч тарттымы — машинадагы телевизорны кабызды. Экран яктырды, тик сурәтләр дә чыкмый, тавыш та килми.

— Төзәттерергә һаман вакыт тими, — диде машина иясе.

— Алай икән, — диде Инсаф, килешкән сыман.

Ул каналны күчерүче «+» тамгалы төймәгә басты. Үзгәреш юк. Ике, өч, дүрт, биш... ун тапкыр басты — үзгәреш юк. Унберенче тапкыр баскач, телевизор урыныннан кузгалгандай итте һәм ... эчендәге «байлыгын» чыгарып салды. Төргәкләрдә ялган номерлар, аларның һәрберсенә караган документлар иде.

Әзмәвердәй егет бармакларын җәеп ике кулын алга сузды. Инсаф күрмәмешкә салышты.

— Бусын ачыклау безнең эш түгел, — диде ул һәм милиция чакыртты. Мәскәү номеры тагылган машинаны тиеше җиргә алып киттеләр...

— Бармакларын күрсәткән булды, бу нине анлата сон? — дип кызыксынды Нургаяз.

— Биш бармак — 500 доллар, диләр. Ун бармак булса, 1000 доллар, янәсе. Үземнен алып караганым юк. Ул наркотик шикелледер инде, бер тәмен татысаң, тукталып булмыйдыр. Үзенне юк-бардан саклау жинел эш түгел шул...

Инсафның сизгерлеген ничек инде күрми калсыннар! ЮХИДИ житәкчелеге дә, оешкан жинаятьчелеккә каршы көрәшүчеләр дә аңа кыйммәтле бүләкләр тапшырдылар. Бер дә юкка түгел. Мәскәүдән килеп ялган номерлар һәм документлар сатып йөрүче «эшем иясен» эләктергән булып чыкты алар. «Товар житештерүне» бик киң колач белән замананың бөтен техник казанышларын кулланып оештырганнар, яшерен фабрика ачканнар. Чын белән ялганны аеруы да кыен. «Бик дәрәжәле номерлар, документлар» әзерләгәннәр. Билгеле, «әзер продукция» складларда ятмаган. Мәскәүнең үзендә дә, төбәкләрдә дә аның «тәмен» белгәннәр.

* * *

Кайберәүләр «чәчләре белән жир себерсә дә», эшләре әлләни алга бармый. Нәрсәдер гел итәкләреннән тарта. Кемнәргәдер жил һаман уңай исә кебек. Моның хикмәте бардыр, булмый калмас. Инсаф болай фикер йөртә: кешеләргә начарлык эшләмәсәң, мәрхәмәтле булсаң, Ходай да рәхмәтеннән ташламыйдыр. «Ходайның яраткан бәндәләре» шулай «туадыр». Инсаф юл хәрәкәте иминлеген саклаучыларның берсе, бик теләсә дә, гел яхшы гына булып бетә алмый. Кешеләр тормышына куркынычтудыручыларны ничек инде тоткарламасын, кайберәүләрне судка житкерергә дә туры килә. Хакыйкатьтән качып изге була алмыйсың. Ничек кенә булмасын, аны «везучий» саныйлар. Менә тагын аңа унай жил исеп куйды, хыялында гына йөргән эшләренә керешә ала ул хәзер: академиягә читтән торып укырга керү мөмкинлеге елмайды. Әле күрмичә үк гашыйк иткән Солтания күңелен яулау өчен дә трамплин була бу.

Укырга керү турында майор Солдатов белән монарчы да сөйләшкәннәре бар иде, тагын исенә төшерергә кирәк. Еламаган балага имчәк бирмиләр. Кулай вакытны кулдан ычкындырырга ярамый.

Әмма Солдатов өздереп жавап бирергә ашыкмады.

— Башлык белән сөйләшеп карармын, — диде ул. — Берәү дә аннан уза алмый. Укырга теләүчеләр күп, кемгә юллама бирергә кирәклеген ул хәл итә. Әлбәттә, синең козырьлар көчлерәк, мин дә кулымнан килгәнчә тырышырмын. Укырга бик лаеклы син...

— Иптәш майор, миңа быел һичшиксез укырга керергә кирәк, яшь бара бит, аннары укыйсы да килмәс, — дип Инсаф хәлен аңлатырга тырышты.

— Дөрес, дөрес, тимерне кызган чагында сугу хәерле. Бүген үк башлык янына керәм. Синең кандидатураңны ике куллап якларммын. Тыныч бул...

«Тыныч бул» дип әйтүе генә жиңел ул. Инсаф йокысыз калды. Башында мең төрле уй: академиягә юллама бирү ул сиңа бүләк-мазар гына түгел. Мин әлегә үземнән югарыраклар әйткәнне үтәп йөрүче. Укып чыксам, үзем әмер бирә башлыйм. Мин аларга, бәлки, йомышчы буларак кадерлерәктер. Югары белемлеләргә артык мохтажлык юк. Теләсә кайсы институт, университеттан да киләләр монда. Кызыл дипломлы Нургаяз да килде бит, алардан офицерлар «ясавы да» жиңел. «Кара эшләргә» әйбәт кешеләр табуы читенрәк. Читтән торып укучылар бүлеккә «бүләк» түгел, аларны сессиягә жибәрергә кирәк, ә бит эш кимеми. Димәк, башкалар тиешледән артыгын эшләргә мәжбүр була. Солдатов та, аннан югарыраклар да моны

белмиме... Шулай да Инсаф укырга хакы бар дип саный. Берьюлы ике бүләк тапшырып та укырга җибәрмәсәләр, ни була инде ул...

Аның борчылулары Нургаязның да тынычлыгын алды. Әмма юатырлык сүзләр табылмый. Монда икенең бере — укырга йә керәсең, йә юк. Һәм бу үзеңнән генә тормый. Башлык ни дисә, шулай була. Юлламасыз академиягә юл юк.

— Укырга керсәм, Солтания белән дә курыкмыйча танышырга булыр иде, — ди Инсаф, хыялга бирелеп. — Простой сержант булып түгел, академиядә укучы сержант булып танышу бөтенләй икенче ул...

— Син күзең белән дә күрмәгән ул Солтанияне онытмадыңмыни? — ди Нургаяз, гаҗәпләнеп. — Әле күрсәң нишләрсең!..

— Нишләрмен?! Өйләнәм! Нуранияның әнкәсе аны юкка гына мактамыйдыр. Нурания дә юкка гына мине ымсындырмады. Ышан, әле бер тапкыр күрмәсәм дә, төшләремә керә Солтания. Академиягә эләгүем турында кәгазь алуымның икенче көнендә үк шул районга китәр идек...

* * *

Бүлек башлыгы кечерәк кенә буйлы полковник. Чын фамилиясе Җантимеров булса да, «Янтимиров» дип кенә әйттерә дә, яздыра да. Журналистларга интервьюлар биргәндә дә алдан кисәтеп куя: минем паспортта шулай язылган, фамилиямне үзгәртеп маташмагыз, янәсе. Аның паспортында татарча кушымта юк, шуңа күрә исем-фамилиясе гел урысчага көйләнгән. Ахметьяновлар, Закирьяновлар, Козловлар, Умеровлар, Комаровлар шулай килеп чыккандыр инде. Ярар, «чүлмәк» дип атасалар да — барыбер түгелмени, мичкә генә утыртмасыннар. Янтимиров Инсафның укырга теләвен хуплады.

— Әлбәттә, андый егетләрне укытырга кирәк, — диде ул, ике дә уйлап тормыйча. Аннары майор Солдатовка төбәлеп сорау бирде:

— Үзең ничек карыйсың?

— Каршы төшәрлек сәбәп юк-югын, тик...

— Нәрсә «тик»?

— Инсаф Нуруллинга артык игътибарлы булуда безне гаепләмәсләрме, дим.

Янтимиров чак кына кычкырып көлеп җибәрмәде. Шулай да Солдатовка каты бәрелмәде, көлемсерәп кенә әйтеп куйды:

— Яртылаш балага узмыйлар, — диде ул, урта бармагы белән өстәлгә кага-кага. — Кемдер күпсенә икән, күпсенсен. Кулларыннан эш килмәүчеләр күпсенә дә, көнләшә дә. Инсаф Нуруллинга бүләкләр тапшырдык, мактадык, укырга керергә тели икән, без аны хупларга тиеш. Юлламасын әзерләсеннәр — кул куярмын. Укысын, белмәссең, аннан күренекле җитәкче дә чыгар... Юлламасын алганчы шушы заданиене үтәсен.

Башлык өстәл тартмасыннан кәгазьләр тартып чыгарды. Берәм-берәм ачып шуларны караштырды.

— Халыктан жалобалар күп керә, — диде ул, борчулы кыяфәттә. — Һәм урынлы жалобалар. Менә шушы машинаны йөртүче берничә тапкыр җәяүлеләр белән конфликтка кергән. Инсаф Нуруллин шуны контрольгә алсын әле.

Солдатов белә: димәк, монда башлыкның үзенә кагылышлы нидер бар. Нәрсә икәнен ачыклауның хаҗәте юк. Задание бирелде — аны үтәү — хезмәткәрләр бурычы. Инсаф Нуруллинга юллама бирү дә шушы конкрет заданиенең үтәлешенә бәйләнгән.

Полковник, әлбәттә, юкка гына бу «эшне» китереп чыгармады. Ул бик оста «планлаштырган». «Контрольгә» эләгәчәк машина кемнеке дисең?!

Район суды рәисе малаеныкы. Әле институтта гына укый ди. Үзен «бик иркен» тота икән. Берничә мәртәбә юл фаҗигасе китереп чыгара язган. Аны «житдирәк итеп» урынына утыртырга кирәк. Үзен генә түгел, әтисен дә... Судларның ни дәрәҗәдә «бәйсез һәм мөстәкыйль булуын» аңлатырга кирәк аңа. Югыйсә чамасыз кылана башлады. Бер судьяның отставкага китүенә инде берничә ай узды, ә аның урынына яна судья сайлау өчен конкурс игълан итмиләр. Әйтүләренә караганда, нindидер бер түрә улының судьялыкка имтихан тапшыруын көтәләр икән. Янтимировның улы да шушы урынга өметләнгән иде, стажы да житәрлек, имтиханнарын да тапшырды, ә менә конкурс игълан итмиләр. Димәк, «мөстәкыйль һәм бәйсез суд рәисе» аңа юл ачарга теләми. Малаенын арт ягына ут төртсән, әтисенең дә теле ачылыр. Янтимиров янына үзләре йөгереп килерләр. Инсаф Нуруллинга шушы «операция» йөкләнә.

Инсаф студент малайның эзенә бик тиз төште. Борыны кибеп тә бетмәгән килеш шундый машинада йөрсен инде. Юкка гына жалоба язмаганнар, һәм ул үзе кулга килеп керде. Иртән институтка соңга калган. Билгеле инде, мондый чакта күзгә ак-кара күренми. Светофорда кызыл ут януына да карамый чаба бу. Инспектор туктарга сигнал бирә — аңа да исе китми. Инсафка әмер килде: «Ак десятка» кызыл утка туктамады, безнен кисәтүгә дә буйсынмады, тоткарларга!»

Инсаф белән Нургаяз урам чатына килеп житкәнче үк аңа игътибар иттеләр. Аларны күреп, машина туктарга мәжбүр булды. Рульдә яшь кенә егет.

— Зинһар җибәрегез инде, институтка соңга калдым, — диде ул, ялварып. — Мин бит берниндди нарушение ясамадым. Менә документларым да тәртиптә. Тоткарламагыз инде...

— Ә теге урамда инспектор сигналына нигә буйсынмадыгыз?!

— Нинди инспектор?!

— Сезне туктатырга тырышкан инспектор. Кызыл утка туктамыйча китеп баргансыз бит.

— Машиналарны буташтыргандыр ул. Минем берниндди нарушение ясаганым юк.

— Бөтенесен ачыкламыйча без сезне машинага утырта алмыйбыз. Әллә нинди фаҗигаләр китереп чыгаруыгыз бар. Бирегез ачкычны! Ахырдан үзегез безгә рәхмәт әйтерсез.

Егет кесә телефоныннан шалтыратты. Әтисе сүзне озакка сузмады.

— Урыныңнан кузгалма, — диде ул. — Аларның житәкчеләре хәзер янгызга барып житәр...

Әмма малайны алып китмәделәр. Әтисе теге танышына да, бу танышына да шалтыратып карады, тик җаваплылыкны үз өстенә алучы табылмады. Янтимировның үзенә барырга мәжбүр булды.

— Ярты сәгать кенә вакытым бар, өлгерсәгез, килегез, — диде бүлек башлыгы. — Аннары безнең киңәшмә башлана.

Ярты сәгатьтә «эшне башкарып чыгу өчен» осталык бик кирәк. Бер генә артык сүзгә дә урын булмаска тиеш. Дөрес, судьялар болай да үлчәп сөйләргә өйрәнгән. Алардан артыгын тартып та ала алмыйсың. Әмма Шакир Шәйдуллин үзен цейтнотка эләккән шахматчыдай хис итте. Ашыгырга кирәк, кабаланып эшне бозып җибәрергә дә ярамый.

Янтимиров сөйләшүгә үзенчә әзерләнде. Студент малайга жәза бирү дә, аны «судан коры чыгару» да катлаулы түгел. Монысына бер сүз житә. Әле машинаны штраф мәйданына озатмаганнар, рәсми кәгазьләргә кермәгән, Инсаф Нуруллин күрсәтмә көтә. Хикмәт моның белән генә бетми. Төп мәсьәлә — Янтимировның үз малае, аны судья итеп сайлау. Суд рәисенең теле ачылырмы?..

Ике җитәкче дә үзенә ни кирәген белә, алар бәхәсләшеп берни дә хәл итә алмыйлар. Юл бер генә — йомышны әйтеп тормыйча ук аңлашу. Кешегә баш ни өчен бирелгән?! Һәм алар бик гади генә чишелеш тә таптылар.

— Көнгә берничәшәр «Эш» карарга туры килә, — диде суд рәисе. — Баш күтәрергә дә вакыт юк. Бер судьябыз отставкага киткән иде, ашыгыч рәвештә аның урынына конкурс игълан итәбез.

Янтимировның көткән сүзе шушы гына иде. Бары тик бер генә сүз! Димәк, аның малаена судьялыкка юл ачылачак... Ул үзе дә бурычлы калмады. Суд рәисенең студент малаена да «җил-яңгыр» тимәде...

* * *

Майор Солдатов хатлар һәм жалобалар белән эшләүнең хәзерге чорда никадәрле җаваплы булуын аңлата-аңлата Инсафка яңа эшләр тапшырды.

— Бусын аерым исәпкә ал, — диде ул, бер машинаның маркасын һәм номерын әйтә-әйтә. — Вак-төяккә бәйләнмә. «Машина йөртүчеләр миннән дә хәйләкәррәк» дип уйла, шул чагында беркайчан да оттырмассың.

— Әйе, әйе, — диде Инсаф. — Аларның һәркайсы үзенчә фикер йөртә, ә без бөтенесе өчен бер төрле уйлыйбыз. Шуңа күрә инде ул очы-очка ялганмаган эшләр дә килеп чыккалый.

Солдатов «игътибар итәргә» кушкан машина иясе төзелешне механикалаштыру фирмасының хуҗасы икән.

Майор йорт салу өчен җир алуга бәйле эшләрне матур гына очлап чыкты, инде фундамент урынын казытырга, тимер-бетон блоклардан нигез салырга, плитәләр җәеп «ноль» циклын «ябып куярга» кирәк. Бик тә мәшәкатьле һәм зур чыгымнар сорый торган эшләр. «Бераз булышса», фирма җитәкчесе хәлне җиңеләйтә ала. Аның фирмасы үзенеке — нинди эш өчен күпме аласын үзе билгели. Аны тикшереп тә аптыратмыйлар. Чама чамага туры килсә, бик яхшы. Солдатовның кирәкле кәгазьләре дә булыр, шактый арзанга төшереп эше дә эшләнер.

Инсаф белән Нургаязның тапкырлыгы моңа җитәргә тиеш. Машина иясен «йомшак ягын»нан эләктерергә кирәк. Шунысы да мәгълүм: ул бик каты чабарга ярата икән.

Идел буенда йорты бар, иртәнге яктамы-кичме, үкчәсенә басу әлләни кыен булмастыр.

Солдатов Инсафка шуны да искәртергә кирәк тапты:

— Юллама академиягә конкурссыз керергә ярдәм итсә дә, имтиханнарны барыбер тапшырырга кирәк. Ничек әзерләнәсең?

— Көн саен укыштырам инде. Вакыт бик аз кала шул.

— Азрак йокла. Тырышмыйча бернәрсәгә дә ирешеп булмый.

Солдатов белән сөйләшү Инсафта шундый фикер дә тудырды: эш мәсьәләсе хәл ителеп беткәнче Нургаязны үзләрендә тотарга мөмкин. Имтиханга әзерләнергә дә уңайлы булачак. Институт тулай торагында кача-поса яшәп маташмасын.

Шул көнне кичке якта Нургаязның мал-мөлкәтен күчереп тә куйдылар. Барысын да урнаштырып бетергәч, рус теле һәм әдәбияты программасын кабатларга керешкәннәр иде, Нургаязның кесә телефонына «җан инде».

— Бу мин...

— Таныйм, таныйм, җаным...

— Җаным, җаным, дисең дә...

— Гаеп миндә. Сиңа шалтырата алмадым. Бик тыгыз көн булды бүген.

— Бик катлаулы операция башкардыгызмы әллә?

— Катлаулынын да катлаулысы.

— Шундый ышаныч казандыңмени инде?!

— Мин түгел, Инсаф. Мин бүген аларга күчтем. Минем байлыкны әле ташып кына бетердек. Төпләп эшкә урнашканчы анарда торачакмын.

— Бусы да яхшы булган. Хәзер шуны «юасызмы» әллә?

— Кызганычка каршы, юк. Инсаф милиция академиясенә укырга керергә җыена. Идарә юлламасы белән. Бергәләп имтиханнарга әзерләнәбез.

— Менә монысы бигрәк тә яхшы, сезгә уңышлар телим. Мине оныттыңмы әллә, дип үпкәләргә исәбем бар иде, болай булгач, «гаебенне» кичерәм инде. Монда бер яңалык булырга тора, иртәгә шалтырат.

— Нинди яңалык?

— Иртәгә әйтермен. Сездә генә түгел, бездә дә яңалыклар күп ул... Имтиханга әзерләнү никадәр җаваплы булмасын, егетләрнең зиһене таралып китте. Бик тырышсалар да, программадагы сораулар башка кермәде. Нураниянең «бездә дә яңалыклар күп» дип әйтүе шактый ук аптырашта калдырды аларны.

— Солтания турында бер сүз дә әйтмәдеме? — диде Инсаф. — Без бит районга барырга сөйләшкән идек.

— Хәзер кая инде районга бару, имтиханнар борын төбендә, — дип Нургаяз сүзне очламакчы булды. — Имтиханнар тапшыргач, иркенләп барырбыз. Эш беткәч уйнарга ярый.

— Мин дә шулай уйлыйм. Хәзер барып эшне генә бозарбыз...

* * *

Инсафның әбисе дә, бабасы да олы яшьтә. Кәефләре көнгә кырыкка төрләнә. Әле бер җирләре, әле икенче җирләре авырта, бигрәк тә баш сызлау белән интегәләр. Ярый күршедә генә участок табибәсе Зөлхәбирә яши. «Хәлләрегез ничек?» дип җае булган саен кереп чыга, киңәшләрен бирә, кирәкле даруларын да юнәтә. Зөлхәбирә утызга җитеп килүче кыз. Әтисе белән әнисе юл-транспорт фаҗигасендә икесе берьюлы һәлак булды. Өч бүлмәле фатирда бер ялгызы яши. «Да, кыз да утызда» дип юкка гына хафаланмыйлар, Зөлхәбирә өчен кайгыручы кеше юк-югын, әмма үзе нинди чиккә җитүен бик яхшы белә, күңелендә кимсенү көннән-көн көчәя. Бу турыда сүз чыкса, «хәзер рәтле ирләр бармыни!» дип кул гына селтәгән була, бәгыре телгәләнсә дә, сер бирми. Мондый кызга бөтен яктан да килгән егет табуы да җиңел түгел. Яшьтәшләре инде башлы-күзле, яшьрәкләр белән бәйләнү хәвефле, хатыны куып чыгарганнардан ерак йөрүең яхшырак. Зөлхәбирәнең фатир да бар, хезмәт хакларын да күтәрделәр, рәхәтләнеп яшисе генә. Аның кисеп ташлаган тырнагына да тормаган кызлар табышкан да, кавышкан да, ирләре дә ир төсле, гөрләтеп яшиләр, ә чибәр Зөлхәбирәнең, уңган Зөлхәбирәнең, эше дә, фатиры да булган Зөлхәбирәнең иркәләнердәй, таянырдай кешесе юк.

Әби белән бабайны карарга кергәндә ул Инсафка да күз төшергәли. Бер дигән ир-егет. Шулай да нидер җитеп бетми. Бөтен нәрсәсе үз урынында, тик аңа Ходай кодрәт бирмәгәнме, ул артык гади күренә. Бар бит инде, эш атлары бар, сабан туе чабышкылары бар, алар күрер күзгә үк бер-берсеннән аерыла. Инсаф шул эш атын хәтерләтә, аны ефәккә төрсән дә, министр итсәң дә, «үз тиресеннән» чыга алмаячак. Зөлхәбирәнең зәвыгы башкарак...

Ул, гадәттәгечә, әби белән бабайның йөрәкләрен тыңлап карарга кергән иде, Инсаф белән янәшә утыручы егетне күреп, телсез калды. Спорт киеме аның тәненә шулкадәр килешеп тора ки, борынгы Алыплар нәселеннән, диярсең. Гадәттә бер сүзеңә биш җавап табучы Зөлхәбирә нишләрен белмичә ык-мык килде. Ниһаять, үзен кулга алды.

— Кунак егетегез дә бар икән, — диде ул, унайсыз хәлдән чыгарга тырышып.

— Ул кунак түгел, ә минем сабакташ дустым, — диде Инсаф, — исеме Нургаяз.

— Исеме дә бик матур икән, таныш булыйк. Мин Зөлхәбирә, күрше фатирдан.

Табибәнең егетләр янында озаграк тоткарлануын карт белән карчык та сизенгән иде, бүлмә ишеген ачып, сәлам бирделәр.

— Тавышыңны ишетүгә үк җаннарыбыз рәхәтләнеп китә, — дигән булды әби карчык.

Зөлхәбирә алар бүлмәсенә үткәндә дә борылып Нургаязга карап алды. Су белән мөлдерәмә тулы чиләкне ничек кенә саклап алып барма, чайпала инде ул, чайпала...

Картларны тынычландыра белү — иң көчле дару. Зөлхәбирә бу яктан осталарның остасыдыр.

— Эчем кибеп китте, икенче көн инде олы хаҗәтемне үти алмыйм, — дип зарланып алды әби карчык

Табибә олы яшьтәгеләрдән мондый сүзләрне еш ишеткәли, күп тапкырлар биргән киңәшләрен тагын кабатлады:

— Кишер, алма уып ашарга кирәк, — диде ул.. — Һавага да чыккалагыз, йөрү-хәрәкәтләнү бик файдалы. Даруга иярләшергә тырышмагыз. Икегезнең дә йөрәкләрегез тәртиптә, ашауны гел төрләндереп торырга кирәк. Олы яшьтә бик мөһим бу.

— Ашны төрләндереп тору өчен әзерләргә кирәк, көч җитми шул хәзер, көч җитми, — диде әби. — Инсаф өйләнсә, җиңелрәк булыр иде дә бит, һаман насыйбы туры килми торгандыр...

— Теләге туса, насыйбы табыла, — диде Зөлхәбирә. — Бөтен хикмәт теләктә, бөтен хикмәт йөрәктә...

— Эше дә бик тынгысыз, укырга да керергә йөри, — диде карт. — Кызларга вакыты да калмыйдыр инде. Без артык кысмыйбыз. Тәүфыйгы булса, җайланыр, Алла боерса...

Карт белән карчык табибәгә мең-мең рәхмәтләр укып калды, ниндидер көч тарттымы — чыгышлый Зөлхәбирә тагын егетләр янында тоткарланды.

— Шундый сабакташың булуын да әйтмәдең, — диде ул, Инсафка үпкәләгән сыман. Тегесе турыдан-туры ярып салды:

— Үземнең дә биш ел күргәнем юк иде әле аны, унынчыны тәмамлагач, юллар аерылды да китте, — диде Инсаф. — Ул институтка керде, мин ГАИга урнаштым, сабантуйларда да очрашырга туры килмәде.

— Сез әллә «Жди меня» аркылы табыштыгызмы? — дип шаяртты Зөлхәбирә.

— Аңа ук барып җитмәдек, — диде Инсаф, көлемсерәп. Зөлхәбирә «күз угын» гына түгел, «тел угын» да Нургаязга юнәлдерде.

— Кунак егет бик тыйнак, ахрысы, сүзгә кушылырга да кыймый, — диде ул, мутлануын яшереп тә тормыйча. — Әллә бик гордыймы?! Институт бетергән вакытта бөтен егетләр дә шундыйрак була. Бөтенесе даһи, бөтенесе матур, бөтенесе таулар күчерергә әзер. Бераздан тузаннары басыла... Тормыш һәркайсының күзен ача... Телем тик тормаганга сез тагын миңа үпкәли күрмәгез...

Нургаязга җавапсыз калырга ярамый иде.

— Мин сездән күземне ала алмыйм, минем әнигә бик охшагансыз, — диде ул, Зөлхәбирәнең уенын дәвам иттерергә теләгәндәй. — Койган да куйган инде.

Егетләр мондый «дипломатиядән» еш файдалана. Үзенә ошаган кыз

белән сүз башлар өчен дә ярап куя ул. Бик кадерле кешенне генә әнием белән чагыштырырга мөмкин ич. Зөлхәбирәгә монарчы болай дип әйтүче булганмы-юкмы, Нургаязның сүзләре аның йөрәгенә сары май булып ятты.

— Әле шулай укмыни?! — диде ул, айның унбишенче кичендәге кебек балкып. — Мин тагын «Бу егет телен йотканмы әллә?» — дип пошаманга төшкән идем, болай булгач, тынычландым, хәзер чыгып китсәм дә ярый. Хушыгыз! Тыныч йокы!

Ишек ачканда Зөлхәбирә янә бер кат егетләргә таба борылып уң кулын изәп алды. «Тыныч йокы!»

Инсаф урыныннан торып ишекне бикләде, монарчы ул Зөлхәбирәнең керүенә артык игътибар да итми иде, керә — әбисе белән бабасының зарларын тыңлый, йөрәк тибешләрен тыңлый, тегене-моны эчәргә куша. Инсафка нинди дарулар алып кайтырга икәнен әйтеп калдыра. Табибәне ул «әйбәт күрше» санаудан узмый иде. Бүген Зөлхәбирә хатын-кыз буларак та ачылып китте. Моның сәбәпчесе — Нургаяз иде. Һәм бу Инсафны бик нык борчуга салды. Хәер, ул бәргәләнгәннән ни файда. Нургаяз яшь-жилкенчәк малай түгел. Институтта да аңа «күз атучылар да, сүз атучылар да» аз булгандырмы?! Нураниясен биздермәгән бит әле. Зөлхәбирәне дә бик якын җибәрмәс.Үзенең күңелендә булмаса, берәүне дә «аздырып» булмый.

Нургаязның моңа исе дә китмәде. Үзенә кемдер күзен тутырып караган саен эреп китә башласаң, дөньяда яшәрлегең дә калмас. Матур кызларга гына түгел, чибәр егетләргә дә тәүфигыңны саклау бик авыр ул. Нургаязга да еш кына «каршылык күрсәтергә» туры килә.

Ул Ташлыярдан нефть төбәгенә күчкән театрда диплом спектакле куйды. Килү белән директор бик нык кисәтте:

— Хатын-кызлар белән уйнасаң, спектаклең барып чыкмаячак. Дипломсыз калуың да бар. Мин моны юкка гына әйтмим. Чибәр булу бәхет кенә түгел, ә гомерлек сынау да ул. Син инде аларга бик каты да бәрелмә, бик якын да җибәрмә. Шул чагында яхшы да булырсың, эшең дә барыр.

Директорны аңларга була. Театрга читтән режиссерлар китереп спектакльләр кую гадәткә кергән инде ул. Яңа фикер, яңача караш. Гел үз казанында гына кайнап булмый. Кайберәүләр хатын-кызлар белән чуалып директорга өстәмә мәшәкатьләр тудыра, шуларны көйли-көйли җан чыга. Диплом спектакле куярга килгән егетнең дә башын әйләндерергә теләүчеләр табылыр, димәк, баштан ук кисәтеп кую мәслихәт.

Нургаяз сүзне кыска тотты:

— Борчылмагыз, сезне уңайсыз хәлдә калдырмам, — диде ул.

— Ышанам, ышанам, — дип кабатлады директор. — Кисәтүем өчен миңа үпкәләмә, яхшы укыгансың, диплом эшең дә сүз килерлек булмасын, дип кайгыртам мин.

Ә шулай да Нургаяз бөтенләй котелмәгәнчә «яңа» язды. Урта яшьләрдәге бер артист аны кунакка чакырды. Күпме кыстасалар да, Нургаяз онытылып эчмәде. Хуҗа үзе бер тотынгач, туктый белми икән. Гадәттә хатыннар ирләрен тыеп калырга тырыша, ә моныкы үзе кыстый-кыстый эчертте. Хуҗаны күтәреп урынга салдылар, чишендереп яткырдылар. Ул шунда ук әллә нинди тавышлар чыгарып гырылдый башлады. Хатын кунакны икенче бүлмәгә чакырды.

— Курыкма, трактор белән тарттырсаң да, уянасы юк, — диде ул, егетне тынычландырырга теләгәндәй. — Кая ашыгасың, өеңдә көтеп тормыйлар ич.

— Сыегыз өчен бик зур рәхмәт, бик зур рәхмәт! — дип Нургаяз ишекне ачты. — Сыегыз өчен бик зур рәхмәт!

Менә шулай «диплом спектакле» башланды. Бик гыйбрәтле сабак булды

бу Нургаязга, спектакль сәхнәгә менгәнче «контроль уты» сүнмәде. Чибәр егет каршылыгына очраган ханым да үпкә сакламады. Бу серне гүргә тапшыргандай иттеләр.

* * *

Инсафның да, Нургаязның да ишеткәне бар: теләккә килгән чакларында пошыйлар үзләренең нишләгәннәрен белеп тә бетермиләр икән. Зур юллар аркылы да әрле-бирле чыгып йөриләр. Шуңа урман юлларында махсус билгеләр бар, алар машина йөртүчеләрне кисәтәләр, артык кумаска, карап кына барырга өндиләр. Тик... «тик» дияргә генә кала. Шушы таләпне санга сукмаучылар бихисап. Иртәгә дөнья бетәсе кебек каядыр ашыгалар, чабалар, үзләренең тормышларын да, башкаларныкын да куркыныч астына куялар. Табигатькә дә зыян китерәләр.

Төзелешне механикалаштыру фирмасы җитәкчесе дә нәкъ менә шушы гөнаһысы өстендә тотылды. Баганадагы билгегә исе дә китмичә урман юлыннан «Мерседес»та оча бу. Инсафның тукталырга сигнал бирүенә дә игътибар итмәде. Ләкин ерак китә алмады.

Кара күзлеген киеп машинасыннан чыкты да:

— Мин бит махсус рәвештә иртүк кузгалам, юлда кеше юк, беркемгә куркыныч тудырмыйм, сез нәрсәгә бәйләнәсез инде?! — диде эре генә. - Штраф түләтәсегез килсә, рәхим итегез! — дип куен кесәсенә үк тыгыла башлады. — Күпме кирәк?!

Инсаф белән Нургаяз беренче тапкыр гына мондый «һавалы затны» эләктермиләр, боргаланырга урын калдырмадылар.

— Сезгә бүлеккә барырга кирәк булыр, — диде Инсаф. — «Тизлек яратуыгыз» турында гражданнардан жалобалар керде. Димәк, ничек чабуыгызны күрәләр дә, борчылалар да икән. Без аларның хаклыгын тикшерергә булдык. Нәтиҗәсен үзегез дә күреп торасыз. Монда хикмәт беркетмә төзүдә генә түгел, хат иясенә җавап бирергә кирәк. Бүген үк вакыт табыгыз, бүлеккә барыгыз, хат майор Солдатовта.

Фирма җитәкчесе авызын кыйшайтып елмаерга мәҗбүр булды. Юк, монда «күз кысу», документлар арасына доллар кыстыру белән генә эш барып чыкмаячак.

— Барысын да сез кушканча эшләрбез, — диде ул. — Барысы да закон кушканча булыр. Хат кемдә дидегез әле, ә.... ә... Солдатовта, мин бит юл-транспорт фаҗигасе китереп чыгармадым, бүген үк янына барам. Аңлашырбыз...

— Юлда иминлек барыбызга да бер дәрәҗәдә кирәк, — дип Инсаф сүзгә нокта куйды.

Көне буе шәһәр яны юлларында йөреп, арып-талып Инсаф белән Нургаяз өйгә кайтып егылдылар.

— Тәмам эт булдык, койрык кына тагасы калды, — диде Нургаяз, шаярткан булып. — Җиңел икмәк түгел бу. Һич тә җиңел түгел.

— Җиңел булса, акчасы күп булса, синең белән миңа тәтемәс тә иде ул, — диде Инсаф. — Безнең әти-әниләр дә хезмәт белән көн күргәннәр, безне дә авырлыклардан курыкмаска өйрәткәннәр. Әтинең «Эшләп кеше үлми» дигән сүзләрне әйтмәгән көне дә булмагандыр. Мин аңа үпкәләмим. Без үз көнебезне үзебез күрергә өйрәнгән.

— Безнең башка юлыбыз да юк, — диде Нургаяз. — Ышанырлык, арттан этеп йөртерлек кешеләребез юк бит.

— Үзең эшләп тапкан тәмлерәк, кадерлерәк була ул. Әтиләре алып биргән машиналарда чабучы малай-шалайлар, курчак кебек кызлардан көнләшмим мин.

— Карале, онытылып киткәнмен, мин бит Нураниягә шалтыратырга тиеш. Нindidер яңалык әйтмәкче иде, — диде Нургаяз.

Бу «яңалыкны» Инсаф та көтә иде. Теге шәфкать туташы булып эшләүче Солтания аның башыннан чыкмый. Нурания берәр хәбәр житкерми микән?

Нургаяз кесә телефонын кулына алып Нурания яшәгән районга «барып житте». Икесенә дә таныш тавыш ишетелде.

— Кичә биргән вәгъдәнне үтә, — диде Нургаяз.

— Нинди вәгъдә?!

— Кичәге вәгъдәнне бүген оныткач, нәрсә була инде ул, жаным?!

— Әй, артык дулкынланып киттем, ахрысы, тавышыңны ишетүгә каушый башлыйм, нинди вәгъдә биргән идем соң әле?

— Алай булгач, үзем үбәм инде, ачуланмыйсыңмы? Килештерә дә беләсең инде үзең. Мин дә бурычлы калмыйм.

— Нindidер яңалык булырга тора, дигән идең, нәрсә соң ул?

— Безнең районга командировкага киләбез, дигән идегез, әллә барып чыкмыйммы? Әллә Инсаф оныттымы?

— Юк, юк, онытмадым, — дип Инсаф сүзгә кушылды. — Монда бик ашыгыч заданиеләр үтәдек. Академиягә укырга керергә йөрим. Укырга керүемнең икенче көнендә үк сезнең районга китәчәкбез.

— Соңардыгыз шул! — диде Нурания. — Соңардыгыз, егетләр!

— Ничек?!

— Без үзебез калага барабыз. Әни белән Солтания медицина академиясендә белемнәрен күтәрәчәкләр. Ә мине фәнни-практик конференциягә чакыралар.

— Үзегез монда киләсезме?!

— Үзебез шул, үзебез.

— Сезне табып булырмы соң? — дип Инсаф хәлгә ачыклык кертергә тырышты.

— Анысы үзегездән тора инде, Инсаф! Үзегездән тора!

Нургаяз белән Инсафны бөтенләй яңа мәшәкатьләр бөтереп алды. Фатирларында да «генераль җыештыру» үткәрергә кирәк. Хатын-кызларны белмәссең, ничек яшәүләрен күреп чыгарга да теләрләр. Килсәләр, егетләрдән өмет өзеп китмәсеннәр. Нураниянең әнкәсе бер карау белән нәтиҗә ясар...

* * *

Майор Солдатов та «үз мәсьәләләрен» чишәргә маташа. Фирма башлыгы аны бик тиз эзләп тапты. Очрашу вакытын билгеләделәр. «Үз эшләрен яхшы белгән» кешеләр бәхәсләшмиләр, бер-берсен алдарга да тырышмыйлар. Аларның һәр сүзе үлчәү тәлинкәсенә салынган алтын сыман. Тәлинкәләр чайкала башласа, эш катлауланырга мөмкин. Ике як та үзләрендә ни барлыгын, үзләренә ни кирәген белеп эш йөртә.

Фирма башлыгы үзе турында язылганнар белән танышып чыккач та кызып китмәде. Тизлекне арттыруның никадәр хәвефле булуын ЮХИДИ хезмәткәрләреннән ким аңламый икән. Пошыйга килеп бәрелгән җитәкчене дә телгә алды. Бу участокта контрольне көчәйтеп дөрес эшләгәнсез, дип тә җибәрде. Солдатов машиналарның техник хәле турындагы мәгълүматларын да бик оста китереп бәйләде. Төзелешне механикалаштыру фирмасында аларның нindиләре генә юк. Әледән-әле шәһәр буйлап йөрергә туры килә. Алар белән бигрәк тә саклык сорала.

Бер мизгелгә икесе дә тынып калды. Елганың бер ярыннан икенчесенә чыгарга кирәк иде. Сүз төзелешләргә күчеп китте.

— Сездә дә андый мәшәкатьләр бардыр, — диде фирма башлыгы. — Хәзер ата ялкау гына төзелеш белән шөгыльләнми. Кирәге чыкса, булыша алабыз. Сезгә бәяләрне «өстәмәләрсез» генә исәпләрбез. Аерма шактый зур анда...

Алар закон бозуга исәп тотып сөйләшмәделәр, киресенчә, закон бозмыйча — бәяләргә «өстәмәләр» кушмыйча эш алып барырга килештеләр. Бу вариант икесен дә канәгатьләндерә иде. Фирманың тимер-бетон заводы белән дә килешүе бар икән, плитәләр, нигезлек блоклар да эзләп йөрисе булмый. Бу җәйдә күп эшләр эшләнеп калырга мөмкин...

Фирма башлыгы визит карточкасын да биреп калдырды, кирәк чагында «рәхим итегез» дигән ишарә иде бу. «Фәрхетдинов Фәһим Фатыйх улы» дип эре-эре хәрефләр белән язылган иде анда...

Икенче көнне майор Солдатов Инсафны үз бүлмәсенә чакыртты. Егет бераз шүрләп тә куйды. ЮХИДИ хезмәткәрләренең үзләренә дә бәйләнергә генә торалар. «Берәр ярамаган нәрсә килеп чыкмагандыр ич?» — дип Нургаяз белән дә киңәшеп карады. Алай борчылырлык сәбәп тапмадылар.

Эштән соң Инсаф Солдатов янына китте, Нургаяз өй мәшәкатьләре белән мәшгуль булып калды. Эшли-эшли кызып киттеме — идәнне дә юып чыгарырга булды. Чиләккә су салып чүпрәкләрен җәйләп кына куйган иде, ишек шакыдылар. Әби белән бабай танып та алды.

— Ул безнең күрше Зөлхәбирә, ачып керт, балам, — диде бабай, идән юарга җыенып йөрүче Нургаязга. Үзебезнең кеше, уңайсызланма, бер эшнең дә ояты юк. Яшьрәк чагы булса, әбиегез сезгә идән юдырып тормас иде дә, картайдык шул, дәрман бетте.

Нургаяз кулларын сөртеп ишекне ачты.

— Әллә кертергә дә теләмисең инде?! — дип төрттерде Зөлхәбирә. — Мине болай көттермиләр иде.

— Мин сезнең шакуыгызны танымыйм шул әле, белештереп бетермәдем, ачулансагыз да, бик каты ачуланмагыз инде, — дип Нургаяз барысын да уенга борды. — Моннан соң аяк тавышыгызны ишетү белән йөгереп килеп ишек ачармын.

Шаяртуны Зөлхәбирә дә куәтләп җибәрде.

— Үз гаебен таный белгән егетләр белән сөйләшүе дә күңелле, — диде ул, күрешергә кулларын сузып. Бусы белән ул Нургаязны кабат сынау алдына куйды.

— Сезнең белән күрешер өчен башта кулларымны юып килим әле, — дип Нургаяз кире киткән булды. — Сез түргә уза торыгыз.

Зөлхәбирә су салынган чиләкне дә, чүпрәкне дә күрмәмешкә салышты. Ул арада Нургаяз ванна бүлмәсеннән чыкты. Зөлхәбирә белән күрешмәкче иде, тегесе бабай белән әби янына кереп киткән иде инде.

— Кулларымны юуым әрәмгә булды, күршем белән күрешеп тә өлгерә алмадым, — диде ул үзалдына, Зөлхәбирә дә ишетерлек итеп.

Табибә әби белән бабайны караштырды да, тагын Нургаяз янына чыкты. Бик серле итеп карап торды да:

— Идән юып бетергәч, миңа кереп чык әле, — диде ул.

— Әле тиз генә бетмәс шул. Мин бит идән юу өлкәсендә өйрәнчек кенә.

— Биючегә сүз әйтмәгез, бии-бии остара, диләр. Курыкма, син дә өйрәнерсең, егеткәй — дип Зөлхәбирә сүзне куертты. — Бетергәч керерсең. Мин көтәргә өйрәнгән.

— Йомышыгызны хәзер үк әйтегез, — диде Нургаяз.

— Монда гына аңлата алмам шул.

— Нинди йомыш икән соң ул?

— Синең өчен, бәли, чепуха гынадыр, минем өчен бик мөһим..

— Шулай да әйтеп карагыз әле.

— Бик яраткан табамның капкачы кулдан төшеп китте, тоткычы сынды, шуны рәтләп бирмәссең микән дим.

Нургаяз белә ул табаның ни икәнен. Ялтыравыклы чит ил табасы ул. Капкачы утка чыдамлы пыяладан. Өйләрендә дә шундый таба белән бик озак маташты. Зөлхәбирә дә аны азапламакчы икән әле.

— Сез ул табагызны монда алып керегез, — диде Нургаяз. — Идәнне юып

чыгару белән юынып алырмын да табага тотынырмын. Бабайның инструментлары да бардыр.

Әллә юри, әллә чынлап, Зөлхәбирә:

— Бабайның инструментлары!!! — дип гаҗәпләнгән булды. Үзенең күзе Нургаязга текәлгән.

— Алар гомер иткән инде, булмый калмас, — дип Нургаяз, хәлне җинеләйтеп җибәрде. — Беләм мин ул табаны, бик катлаулы эш ул, аңа әллә нихәтле корал кирәк.

Зөлхәбирә егетне кызган табага бастырмакчы иде, барып чыкмады, эчтән генә уйлап куйды: «Бу кадәр оста кыланырга моны кем өйрәтте икән? Юкка гына режиссерлыкка укып йөрмәгән...»

Фатирына чыккач, Зөлхәбирә үзе дә сизмәстән көзге каршысына килеп басты. Күрче, бу муллыкны, дигән шикелле үзенә-үзе сокланып карап торды, Кулмәгенең өске сәдәфләрен ычкындырып, хозурланып хыялга бирелде. Юк, килмәгән җире юк. Теләсә кайсы ирне иркәләрлек, шаштырырлык муллык бит. Мул да, килешле дә. Бу Нургаязның күзенә көл сипмәгәннәрдер бит. Керфеге дә селкенми, ичмасам. Теленә дә шайтан төкергәнмени... Зөлхәбирә егетләр белән «уйнарга» ярата. Бәлки, шуның белән аларны биздерәдер дә. Әйбәт-әйбәтләре очраганы бар, әмма «олы максатка» житә алмыйлар, аралар суына. Зөлхәбирә каршында эреп төшәргә тиешле Нургаяз «уйнарга» да ирек бирми. Читкә дә какмый, якын да җибәрми.

* * *

Инсаф майор Солдатов бүлмәсенә сагаеп кына керсә дә, бик тиз үзен-үзе кулга алды. Нәчәлникнең урыныннан торып кул биргә үк бернинди куркыныч юклыгын сиздерде,

— Әйдә, утыр, — диде Солдатов. — Миңа билгеле булганча, эшләрегезгә тел-теш тидерерлек түгел. Имтиханнарга әзерлек ничек бара?

— Көн саен төн урталарына кадәр шөгыльләнәбез. Нургаяз бик булыша.

— Бусы бик әйбәт. Форсаттан файдаланып кал инде син...

Инсафка:

— Ярар, тырышырбыз, — дип әйтергә генә калды. Чыннан да сыбызгы сызгыртып йөреп кенә әллә ни ерак китеп булмас. Майор хаклы, мең кат хаклы.

Егет шуны да шәйләде: Солдатов аларның хезмәтен хуплый. Югыйсә үз итеп сөйләшер идемени...

Фатирга кайтып чишенергә дә өлгермәде, ишек төбенә үк килеп Нургаяз сорашырга тотынды:

— Каты бәрелмәдеме?

— Киресенчә, бик үз итеп сөйләште. Икәүләп балалар бакчаларында, мәктәпләрдә юл иминлеге тәрбиясе алып барырсыз, ди. Синең режиссер булуыңны файдаланмакчылар.

— Бусы куркыныч түгел, үзебезгә дә файдалы булыр. Балалар каршына

бару өчен даими укырга кирәк, күп укысаң, күп беләсең, — диде Нургаяз, мәсьәләне хәл итеп бетергәндәй. Бу — безгә ышаныч, безнең киләчәк турында кайгырту.

Инсаф бусагадан атлау белән фатирдагы һаваның үзгәрүен тойган иде. Бөтен бүлмәләр ялт иткән.

— Синең мондый осталыкларың да бар икән, — диде ул, Нургаязга рәхмәтен белдергәндәй.

— Үзебез өчен бит, — диде Нургаяз. — Безнең әти дә, әни дә тәртип ярата, безне дә шуңа өйрәттеләр. Моның өчен әлләни талант та кирәкми. Матур хәбәр алып кайттың, моны яхшыга юрыйк без. Килер бер көн— Солдатовка рәхмәт әйтербез әле. Эш таләп иткән, эшкә өйрәткән кеше яхшы кеше ул. Алар кичке ашка утырмакчылар иде, ишек шакыдылар. Икесе дә танып алды — Зөлхәбирә бу. «Ачыйкмы?» дигән шикелле Нургаяз Инсафка төбәлде. «Ничек инде ачмыйсың!» дип Инсаф ишеккә таба атлады.

— Син дә кайтып җиттеңмени? — диде Зөлхәбирә, керә-керешкә үк. Кулында таба капкачы. — Нургаяз тоткасын төзәтеп бирмәкче иде.

— Мактап йөрисез, — дип Нургаяз, сүзне озайтырга ирек бирмәде. — Әйдә, утырыгыз.

— Сезне ничек инде яманлыйсың! — дип Зөлхәбирә дә мутланып алды. — Мондый егетләрне яманласаң, телең корыр.

— Әйдәгез, түргә узыгыз, — дип Инсаф ныклап кыстарга тотынды.

— Мин режим белән генә ашыйм, артыгы ярамый, фигура бозылмасын дим. Хәзерге егетләргә әле болай да ярап бетеп булмый.

— Әллә сезне яратмаучылар да бармы? — дип утка май өстәде Нургаяз. — Булмас, күзе сукырлар да сезнең чибәрлекне күрәдер..

Зөлхәбирәне тагын кыстап маташтылар. Әмма ул борчуы өчен гафу үтенә-үтенә таба капкачын сузды.

— Шуның тоткасын рәтләп бирсәгез, үзегезгә мең-мең рәхмәт әйтермен. Бер рәхмәт мең бәладән коткара, диләр.

Бу уенның нәрсә белән бетәсен көткән кебек Инсаф сүзгә кушылмауны яхшырак күрде.

— Бабайның инструментлары да бар икән, иртәгә әзер булыр, — диде Нургаяз. — Алай бик яраткан табагыз да булгач, тырышмыйча ярамас. Күрше хакы— тәңре хакы.

Ул чыгып киткәч, Инсаф эчен уа-уа көләргә тотынды.

— Авыртмаган башка тимер тарак кына түгел, тимер таба да була икән, — диде ул, күзләрен сөртә-сөртә. — Каян уйлап чыгарган моны?! «Зөлхәбирә-Нургаяз» спектакле туа мәллә? Чит ил әйберләре ремонтлауга исәпләнмәгән ул. Ватыла икән, аларны чыгарып ташлыйлар. Без шул һаман ярлы-фәкыйрь психологиясеннән чыга алмыйбыз. Безнең киемнәр дә, савыт-саба да гомерлек булырга тиеш. «Ярлы кеше яманыр да куаныр» дип тә юкка гына әйтмәгәннәр. Ә син моңа тотка куя аласыңмы соң? Ясап бирсәң дә, рәхәтләнеп көләчәк әле ул синнән...

— Ә мин көләрлек итмим. Өйдә дә эшләп куйдым мин аны. Әни ничек шатланырга белмәде. Бик яхшы таба ул. Ризык анда шулкадәр тәмле пешә, көйми дә.

— Ясый белгәч, ясыйсың инде. Кара аны, бу таба башыңа төшмәсен. Зөлхәбирә бер ияләштерсә, бирер кирәгенне...

— Кайгырма, дус, шаяру — кешене яклаучы иң көчле корал ул. Хуҗа Насретдиннәр юкка гына тумаган.

— Әйттем исә кайттым, — диде Инсаф. — Әйдә, аш та суынадыр.

Гадәттә кичке аштан соң имтиханнарга әзерләнәләр иде, бүген Нургаяз көн тәртибен үзгәртте.

Бабайның эш кораллары тартмасында ниләр генә юк икән. Нургаяз кыскыч белән металл кискеч пычкыны алып эшкә керешге. Өйләрендә бер эшләгәнгә күрә, таба капкачы белән әллә ни озак маташмады да. Шөрепне кисеп алгач, яна тотка куюы авыр түгел иде.

— Хәзер дәрескә тотынабыз, — диде Нургаяз. — Бүгенге планны бүген үтәргә тиешбез.

Инсафның язу ягы йомшак. Бигрәк тә өтерләр куярга оныта. Язганнарының очына барып чыгу өчен берничә тапкыр укырга кирәк. Нургаяз күптән телдә йөргән бер мәзәкне искә төшерә. «Өйләнергә мөмкин түгел онытырга» дип язып куя.

— Менә шушы сүзләрнең мәгънәләрен аңлатып бирә алсаң, өтернең нинди көчкә ия булуын да төшенерсең, — ди, астыртын гына елмаеп. — Бу — классик мисал...

Инсаф монда ниндидер «этлек» яшеренгәнен чамалый, әмма шартлатып кына әйтеп бирә алмый.

— Бүген күпме утырсак та утырырбыз, син моның хикмәтен үзең табарга тиеш. Тапмыйча йокларга да ятмыйсың, — диде Нургаяз. — Сине шулай өйрәтмичә булмый.

Инсаф дустының яхшылык теләвен белә, шуңа күрә, «укытучының кырыслыгын» балаларча инану белән кабул итә.

— Ярар, йокламасам, йокламам — барыбер серен ачам, — ди ул. — Үзең дә йокламыйсыңмы?

— Йокламыйм, билгеле.

— Сине дә, үземне дә азапларга теләмим, таптым мин моның серен, — ди Инсаф, очардай булып.

— Йә, ничек?

— Менә укы, хөрмәтле Нургаяз! — дип Инсаф язган кәгазен суза. «Өйләнергә, мөмкин түгел онытырга.» «Өйләнергә мөмкин түгел, онытырга!» — Ничек?! Йокларга рөхсәт итәсеңме?!

— Ерып чыктың. Рөхсәт бирмичә дә булмас, — ди Нургаяз көлеп. — Безгә тормышта да вариантлар сайларга туры килер әле. Анда хаталар китмәсен иде. Тәмле йокы!

Шулай да егетләргә тиз генә йоклап китү насыйп булмады. Нургаязның кесә телефоны аваз салды. Нурания икәне әллә каян сизелеп тора.

— Контроль! — дигән тавыш ишетелде. Шундук көлү тавышы яңгырап китте.

— Контроль тынычлана ала, — дип җавап кайтарды Нургаяз. — Икебез дә урында.

— Бик яхшы! Ышанычны аклыйсыз. Азып-тузып йөрмичә вакытында өегезгә кайткансыз. Болай булгач, җитдирәк сөйләшергә дә була.

Нургаяз, безнең эшләр катлауланып китте бит әле. Әни синең турыда сүз чыгарган иде, әти дә безнең белән бармакчы булды. Безне машина белән китермәкче. Сине күрергә тели ул. «Кызымның нинди егет белән аралашуын үз күзем белән күрмичә тынычлана алмыйм», ди. Ничек килеп чыгар икән бу? Әллә «командировкага киткән» дип аңлатыйммы? Әти дә белгәч, үзебезне бик кырыс кысага кертәбез бит...

— Күрергә теләгәч, килсен, аннан качып кала алмыйбыз. Мин үзем моны хәерлегә юрыйм. Күрсен дә, әйтәсе сүзен әйтсен дә. Соныннан үпкәләшеп йөргәнче болай яхшырак, — диде Нургаяз, шик-шөбһәгә урын калдырмыйча. — Кайчан киләсез?

— Ике көннән, чәршәмбедә. Пәнҗешәмбедә фәнни-практик конференция. Нәкъ минем диплом темасы буенча. Җомгада сәгать көндезге икедә Яңа мәчетне карарга барабыз.

— Шундый матур хәбәрләрең өчен үбәм үзеңне. Әти-әниеңне күрү минем өчен дә күңелле.

— Инсафка сәлам әйт.

— Солтаниянең үзенә аның хакында әйткәнең бармы?

— Юк. Мин Инсафка әйттем, шул җиткән, калганы алар эше.

— Инсаф та сиңа сәлам әйтә.

Нургаяз телефоннан бик батыр сөйләшсә дә, егетләр пошаманга төште. Нураниянең әтисе килүен алар төрлечә юрап карады. Аның кызы өчен борчылуы аңлашыла. Әфган сугышында катнашып, бик авыр хәлләр кичергән. Дөньяның кырыслыгын мул татыган. Ул бер карау белән кемнең кем икәнен таныйдыр. Бу егетләргә дә үз бәясен бирер. Нургаязны кызына лаек тапмаса да, үпкәли алмыйсың әле. Тормыш катлаулы, һәр кешегә ул үзенчә катлаулы. «Өйләнешүчеләрнең фәлән кадәре аерыла» дип сөйләү бер хәл, ул үзеңә килеп кагылса, балаңа килеп кагылса, бөтенләй икенче нәрсә. Бу — фаҗига! «Юл-транспорт һәлакәтендә илдә ел саен 30-35 мең кеше үлә» дигән статистик саннар да дөнья җимерелү түгел әле ул. Ә менә әтиең-әниең, хатының, ирең, балаң, сөйгән ярың бәхетсезлеккә тарыса, бу синең өчен дөнья җимерелү шикелле.

Каян килгән рухи афәт бу?! Без тормышка бик җиңел карыйбыз. Аны уенга, күңел ачуларга, кәеф-сафа сөрүләргә, рәхәт күрүләргә кайтарып калдырабыз. Хатын-кызлар белән мөнәсәбәтләрне «бәрәңге ашау кебек артык гадиләштерү дә» куркыныч хәл. Гаилә нык булмаса, дәүләт нигезсез дә, хәтерсез дә кала. Рәтләп гаилә кора алмаган кешеләрнең дә кайсысы олы бәхеткә ирешкән соң?! Гаиләдә патшалар да, бөекләр дә юк, гаилә аларга да җир кешеләре икәнлекләрен искә төшереп тора.

Егетләр янә бер кат Нураниянең акыл белән эш йөртүен мактап алдылар. Бөтенесе ачык, бөтенесе билгеле. Инсаф белән Нургаязга шунысы да бик җайлы чыкты: җомга көн аларның ялы. Эш кешесенә монысы да бик мөһим. Егетләр өйгә кайбер нәрсәләр дә алып куярга уйлаштылар. Керсәләр, кунакларны коры чәй белән генә сыйлап җибәреп булмас.

Зур һөҗүмгә әзерләнгән командирлар кебек төне буе сөйләшеп, киңәшеп чыктылар. Таң алдыннан гына йокыга киттеләр.

* * *

Нургаяз эштән кайтышлый мебель кибетенә кереп таба капкачына яраклы тотка сатып алды. Бик матуры туры килде. Моны куйсаң, заводның үзеннән үк шулай чыккан дип уйлаулары да бар. Кайтып чәй эчеп алды да эшкә тотынды. Инсаф имтиханнар расписаниесен ачыкларга академиягә китте, Нургаяз бер ялгызы бирелеп таба капкачы белән булышты. Бик шәп килеп тә чыкты. Хозурланып карап торырлык. Бабай да мактады.

— Карап-карап торам да син дә бик оста күренәсең, — диде карт, Нургаязга төбәлеп. — Алла боерса, бәхетең дә булыр.

— Бабай, сакал-мыегыңны тигезләп җибәрсәк, ничек булыр икән? — диде Нургаяз. — Инсаф кайтканчы матурлап куйыйм әле үзеңне.

Бабай җавап биреп өлгергәнче ул кайчыларын, пәкеләрен күтәреп кереп тә җитте.

Бабайны тәрәзгә якын утыртты, иңнәренә ак җәймә салды. Җайлап кына эшкә дә тотынды.

Инсаф кайту белән бабайдагы үзгәрешне күреп алды.

— Бу да синең эшеңдер әле, — диде ул, соклануын яшермичә. — Мин белмәгән якларың бик күп икән синең...

— Моның әллә ние юк, без мәктәптә укыганда ук «модный прическаларны» үзебез ясый идек ич. Әллә оныттыңмы?!

— Киләсе атнада имтиханнар башлана, — диде Инсаф. — Ерып чыгып булса, ярый инде. Әллә нигә хәвефләнә башладым.

— Гел «5»легә укыганнар да имтиханнардан курка. Нормаль хәл бу. Йөрәгенә йон үсмәгән кеше борчылмыйча калмый.

Ашап-эчкәч, программа буенча узганнарны кабатлауга керештеләр. Инсаф хәзер шактый яхшы йөзә. Академиягә мондый егетне алмасалар, гөнаһ булыр.

Йомшак кына ишек якканнары ишетелде. Зөлхәбирә инде бу, Зөлхәбирә.

Карт белән карчык бер генә зарлану сүзе дә әйтмәде. Гүяки бөтен дөньялары түгәрәкләнгән. Даруларның да кирәге калмаган. Уен-көлке дә кешене үзгәртә шул. Гел тешеңне кысып, иреннәреңне кысып яшәсәң, бернинди йөрәк тә түзмәс.

Зөлхәбирә әби белән бабайның йөрәген тыңлап карады, тегене-моны сораштырды, «әйбәт, әйбәт»дип тегеләрне тынычландырды. Егетләр янына чыккач, күзләрен уйнатып:

— Кая күчтәнәчегез?! — дигән булды.

— Бернинди күчтәнәч тә әзерләп өлгермәдек әле, — диде Нургаяз, көлемсерәп. — Ачуланма инде.

— Кичәге сүзеңне оныттың мәллә? Таба капкачын ясап куям дип үз телең белән әйттең ләбаса.

— Шул да булдымы күчтәнәч?!

— Минем өчен ул бик зур күчтәнәч. Бик яраткан табам бит ул минем. Кыйммәтле дә.

— Алайса, рәхим итегез! — дип Нургаяз таба капкачын сузды.

Зөлхәбирә күрде дә шаккатып калды. Каян тапкан шундый матур тотканы. Бөтен ягын туры китергән, заводныкыннан бер дә ким түгел.

— Нигә алмыйсыз, ошатмадыгыз мәллә? — диде Нургаяз, хәйләкәр елмаеп. — Капкачы ошамаса, табасын да безгә кертегез.

— Кулың гына түгел, акылың да алтын икән, егет! Бу табада пешкән ризыкны авыз итәргә теләсәң, үзең керерсең. Телеңне йотардай итеп пешереп куярмын.

— Нишлибез, Инсаф? — дип белешкән булды Нургаяз.

— Болай чакырып торгач, карышып маташмабыз инде, — диде тегесе.

— Әби дә сине мактый, мин дә мактый башласам, башың әйләнмәсме соң, Нургаяз?! — диде Зөлхәбирә, таба капкачын алып. — Чыннан да мактарлык икәнсең шул. Рәхмәт! Ярар, комачаулап тормыйм, укуыгызны дәвам итегез.

* * *

Зөлхәбирә фатирына чыгу белән үксеп-үксеп еларга тотынды. Нургаязга үлеп гашыйк булуына үртәлде ул. Хатын-кызның үзеннән җиде-сигез яшькә кечерәк егеткә тагылырга маташуы бу нәрсә инде, йә?! Ир-ат күрергә тилмергән, ир-ат назына сусаган хатын-кыз гына шулай башын җуя ала. Димәк, Зөлхәбирә дә шундый халгә килеп житкән. Шушы буе-сыны, төсе-кыяфәте белән ул әллә кемнәрнең башын әйләндерерлек ләбаса. Юк, кирәк бит, өстендәге күлмәгеннән башка бернәрсәсе булмаган егетне күрү белән үк сихерлән инде... Сихерли белә шул, чукынчык. Мондый егеткә гашыйк булмасаң, дөньяга тумавың хәерлерәк. Берәр хәйлә табып, Нургаяз үзе Зөлхәбирә янына керсә, егетлек гайрәтен күрсәтергә теләсә дә, буйсыначак Зөлхәбирә. Буйсыначак кына түгел, үзе үк шуңа ишарә ясаячак. Ә Нургаяз керми. Таба капкачын төзәтергә дә кермәде, димәк, жай эзләми, берәү булса, атылып кереп житәр иде, табасын төзәтәмеюкмы, әмма Зөлхәбирәнең куенына кермичә чыкмас иде.

Нургаязны «кулга ияләштерергә» Зөлхәбирә тагын бер сәбәп тапты. Өйдә электр сүнеп торган арада аның йокы бүлмәсендәге электрон сәгате көйсезләнеп калды. Нургаязны чакыру өчен моннан да җайлырак сәбәп табылмас та. Инсаф өйдә юк чакта чакырырга кирәк үзен...

Зөлхәбирә күзен сөртеп алды да өстәл тартмасыннан альбомын тартып чыгарды. Егерме ике яшьтәге рәсемен эзләп тапты да бик озаклап текәлеп карап торды. Аннан соң җиде ел үткән. Бүгенге Зөлхәбирә белән аермасы бармы? Бар шул. Картаймыйм дип үз-үзеңне алдасаң да, аерма бар шул, аерма зур. Нургаязга хәзер егерме ике яшь, ул да бит күрә аерманы. Нишләп ул синең белән бәйләнсен ди.

Зөлхәбирә үзен ачуланып ата, шунда ук аклап та куя. Тик нишләмәсен, бәгырьләре телгәләнүен туктата алмый.

* * *

Инсаф белән Нургаязның һәр минуты исәптә. Эштә дә нинди генә киеренке хәлләр тумый. Кемдер тизлекне арттырып чаба, кемдер салган килеш руль артына утырган, кемнеңдер таныклыгы да юк — менә шулар юлда фаҗига китереп чыгаралар да. Барысын күреп тә бетерә алмыйсың. Җәяүлеләр дә бик саксыз. Әлегә юл иминлеге турында кайгырту канга сеңмәгән, «ана сөте белән кермәгән тана сөте белән керми». Машина йөртүчеләрнең кайда ничек юл йөрү кагыйдәләрен бозуын теркәп бару да әлегә бик зур үзгәрешләр бирми. Шулай да файдасы булмый калмас кебек. Алдыңны-артыңны карап йөрмәсәң, ул билгеле чиккә бик тиз житә, шулай машина йөртү хокукыннан да мәхрүм калырга мөмкин. Компьютердагы мәгълүматлар архивтагы кебек саклана, бу инде руль артына утыручыларны азмы-күпме йөгәнләргә тиеш. «Гөнаһ дәфтәреңнең» тизрәк тулуын кем теләсен икән?

Ә шулай да юлларда хәвеф кимеми. Башка сыймаслык хәлләр килеп туа. Менә бүген дә шәһәр уртасында чак кына бик зур фаҗига килеп чыкмады. Инсаф белән Нургаязның котырган үгез сыман чапкан бер машинага күзләре төште. Эчендә кеше дә күренми. Кемдер кабызып үзе төшеп калган төсле. Аны кичекмичә туктатырга кирәк! Тик ничек?! Нинди әмәл табарга?! Могҗиза булган кебек машина Инсаф әмеренә буйсынды һәм юл кырыена килеп туктады. Ишеген ачып карасалар, руль артында бер малай!

Менә кем гаепле? Гаеплеләр күп. Кайберәүләр бармак кадәрле балаларын да руль артына утырткан булалар, өйрәтә торалар, янәсе. Тегеләре батыраеп китә, машинаны әтиләреннән башка да гараждан алып чыгалар, «кызык эзлиләр». Күпмегә төшә мондый «кызыклар»!

* * *

Чыгышларны язып барырга рөхсәт иткәнлектән, Нурания фәнни-практик конференциягә диктофон да алып килде. Монда яшерен сүз юк. Судьялар, прокурорлар, адвокатлар, галимнәр суд реформасын ахырына житкерү турында кайгыртып сөйлиләр. Суд процессында гаепләүче һәм яклаучы якларның тигез хокуклылыгын, аларның үзара ярышын тәэмин итү демократия үсешенә көчле этәргеч ясар иде. Бу бердәм фикер. Әмма монда ничек ирешергә соң? «Демократия» дигән сүз белән нинди генә алу-сатулар юк. Бу конференция дә чираттагы шаукым гына булмасмы?! Хәер, алга киткән илләрдә судта якларның тигез хокуклыгын тәэмин итү мәҗбүри шарт санала икән, бездә ул яңарак кына телгә керде. Нурания сөйләгәннәрнең күбесен аңлап та бетермәде. Диктофонга языла, кабат-кабат тыңларга булыр, аңлап житкермәгәннәрен диплом житәкчесеннән дә сорашырга мөмкин. Шулай да Нуранияне сискәндереп

җибәргән бер чыгыш булды. Хәрби суд рәисе урынбасары, юридик фәннәр кандидаты шундый мисал китерде, Нургаяз сүзләрен кабатлады. Ул җинаять ясаган генерал һәм аны судка биргән солдат турында иде. Судта аларның тигез хокуклыгын ничек тәэмин итәргә? Гомумән, мөмкин хәлме бу?! Нуранияннең әтисе дә шундыйрак эш белән чиләнә. Ул әфганчылар, кайнар нокталарда сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, чернобыльчеләрнең район оешмасын җитәкли. Почетлы кеше нинди каршылыкларга гына юлыкмый. Җитәкчеләр белән бәрелешмәгән көне дә юк. Әфган сугышында бер аягын калдырып кайткан иптәше ит комбинатында эшли, йорт сала башлаганда аңа фатир вәгъдә иттеләр. Исемлектә иң башта ул иде. Йорт өлгергәч, сатып алырга кушалар. Имеш, алар турында дәүләт кайгырта, өстенлекләр барысы да федераль казнадан түләнә. Ә ит комбинаты муниципаль милек. Ул җирле үзидарә органына буйсына. Нуранияннең әтисе тоткан җиреннән өзә торган гаярь зат булса да, юк-бар белән башны әйләндереп йөрүчеләрне җенә алмый. Эш судка барып җитте. Суд буласы көнне билгелиләр — ит комбинаты директоры бик ашыгыч рәвештә каядыр киткән, суд утырышын кичектерәләр. Икенче тапкыр суд буласы көнне ул авыруга сабышкан, кәгазен ярдәмчесе аркылы җибәргән, суд утырышы тагын өзелә. Әллә ничә ай буена шундый ыгы-зыгы бара. Ә район муниципаль берәмлеге башлыгы «суд эшчәнлегенә тыкшынмыйм, судларның бәйсезлегенә, мөстәкыйльлегенә каршы бара алмыйм» дип кул гына селти. Мәскәүгә язарга киңәш бирә. Ул шуны яхшы белә: кәгазьләр йөргән арада комбинат төзегән йорт бүленеп тә бетәчәк.

Ит комбинаты директоры һәм әфган сугышында аягын калдырып кайткан дәгъвачының тигез хокуклыгын судта ничек тәэмин итәргә икән?! Мал иясе хәтта суд утырышына килмәскә дә хәйлә таба. Ә милиция белән алып килә алмыйсың, гражданлык эшләрендә бу каралмаган...

Судьяларны, прокурорларны, адвокатларны, галимнәрне, үзенең фәнни җитәкчесен бик бирелеп тыңласа да, Нурания тормыш тудырган сорауларга җавап таба алмады. Сораулар артты гына. Алай гына да түгел, бик куркыныч хәвеф янавын да сизенде ул.

Конференция ябылу белән фәнни җитәкчесе аны эзләп тапты.

— Кая ашыгасың? — диде ул. — Әле бит очрашуның беренче бүлеге генә бетте. Аның иң кызыклысы башлана гына... Монда җинелчә генә тамак ялгап алгач, пароход белән сәяхәткә китәбез. Тукталыш минем дача янында гына булачак. Анда да кереп чыгарбыз...

Нуранияга Ходай тел ачкычы бирдеме — кыстатып та тормаслык итеп җавап кайтарды:

— Мине әти көтеп тора. Ул төгәллекне ярата, әфганчылар бик кызу халык. Чакыруыгыз өчен рәхмәт.

Фәнни җитәкче күз алдында кара янып чыкты. Атна буе корган планы мизгел эчендә җимерелде дә төште. Сакал-мыек үстереп йөрүче бу кырык яшьлек доцент — астыртын карчыгаларның берсе. Ел саен бер кызның диплом җитәкчесе була. Консультацияләрне күбрәк дачасында үткәрә. Кызны үзенеке итәр өчен нинди генә җәтмә кормый. Нурания аның карталарын бутады. Өметләнеп йөрмәслек итеп әйтте ул. Әтисенең әфганчы булуын, аларның кызу халык булуын басым ясап, авыз тутырып әйтте. Андыйларның кызлары янында да ерак йөрергә кирәк. Диплом җитәкчесе булсаң да, бик азынма. Нурания яхшы укый, үзе дә бик өркеп тормаячак. Андыйлар белән бәйләнсәң, итәгенә ут кабуы да бар. Шулай да галим дәрәҗәсен төшермәслек итеп кенә хәлне рәтләп җибәрде:

— Әти кешене көттереп торырга ярамый, — диде ул. — Мондый сәяхәтләр

соңгысы булмас әле. Иң мөһиме: дипломыңа юнәлеш бирерлек материаллар күп булды конференциядә.

— Чакыруыгыз өчен рәхмәт! — дип Нурания җитәкчесе белән саубуллашты.

Саубуллашуын саубуллашты, әмма арттан ияреп килмиме дигән шикелле әллә ничә тапкыр як-ягына караштырды. Ниндидер кара көч аны эзәрлекли сыман. Суд процессында якларның тигез хокуклыгы турында сүз куертучы кеше бит үзе. Судта гына түгел, тормышта да кешеләрнең тигез хокуклыгын тәэмин итү бик авыр шул. Үзең каршы тора алсаң торасың, йомшаклыгыңны сизсәләр, изәләр... Нурания шуңа гаҗәпләнде: әтисенең әфганчы булуын ничек әйтә алды соң ул?! Һәркемдә үз-үзеңне саклау инстинкты бар. Кемдә ничек — бусы икенче нәрсә. Конференциядә ишеткәннәрне, һичшиксез, дипломында файдаланачак, җитәкчесен кисәтү дә бик табигый килеп чыкты, әфганчы кызы белән «алдым-бирдем» уйнарга исәп тотмасын...

* * *

Инсаф белән Нургаяз Яңа мәчет янында очрашуга бик җентекләп әзерләнделәр. Өйне әйбәтләп җыештырдылар. Кирәге чыкса, бик тиз генә табын җәярлек итеп тә калдырдылар. Әби белән бабайның да фатихасын алдылар. Машина ягын да уйлаштылар. Җәй көне өскә әлләни киясе юк, ак күлмәк тә ак чалбар. Аякта җиңелчә туфлиләр. Хәзер бөтен урам бертөрле киенә сыман.

Яңа мәчет янына алар бер яктан, Нуранияләр икенче яктан килеп чыкты. Гүяки минутына кадәр исәпләгәннәр. Монда төп фигура Нурания иде, ул барысын да бер-берсе белән таныштырып чыкты. Читтән карап торсалар, алар беренче тапкыр очрашкандыр дип уйламаслар да иде.

Мәчеттән чыккач, алдагы маршрутны Нургаяз билгеләде.

— Хәзер анда-монда йөреп тәэсирләрне тоныкландырмыйк әле, — диде ул. — Безгә кереп чәй эчеп алыйк. Чәй янында сүз дә тәмле була. Бер-беребез белән якыннанрак танышырбыз да.

Барысы да Нуранияга төбәлде: җавапны ул бирергә тиеш. Нургаяз чакыра, Нурания ничек әйтсә, шулай булачак та.

— Әти, әни, сез ничек уйлыйсыз? — диде Нурания.

— Көн дә бик эссе, чәй эчеп чыксак, яхшы булыр, — ди әтисе. — Син инде белмәгән җиргә алып бармыйсыңдыр?

— Әлегә кадәр кереп караганым юк, әмма бу егетләргә ышанырга була, — дип елмайды Нурания.

— Сезне әби белән бабай да көтә, — диде Инсаф, бөтен сорауларга берьюлы җавап биргәндәй.

Барырга булдылар. Кибеткә кереп тәм-томнар алдылар.

Кунаклар әби белән бабайга бүләкләрен, күчтәнәчләрен тапшырып, хәл-әхвәл белешкән арада Нургаяз белән Инсаф табын әзерләп то куйды. Нурания белән Солтания булышмакчылар иде, аларга эш калмаган да булып чыкты.

Хуҗалар белән кунакларны бәйләп торучы — Нурания. Шуңа күрә Нургаяз белән Инсаф «җитәкчелекне» аңа тапшырдылар.

— Шулай әйбәтрәк булыр, — дип, Нурания үзе дә килеште.

Егетләр шампан турында сүз катканнар иде, Нурания шундук кире какты.

— Әти рульдә, әчми дә әчми инде, аның каршында авыз күтәреп шампан чөмереп утырмабыз. Без чәй эчеп чыгарга кердек бит. Мәчеттән кайтуыбызны да онытмыйк, — диде ул.

Утырыштылар. Әчәселәре дә, ашыйсылары да килгән — артык кыстатып тормадылар. Алга куйганның күбесеннән авыз иттеләр. Нуранияңең әтисе егетләрне мактап та алды:

— Ризыкларыгыз шулкадәр тәмле, сезгә фәрештәләр булышкандыр инде, — диде ул. — Алар сезне киләчәктә дә саклап йөрсен.

Аны Нурания күтәреп алды.

— Сез калага килмәсәгез, Нургаяз белән Инсафның мондый осталыкларын белмәгән дә булыр идем әле, — диде кыз..

Каюмнур читләтеп тә, турыдан-туры да үзен кымырҗытып торган сорауларга җавап эзләде.

Мәдәният һәм сәнгать институтын кызыл диплом белән тәмамлаган Нургаязның ЮХИДИгә килергә җыенуын да хуплады.

— Бу ышанычлы, — диде ул. — Тотрыклылык ил өчен дә бик кыйммәт, аерым кешеләр өчен дә бик мөһим. «Иртәгә нәрсә булыр икән?» дип яшәү бик авыр ул. Тотрыклылык булса, кеше авыр хәлдән чыгу әмәлен дә таба. Тотрыклылык булмаса, ышаныч бетсә, нишләргә дә белмисең. Андый чакта «иртән корган планың кичкә ярамый». Саклык банкларында кешеләрнең акчалары янгач, дәүләткә дә, хөкүмәткә дә ышаныч калмаган иде, аны кире кайтарулары бик авыр шул. Сез андый афәтләрне күрмәсәгез иде... Әйбәт кенә эшләргә язсын, Нургаяз. Бездән теләк шул сиңа. Калганын үзең карарсың.

Әфган сугышында янган танкта һөҗүмгә барган, сират күперен кичеп исән калган кешенең телендәге «тотрыклылык» сүзе аерым мәгънәгә ия, аны колагың белән генә түгел, йөрәгең белән дә ишетергә кирәк.

— Әтиебез тормышның да, кешеләрнең дә тотрыклы, ышанычлы булуын ярата, бу турыда сәгатьләр буе да сөйләргә риза ул, — дип, хатыны да читләтеп кенә егетләрнең колагына киртләп куйды. — Дөньяда бер тапкыр гына яшибез, гомереңне юкка исраф итсәң, кире кайтарып булмый. Алга ышаныч белән яшәү генә кешене канатландыра, көчле итә.

Яшьләр аларны бүлмичә генә тынлап утыралар иде, көтмәгәндә Инсаф барысын да гаҗәпләндерерлек сүз әйтте:

— Гөлбаһар апа, Каюмнур абый, — диде ул, тәмам чишелеп китеп. — Мин Нураниягә «үзең шикеллерәк бер кыз табып бир әле», дигән идем. Ул «сеңлем юк шул, булса таныштырыр идем» диде. Ә Солтания кемегез соң сезнең?

— Әллә бик ошадымы? — диде, Гөлбаһар елмаеп. — Солтания дә үзебезнең кызыбыз кебек. Ул минем белән бергә эшли. Икәүләп менә медицина академиясендә белемнәребезне күтәрергә килдек.

— Ошады гына түгел, «пленга алды», — диде Инсаф, шаярткан булып. Солтаниянең йөзе алсуланып китте. Инсафның кызыксынуы күңеленә хуш килде аның. Кайсы кызның игътибардан читтә каласы килсен. Ике егетнең икесе дә Нураниядән күзен алалмаса, Солтаниянең хәтере дә калыр иде. Инсаф нәрсә уйлап әйткәндер, анысы аның эше, әмма ул чын джентельмен икән. Табынга да яңа рух өрде кебек.

Алар бер-берсенең авызына керердәй булып сөйләшкәндә генә ишек шакыдылар. Егетләр өчен яңалык түгел инде бу. Зөлхәбирәнең керәсен көтеп торган сыман Инсаф ишекне ачарга китте.

— Күршедер ул, — дип аңлатып куйды Нургаяз. — Участок табибәсе. Әби белән бабайны бик карый.

Зөлхәбирә кунакларның керүен күреп калгандыр, мөгаен, үзен бик иркен тотып кына түргә узды. Кулында таба. Өеп-өеп коймак тутырган.

— Кунаклар да бар икән, әйтәм, коймагым бик уңды. Насыйп ризык тешне сындырып керә, диләр. Кая куйыйк соң моны? — диде ул.

Нурания бик тиз җаен тапты, коймакларны тәлинкәләргә таратып чыкты. Аның үзен шулай хуҗаларча тотуы Зөлхәбирәнең йөрәгенә ут төрткәндәй итте. Нурания аңа үзе белән рәттән урын да күрсәтте. Бу фатирда күпме

йөреп тә Зөлхәбирә үзен болай иркен тотмый, ә бу кызыйны кара... Кайсысыныкы икән бу? Нургаязныкымы, Инсафныкымы?

Күршесенең януларын сизгән шикелле Инсаф аны кунаклары белән таныштырырга кирәк тапты.

— Гөлбаһар апа белән Каюмнур абый, аларның кызы Нурания, ә бусы Солтания, Гөлбаһар апа белән бергә район хастаханәсендә эшли, медицина академиясенә белемнәрен күтәрергә килгәннәр, — диде ул, һәркайсына кулларын төбәп.

— Коллегалар икәнбез, — диде Зөлхәбирә, — мин участок табибәсе. Күршедә генә яшим. Әби белән бабайга кулымнан килгәнчә ярдәм итәргә тырышам. Егетләр бик уңган булсалар да, кайбер нәрсәләрне әйткәләргә туры килә. Алар да миңа булыша. Менә бу табаның капкачын төшереп, тоткасын сындырган идем, Нургаяз заводтан чыккан кебек итеп бирде. Шул табада коймак пешереп сыйларга теләгән идем үзләрен, сезгә дә авыз итәргә язган икән...

Зөлхәбирә ялгызы гына өч бүлмәле фатирда яшәвен әйтергә дә җай тапты. Кызлар аның күңелен ничек борчыса, ул да тегеләрнең тынычлыгын алырга теләде.

— Сезнең белән танышу бик күңелле булды, әби белән бабайның хәлен дә белеп чыгыйм инде, — дип, Зөлхәбирә табын яныннан торды. Өлкәннәр янында да артык тоткарланмады, кунаклар белән саубуллашып өенә чыгып китте.

Фатирына чыккач кына Зөлхәбирә нинди удар алганын аңлады. Нургаяз белән Инсаф уйнап-көлеп кенә сөйләшкән булалар, ә Зөлхәбирәгә нинди сабак бирделәр. «Безнең тирәдә буталма» диюләре инде бу. Әй, бик каты аңлаттылар. Кысылып йөрмәслек иттеләр.

Кызлар егетләрне күзләргә килгәннәрдер. Алар янында Зөлхәбирә оттыра, оттыра шул. Һәр җимешнең үз вакыты. Вакытында өзеп алмасаң, ул төсен җуя башлый.

Китәр алдыннан кунаклар янәдән әби белән бабай янына керделәр, борчулары өчен гафу үтенделәр. Алар чыгып барганда гына әби әйтеп куймасынмы:

— Бу кызлар икесе дә сөйкемле, кайсы безнең киленебез була соң? Без бит картлар, икесенең берсенә Инсафны өйләндерер идек, — диде ул, өлкәннәрчә туры ярып. — Без никахлашу турында киңәшергә килгәнсез дип юраган идек.

Кунаклар ни дияргә белмичә бер-берсенә карашып торганда Нургаяз хәлдән чыгу җаен тапты.

— Берьюлы ике чибәрне күргәч, Инсаф аптырашта калды, — диде ул. — Кайсын сайларга да белми. Бераз уйларга булды.

Сүзгә бабай кушылды:

— Ике кыз арасында адашып икесеннән дә колак кага күрмәсен тагын, — диде ул.

Кунакларның китәргә җыенуын Зөлхәбирә дә сизенгән, ахрысы. Ул да ишеген ачып фатирыннан чыкты.

— Китәсездәмени?! — диде ул, гаҗәпләнгән сыман. — Юлларыгыз уң булсын.

Кулына таба тотып, коймак күтәреп кергән Зөлхәбирә генә түгел иде инде бу. Чәчләрен яшьләрчә маңгаена төшергән, гәүдәсенең бөтен хозурлыгын сиздерерлек итеп киенгән, бармакларына зөбәрҗәт кашлы йөзекләр тезгән, алкалар таккан, иңенә бик кыйммәтле сумка аскан — дөньяның теләсә кайсы шәһәрендә дә башын күтәреп йөрерлек чибәр. Моны күрми мөмкин түгел.

Каюмнурның «Волга»сы ишек каршысында гына тора иде, ишекләрен ачып бераз җилләтеп алды. Гөлбаһарның ике ягыннан барган Нурания белән Солтания егетләргә елмаюларын бүләк иттеләр. Барысы да машинага кереп урнашкач, Каюмнур янә бер кат озатып калучыларны сәламләде.

— Хәерле сәгатьтә, хәерле юлга! — дип кузгалып та киттеләр.

— Кунакларны каршылау да күнелле, озатуы тагын да күнеллерәк, — диде Зөлхәбирә, канәгатьләнүен яшермичә. — Боларның кайсы кайсыгызныкы соң?

— Берсе дә безнеке түгел әле, — диде Нургаяз.

— Тиккә генә әтиләрен-әниләрен ияртеп килмәгәннәр инде, юкны сөйләмә, — диде Зөлхәбирә. — Ярамаслык кызлар түгел. Нурания дигәне синеке кебек күренә, укыймы, эшлиме?

— Университетта соңгы курска күчте, — диде Нургаяз.

— Кем булырга укый?

— Юристлыкка.

— Бәхетең бар икән, — диде Зөлхәбирә, көлемсерәп.

— Нишләп алай дисез?

— Хатын-кызның чи наданы да бер дигән юрист аның. Синеке икеләтә право качать итәр инде...

Егетләр сүзнең артык тирәнгә китүен теләмиләр иде, өйгә керергә булдылар.

— Миңа да борылмыйча булмый, — диде Зөлхәбирә. — Акча алырга онытканмын. Матур сумка тагыйм дип акчалысын калдырганмын. Минем башымны да бутадыгыз әле, егетләр, бик бутадыгыз!

Өчәүләп өскә менеп киттеләр. Зөлхәбирә алдан бара, Нургаяз белән Инсаф каршында гәүдәсен еландай уйната. Карамыйм дисәң дә күзең төшә.

Өченче катка менеп җиткәндә Зөлхәбирә егетләргә борылып:

— Беркөннәре өйдә электр сүнеп торган арада йокы бүлмәсендәге электрон сәгатем буталып калды, шуны рәтләп чыкмассыз микән? — дип сораулы караш ташлады. — Бик яхшы сәгать ул, тавышы чыкмый, әллә каян күренеп тора. Керәсезме?

Инсаф белән бергә булгач, шикләнеп торасы юк, Нургаяз уйлап та тормыйча:

— Ярар, ярар, хәзер үк рәтләп чыгарбыз, — диде.

— Аны берүзең дә рәтли аласың инде, — диде Инсаф.

— Алай да ярый, — диде Зөлхәбирә. — Уянган саен күз төшерәм мин аңа. Бер иптәш шикелле ул.

— Инсаф, бергә керәбез! — диде Нургаяз, әмер биргәндәй.

Зөлхәбирәнең фатиры да үзе кебек матур, зәвык белән җиһазланган.

Барысы да заманча. Евроремонт ясаткан. Теләсә кемнең моңа көче житми. Зөлхәбирәгә иркенлек-муллык өмет итмәгән җирдән килде шул. Фәнни җитәкчесенең хатыны көнләшеп аптыраткач, аспирантурадан участок табибәсе булып киткән иде. Һәм ул отты. Участок табибләренең хезмәт хакларына унар мең сум өстәделәр. Хәзер фән докторлары да алардан көнләшә. Бик күпләр участокта йөрер иде бүген. Акчасы зур булгач, теләүчеләр табыла. Тик моңа юл табу өчен «сират күперен» чыгарга кирәк.

Егетләр фатирны да, хуҗаны да мактамыйча кала алмадылар. Матурлыкны күрә беләләр бит алар, күрә беләләр. Нишләп әле күршенең күнелен күрмәскә?! Мактау сүзләрен кемнең ишетәсе килмәсен. Бигрәк тә шундый егетләрдән.

— Ишекләребез бер-берсенә терәлеп торса да, ничек яшәвегезне

белмәгәнмен икән, — диде Инсаф. — Безнеке шикелле гади генә фатирны супер ясагансыз. Күршедә шундый үрнәк була торып без бик нык артка калганбыз.

— Алай димәгез, — диде Зөлхәбирә. — Сез миннән дә уздырып җибәрерсез әле. Сезнең барысы да алда.

— Безгә ничек яшәргә икәнен күрсәттегез, — диде Нургаяз. — Тик безгә моңа бик ерак әле, бик ерак.

— Генерал булырга хыялланмаган солдат юктыр, — диде Зөлхәбирә, елмая-елмая. — Генерал булгач, безнең кебекләргә сәлам дә бирмәссез. Әхәзергә әле минем сәгатьне көйләгез.

Нургаяз берничә төймәгә басу белән сәгать секундына кадәр дөрес итеп вакытны күрсәтә башлады.

— Бусы өчен рәхмәт! — диде Зөлхәбирә. — Бәлки, берәр йотым коньяк эчәрбез.

— Башка вакытта, Зөлхәбирә, башка вакытта... Имтиханга әзерләнәбез бит. Академиягә керү турында фәрман чыгу белән үзем сине кунакка чакырам. Бүгенгә ачуланма! Әрләсәң дә, бик каты әрләмә, — диде Инсаф кистереп.

Нургаязга Инсаф бөтенләй көтелмәгән яктан ачылды. Уңайсыз хәлдән оста чыга белә икән. Зөлхәбирә дә үзен кулга алды, тынычланды.

Егетләр берни булмагандай чыгып киттеләр. Әби белән бабайның колаклары да, күзләре дә ишектә иде, аларның кайтуын күргәч, иркенләп тын алдылар.

Инсаф белән Нургаязның ашыйсы да килгән икән. Кара-каршы утырып затлы ризыкларны урдылар гына. Әби белән бабайны да үз яннарына дәштеләр. Тегеләре дә артык кыстатып тормады, дүртәүләп кенә сөйләшәсе килгән иде аларның.

— Кунак килер дә китәр, үзебез дә сыйланып калыйк, — диде бабай. — Кай арада шулай әзерләп куйдыгыз, исебез китте.

— Көчле чаклары шул, көчле чаклары, — дип мактады әби. — Кулларыннан эш тә килә. Шундыйларны кызлар да кулдан ычкындырмаска тырыша. Күрдең ич, теге ике чибәрнең дә күзләре ут яна.

— Сез аларны югалта күрмәгез, — дип киңәш итте бабай. — Карап торырга кызлар күп тә, бергә гомер итәрдәйләре азрак. Болар сезнең өчен туган, сезнең өчен үскән, сезнең өчен утка-суга керергә әзер. Андыйларның кадерен дә белергә кирәк. Тормыш алып барулары бик авыр ул. Икең бергә төпкә җигелеп тартсаң гына тормыш арбасын алга өстерисең. «Гаиләдә кем баш?» дип ләчтит сатулар буш нәрсә ул. Анда баш та, муен да, аяк та, кул да юк, анда бөтенесе бергә, «бары бергә — югы уртак». Шулай итеп яшәмәсәң, тормыш арбасы шыгырдый башлый, йә тәртәсе, йә күчәре сына, йә тәгәрмәче таралып китә...

— Әти-әниләре дә булдыклы, инсафлы күренә, — диде әби, кызлар димләп йөрүче карчыктай. — Ходай кушып, кавышып яши алсагыз, бик шатланыр идек. Бу дөньяда яратканыңны табуы да авыр, мәхәббәтне саклавы да җиңел түгел. Югалта күрмәгез сез аларны!

— Сезгә ошагач, без бик шат инде, — диде Нургаяз. — Инсафка бәхет эзләп йөрисе дә калмады. Ходай рәхмәте шул буладыр, Инсаф күрергә теләгән кызны берничә айга монда укырга җибәргәннәр. Районга кайтармыйча алып калсагыз да була инде.

— Бирсен Ходай! — дип бабай мөһер суккандай итте. — Инсафка бераз җиңелрәк булыр иде. Эшләргә дә, безне карарга да кирәк бит ана.

— Инсаф балам, без риза, әти-әниең дә шатланыр моңа, — диде әби, соңгы сүзне әйткәндәй.

* * *

Икенче якның да сөйләшер-аңлашыр сүзләре күп булып чыкты.

— Бүгенгә кадәр мин сиңа кызым итеп кенә, балам итеп кенә карый идем, син икенче кеше икәнсең инде, — диде Каюмнур Нураниянең иңнәреннән кагып. — Шулай булырга тиеш тә. Әмма сиңа әле ашыгуның кирәге юк. Нургаяз да, син дә гаилә корырга өлгермәгән... Инсаф белән Солтаниянең хәле башка, яңа тормыш корырга аларның бөтен нәрсәләре көйләнгән, — дип куәтләде ул. — Өч бүлмәле фатирлары бар, эше яхшы, укырга кереп йөри. Бу яшьтә бик сирәк кеше боларга ия. Күпме хезмәт итеп отставкага чыккан офицерлар да йортсыз-җирсез бик аптырыйлар әле.

Кызы буйга җиткән ата кешенең бу якка басым ясавы аңлашыла: кем баласының муллыкта яшәвен теләмәсен. Хәзер өйләнешүчеләргә: «Гомерегез үтсен сезнең тазалыкта, байлыкта» дип теләк тә телиләр. Зур-зур кешеләр дә мал-мөлкәткә, байлыкка мөкиббән китте. Затлы машиналары, коттеджлары белән мактанучылар күпме... Алар янында берәүнең дә мескен булып каласы килми. Баласының киләчәген кайгырткан ата-ана кемгә йөз тотасын белә. Инсафның кешедән артык байлыгы юк, әмма адәм рәтле яшәргә мөмкинлеге җитәрлек. Мондый егетне күздән ычкындырырга ярамый...

Ашын ашаган, яшен яшәгән олылар гына түгел, яшьләр үзләре дә акны карадан аералар. Күпме генә бәхәсләшсәң дә, бер нәрсә ачык: мал-мөлкәт мәхәббәтнең дошманы түгел. Солтания дә бик яхшы аңлый боларны. Үзен сорап йөрүче егетне кире борып җибәрүе дә фатир мәсьәләсенә барып тоташты ич. Нигә моны яшереп торырга. Юк, Солтания үзенең әти-әнисе йортына кияү алып кайтырга теләми. Гөлбаһар апасы белән белемнәрен күтәрү турында кайгыртулары да тиккәме?! Һич тә тиккә түгел. Күбрәк хезмәт хакы алу өчен кирәкте бу. Гөлбаһар апасы участок табибәсе булып күчәргә җыена, ник дисәң, акчасы берничә мәртәбә арта. Солтанияне дә үзе белән алмакчы. Мең сорауга бер җавап, һәм дөрес җавап. Инсафка бәя биреп бетермәсә, Солтания җүләр булыр... Мондый егеткә килергә теләүчеләр табылыр, бер кулдан ычкындырса, Солтаниянең үзенә андый яр табылырмы?!

«Инсаф вакыйгаларны ашыктырмаса ярар иде, — дигән уй үтте Гөлбаһарның башыннан. — Яшьләрнекен белмәссең. Районга кайтып та торма дип кыстый башласа, бөтен эшне чуалтуы бар...» Шуңа күрә кисәтү дә зыян итмәстер.

— Бер күрүдә гашыйк булганнар нинди була? — дип сорасалар, мин Инсаф белән Солтанияне атар идем, — диде ул, ачыктан-ачык. — Мондый парлар күп түгелдер. Бирсен Ходай, икесенең дә бәхетенә булсын....

Солтания каршы төшеп тә, нидер аңлатып та маташмады. Гөлбаһар апасының күзеннән күңелендәгене яшереп буламыни!

— Солтания, үпкәли күрмә, сиңа шуны әйтәсем килә, — дип дәвам итте Гөлбаһар. — Инсаф өйләнү турында сүз кузгатырга мөмкин. Син каршы да төшмә, укырга килеп кияүгә чыгып калырга ярамаганын да аңлат. Безнең белемнәрне күтәрү өчен шактый зур акча тотыла. Димәк, без билгеләнгән программаны үтәргә, имтихан тапшырырга, районга кайтып хисап тотарга да тиешбез. Әгәр син кайтмыйча калсаң, барлык чыгымнарны түләтергә дә күп сорамаслар.

— Инсафның кызып китүе әле өйләнергә тәкъдим ясау түгел. Егетләр бүген — болай, иртәгә тегеләй, — диде Солтания, бу сүзләргә артык исе китмәгәндәй.

— Күз карашыннан бөтенесе дә күренә ич, — диде Нурания, әнисенә кушылып.. — Ул сине Ходайның бүләге дип уйлыйдыр. Мин дә шул фикердә. Сез бит бөтен яктан пар килгән. Инсафка кичекмәстән өйләнергә

кирәк. Әбисе белән бабасын да күрдең бит. Алар да сине ошатты. Мондый бәхет Ходайның яраткан кешеләренә генә елмаядыр. Өйләнешмәсәгез, гомер буе үкенерсез... Тик әни әйткәнне искә алмыйча булмый. Инсаф районга кайтып, үзе сине алып китәр. Шул чагында беркем дә бәйләнә алмас.

Каюмнур да үз сүзен әйтмичә калмады:

— Явыз кешеләр бик күп хәзер, аларга явызлык эшләргә ирек бирергә ярамый, — ди ул, кызларның икесен дә кисәтеп. — Алдыңа-артыңа, якягыңа каранып йөрсәң дә бик таман гына бу дөньяда. Кызларга бигрәк тә... Ата кеше буларак әйтәм: егетләр миңа ошады...

Дүртәүләп бик күп нәрсә турында кинәштеләр, шулай да Нуранияның әти-әнисеннән дә, Солтаниядән дә яшергән серләре калды. Йөрәгендә моңарчы беркайчан да булмаганча шик яралды. Диплом җитәкчесенең аны дачага алып барырга җыенуы җанны өшетте. Аннан сакланып бетеп булырмы? Нургаяз тирәсендә еландай Зөлхәбирәнең бөтерелүе дә бик хәвефле. Үзеңне генә түгел, егетеңне дә сакларга кирәк икән. Боларга көч җитәрме соң?! Инсаф белән Солтаниянең киләчәге ачык, алар өйләнешер дә, матур итеп яшәрләр дә. Аларны таныштырган Нурания үзе каршылыклар алдында калды. Күнеле сизә: бик кырыс сынаулар көтә аны. Йә, Раббым, көч бир, ташлама син бу гөнаһсыз баланңы...

* * *

Майор Солдатов «Инсаф-Нургаяз» дуэтыннан бик канәгать. Үзе теләгәнчә җырлата ул егетләрне. Сыбызгыны да үзе теләгәнчә сызгырттыра. Алар Солдатовка ничек «хезмәт итүләрен» сизмиләрдер дә. Гайре табигый эш белән шөгыльләнмиләр, хезмәтләре буенча нәрсә каралган — шуны гына башкаралар. Артларыннан эз калырлык та итмиләр. Майорның эше дә көйләнгән, йорты да күтәрелә. Төзелешне механикалаштыру фирмасы башлыгы башлы егет булып чыкты. Эшне майлаган кебек алып бара. Йортның нигезе бик нык утырды. Озын-озакка сузмыйча стеналарны торгыза башларга да була. Солдатов монысын да җиңел генә ерып чыгарлык вариантлар эзли. Кирпеч заводы, төзүчеләр белән бәйле «операция» башкару көн тәртибенә менде. Инсаф белән Нургаязга маршрут билгеләрдәй бер-ике жалоба «көйләп» куярга булыр. Әлләни эзләнергә дә туры килмәде. Халыктан кергән хатларны актарганда таныш фамилиягә юлыкты. Фәрхетдинов Фазыл Фатыйх улы. Бу теге фирма башлыгы Фәһимнең йә абыйсы, йә энесе булырга тиеш. Солдатов аның визит карточкасын алып та тикшереп карады. Туры килә. Бусы автобуслар юнәтеп үз маршрутын булдырган, һәм менә бу автобусларда айлык билеты булган пенсионерларны да бушлай йөртмиләр икән. Шәһәр җитәкчеләре әмер бирделәр, ә боларның үз туксаны туксан. Шәхси автотобусларны беркем дә мәҗбүр итә алмый, янәсе. Халык сүзе дөрескә чыкса, маршрутны ябарга да мөмкиннәр. Солдатов инде яхшы танышына әверелгән Фәһимгә шалтыратып белешмәкче иде, бу фикереннән кире кайтты. Башта тикшереп карарга кирәк. «Инсаф-Нургаяз» дуэты мондый «операцияләрне» бик оста ерып чыга.

Шул ук көнне Инсафны чакыртып задание дә бирде.

099 маршруты шәһәрнең бер ягыннан икенче читенә кадәр йөри. Халык һәрвакыт күп була.

Егетләр бик-бик аяныч хәлләргә юлыктылар. Автобус тукталыштан шактый ук китеп өлгергән иде, ишекне ачып бер әбине төртеп төшерделәр, карчык аягы таеп чак кына егылмады. Нургаяз аның өзгәләнеп елаганын кесә телефонына яздырып та алды. Билет алырга акчасы булмаган икән, кемдер үзенекен тәкъдим итеп караган, әмма кондуктор аның кулын да кире этеп җибәргән.

— Автобуста да садака җыярга өйрәнеп китмәсеннәр! — дип, кырт кискән.

Егетләр аяныч хәлләр турында Солдатовка житкерделәр, кесә телефоны белән язып алынган кадрлар да бик отышлы чыккан. Әйе, монда ут уйнатырга «утын» җитәрлек.

Солдатов фирма башлыгы Фәһим Фәрхетдиновкә шалтыратып, аны да бу эшкә тартырга кирәк тапты. Ул сыналган, аның белән уртак тел табуы кыен түгел.

— Фәһим Фатыйхович, исәнмесез, Фазыл Фатыйхович Фәрхетдинов сезнең кемегез була? — дип башлады сүзен. — Әле менә халыктан кергән хатларны караштырганда шундый кешегә тап булдым.

— Әллә берәр нәрсә китереп чыгарганмы? — диде тегесе. — Минем бертуган энекәшем ул.

— Пенсионерларны бик обижать итә икән.

— Хәзер икәүләп сезнең янга барып җитәбез. Урыныгызда буласызмы?

— Ярты сәгатьләп вакытым бар, аннан ашыгыч эш белән чыгып китәм.

— Без унбиш минуттан да калмыйбыз.

— Алайса, көтеп торам.

Хатлар, жалобалар белән эшләүне Солдатов башта бик вак нәрсәгә санаган иде. Бик четрекле, ризасызлык белдерүчеләр күп. Кемгә генә ярап бетәсең. Уйламаган җирдән нинди «мөмкинлекләр» ачылды. Монда гаепләләрне үзенә каратуы бик җиңел. Законнарны бозудан курыкмаган «зур балыклар» да халык алдында чын йөзләре ачылудан шүрлиләр. Алар өчен Солдатовка йорт салу ни ул?! Чүп кенә. Берсе дә үз акчасын чыгармый. Шуңа күрә уңайлы вариантларны үзләре тәкъдим итәләр. Хәзер менә кирпеч, измә кирәк булачак, монысы белән дә тоткарлык тудырмаслар...

Эшмәкәрләр төгәл халык. 15 минут дигәндә Фәһим Фәрхетдинов килеп тә җитте. Башта Солдатов янына үзе генә керде.

Бүлмә хуҗасы сүз белән мавыкмады. Хатлар, кесә телефонына теркәлгән гыйбрәтле язмалар белән таныштырды.

— Нишлибез?! — фирма башлыгы Фәһим бер генә сүз әйтте.

— Үзе мондамы? — диде Солдатов.

— Коридорда көтеп тора.

— Әйтегез, керсен.

Фазыл Фәрхетдинов абыйсына каршы утырды. Гөнаһларын үзе дә белми түгел. Аның әмереннән башка гына автобусларда пенсионерларны кыерсытмыйлар. Чамасыз кыландылар бугай шул. Уеннан уймак килеп чыкмагае.

— Бер тотынгач, без контрольне йомшартмаячакбыз, Фәһим Фатыйхович, энегезгә сез дә аңлатыгыз, шулкадәр автобус сатып алгач, файдасын да күрерлек булсын.

— Һичшиксез, һичшиксез, — дин кабатлады өлкән Фәрхетдинов. — Кисәтүегез өчен рәхмәт сезгә...

Икенче көнне ул тагын Солдатов янына килде. Энесе белән нинди «тәрбия» эшләре үткәрүен әйткәч, шуны да өстәп куйды:

— Сез йортыгыздагы эшләрне дәвам иттерергә ниятлисездер, мин бер вариант таптым, — диде ул.

— Нинди вариант? — дип кызыксынды Солдатов.

— Без гараж салдырган идек, ике йортлык кирпечебез, плитәләребез артты. Ул инде калдык санала. Аның бәясен дә үзебез куябыз. Сезнең өчен моннан да яхшы вариант була алмас. Бер йортлык материалларны сезнең исемгә рәсмиләштерик.

Майор Солдатов моның ни икәнен бик тиз анлады билгеле.

— Санап карагыз, риза булыргамы, юкмы икәнен әйтермен, — диде ул. — Анда ватылганнары, кителгәннәре дә бардыр. Бу инде «бу»га (бывшего употребления) керә.

— Әйе, шулай рәсмиләштерәбез. Сезгә бик авырга туры килмәс. Акчасын кассага кертерсез. Кирәкле кәгазьләрне дә алырсыз. Безнең гаражны төзегән осталар стенаны күтәреп тә куяр.

Монда оттыручы булмады. Бөлгенлеккә чыккан завод мөлкәтен сатканда кирпечне шактый арзан бәядән кулга төшергәннәр иде. Фирма ихтыяҗларын үтәргә дә җитте, байтак кына калды да. Солдатовка арзан бәядән бирсәләр дә, башкалардан, юл-транспорт чыгымнарын да өстәп, артыгы белән каердылар. Фәһим Фәрхетдиновның үз кесәсе дә калынаеп калды. Эшли белгән кешегә хәзер мөмкинлекләр күп. Энесе Фазылга җилянгыр тимәде. Иң кыйммәтлесе шул: әллә кемнәр тикшереп караса да, гаеп табарлык түгел.

«Солдат йоклый — хезмәте бара» диюләр чүп кенә ул, майор халыктан кергән хатларны караштыра, шушы шаукымда аның ике катлы коттеджы күтәрелә. Чуртан кушуы беләнме бу, әллә «чурт кушуы» беләнме?!

* * *

Каникуллар Нурания өчен котелгәннән дә киеренкерәк килеп чыкты. Әнисе укуда булгач, өйдә дә бөтен эш аның өстендә. Бакчада да эш муеннан. Чүп утау да, «ерактагы дуслар бүләге» — колорадо кондызын җыю да бирә кирәкне. Әтисе җәмәгать эшләре белән чаба, ашарга да йокларга гына өйгә кайта. Ана үпкәләп тә булмый, «интернациональ бурычны үтәргә» дип утларга кергәннәрнең, саулыкларын югалтканнарның кайгысын кайгыртып чаба ул. Ит комбинаты директоры белән тәмам чиләнеп бетте. Кеше хокукларын яклау буенча вәкил булышмаса, Әфганстанда аягын калдырып кайткан иптәшенә фатир тәтеми иде.

Каюмнур кызы Нурания белән дә яну-көюләрен бүлешә. Власть ияләренә бик үпкәле ул. Әфганстаннан яраланып кайткан подполковник бер тиен алмыйча үзенең туган җирендә урындагылар белән даулашып йөрсен инде. Үзе өчен түгел, сугыш кырларыннан гарипләнеп кайтканнарны кайгыртып. Күбесенең рәтле фатиры юк, кемдер даруга аптырый. Үлеп калганнарның гаиләләре дә гозерләре белән Каюмнур янына йөгереп киләләр. Алар турында властьлар кайгыртырга бурычлы югыйсә...

Заманында «Сәнгать сәнгать өчен» дигән уйдырма белән бик күп кенә әдәбият һәм сәнгать осталарын харап иткәннәр. Хәзер менә «Власть власть өчен яши» дип уйлыйлар микән?!. Гади кешегә хакыйкатьне табу өчен мең кат үлеп, мең кат терелергә кирәк. Коррупциягә каршы көрәшү өчен махсус хезмәтләр барлыкка килде. Власть белән халык арасындагы упкын тирәнәймәсен диптер, Иҗтимагый палата төзеделәр. Ярый ла бусы да властьлар тегерменәнә су коймаса!

Болар турында Каюмнурның үз кызы белән сөйләшүе тикмәгә түгел, Нурания бер елдан юрист дипломы алачак, ул хаклык өчен көрәшнең бик кыен икәнен аңларга тиеш.

Нурания район судында булырга да тырыша, ачык суд утырышларында да катнаша. «Суд процессында катнашучы якларның тигез хокуклыгы һәм аларның үзара ярышы» дигән диплом темасына материаллар туплый. Фәнни-практик конференциядә катнашучыларның борчылып сөйләве урынлы икән. Бөтен җәмгыятьне кузгаткан мәсьәлә бу. Нурания «Суд статистикасы» дигән кулланма белән танышканда хәйран калырлык мәгълүматларга юлыкты. Судларда дәгъвачыларның гаризаларын кабул

итмәү дә, эшне карауны бик нык сузу да очрый икән. Кайбер судьялар чыгарган карарларның шактые югарыда расланмый. Димәк, закон бозылган. Болар әле күзгә күренеп торганнары гына. Судта якларнын тигез хокуклыгын тәэмин итү күп нәрсәгә бәйләнгән шул.

Нурания газетаданмы, журналданмы укыган иде, берәүне бер тавык өчен биш елга ирегеннән мәхрүм иткәннәр. Моның хакында язып та чыкканнар, кинәшмәләрдә судьяның исемен тәрләндергәннәр. Ә гаепләүче белән яклаучыны искә алучы да юк. Алар да гаепле монда. Димәк, яклаучы адвокат гаепләүчегә «тәртәне артык каерырга» ирек биргән, үзенең көчсезлеген күрсәткән.

Диплом темасы Нуранияне бик шүрләтсә дә, йокысыз калдырса да, бер үк вакытта шатландыра да. Ничә ел укып та бу хәтле тирәнгә китеп уйланганы юк иде әле аның. Әтисе сөйләгәннәр дә кеше хокукларын яклауның никадәр четерекле булуын искәртә. Моның да дипломга кагылышы бар.

Нуранияның болай да баш-күз алалмаган чаклары, житмәсә, Мәскәүдән кайткан берәү бәйләнде. «Мин өйләнергә кайттым, сине алып китәм», ди. «Газпром»да шактый гына зур урында икән. Ике сүзнең берендә әйткәне шул: фатиры, дачасы, машиналары — барысы да супер, янәсе.

— Миңа бер генә нәрсә житми; синең кебек чибәр хатын гына.

— Мәскәү хәтле Мәскәүдә ничек үзегезгә тиң яр таба алмадыгыз икән? — ди Нурания, гаҗәпләнгән сыман.

— Минем туган ягымда үскән кызны бәхетле итәсем килә, — ди егет.

— Ә сез аны бәхетле итә алырсызмы соң?

— Бәхетне кем ничек аңлый бит...

— Ә үзегез ничек күз алдына китерәсез?

— Кеше рәхәтләнеп яшәргә тиеш. Ашыйсы килгәнне ашап, киясе килгәнне киеп, барасы килгән жиренә барып. Акча санамыйча яшәп.

— Без шул моңа өйрәнмәгән, безнең барысы да санаулы, эшләп тапкан акча санаусыз була алмый, — дип Нурания аның авызын томалады.

Шуның белән мәскәүленең юлы киселде.

Нурания телефоннан әнисе, Солтания, Нургаяз белән дә сөйләшкәләп тора. Барысын да шатландырган зур вакыйга булган: Инсафны академиягә укырга алганнар.

* * *

Шифалы янгырлар явып узгач, игеннәр күз алдында исәеп киткән шикелле академиягә укырга керүе белән Инсаф та кинәт үзгәрде. Гәүдәсе турайды, иңбашлары күтәрелде, күз карашы да, аяк атлаулары да бүтән хәзер. Вакытында югары белем алмыйча калуы өчен кимсенүеннән дә котылды, ахрысы, кыюлана төште. Өйләнүен дә ашыктыра башлады. Ул инде «Солтания артыннан йөрүче» гашыйк кына түгел, ә аның үзен ияртеп житәкләп барырга ашкынучы ир-егет.

— Мин әти белән әнине чакырам, алар да сине күреп китсеннәр, безгә фатиха бирми калмаслар, — диде ул Солтаниягә кистереп. — Синекеләрне дә дәшик. Булачак кода-кодагыйлар да бер-берсен күрсен, белсен. Шулай яхшырак булыр.

Гөлбаһар элек әйткән сүзләрен кабатларга мәжбүр булды:

— Инсаф балакай, син безнең хәлгә дә кер, — диде ул. — Безне бит укырга жибәрделәр. Моңа зур акчалар тотыла. Без программаны үзләштереп, имтиханнар тапшырып, таныклык алып кайтырга тиешбез. Шунсыз бездән акчаны түләтәчәкләр. Ул бит безнең бер еллык хезмәт хакы кадәр. Солтания аны каян алсын?! Синең дә артык акчаң котырып ятмыйдыр. Шуңа күрә бик ашыктырма. Без эшли башлагач, районга кайтырсың да Солтаниянең

әти-әнисеннән ризалык алырсың. Арттан тавыш чыгарырлык булмасын. Мин дөрес сөйлимме, Солтания?!

— Әлбәттә, дөрес. Монарчы түзгәнне тагын бераз гына түз инде, Инсаф! — дип Солтания сүзгә нокта куймакчы булды. — Өйләнешү генә түгел, яшисе дә бар бит әле.

— Без болай итик, — диде Инсаф, дипломатларча. — Сез кайтып киткәнче үк гариза биреп куйыйк. Сынау вакыты чыкканчы барысы да көйләнер, аннары Гөлбаһар апа әйткәнчә, барысын да җиренә җиткереп туй ясарбыз.

— Иркегез, — диде Гөлбаһар. — Монысы үз иркегездә... Бик хәйләкәр егет булып чыктың син, Инсаф! «Солтания пленга алды» дип шаярткан булдың да, инде аның үзен әсир итмәкче...

— Сез минем өчен әнием кебек, — диде Инсаф. — Сездән яшерен серем юк. Монарчы беркемгә дә болай гашыйк булганым юк иде, нишләп әле мин үз бәхетемне үзем кулдан ычкындырыйм?!

— Син Каюмнурның яшьлеген хәтерләтеп куйдың,— диде Гөлбаһар, күзләреннән бәреп чыккан яшь бөртекләрен сөртә-сөртә. — Ул да шулай бөтереп алды. Үзе Әфганстан сугышына китәргә җыена, мине никахлашырга кыстый. Гариза да язып тормадык шикелле, язылыштык та кайттык. Мин кыз килеш калдым, ул сугышка китте. Бер елдан соң ир белән хатын булып яши башладык. Хәзер боларны сагынып искә төшерәбез. Сезнең дә бу көннәрегез сагынып сөйләрлек булып хәтерегездә калсын.

* * *

Балалар бакчасында Нургаязны сәерсенеп кенә каршы алдылар. Вакытлыча бирелгән катыргы таныклыкны әйләндереп-әйләндереп карагач кына мөдир бүлмәсенә үткәрделәр. Сагаюлары да юкка түгелдер. Кемнәр генә тикшерергә килми. Янгынга каршы көрәш командасыннан да, санэпидстанциядән дә эзне суытып тормыйлар. Бертуктаусыз тикшерәләр. Кыек куллы кешеләр дә туры килгәли. Хәвефле хәлләр турында көне-төне шаулыйлар, телевизорның кайсы каналына бассаң да, хәвеф тә хәвеф.

— Мин тикшерергә килмәдем, — ди Нургаяз. — Мин бергәләп эшләү турында киңәшергә килдем. Балаларга юл хәрәкәте иминлеге кагыйдәләрен өйрәтү буенча уеннар оештырып булмасмы дим. Кечкенәдән өйрәнеп үссәләр, файдасы күбрәк булыр иде. Уеннар оештыру өчен ниндирәк шартларыгыз бар икән?..

— Карап торган кечерәк кенә бер залыбыз бар, — диде мөдир. — Хәзер бераз иркенрәк, балалар бакчадагы мәйданда уйныйлар.

Шулардай файдаланып карарбыз, — диде Нургаяз. — Ризалык бирсәгез, мин аның планын-сценариесен әзерләр идем. Аны бергәләп тикшерербез. Болай кулдан килмәслек эш түгел инде бу. Мин режиссерлыкка укыган идем, тамаша ясауны бераз күз алдына китерәм.

Нургаязның соңгы сүзләре мөдирне сагайтып җибәрде.

— Алдан ук кисәтүем өчен гафу итегез, — диде ул. — Сезгә түләргә безнең акчабыз юк. Махсус белемле кешеләр бушка йөрми.

— Борчылмагыз, мин акча алырга исәп тотмыйм да. Бу ЮХИДИ башлангычы.

— Ул чагында уйлап карарга ярый. Сез, бәлки, балалар үзләре йөртерлек машиналар да юнәтерсез.

— Бер тотынсак, акрын-акрын җайга салыныр. Эшләп карамыйча булмый. Димәк, сез риза?

— Ничек инде риза булмыйсың, — диде мөдир. — Бу бит барыбыз өчен дә кирәк. Без дә сөйләштерәбез балаларга юл хәрәкәте иминлеге турында, без сөйләгән бер нәрсә, сез аны кызыклы тамашага әйләндерә алсагыз, бу

— бөтенләй башка. Сез үзегезнең оешмадан рәсми кәгазь дә алып килерсез инде, «нигә болай?», «нигә тегеләй?» дип тикшереп йөрүчеләргә күрсәтерлек булсын. Кемгәдер ул уен гына булып тоелырга мөмкин, тик ул дәүләткүләм әһәмиятле эш. Бергәләп тырышсак, файдасы тими калмас.

Нургаязга мөдирнең «дәүләткүләм эш» диюе бик ошады. Аның белән бергәләп эшләве дә күңелле булыр.

Өйләренә кайтканда нинди генә планнар корып бетермәде ул. Иң башта светофор ясарга кирәктер. Уты яна торган. Моны өч кесә фонареннән эшләргә була. Пыялаларын кызыл, сары, яшел төсләргә буяп, матур гына бер тартмага урнаштырсаң, чын светофор килеп чыгар. Кызыл, сары, яшел тасмалар белән дә әллә ниләр ясарга була. Бер тотынгач, үзен дә кызыксынып китәсен ул... Инсаф та төрле кызыклар китереп чыгарырга бик оста.

Үз уйлары, үз планнары белән мавыгып бара иде, көтмәгәндә бер «джип» «бөкедән» чыгып, тротуарга очып менде, Нургаяз ничек читкә тайпылып өлгергәндер! Алдарак баручы әби белештермичә калды, машина аны бәрдереп тә китте. Карчык башы белән тимер рәшәткәгә килеп бәрелде, ә кара тәрәзәле кара «джип» берни булмагандай икенче урам чатында машина юлына чыкты да, су кебек агучы ташкынга кушылды.

Бу фаҗигенең бердәнбер шаһите Нургаяз иде. Әби аңын югалтканмы, әллә шундук җан биргәнме — Нургаязның ачыклап торырга вакыты юк иде, ул «ашыгыч ярдәм»гә һәм милициягә хәбәр бирде. Ни кызганыч, машинаның номерын күреп калмаган, кара «джип» икәнен генә һәм карчыкны сул ягы белән бәрдерүен белә.

«Ашыгыч ярдәм» дә, милиция дә озак көттермәде. Нургаяз бөтенесен дә бик җентекләп аңлатып бирде.

Тик әби генә аңына килмичә вафат булды.

Шәһәрдә фаҗига урыныннан качкан кара «джипны» тоту операциясе башлана. Контроль-үткәрү пунктларында һәр машинаны җиз иләктән иләгәндәй итәләр. Олы юлларны, урамнарны гына түгел, тыкрыкларны да актаралар. Зур калада кара төстәге «джип»лар күп шул, бу инде салам эскертеннән энә эзләү шикеллерәк. Әмма барыбер табарга кирәк, мондый адәм яңа фаҗигаләр дә китереп чыгарырга мөмкин...

Нургаяз ерак та китмәде, агачлар арасындагы бер машинага игътибар итте. Кара «джип». Моңарчы аның бу тирәдә күренгәне юк иде. Ерактан гына булса да, номерын да ачыклады. Карчыкны бәрдереп киткән машинага бик тә охшаган.

Ул әлегә гади халык киеменнән генә йөри, шулай да «читтән карап торучыдан» узган инде, җинаять ясаучының эзенә төшәргә булышучы нәрсәләргә күзе үткер. Фатирга кереп тә тормыйча телефоннан шалтыратты:

— Агачлар арасында бер кара «джип» тора, шуның белән кызыксынгыз әле, — диде ул. — Кирәгем чыкса, телефон номерын язып алыгыз. Машинаның сул ягына күз салыгыз.

Кара «джип»ны эзләүчеләр сак кына эш иттеләр. Әйләнә-тирә йортларда яшәүчеләр арасында ыгы-зыгы кубарлык булмасын. Башта берәү машина турысыннан үткән булды, аннары икенчесе әйләнде. Номеры буенча иясен ачыкладылар. Дәүләтов Талип Харис улына теркәлгән. Быел гына кайтарылган, яңа машина, анда энә эзе дә әллә каян күренеп торырга тиеш.

Кояшта кызмасын дип машинаны агачлар арасына куйганнармы?!

Менә кулына чиләк һәм чүпрәк тотып бер ир подъездан чыкты да туптуры машинага таба юнәлде. Көзгедәй ялтырап торган «чибәркәйне» юунын

нигә кирәге чыкты икән? Шунысы да бик сәер: мондый кыйммәтле машина хуҗалары чиләк, чүпрәк күтәреп йөрми. Аларның тәртип башка.

Ул чиләген машинаның сул ягына куеп, эшкә керешәм дигәндә генә каршысында өч ир пәйда булды.

— Безне аэропортка илтмәссез микән? — диде аларның берсе. — Самолетка соңга калабыз.

— Күрәсез бит, машинаны юа да башламаган, кайчан бетерәм әле, диде теге. — Чиләкләп су ташыгач, озакка китә ул. Сез миңа ышанып тормагыз.

— Теләсә кайда машина юу тыелганын белмисез мәллә?! Табигатькә зыян китерәсез ич!

— Миңа акыл сатарга сез кем әле?! Мин үзем табигатьне саклаучыларның башлыгы. Менә мондый кенәгәне күргәнегез бармы?!

— Кая, нинди кенәгә ул? Ә...ә... Табигатьне саклау фондының башкаручы директоры. Дәүләтов Талип Харис улы. Беләсегез килсә, безнең дә кызыл кенәгәбез бар! Сезгә безнең әмерне тыңларга туры килер, машинаны юмыйсыз, без аны тикшерүгә алып китәбез.

— Аның нәрсәсен тикшерәсез?! Машина да, аның иясе дә күз алдыгызда. Күпме кирәк, тикшерегез! Яшерерлек бернәрсәбез дә юк!

— Бу сезнең үзегез өчен кирәк.. Бездә шик туды, урынга барып ачыкламыйча булмый.

— Бәлки, сез машинаны да, мине дә урларга җыенасыздыр, хәзер кызыл кенәгәләләр арасында кемнәр генә очрамый.

— Шуңа күрә тикшерәбез дә. Димәк, сезнең кызыл кенәгәгә дә ышанырга ярамый. Бирегез машина ачкычын. Бездән курыксагыз, милициягә шалтыратыгыз. Машинаның номерын, маркасын әйтегез. Мине тикшерергә алып китмәкчеләр, диегез.

— Башбаштаклыгыгыз өчен җавап бирәсегезне белеп торыгыз! — диде Дәүләтов, тавышын күтәреп. — Тапканнар тикшерер кеше!..

Милиция хезмәткәрләре машина хуҗасының ике кулыннан алып арткы урынга урнаштырдылар, берсе руль артына утырды, инде барысына да билгеле маршрут белән фаҗига булган урынга китеп бардылар.

Ике урам кисешкән чатта машинадан төштеләр.

Барысы бергә салмак кына атлап тротуар буйлап киттеләр. Тимер рәшәткәгә, асфальтка чәчрәгән кан таплары каршында туктап калдылар.

— Бу кан сез бәрдереп киткән кешенең каны түгелме икән?

— Сез мине кемгә саныйсыз?! Монда минем ни катнашым бар! «Эзтабарлар» агач төбендә асфальтланмаган җирдәге машина эзенә игътибар иттеләр. Бу, һичшиксез, бик кыйммәтле табыш. Җинаятьне ачуда ул кире кагып булмаслык дәлил булырга мөмкин. Дәүләтов машинасының көпчәге белән чагыштырып карыйлар, сырлары туры килә кебек. Көпчәкләр яңа, эзләре дә аермачык.

— Сез моңа ничек карыйсыз? — дигән сорауга да Дәүләтовның җавабы әзер иде:

— Көпчәкләр заводта ясала, анда минем өчен генә аерым линия юк, — диде ул.

— Машинаның сул ягында эз калган, көпчәк эзләре дә туры килә — болар бик җитди дәлилләр, махсус белгечләр бөтенесен янә бер кат ачыклар, ә хәзергә без сезне тоткарларга мәҗбүр булабыз, иптәш Дәүләтов!

Мизгел эчендә аның кулларына «беләзек» кидерделәр.

Шик тудыручыларның һәркайсы җинаятьче димәгән, аларны сак астына алу-алмауны суд хәл итә. Ике тәүлек эчендә билгеле булачак бу...

* * *

Алар берничә көн генә элек таныштылар. Зөлхәбирә үз участогындагы бер гаиләгә матди ярдәм күрсәтеп булмасмы дип район башлыгы янына барган иде. Аккалага күптән түгел генә күчкән, яна фондның башкаручы директоры булып билгеләнгән Талип Дәүләтов исә үз эшнәсенең хәлен белешергә кергән. Менә шунда беренче тапкыр бер-берсенә карашып алдылар. Талип Дәүләтов күзе төшкән хатын-кызның күнелен күрә белә, Зөлхәбирәне машинасына утыртып өенә кайтарып та куйды. Шулай танышып киттеләр. Мондый кеше белән араларны ныгытырга Зөлхәбирә үзе дә каршы түгел.

Талип белән Зөлхәбирә арасында мавыктыргыч роман башланырга тора иде. Бүген алар Дәүләтов Ташлыярда эшләгәндә үк салдырып куйган «хан сарае»нда мунча кереп, бассейнда су коенып иркәләнергә тиешләр иде. Дәүләтов үз иномаркасында «яна сөеклесен» алып китәргә, ул яшәгән урамның икенче ягында көтәргә сүз биргән иде.

Килгәндә ул «бөке»гә эләкте. Үч иткән шикелле булды бу. Дәүләтов районда чакта юл хәрәкәте иминлеге кагыйдәләрен «гаишник»ларны пыр туздырганда гына исенә төшерә иде, үзе руль артына утырганда исә бернәрсә белән дә исәпләшмәде. Берничә тапкыр фаҗига да китереп чыгара язды. Зыян күрүчегә фатир биреп котылып калды. Дөресрәге, эшне йомдылар.

Сөйкемле сөяге бардыр инде, Ташлыярдан кудылар — Аккалада тагын да төшемлерәк эш бирделәр. Элитный йорттан үзе сайлап фатир алды. Ә коттедж күптән әзер иде. Кесә тулы акчаң, йөзләгән «дустың» булгач, закон ни ул!..

«Бөке»не читләтеп тротуардан үтәргә теләве дә аныңча. Кемгәдер кагылып китмәсә, бернәрсә дә булмас иде. Талип үзе аны күрми калды, икенче чатта машиналар арасына керү турында уйлап бара иде ул, күзе дә шул якка төбәлгән, тротуарның сул ягыннан баручыга кагылып киткән шул. Тимер рәшәткәгә бәрелмәсә, зыян да тимәс иде дә бит...

Зөлхәбирә урамга чыгып аны шактый көтте, арлы-бирле йөреп тәмам кәефе кырылды. Талип Дәүләтов килеп җиткәч тә юлга чыгарга ашыкмады, машинасын агач арасына урнаштырды да Зөлхәбирә фатирына кереп диванга ауды.

— Чакрымга сузылган «бөке» башыма сукты, — диде ул. — Каты итеп чәй ясап бир әле.

Зөлхәбирәнең дә кәефе бик яхшыдан түгел иде, икәүләп диванга утырып кына чәй эчтеләр.

Бераз тынычлангач, онытылып киттеләрме — Дәүләтовның куллары уйный башлады. Зөлхәбирә дә киреләнеп маташмады. Кунак түрәләрчә вәкарь белән генә сорау бирде:

— Син табибә, менә моңа җавап тап әле, — диде ул.

— Йә, әйтеп кара.

— Башың авыртканда да, эчең авыртканда да нишләргә кирәк?

— Кызык, бик кызык сорау бу. Бу турыда минем башыма килгәне юк әле. Сез бөтенесен беләсез, җитәкчеләрнең белмәгәне юк. Сез табибләрне дә, укытучыларны да, профессорларны да, әдипләрне дә, галимнәрне дә, композиторларны да, җырчыларны да, инженерларны да, игенчеләрне дә, терлекчеләрне дә өйрәтәсез. Башкаларны өйрәтү — җитәкчеләрнең төп һөнәре ул. Ничә ел табибә булып эшләсәм дә, мине дә тоттыгыз, эч авыртуын да, баш авыртуын да басарлык гамәлне белмим мин, — диде Зөлхәбирә, төрттереп. — Сезнең белән ярышып булмый...

Дәүләтов астыртын гына елмаеп Зөлхәбирәне кочагына алды.

— Белмәсәң, бел, — диде ул, күзләрен мутландырып. — Башың авыртса

да, эчең авыртса да яратышып алырга кирәк. Майлаган кебек итә дә куя.

— Сез диван шуның өчен генә кирәк, дип уйлыйсызмы? Сез моңа ияләнгән шул.

— Дөнья өйрәтә ул. Бер бездән генә калмаган.

Дәүләтов җанашын шундый итеп кысты ки, Зөлхәбирә тын алалмыйча торды.

— Үтерәсең ич, аю! — диде ул, әллә ачуланып, әллә хуплап...

«Баш авыртуын да, эч авыртуын да» бастыргач, кунак машинасын караштырып керергә булды. Маскировка өчен кулына сулы чиләк һәм чүпрәк алды. Баксаң, аны көтеп торалар икән...

Милиция хезмәткәрләре операциясендә турыдан-туры катнашмаса да, Нургаяз вакыйгаларның агышы белән таныш иде. Талип Дәүләтовны да танып калды. Чыннан да фаҗигане китереп чыгаручы ул булдымы икән әллә? Гөнаһсына кирә алмый, руль артында кем икәнен ул күрмәде, машинасы охшаган, шуңа күрә милициягә хәбәр дә итте, гаебе булмаса, җибәрерләр. Егетнең язмышын бик буташтырса да, үз районнарында башлык булып эшләгән кешенең җинаятьче булып чыгуын теләми ул. Юк, теләми!

Нургаяз шуның белән үзен юата: гаебе булмаса, Талип Харисович хаклыгын раслый белер, моңа аларны өйрәтәсе юк. Дус-ишләре дә, танышлары да «кодрәт иясе». Аның өчен бик борчылып торасы юк. Нургаяз кебекләргә читенрәк. Әле ярый Инсаф булды, югыйсә нишләп йөрер иде. Дөнья ничек тар диген! Шушындый зур калада — гайре-табигый хәлдә юллар кисешсен инде.

* * *

Кешене тоткарлау — ул әле хөкем итү түгел. Элек шик төшкән кешене — прокурор сак астына алырга санкция бирә иде. Ялгышлар да китә, билгеле. Хәтта бер гөнаһысы булмаганнарны тикшерү изоляторына ябып куюлар да закон бозу саналмады. Гаебе юк икәне ачыкланса, чыгаралар да җибәрәләр, шуның белән вәссәлам. Беркем дә җавап тотмый. Хәзер башкачарак. Шикле кешене сак астына алуны бары тик суд кына хәл итә. Бу инде җаваплылыкны күтәрә. Шунысы да бик катгый: шикле затны сак астына алу-алмау турында суд карары ике тәүлек эчендә, 48 сәгатьтә чыгарылырга тиеш.

Талип Дәүләтовны сак астына алу өчен дәлилләр җитәрме? Тикшерүчеләр моңа кыска гына вакыт эчендә җавап табу өчен бөтен мөмкинлекләрне эшкә җиктеләр. Криминалистлар фаҗига булган урындагы эзләрне дә, машинаны да энә күзеннән үткәргәндәй иттеләр. Нәтиҗәләр Талип Дәүләтов файдасына түгел. Өстәвенә вакыт факторы килеп кушылды. Фаҗига 12 сәгать 45 минутта ясалган. Нургаяз милициягә шундук хәбәр дә иткән. Бу ташка язылган кебек теркәлеп калган. Зөлхәбирә раславынча, Талип Дәүләтов аның фатирына 13 сәгать 05 минутта килеп җиткән. Аерма 20 минут. Күрәмсең, җинаять ясавын белгән Талип Дәүләтов зур юллардан, зур урамнардан аулак урынга чыгып, эзне яшерергә өметләнгән. Машинаны агачлар арасына урнаштыруы да шуңа исәпләнгән. Болар шактый көчле дәлилләр. Аны сак астына алу мәсьәләсен карау өчен судка тәкъдимнамә тапшырылды.

Шимбә көн булуга карамастан, бернинди тоткарлык тумады, дежур торучы яшь судья Памир Янтимиров кичекмичә суд утырышын ачты.

Прокурор икеләнүгә урын калдырмаска тырышып, һәр дәлилне берничә тапкыр кабатлады, Талип Дәүләтовның җинаять ясавы шик тудырмый, янәсе, аны сак астына алмыйча булмый.

Билгеле инде, адвокат аяк терәп каршы чыкты.

— Шикле затны сак астына алу — бу соңгы чик, — диде ул. — Законда каралганча, бу һәр очракта да мәҗбүри түгел. Талип Харис улы Дәүләтовның даими эше, даими яшәү урыны бар. Монарчы суд җаваплылыгына тартылмаган. Ул җәмгыятькә куркыныч тудырмый. Тикшерү барышында нигә аны сак астына алырга ди!? !

Судья бер якка да кушылмыйча үзенчә фикер йөртә: монда бер-берсенә бәйләнгән дәлилләр җитәрлек, алар юкка гына туры килми, тротуар кырыендагы эзләр дә, машинаның сыдырылуы да очраклы рәвештә килеп чыкмаган. Фаҗига урыныннан китеп машинаны агачлар арасында калдыру да — бөтенесе бер чылбырның буыннары. Талип Дәүләтовның салкын акыл белән эш йөртә белүе дә күренә боларда. Аны сак астына алмау тикшерүне катлауландырачак.

Яшь судья ике якның да фикерләрен гаделлек үлчәве тәлинкәсенә салып карый. Прокурор дәлилләре баса төшә. Вакыйгалар мантыйгын да исәпкә алмый булмый. Җентекләп тикшерә башлагач, яңа дәлилләр дә өстәләчәк әле.

Судта «Дәүләтов Талип Харис улын сак астына алырга» — дип карар чыгарылды.

* * *

Һәр көннең үз мәшәкатьләре. Вакыйгалар артыннан йөгереп тә житә алмассың. Әле берничә көн генә элек Талип Дәүләтовны сак астына алу турында сүз куерса, инде аның изоляторда ачлык игълан итүен бик зур яңалыкка әйләндерделәр. Мондый хәбәрләр газеталарга да, радио-телевидениегә дә бик тиз барып житте. Берсен-берсе уздырып язалар. Арада судьяны өйрәтергә теләгәннәре дә бар. Янәсе, ул әле яшь, тәҗрибәсе юк, барлык нечкәлекләрне искә алып бетермәгән, шуңа күрә шик төшкән кешене сак астына алырга карар чыгарган. Даими эше, даими яшәү урыны булган кешегә, моңарчы суд җаваплылыгына тартылмаган кеше белән саграк та булу кирәк иде. Ул бит җәмгыятькә куркыныч тудырмый. Алдан планлаштырып җинаять ясамаган...

Дәүләтовның ачлык игълан итүен «хакыйкать өчен көрәшнең» бер юлы дип бәяләүчеләр бер сүзне әйтеп бетермиләр: аның фонд башлыгы булуын белмәмешкә салышалар. Югыйсә бөтен хикмәт шунда. Фондның башкаручы директорын, миллионнар белән эш йөрткән кешене яклаучылар бик күп. Эшләр уңай якка борылса, алар ук фондны имәргә өметләнәләрдер. Гади хезмәт кешесен кайчак бер гөнаһсызга утыртып куялар, андый ялгышлар киткәли, алар белән «вакланмыйлар». Әле ярый нахакка рәнжетелгән кеше югарырак судка мөрәҗәгать итә ала, бик авырлык белән хакыйкать ачыклана. Ачыкланмый калганнары да бар.

Дөрес, Талип Дәүләтовны иреккә чыгаруны таләп итеп митинглар оештырмадылар-оештыруын, әмма аның сак астында була торып та утны оста уйнатуы бәхәссез иде. Яшь судья Памир Янтимировны менә шулай «чамасыз» шау-шу куптару тынычландырды да. Димәк, ул дөрес фикер йөрткән, дөрес карар чыгарган.

Бу хәлләргә катнашы булган Нургаяз белән Инсаф та тынычлана төште. Юк-юкта Нургаяз шактый борчыла иде. Ул милициягә хәбәр итте, «эзтабарларга» ул юнәлеш бирде. Шул чакта күрмәмешкә салынып үтеп китсә, беркем дә аны гаепли алмас иде. Ә ул хәбәр итте. Машина йөртүченең Талип Дәүләтов булуын белсә, әйтер идеме?! Начармы-яхшымы, күз күргән кеше ул. Нургаяз үзе дә белештермичә аны «батырды» түгелме?!

Аның кичерешләрен бүлешкән сыман Инсаф үзенчә ачыклык кертте:
— Минем дә бөтен курыкканым шул, — диде ул. — Туганнарым,

якыннарым, танышларым әләгүдән куркам. Погон такканмы-такмаганмы, барыбыз да адәм баласы бит инде. Беребез дә робот түгел. Туганыңа да, якыныңа да, танышыңа да каты бәреләсе килми. «Атасын да, анасын да сатканнар», ничек кенә булмасын, юньле бәндә түгел алар. Шуңа күрә туганнарымны да, танышларымны да кисәтеп куйдым: «Карап йөрегез, мине уңайсыз хәлгә куймагыз», дидем. Рәхмәт, сүземне аяк астына салып таптамыйлар. Бүгенге көнгә кадәр берсе дә артык мәшәкать тудырмады.

Сүз кинәт кенә тормышның башка якларына күчте. Инсаф академиядән алып кайткан программаларын, дәреслекләрен Нургаязга берәм-берәм күрсәтте.

— Боларны ничек башка сыйдырырга инде?! — диде ул, авыр сулап.

— Авыр сулама! — диде Нургаяз, шаяртып. — Син моның турында төннәр йокламыйча хыялландың, хәзер инде артка чигенү юк!

— Әле ярый син бар, Ходай безне минем бәхеткә очраштыргандыр. Китап-дәфтәрләр белән эш йөртергә мине тәмам өйрәттең син. Алай гына да түгел, син тормышымның кыйбласын табарга булыштың. Шулай гомер буена бер-беребезгә таяныч булып калсак иде...

— Вакытлары бик тармы, Солтания белән Гөлбаһар апаның бер дә килгәне юк, әллә чакырмыйсыңмы? — дип белеште Нургаяз.

— Мин үземчә план кордым әле. Әти белән әнине чакырам. Солтанияне күреп китсеннәр. Гариза биргәнебезне дә әйтербез.

— Бу инде туйга әзерлекнең башлануы!?

— Алай дияргә дә була. Никахлашырга гариза биргәч, туе да булырга тиеш инде.

— Бәхетле булыгыз!

— Рәхмәт! Миндә тагын бер идея бар бит әле, Нургаяз!

— Нинди идея?

— Каюмнур абый белән Нуранияне дә чакырырга кирәк. Гөлбаһар апа да аларны бик сагынган. Син дә бәгырькәеңне бик юксынасың...

— Өйләрен калдырып килерләр микән соң? Гөлбаһар апа нәрсә дияр?

— Без аңа әйтеп тә тормыйк. Бер сюрприз ясыйк. Шулай җыелып алсак, бик күңелле булачак.

— Идеяң бик матур.

Әби белән бабай да хуплады егетләрне. Алар да Ташлыярда яшәүче уллары белән киленнәрен бик сагынган икән.

Инсаф шундук Ташлыярга — өйләренә телефоннан шалтыратты. Үзенекеләр белән аңлашып бетергәч, янәдән телефон номерын җыя башлады. Бусы — Нурания яшәгән Солтанай авылы, район үзәге. Кесә телефонын уйлап чыгаручыга мең-мең рәхмәт. Күз ачып йомган арада дөньяның әллә кай якларына барып җитәсең. Солтанай да бик тиз җавап бирде. Инсаф телефонын Нургаязга сузды.

— Исәнме, җаным! — диде дә Нургаяз, иң кирәкле сүзне табалмагандай, бер мәлгә тынып калды. Нураниянең:

— Сез анда ничек яшисез? — дигәне ишетелде.

— Сезне сагынудан башка борчылырлык нәрсәбез юк, — диде Нургаяз. — Гөлбаһар апа да, Солтания дә сезне бик юксыналар. Әллә бу ялда килеп китәсезме!? Килсәгез, бик сөенер идек. Каюмнур абыйны да күндер инде, әле атлыгып торадыр. Көтәбез! Үбәм үзеңне... Рәхмәт!

Егетләрнең осталыгын белсәләр дә, табынны Гөлбаһар белән Солтания үзләре әзерләргә булдылар. Өй эшләреннән беразга аерылган Гөлбаһар хуҗабикә мәшәкатьләрен сагынган иде. Ул үзе изгән, үзе баскан камыр исен тансыклады. Өйләрендә пешергән ризыкларның исе урамга кадәр

чыга. Каюмнуры да, балалары да аны әллә каян танып, елмаеп кайтып керәләр. Ирен яратып, балалары өчен шатланып яшәгән хатын-кызга моннан да артык бәхет юк сыман. Кешенең сау-сәламәт яшәве киеменә дә, алтын-көмешләренә дә түгел, беренче чиратта ничек туклануына бәйләнгән. «Ашау өчен түгел, яшәү өчен ашаган» кешеләрнең рухы да көчле була.

Инсафның әти-әнисе дә, Каюмнур белән Нурания дә буш кул белән килмәделәр. Хәзер бакчаларның гөрләгән чагы. Ул җиләкләрен күрсәң, шундый эреләр, хуш иселәр, сокланып карап торырсың. Июль ае башына кыяр да өлгерткәннәр. Авызга кабу белән эреп китә. Тәмләткеч үләннәрне дә онытмаганнар.

Ата-ана уллары Инсафның кәләше Солтанияне дә бик ошатты.

— Әтисе белән әнисенең ризалыгын алырга кайчан барасыз? — дип тә кызыксындылар.

— Укуларын бетереп районга кайткач була инде, — диде Инсаф. — Шулай сөйләштек. Башта сезнең ризалыкны алырга теләдек.

Инсафның әнисе Солтаниянең иннәреннән кага-кага:

— Без сине үз балабыз кебек якын итәрбез, — дип әйтеп куйды. — Сез матур яшәсәгез, без дә бәхетле булырбыз. Әби белән бабайның да картлык көннәре матур булсын иде...

— Әби белән бабайны мин бер күрүдә ошаттым, сез дә күңелемә якын булып киттегез, — диде Солтания. — Рәхмәт сезгә!

— Бәхетле булырга сезнең бөтен нәрсәгез бар, — дип куәтләде Инсафның әтисе. — Еллар авыр, дип зарланып ятмыйбыз, үз көнебезне үзебез күрерлек, дөнья беркайчан да без теләгәнчә генә булып бетми ул.

Каюмнур белән Гөлбаһар да, Нурания белән Нургаяз да — барысы да бик бәхетле иде. Бәхетне әллә кайлардан эзләргә кирәкми, ул безнең гамәлләребез, яратуыбыз-яратылуыбыз, игелекле юлларда калган эзләребез. Ул — безне тудырганнарның сөенечле күз карашы, үзебез тудырганнарның мәрхәмәтле булуы, игелек кылуы. Ул ил, халык кайгысын күтәрешү дә. Ил мәнфәгате башыңнан чыгып бетсә, йөзеңне югалтасың. Бәхетне тотып булмый, тоеп кына була. Бәхет ул өй эченә генә сыешып бетә алмый. Биек-биек коймалар, тимер капкалар белән уратып та бәхетне саклап булмый. Ул ирекле мәгърур кош сыман. Оя корган җире тәнне генә түгел, җанны да җылытып тормаса, анда бәхет үсеп, ныгып китә алмый.

Инсаф белән Солтаниягә әти-әнисенең, әби-бабасының фатиха бирүе барысы өчен дә олы шатлыкка әверелде.

Кунаклар таралышкач, Нуруллиннар янәдән кара-каршы утырып киңәшләшеп алырга булдылар. Өч буын бергә алар. Иң өлкәне — Сафа Нуруллин, аның улы Лотфулла һәм өченче буын Инсаф. Каенана белән килен. Алар да гомер буена ана белән кыз кебек яшәделәр. Болай очраша алу — зур бәхет. Инсафны өйләндерү — шушы түгәрәк тормышны саклау, кайгырту ул.

Башлы-күзле булгач, иң кирәге нәрсә? Башыңны куеп йокларлык урының булырга тиеш. Үз куышың, үз почмагың. Бу яктан Инсафның кайгысы юк. Әби белән бабайның өч бүлмәле фатиры аның исеменә язылган. Хәзерге заманда моннан да зуррак бүләк мөмкинме?!

— Туйны кайда үткәрәбез? — диде Лотфулла, иң җаваплы кеше булуын сиздергәндәй. Сүзнең шулай башлануы гаҗәп тә түгел. Ташлыярдагы йортларында — Инсафның туган нигезендә иркенрәк булыр иде. Туган-тумача, танышларны чакырырга да уңайлырак. Бакчаларында барысы да өлгерде. Кай яктан карасаң да файдалырак. Әмма иң өлкән Нуруллин моны хупламады.

— Көнелләр иркен булса, монда да сыярбыз, диде Сафа абзый. — Киленне без монда каршылыйбыз, алар монда яшисе. Кода белән кодагыйга да монда килүе җайлырак булыр.

Барысы да килеште аның белән. Әлбәттә, Ташлыярга да, Солтанайга да кайтырлар, яшьләрне күрергә теләүчеләр табылыр. Бирсен Ходай.

Туй чыгымнарын да санап карадылар. Бусы да көчтән килмәслек түгел. Кода белән кодагый өлешенә исәп тотарга да кирәкми. Өч буын Нуруллиннар исән-имин чакта мондый гына мәшәкатьләрне күтәрмәслекме соң?!

Энәсеннән алып җебенә кадәр дигән шикелле һәммәсен дә кат-кат санадылар, «монысы белән нишләрбез икән?» дип баш ватарлык бернәрсә дә килеп чыкмады. Барысын да хәерлегә юрадылар.

Инсафның әтисе үзенең кайбер йомышларын да улына җиткерергә кирәк тапты.

— Синең ГАИда эшләвең миңа да карашны үзгәртте,— диде ул ачыктан-ачык. — Хәзер бит машинасы булмаган йорт юк. Билгеле инде, тегенди-мондый гаепләре дә килеп чыккалый. «Инсаф булыша алмас микән?» дип әйтүчеләр дә байтак. Мин бик ышандырырга тырышмыйм. «Аларны да тикшереп кенә торалар» дип үземчә акланган булам. Әмма арада бик кирәк кешеләр дә бар. Безнең завод директорының бертуганы машина йөртергә таныклык алалмый интегә. Өч тапкыр имтихан тапшырып караган, гел яндыралар икән.

— Анда компьютерга җавап бирергә кирәк шул, — диде Инсаф. — Ялгыш җибәрсәң, берни эшли алмыйсың. Аларның эшенә тыкшынырга бик авыр.

— Шулайдыр, — диде ата кеше. — Шулайдыр. Тик хикмәт компьютерда гына микән? Компьютерның да «башын әйләндерә» беләләр хәзер. Имтихан саен акча түләргә кирәк ич. Барысы да шул акчага барып тереләдер кебек. Ул кешене беләм мин, башы да бар, акылы да бар. Кулыңнан килсә, берәр әмәлен тапмассың микән? Завод директорының сүзен аяк астында калдырмыйсы иде.

Инсаф та мондый «әкәмәтләр» турында ишеткәли, әтисе хаклы, «компьютерларның башын әйләндерүчеләр» кайда гына юк. Тик «осталар» белән бөеренә таянып сөйләшеп булмый. Алай зурдан кубып сөйләшергә Инсаф кем соң әле ул?!

Шулай да егет әтисе каршында бик җебегән булып та күренергә теләмәде.

— ЮХИДИ бүлегенә жалоба язсын, — диде ул. — Хәзер тикшерүдән бик куркалар. Хатның күчермәсен миңа да калдырып китсен. Мин аны контрольдә тотармын.

Инсафның әнисе дә «йомышның» гади генә түгеллеген аңлатты:

— Моны син булдырырга тырыш инде, балам, — диде ул, йомшак кына. — Икебез дә шул заводта эшлибез бит. Безнең дә йомыш гел чыгып тора. Йортны, бакчаны тоту җиңел түгел. Тегесен дә, бусын да директордан сорарга туры килә.

Инсаф әтисе белән әнисен бик яхшы аңлый, алар шушы завод белән аякка басканнар. Слесарь булып эшли башлаган әтисе хәзер смена башлыгы, әнисе әзер продукцияне кабул итү участогын җитәкли. Икесе дә хөрмәтле кеше. Завод булышлыгы белән заманча йорт җиткерделәр. Инсафны да заводка урнаштырмакчылар иде, әбисе белән бабасы янына китәргә кирәк булды. Хәзер менә завод директорының да аңа гозере төшкән. Инсаф чамасыз кыланмый, шулай да кирәк кешеләрен кире борып та җибәрми. Бу юлы да җаен табачак ул...

* * *

Бүлек башлыгының һәр көне бик киеренке. Юлларда ни генә булмасын, берсе дә аны читләтеп узмый. Житәкчеләр белән эш йөртүләре дә пәке йөзеннән бару кебек. Көтмәгәндә-уйламаганда Нургаяз да көндәлек мәшәкатьләрнең үзәгенә керде. Янтимиров белә: тротуарда кеше бәрдереп китүченең эзенә төшүдә ул төп геройга әйләнергә мөмкин. Әгәр судта аның версиясе расланып, хөкем карары чыкса, егетнең сизгерлеген махсус боерык белән билгеләп үтәргә дә кирәк булачак, аны эшкә алу да үзеннән-үзе хәл ителәчәк.

Бүлек башлыгын тагын бер нәрсә Нургаяз белән бәйли: Талип Дәүләтовны сак астына алу турындагы тәкъдимнамәне Янтимировның улы — яшь судья Памир Янтимиров карады. Аның адресына каты-каты сүзләр дә әйткәләделәр, имеш, ул тәжрибәсезлеге аркасында кирәгеннән артык каты карар чыгарган, Дәүләтовны сак астына алдырырга ашыккан. Бу «Эш»нең чишелеше Нургаязның да, улының да киләчәк язмышына бик нык йогынты ясарга мөмкин. Алай гына да түгел, бөтен бүлекнең абруена да кагыла бу. Башлыкның үзенә дә. Ул әлегә аттестация дә узмаган, гражданнар киемендә генә йөрүче Нургаязны үз бүлмәсенә чакырып сөйләшеп карарга кирәк тапты.

Озын буйлы, нык бәдәнле егет башлыкка бер күрүдә ошады. Сөйләшә башлагач, тагын да күбрәк ошады. Сүзе мәгънәле. Гүяки гомер буе монда эшләгән, үзен бик иркен тота, юл хәрәкәте иминлегенә кагылышлы мәсьәләләр турында кыю фикер йөртә. Талип Дәүләтовны сак астына алуның хасиятен дә ачып бирде.

— Изоляторда килеш тә суны ничек болгата, иректә калса, нишләмәс иде, — диде ул, һич кенә дә икеләнмичә. — Зур кешеләрнең вак эшләре үзләренә бик кыйммәткә төшә. Гадиләргә ярамаган аларга ярый дип бик ялгышалар.

— Болай булгач, Дәүләтовның гаебе расланыр дисеңме?

— Анысын инде суд хәл итәчәк. Мин бит аның үзен жинаять өстендә тотмадым. Мин кара «джип» икәнен беләм. Карчыкны бәрдереп китүен үз күзем белән күрдем. Шуңа охшаш машинаны агачлар арасында күреп алдым. Гражданин буларак милициягә, «Ашыгыч ярдәм»гә хәбәр иттем. Калганы миннән тормый.

Күпне күргән, күпне кичергән Янтимиров, тыштан сиздермәсә дә, шактый ук дулкынланып китте, Нургаяз ана үз улыдай бик якын тоелды. Режиссерлыкка укыган шул, кешеләрне тыңларга өйрәнгән. Үзенең дә һәр сүзе урынлы, шулкадәр килештереп әйтә. Юкка гына кызыл диплом белән институт тәмамламагандыр инде. Аның сиземләве дә аерылып тора.

Бүлек башлыгы әле эшкә дә урнашып бетмәгән кешеләр белән артык аралашмый, мондый вак-төяк мәшәкатьләр башкаларга йөкләнгән. Дәүләтов «Эше» уңаеннан улы чыгарган суд карары тынгылык бирми ана. Менә Нургаяз сөйләгәннәрне тыңлагач, фикере ныгый төште. Улы хаклы булырга тиеш.

Янтимиров үзен дә күрсәтә белә. Ул Нургаязның тормыш хәлләре, киләчәккә планнары турында да сораштыра башлады.

— Минем киләчәк планнарым сезнең боерыкка бәйләнгән инде, — диде егет ачыктан-ачык. — Эшкә алсагыз, күңел биреп эшләргә исәп бар. Ошый миңа монда. Көндәлек эшләрдән тыш сержант Нуруллин белән бергәләп балалар бакчаларында, мәктәпләрдә юл хәрәкәте иминлеге кагыйдәләрен өйрәтү буенча төрле уен-тамашалар оештырырга да җыенабыз. Беләсезләр, ул академиягә укырга керде. Мин белемем буенча — режиссёр, моның ни икәнен бераз чамалыйм. Майор Солдатов та булышмакчы...

Аны тыңлый-тыңлый Янтимиров әллә ниләр уйлап бетерде, ул бүгеннән үк Нургаязны эшкә алу турындагы боерыкка кул куярга әзер иде, тик «сынау вакыты узып барганда моның кирәге бар микән?..» дип ашыктыруның мәгънәсен тапмады.

* * *

Нургаяз куйган спектакль нефть чыккан якларда тиз арада зур уңыш казанды. Театрны башка районнарга да чакыралар. Юл чыгымнарын капларга акча бирүчеләр дә табылды, һәркайда заллар шыгрым тулы, алма төшәр урын да калмый. Театрның Аккалага гастрольләре планлаштырылган иде, спектакльне анда да алып барырга булдылар. Бу турыдагы хәбәрләр Нургаязга да килеп житте.

Театрдан суына башлаган күңел кинәт дөрләп яна башлады. Пыскып яткан күмерләргә кемдер өреп җибәргәндәй итте. Нургаяз ЮХИДИга ике куллап ябышкан кебек иде инде, ул тагын тынычлыгын җуйды. Бүлек башлыгы Янтимировка әйткән сүзләрен дә җилләр алып китте сыман. Нураниянең хуплаулары да әллә кайда — томан артында калды кебек. Юк, театрны алай җиңел генә күңелдән алып атып булмый шул. ЮХИДИ аңа бүген тормышта бәрелә-сугыла йөрмәс өчен, тернәкләнеп китү өчен кирәк. Монда ул тотрыклы хезмәт хакы алачак, тамагы тук, өсте бөтен булачак. Вакыты белән торакны да көйләп куярлар. Күпләр, бик күпләр шулай яши, шулай көн күрә. Нургаяз да шушы җир кешесе. Тик хыяллары яңадан баш күтәрде. Аларны тыеп булырмы соң?!

Афишаларда үзенең исемен күргәч, Нургаязга канатлар үсеп чыкты сыман. Таныш-белешләр дә күреп алганнар. Телефоннан шалтыраталар, котлыйлар.

Солтания дә игътибар иткән.

— Бу спектакльне бергәләп карамыйча булмый инде, — диде ул. — Дүртәүләп барырбыз. Аккалага килеп хет бер тапкыр театр күреп калырбыз. Сиңа билет бирерләрдер инде...

Нургаязның күңеленә хуш килде бу тәкъдим. Югыйсә үзе куйган спектакльгә «культпоход» оештырырга уңайсызланыр иде. Солтания әйткәч, рәхәтләнеп риза инде.

Билетлар белән авырлык килеп чыкмады. Директор үз фондыннан дүрт билет бирде.

— Сина рәхмәт тә әйткән юк, — диде ул. — Минем сүздән чыкмадың, юк-бар белән маташмадың, эшкә бөтен күңеленне бирдең. Безнең тәвәккәллек зыянга булмады. Спектакль гөрләп бара. Синдә өмет бар, Нургаяз, өмет бар...

Спектакль буласы көнне Нургаяз ничек дулкынлануын үзе генә белә. Бераз тынычланмаммы дип өйләрендә әллә нихәтле эш эшләп атты. Бу көнне Инсаф бик җаваплы эшне юлга салды — әтисенең гозерен үтәргә тиешле кеше белән аңлашып кайтты. Шикәр заводы директорының туганы имтихан бирә алмыйча аптырап йөрмәячәк хәзер. Компьютер аны «аңлаячак».

Өйдәге хәлләрне күреп тә Инсаф ничек кенә шатланмады.

— Күңелдә шатлык булганда спектакль карарга да ярый, — диде ул, хискә бирелеп. — Матурлык коткарыр дөньяны дип тикмәгә генә әйтәләрме?! Матурлык матурлыкка юл күрсәтә...

Гөлбаһар белән Солтания бик вакытлы килеп житте. Спектакль башланганчы фойедагы күргәзмәләр белән дә танышырга мөмкин. Бусы үзенчә хозурлык. Нинди олы затлар уйнаган сәхнәдә бүген Нургаяз куйган спектакльне күрсәтәчәкләр. Моның ни икәнен аңлатып бетереп тә булмый.

Нургаяз таныш-белешләре күзенә чалынырга бик теләмәсә дә, күрәләр шул, каршыга елмаеп киләләр, котлыйлар, яна уңышлар телиләр. Берәү дә режиссер буласы егет ЮХИДИга урнашып йөри дип башына да китермидер. Бергәләп залга үттеләр, билетларда күрсәтелгән урыннарга утырдылар.

Спектакль башланды. Нургаяз сәхнәдәге вакыйгаларны беренче тапкыр күргән кебек тынсыз калды. Артистлар уеннарын бик нык шомартканнар. Тормыштагы фаҗигаләрне сәхнәгә менгереп кенә куйганнар диярсең. Кайнар ноктага эләккән авыл малаеның газапларын бөтен зал бергәләп кичерә. Бер ай гына элек цинк табутта солдатның «үле гәүдәсен кайтарганнар», авыл белән аны җиргә индергәннәр. Сөйгән кызы күз яшьләренә буылып кабер яныннан кайтып килгәндә авылда яна хәбәр тарала: аның егете исән икән, Мәскәүдән телевизордан күрсәткәннәр.

Ике кулсыз калган егетне авылга кайтаралар. Авыл халкы шакката. Егетнең әнисе аңын югалтып егылган, табибләр аны саклап калу өчен көрәшәләр. Солдатны күкрәгенә кысып сөйгән кызы юатмакчы. Тик егет аны да якын җибәрми...

Сәхнәдәге тетрәнү залга күчә.

Егет: Мин болай да газапларыма чыдый алмыйм, газапларымны арттырма, җаным! Ничек инде без бергә була алыйк! Мин бит сине кысып кочаклый да алмыйм. Минем сине бәхетсез итәргә хакым юк.

Кыз: Мине кем бәхетле итәр дип уйлыйсың соң?! Сине кем бәхетле итәр дип уйлыйсың?! Без икәү бергә булганда гына бәхетсезлекне җиңәчәкбез! Ишетәсеңме, икәү бергә генә бәхетсезлекне җиңәчәкбез!

Зал хушсыз калган кебек булды. Кинәт кул чаба башладылар. Тамашачылар аяк өсте басып артистларны алкышларга күмделәр.

— Авторны — сәхнәгә! Режиссерны — сәхнәгә! — дигән авазлар кабатланды. Әмма Нургаяз урыныннан кузгалмады. Артистлар уртасында калган баш режиссер кул изәп чакыргач кына, ул, рәтләр арасыннан чыгып, сәхнәгә күтәрелде. Алкышлар тагын да көчәеп китте. Әле исемен дә белеп бетермәгән егеткә кызлар чәчәк бәйләмнәре тапшыра. Кыюраклары үбеп тә алалар.

Мондый чакта җитәкчеләр дә үзләрен күрсәтеп калырга тырыша, билгеле. Мәдәният министры урынбасары гаҗәеп спектакль тудыручылары белән бөтен коллективны кайнар котлап, иң изге теләкләрен ирештерде. Нургаязны да читләтеп үтмәде.

— Иртәгә вакыт табып минем янга кереп чык әле, — диде ул. — Көндезге сәгать икедә килә аласынмы?

— Тырышырмын, — диде Нургаяз. — Нәкъ сәгать икедә.

Җәйге кичләр озын. Спектакль тәмамланганда да караңгы төшеп өлгермәгән иде әле. Көндезге челлә инде шактый сүрелгән, сулыш алулары да рәхәт, тамашачылар да өйләренә кайтырга бик ашыкмыйлар төсле. Урамга чыккач та Нургаязны әле тегесе, әле бусы сәламли. Юлдашлары — Гөлбаһар апасы да, Солтания белән Инсаф та һаман рәтләп сүз башлый алмыйлар. Инсаф чакырткан машинага утыргач та сүз белән бик мавыкмадылар. Медицина академиясенең тулай торагы аулак кына бер тыкрыкка урнашкан, шунда кайтып житкәч, телләре чишелде.

— Бу чыннан да булган хәлме соң? — дип белергә ашыкты Солтания. — Кайсы районда булган вакыйга бу?

— Ничек аңлатыйм икән? — диде Нургаяз. — Мондый фаҗига теләсә кайсы районда да бар инде. Бер гөнаһсызга бәхетсезлеккә юлыгучылар бик күп. «Кайнар нокта» дигән сүзе каян чыккан аның?! Кемгәдер «кайнар нокта» гына, кемгәдер җәһәннәм. Бөтенесен йөрәк аша үткәреп туды инде бу спектакль.

— Сиңа моны ничек ышанып тапшырдылар соң? — диде Инсаф. — Студент башың белән моңа ничек йөрәгең житте?

— Миңа диплом алу өчен спектакль куярга кирәк иде, бу театр безнең Ташлыярдан киткән театр бит, шуңа күрә читкә этәрмәделәр, мин аларның ярдәменә исәп тоттым. Спектакль уртак хезмәт жимеше ул. Рәхмәт инде үзләренә.

— Солдатов бүлмәсендә сейфка «бәйләнеп» тә шаккатырган идең, бүген тәмам сихерләдең, — диде Инсаф. — Безнең ЮХИДИга гына сыеп бетәрсең микән син? Берәр театрга чакырырлар үзеңне дип курка да башладым инде. Аттестация узарга торганда гына бутап куймасыннар тагын...

— Бу яктан борчылма. Синең өйрәтүләрне юкка чыгармам, дускай, — диде Нургаяз. — Бернәрсәне очламыйча икенчесенә ябышырга ярамый.

Бу сүзләре белән ул Гөлбаһар күңелендә бөтерелгән сорауларга да җавап бирде, ахрысы.

— Анда-монда чакырсалар да, бик ашыкма, — диде Гөлбаһар. — Башта ЮХИДИга төпләнеп кара әле. Тормыш ул катлаулы, уйлап эш йөртсәң дә таманга килә.

Алар сәнгать кешеләре түгел, аның бөтен нечкәлекләрен белеп тә бетермиләрдер, сораулары да мәзәк тоелырга мөмкин, тик шунысы бәхәссез: спектакль барысын да тетрәндергән, шундый эшләргә сәләтле Нургаязның алар белән бергә булуы бер могжиза сыман...

Гөлбаһар ире Каюмнур сөйләгәннәрне дә искә төшерде. Бу спектакль аңа бик тә ошар иде. «Кайнар нокта»ларда яшьлеген, саулыгын, хыялларын калдырып кайтканнарны монда да бик иркәләмиләр бит әле. Вак-төяк йомышлар белән дә аптырап йөрергә мәжбүрләр. Алар хакын хаклап иренең ничек чабуларын Гөлбаһар үз күзе белән күреп тора.

Ут эчендә кылган батырлыклары өчен күпләр орден-медальләргә лаек булган, дистә еллар узса да, бүләкләрнең күбесе әле һаман ияләренә барып житмәгән. Бу спектакльне власть башында утыручыларга күрсәтергә иде!..

— Театрга алып баруың өчен зур рәхмәт, шундый спектакль куюың өчен мең рәхмәт, Нургаяз! — дип Гөлбаһар эскәмиядән торды. — Керсәк тә ярыйдыр, Солтания.

— Сез керә торыгыз, без аз гына әйләнеп килик әле, — диде Инсаф. — Киче бик матур бит.

Нургаяз Гөлбаһар апасын озатырга булды, Инсаф белән Солтания култыклашып тыкрыкның икенче ягына таба юнәлделәр. Егерме адымнар киттеләр микән, каршыларына әзмәвердәй дүрт малай килеп чыкты. Инсаф белән Солтанияне уратып алдылар.

— Кызыңны безгә биреп тор, — дип берсе Солтанияне үз ягына тарта да башлады.

— Матур чакта китегез, егетләр! — дип Инсаф тегеләрне тынычландырмакчы иде, аргта басып торганы каты итеп муенына сукты.

— Давай, тарткалашып торма! Бездән сиңа да кала әле ул... — диде. Инсаф аның тез астына тибеп жиргә екты. Икенчесен дә сугып аударды.

Солтания «Коткарыгыз! Коткарыгыз!» дип кычкырырга гына өлгерде, икәү берьюлы аңа пычак белән кададылар. Шул ук канлы пычаклар Инсафның да йөрәген телгәләде.

Тулай торак ишеге төбендә Солтания белән Инсафны көтеп торган Нургаяз «Коткарыгыз!» дигән тавышны ишетеп, ярдәмгә йөгергәндә юл кырыендагы машинадан аттылар, ул асфальт өстенә сыгылып төште.

Бер-бер артлы өч кешенең гомерен өзгән адәм актыклары төрлесе төрле якка сибелде...

Аулак тыкрык кинәт тавыш-гауга белән тулды. Солтанияне күтәреп борчыла башлаган Гөлбаһар тәрәзәдән урамга караш ташлады. «Ашыгыч ярдәм», милиция машиналарынын хәвефле кычкыртуларын ишетеп, чак кына хушын югалтмады.

«Безнекеләр белән нидер булган мәллә?» дип атылып урамга чыкты. Үлекләр яткан урыннарны милиция әйләндереп алган, кешеләрне якын җибәрмиләр, шулай да Гөлбаһар шәйләде: Солтания, Нургаяз, Инсафны харап иткәннәр...

Йөрәге аркылы яшен яшьнәп узгандай итте, аякларында ничек басып калгандыр — әйтүе дә кыен.

— Һәлак булучыларны танучылар юкмы? — дип белеште милиция хезмәткәре.

Көч-хәл белән ике-өч адым ясап, Гөлбаһар алга чыкты.

— Мин таныйм аларны, — диде ул. — Һәркайсын беләм. Бусы — Солтания, минем белән бергә укый иде. Тулай торакта бер бүлмәдә яшәдек тә. Монысы — Инсаф, ЮХИДИ хезмәткәре. Нургаяз да ЮХИДИга урнашып йөри иде...

Гөлбаһар чак кына аркан аумады.

— Су бирегез! — дип әйтеп өлгермәсә, ни буласын кем белгән. «Ашыгыч ярдәм» табибе белән шәфкать туташы аңа дару каптырдылар, су эчерттеләр, Гөлбаһар аңына килеп күзләрен ачты.

— Мине бүлмәгә кертеп яткырыгыз, — диде ул, хәзер үтәргә тиеш, үтәргә тиеш...

Табиб белән шәфкать туташы аны ике кулыннан алып тулай торакка алып керделәр, урынына яткырдылар. Янына гына кирәкле даруларны куйдылар. Әмма барыбер ялгызын гына калдырырга ярамый иде, күрше бүлмәдән бер ханымны чакырдылар.

Табиб белән шәфкать туташы киткәч, милиция хезмәткәре кереп чыкты. Артык бер сүз дә әйтмәде.:

— Сез аны берүк саклый күрегез, — дип караватъ янында утыручы ханымны гына кисәтте.

Күпме авыруларны саклап калган Гөлбаһар үзен дә кулга алды. Маңгаеннан бәреп чыккан салкын тир бөртекләрен уч төбе белән сөртеп җибәрде.

— Үтә, үтә, — диде ул үз-үзенә. Аннары янында утыручы ханымга рәхмәтен белдерде.

— Әлбәттә, уза, уза, — дип җөпләде тегесе.

— Миңа сумкадан кесә телефонын алып бирегез әле.

— Кая шалтыратмакчы буласыз?

— Өйгә. Бу хәлне ирем белән кызыма әйтмичә булмый.

— Әллә бераз түзикме?!

— Нигә алай дисез?

— Борчылып төнгә каршы юлга чыгарлар. Төнге юлда ни булмас?!

— Сезнең сүз дә дөрес. Иртә белән шалтыратырбыз. Алырга килегез, диярмен.

— Аларны да куркыныч астында калдырырга ярамый.

— Солтаниянең әти-әнисенә ничек хәбәр итәргә икән? Монысына башым җитми, — диде Гөлбаһар. — И..и... Ходаем, безне ярдәменнән ташлама инде...

Кинәт ул кычкырып елап җибәрде. Янында утыручы ханым су китереп:

— Әчегез, әчегез, — дип кабатлады. — Тынычланыгыз. Кайгы агач башыннан түгел, адәм башыннан йөри шул. Тынычланыгыз.

— Егетләрне дә көтәләр бит. Алар белән нишлибез?

— Хәсрәт ничек кенә авыр булмасын, аны яшереп калып булмый.

— Минем көчем җитми, әби белән бабайга сез шалтыратыгыз, — диде Гөлбаһар.

Берьюлы өч кеше — Солтания, Инсаф, Нургаязның гомере өзелү ачысы аерым бер гаиләләргә генә сыеша алмады. Халык нәфрәтенең иге-чиге юк. Төрлечә юрыйлар. Үч алырга теләгәннәрдер, диючеләр күбрәк. Кем нәрсә димәсен, бу асыл затларны табып үстергән ата-аналар ничек түзәргә тиеш?! «Үлем сәбәпсез булмый» дип кенә юанып утыра алмыйсың бит. Монда нинди сәбәп бар?! Бөтен сәбәп шул: кеше булып туу. Кеше булып яшәргә омтылу. Гашыйк булып сөйгәнең белән җәйге кичтә култыклашып йөрү сәбәп булдымы?! Театрга барып спектакль карау сәбәп булдымы?! Өеңнән чыкмыйча ятсаң да, фаҗигаләрдән качып котылып булмый. Аяныч, бик аяныч, биек-биек коймалар, тимер ишекләр дә бәхетсезлектән саклый алмый. Явызлыкны ничек җиңәргә соң?!

...Солтания, Инсаф, Нургаязның үле гәүдәләрен вакытында җирли дә алмадылар. Суд-медицина тикшерүләре үткәрү өчен мәетләрне сакларга кирәк иде. Моргка аларның аталары, ир туганнары гына кереп чыкты. Хатын-кызлар йөрәге чыдамас дип курыктылар. Менә шундый хәлләргә түз син, адәм баласы!

Мәетләрне машиналарга урнаштырып юлга әзерләнгәндә бабай киңәш бирде:

— Балаларның кырыгына монда җыелыгыз, — диде ул. — Аларның җаннары бу нигезгә кайтыр. Алар өчесе дә үз балаларыбыз кебек иде.

Лотфулланың күзе әтисенең сакал-мыек баскан йөзенә төште. Кайгы-хәсрәт белән моңарчы күзгә чалынмаган. Аны болай калдырып булмый.

— Әти, юлга чыкканчы чәчеңне, сакал-мыегыңны рәтләп өлгерәм әле, — диде ул.

Сабир абзый үзе дә моны көтеп торган сыман Нургаяздан калган приборларны китереп бирде.

— Бик дөрес, улым, авыр чакта да ямьсез күренергә ярамый, — диде ул. Картның тыныч кына әйткән бу сүзләре Нуранияне тетрәндереп җибәрде. Бер баксаң, анда-монда чыгып та йөрми, шулай да пөхтә, матур буласы килә. Ә Нуранияның — егерме бер яшьлек кызның соңгы көннәрдә көзгегә караганы да юк шикелле. Йөрәге урыныннан кузгалып билгесез җиргә күчкән кебек, кая инде монда матурлык турында кайгыртасың... Ул өлкәннәр сүзенә кушылмый да, эчтән яна, эчтән көя. Кыз кешегә онытылып бетәргә дә ярамый шул... Әмма бабай да дөрес әйтә бит. Авыр чакта да йөзеңне югалтырга ярамый.

Нургаязга әйтәсе бик күп сүзләре калды Нуранияның. Нургаязга гына дигән назлары калды. Нургаяз өчен саклаган сафлыгы калды. Нурания бөтенләе белән аныкы буласы иде, барысы да калды. Әле серләре дә калды. Диплом җитәкчесенең Нуранияне дачага чакыруын белсә, нишләр иде икән Нургаяз?! Җавабын табар иде ул. Әйткәне булды бит: «Дөньяда ике мәгънәсез эш булса, берсе — җил саклау, икенчесе — хатын-кызны саклау» дия иде. Җилне дә, хатын-кызны да саклап бетереп буламы?! Тик чын ир-егетләр җилләр каршына үзләре басып, яратканнарын җилләрдән дә, яман күзләрдән — нәфесен тыя алмаганнардан да аралый ала. Нургаязны менә шундый ышанычлы кыя итеп күз алдына китерә иде Нурания.

«Дипломны «5»легә якласам...» дип сүзен әйтеп бетермәгән иде, әллә ни сере дә юк аның, биш тапкыр «Мин сине яратам, Нургаяз, яратам!» димәкче иде Нурания. Тик... «Мин сине яраттым, бәхил бул, җаным!» дияргә генә

калды. Калды!!! Сина дигән бөтен нәрсә калды, Нургаяз! Кызыл дипломың да истәлеккә генә калды...

Инсаф белән Солтаниянең никахларын теркәүне сорап язган гаризалары калды... Инде балаларның жаннары күбәләк булып кайтканны гына көтәсе калды...

АВТОРДАН:

Балаларым, туганнарым шикелле бик якын булып киткән Нургаяз, Инсаф, Солтанияне кинәт кенә югалту үзем өчен дә бик авыр. Аларны бик бәхетле итеп күрәсем килгән иде. Тик саклап бетерә алмадым. Тормыш кырыслыгы миннән көчлерәк булып чыкты. Аларны харап итүчеләрне һаман таба алганнары юк. Һәлак булучыларның ата-аналары тикшерүнең бик сүлпән баруына ризасызлык белдереп, генераль прокуратурага хат язганнар.

Дәүләтовнең жинаятен раслый алдылар. Суд булды, аны дүрт елга утыртырга хөкем карары чыгарганнар иде, әмма бу жәзаны йомшартырлык сәбәпләр «табылды». Талип Харис улы Дәүләтовка хөкем карарын шартлы рәвештә үтәргә ирек бирелде.

Майор Солдатов жырын хәзер яңа «дуэт башкара», йортын да төзеп бетергәннәр. Жил кайсы яктан иссә дә, андыйларның тегермәне тарта.

Инсафның туганнан туган ике сеңлесе— игезәкләр Әнисә белон Нәфисә урта мәктәпне алтын медальгә тәмамлап медицина университетына укырга керде, аларны әби белән бабай үзләренә сыендырды. Кызлар өлкәннәргә бик тә ышанычлы таяныч.

Зөлхәбирә фатирын алмаштырып, затлы йортка күчеп китте.

Нураниянең бик үжәтләнеп судтан— судка йөрүләре, гажәеп бай материал туплавы бушка китмәде, дипломын «5» легә яклады, аны диссертация итеп үстерү турында фикерләр әйтелде. Суд процессында катнашучыларның тигез хокуклылыгын һәм үзара ярышын тәэмин итү өчен бик күп эшләр башкарырга кирәк әле. Гаепләүченең дә, яклаучының да, судьяның да гадел булуы гына житми, судлар эшчәнлегенең сыйфатын, культурасын күтәрү бик мөһим. Бөтен кеше закон каршында бертигез булганда гына, кешене иң зур байлыгы итеп санаган дәүләттә генә моңа ирешергә мөмкин.

Барыбызны да гашыйк иткән Нуранияне Америкага алып китәргә Нью—Йорк профессоры кайткан. Шул Солтанай авылыннан чыккан егет икән. Нураниядән биш ел гына элек мәктәпне тәмамлаган. Әлегә Нурания тәгаен генә җавап бирмәгән. Нургаязның елын үткәргәннән соң ни дияр?..

*2005-2006 еллар, Казан.*



Эльмира
Шәрифуллина

# ОЧЫШТА ДА КҮҢЕЛ СЫНА ИКӘН...

## Ата хакы, ир хакы

МӨНӘҖӘТ

**Ата хакы — олы хак ул, белегез сез,**
**Ата хакын хаклау юлын күрегез сез.**
**Ата хакын хаклап яши өйрәнсәгез**
**Рәхәт тормыш кичерерсез күбегез сез!**

**Ир-ат хакы — бик олы хак, белик шуны,**
**Ирле кеше җиңеп чыгар утны, суны.**
**Тәрбия итик ир баланы, ир-атаны,**
**Яшик гөрләп, тотынышып кулга кулны!**

**Ата-баба нигезләрен саклый белик,**
**Ата-баба хәтерләрен хаклый белик!**
**Угланыбыз Ата булсын, Бабай булсын,**
**Нәселебез ышанычын аклый белик!**

## Заманмыни?

**Үзем җирдә, уем күктә,**
**Хыялларым далада.**
**Уйларым күктә булса да**
**Эшем җирдә — калада.**

**Хыялым очса да иңләп**
**Дөньяны, далаларны.**
**Җиремдә үстерәм ич мин**
**Тудырган балаларны.**

**Җиремнән илһам аламын,**
**Җиремдә гомер юлым.**

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА — *шагыйрә, прозаик; «Уйлы еллар», «Сөюемнән мин чибәр идем...», «Мәхәббәтнең җиде төсе» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Җиремне сөям, кочаклыйм,
Канаттыр ике кулым!

Җиремне зурлап яшәүдән
Яшәрә күңелләрем.
Заманмыни?!.
Дип, заманның
Кырмагыз күңелләрен!

## Югалтасым килми

Югалтасым килми үз ярым,
Син сөекле, газиз, тиң парым.
Сөюемнән килми танасым[1],
Синең белән килә барасым.

Югалтасым килми үз парым,
Син яңгырым, җилем, ак карым.
Бергә булсын юллар, сәфәрләр,
Ялгыз калу юлда хәтәр лә.

Югалтасым килми үз парым,
Ямьле җәем минем, көз, язым.
Бергә үтсен гомер юлыбыз,
Нәсел җебе — тусын улыбыз.

Югалтасым килми үз ярым,
Шатлыгым син минем, таң, назым.
Йөрәгемдә йөргән хисләрнең
Бәян иттем әле бик азын.

## Гүзәл Казаным

Алтын бишегем,
Гомер ишегем
Ачтым мин синдә,
Гүзәл Казаным!
Яшьлек елларым,
Барыр юлларым
Сиңа тоташа,
Данлы Казаным!

Синдә батырлар,
Синдә матурлар,
Синдә көчләләр
Туа, Казаным!

Моңлы сазларың,
Көзең, язларың
Илһамландыра,
Гүзәл Казаным!

Шагыйрьләр иле,
Галимнәр иле,
Шанлылар иле —
Гүзәл Казаным!
Миллионнар иле,
Милләтләр иле,
Татарлар иле —
Данлы Казаным!

## Эчкән суым — таулар бәлзәме

Баш очымда — кояш,
Йөземдә — нур,
Күз алдымда гөлләр, калалар.
Тирә-юньдә төсле шарчык кебек
Йөгерешә нәни балалар.

---
[1] Тану — инкяр итү, баш тарту.

Аяк астым — газиз Туган җирем,
Эчкән суым — таулар бәлзәме.
Кавемеңнең кадерлесе булып,
Яшәүләре үзе — җан тәме!

## Син югында...

Син югында өем ямьле түгел,
Син югында күңел төшенке.
Син барында шатлык качмас кебек,
Кайгы какмас кебек ишекне.

Синең белән дәртле, дәрманлы мин,
Синең белән барам кояшка.
Биеклеккә, бөеклеккә менәм,
Синең белән үсәм мең башка.

Син барында үзе йөгереп килеп,
Шакыр кебек шатлык ишекне.
Син югында эшем көйле түгел,
Син югында күңел төшенке...

## Сыну

Сөю татлы,
Чая яшьлегеңдә
Пар күзләрең очкын чәчсәләр.
Ялгышларың бары сабак бирсә,
Шатлыкларың алга дәшсәләр.

Алган гыйбрәт, сабакларың белән
Хыялларың җиргә төшсәләр —
Очышта да күңел сына икән,
Өметләрең капылт киссәләр...

## Сагыну

Карашларың эзләп, кара гүрең тырныйм,
Сулышларың сагынып, кара янып елыйм.
Кабер өсләреңдә чәчәк булып сулыйм,
Үлән арасында җилләр булып дулыйм.

Тырнак төпләремә кара туфрак тула,
Күз төпкелләремә кара төсләр куна.
...Вакыт үтә, гөлләр күзен йома,
Кара җиргә чүккән җаным туңа...



Рәмзия Габделхакова

# КОЯШЛЫ МИЗГЕЛ

БӘЯН

— Менә монда хата киткән. Төзәтегъгә кигъәк, — диде аның гаризасын алучы тәбәнәк буйлы кара хатын. — Яки кигъедән языгыз.

Хатын «р» авазын дөрес әйтә алмыйча, французлар сыман сакаулап-бизәкләп сөйләшә иде.

— Мин ашыгам, вакытым юк, — дигән булды Раян.

Вакыты булса да, беркая ашыкмаса да шулай диде. Чөнки кире язып мәшәкатьләнәсе килмәде.

— Алайса когъектогъ каләм белән пөхтә итеп, үз кулыгыз белән төзәтеп куегыз. Миндә андый каләм юк, секъетагъдан согъасагыз гына. Ул өченче катта утыра.

Раян «әй җәфалыйсыз да!» дигән сыман кул селтәп, өченче катка менеп китте. Ләкин сырланып, хокук даулап йөрер чак түгел, тимерне кызуында сугарга кирәк, бирәм дигәндә — алырга! Ул «Татнефть» системасына караган әлеге оешмага заказ буенча унлап картина эшләп биргән, язның ап-аяз якты бер көнендә хезмәтенә күрә хөрмәтен, өлешенә тигән көмешен юллап йөрүе иде.

— Күчегъәсе дә кабат язасы гына бит, ние багъ инде аның, — дип мыгырданып калды аның артыннан сакау хатын.

Раян исә, ни затлы булса да, бары табан үбеп ятарга хөкем ителгән мәрмәр баскычларны яшь егетләр сыман җиңел генә сикереп үтеп, үзалдына такмаклый-такмаклый өскә күтәрелде:

— Кәгазьдәге ялгышларны
Була төзәтеп.
Ләкин язмыш хаталарын
Булмый үзгәртеп!

Раян шигырьләр укырга ярата, бик тиз исендә калдыра һәм төрле тантаналарда, очрашу-мәҗлесләрдә җай килгән саен аларны яттан сөйләп, дус-ишләренең күңелен күрә иде. Аның хәтер кесәләрендә һәр очракка туры килердәй берәр шигырь йомарланып ята, бу байлыгы кешеләр арасындагы

Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА — *шагыйрә, прозаик; «Көзге яшен», «Көмеш төн», «Кар өстендә миләшләр» һ.б. китаплар авторы. Лениногорск шәһәрендә яши.*

киеренкелекне йомшартырга, дуслык җепләрен ялгарга ярап куя. Кәефе яхшы чакта, үзалдына шигырь сөйләп, җыр көйләп йөрү гадәте дә бар.

Ә бүген аның кәефе, чынлап та, шәп иде. Бердән, язгы кояшлы көн җанына рәхәтлек бирсә, икенчедән, кулына кирәсе мул акча да канәгатьлек, шатлык хисләре өсти. Хезмәтең тиешенчә бәяләнсә генә эшләргә дә, яшәргә дә кызык ич бу дөньяда!

Өченче катка менү белән аның каршына бер кочак кәгазь күтәргән нечкә билле, озын, төз аяклы чибәр кыз килеп чыкты. Хәзер бөтен кантурны (хәзергечә әйтсәк, офис) шундый таш йөзле курчаклар «бизи». Хатын-кыз затын эшкә алганда белем-акылына карап түгел, мал сайлагандай, тышкы кыяфәтеннән бәялиләр. Яшь, чибәр кызларга ишекләр җинелрәк ачыла, якты чырай мулрак эләгә.

Ир җанлы курчактан кабул итү бүлмәсен сорады. Үз чибәрлегенә үзе шаккатып йөрүче көязбикә дәшмәде, иренен пилмәндәй бөреп, ялкау карашы белән уң яктагы ишеккә ымлады да, тырт-пырт басып юлын дәвам итте.

Раян ул күрсәткән бүлмәгә керде. Керде... һәм баскан урынында катып калды. Өстәл артында, зур яфраклы фикус гөлләре арасында, тәрәзәдән төшкән кояш нурларына күмелеп, бер Фәрештә утыра иде...

Раян аның шикәр кебек ап-ак кофтасын, шул кофтаның челтәрле нәфис якасыннан калкып чыккан мәрмәр муенны, озынча алсу йөзне, кояш нурында көнбагыш чәчәгедәй чагылган соргылт-сары каш-керфекләрне, иңнәренә таралып төшкән алтын чәчләрне күрде. Барысын да художник күзе белән күрде. Гүя аның каршында чынбарлык түгел, ә бөек рәссамның каләм-буяулары тудырган, камиллекнең үзе булган илаһи бер картина иде. Фәрештә, аккош канатыдай нәфис кулларын өстәлгә салып, уйчан йөзен тәрәзәгә таба бора төшеп, бер халәттә катып калган. Фани дөньядан аерылып, үзе генә белгән уй-хыяллар куенына кереп чумган бер тын мизгеле иде булса кирәк. Ул хәтта Раянның керүен искәрми калды. Шуңа күрә ир аны һич уңайсызланмый рәхәтләнеп күзәтте.

«Нинди сөйкемле ханым! Унтугызынчы гасырдан адашып килеп чыккан нәзакәтле гүзәл ич бу. Их, минеке булса икән бу серле чибәркәй, сокланып, назлап кына торыр идем!»— дип уйлады Раян. Күнелендә кузгалган назлы хисләргә буйсынып, матур, сөйкемле ханымны кочып алудан үзен чак тыеп калды. Җанында кинәт кабынган бу мәхәббәт уты, тәнендә кузгалган дәрт бу арада «сүнәм-сүнәм» дип пыскып яткан илһам чаткысын дөрләтеп җибәрде: «Мин бу фәрештәне һичшиксез ясыйм, менә дигән картина килеп чыгачак!» Образ тудырып баш ватасы да юк, менә ул бербөтен, әзер инде, якты, көләч буяуларыңны кызганмый тукымаңа төшер дә куй гына.

Шулчак өстәлдәге телефоннарның берсе тынлыкны сискәндереп чыңлап куймаса, әлеге серле, хыялый-тантаналы мизгел күпме дәвам итәр иде, билгесез. Язгы кояшның иркә нурларында коена-коена, уйлар дингезендә йөзгән хатын ялт итеп бүлмәгә таба борылды, кабаланып телефон трубкасына үрелде һәм Раян колагына арфа кылларында тирбәлеп чыккан ифрат назлы, иркә тавыш килеп ирешге. Нинди сүзләргә ияреп чыкты ул авазлар, ир игътибар итмәде, анысы аның өчен мөһим дә түгел иде. Чишмә тавышыдай чылтырап аккан бу йомшак, нәфис тавыш аны тәмам әсир итте, шул мизгелдә ул үзенең менә шушы хатынга, гомерендә беренче тапкыр күргән серле чибәркәйгә баштанаяк гашыйк булуын аңлады. Биредә нишләп йөрүен, бу бүлмәгә ник керүен дә онытты. Әгәр хатын зәңгәр нур тулы карашын күтәреп:

— Исәнмесез. Сезгә ни кирәк иде? — дип үзе сорамаса, Раян томанлы карашын аңа төбәгән килеш тәки шулай басып торыр иде.

— Исәнмесез... — диде ул ярым пышылдап.

Йомышын, үзенә ни кирәген исенә төшерергә азапланды. Зиһене томаланган, «корректор» дигән сүз шул томан эчендә адашкан-югалган иде. «Миңа инде хәзер берни кирәкми, бары син генә кирәк!»— дип аваз салды мәхәббәттән исергән күңеле.

Фәрештә, аның уйларын сизгәндәй, матур күзләре, тулы иреннәре белән, үз итеп, бик йомшак итеп елмаеп куйды. Болай да кояш нурлары белән тулы бүлмәдә бар төсләре белән уйнап, гүя салават күпере балкыды.

Бусы инде артык иде! Раянның бу сихри карашны күтәрергә көче житмәде, оялудан муенына кадәр кызарып, бүлмәдән атылып чыгып китүен үзе дә сизми калды. Ашыгып-кабаланып урамга чыкты. Биш катлы бу затлы бинага аяк басып кергәндә сатылган картиналары өчен акча юллап һәм шул акчага иске машинасын яңартырга исәпләп йөрүче аек акыллы, бик эшлекле илле яшьлек ир иде ул. Аннан исә беренче тапкыр гашыйк булган һәм бу халәттә нишләргә тиеш икәнен белми йөдәгән самими үсмер егет булып килеп чыкты. Үзе генә түгел, алтын чәчле, зәңгәр күзле патша кызы да ана ияргән иде...

***

Ләкин фикус яфраклары арасында кояш нурларына күмелеп утырган гүзәл ханбикәнең рәсеме ясалмады...

Рәссам, шагыйрь кебек чынбарлыктан аерылып, хис-хыяллар дөньясында яшәүче ижади затларның күңеле чуар, аларның сәер-серле тормышында андый талпыну-ашкынулар, илһамлы мизгелләр еш була. Ләкин тиз кабынган тиз сүнә, жете кызыл тиз уңа... Ул илһамлы мизгелләр кайчак яшен кебек бер балкып ала да, күздән югала, ә кайчак кояшның үзе кебек күңел күгендә байтак эленеп тора. Аңа инде күнәсен, тиз генә сүнмәсен аңлыйсың, хыялны чынга ашыру өчен вакыт чиксез кебек тоела. Тик көннәрдән бер көнне кояшны болыт каплый...

Әгәр тормышы бер эздән генә барса, көтелмәгән мәшәкатьләр килеп чыкмаса, бәлки Раян матур хыяллар илендә байтак адашып йөрер, остаханәсенә бикләнеп, полотносына капланып, күңел кояшының рәсемен төшерү белән мәшгуль булыр иде.

Беренче мәшәкать күңелле иде: яңа гына институт тәмамлаган олы кызы, Казаннан киявен ияртеп кайтты да, без язылыштык— өйләнештек, диде. Ана белән ата «ах» итте. Никахсыз-туйсыз нинди өйләнешү ди ул, булмаганны! Без кешедән кимме? Туган-тумача, дус-ишләр ни әйтер?

Туй кәмитенә бер утыргач, әйләнәсең дә әйләнәсең икән. Башларың тубал булганчы әйләнәсең... Кәмит туктагач, барча мәшәкатьләр узгач, Раян бу хәлләргә ышанып бетә алмыйча, башын тотып, үзенә үзе аптырап, байтак гасабиланып йөрде. Киявенең «бабай» дип дәшүе аның өчен шул хәтле сәер иде. Сәер генә түгел, бу бер фажига иде! Монарчы заманнан калышмыйча яшьләрчә киенеп, бераз әтәчләнеп-егетләнеп тә йөргән Раян шушы туйдан соң үзенең яшьлек иленнән куылган зат икәнен аңлады. Житмәсә шул елның көзендә аның юбилее да иде. 50 саны карап торуга бик күркәм булса да, жирдә шул хәтле йөрүенә ышанасы, еллар йөгән иннәргә һич тә саласы килми икән. Үзе укыган һәм дә иш янына куш булсын дип, бераз укыткалап та йөргән училищеның актлар залында үткән юбилей тантанасында аңа: «Бу әле картлыгыңның яшьлеге генә, әле яшен кебек балкыр чагың!» — кебегрәк күңел юаткыч купшы сүзләр күп әйтелсә дә, картаерга теләмәгән йөрәге үксеп елый иде. «Илле чиген узгач, алтмышка юл ачыла, ә гомер шундый тиз үтә... Күңелле чаклар, куанычлар артта калды, алда — картлык, мин — бабай, бабай... Озакламый кулга беренче оныкны тоттырырлар...» — жанын шундыйрак уйлар үртәп, Раянга тынгы бирмәде. Аның бу дөньяда карт кеше булып яшисе килми иде.

Күңел халәте караңгы буяуларга ияреп рәсемнәренә төште. Томанга төренгән

буш кырлар, җил кыйнаган шәрә агачлар, таш сукмакта бөрешеп яткан гөлләр, яшен сугып кумергә әйләнгән ялгыз имән, йөзен җыерчык баскан, карашыннан әҗәл карап торган карт сурәте — барысы-барысы кулга сабын белән бау алып, яшәү белән алыш-бирешне өзәргә әнди торган рәсемнәр иде. Бу рәсемнәрдә кояшның үзе түгел, хәтта нәни нуры, шәүләсе дә юк, алардан соң Малеевичның атаклы кара шакмагына карап та күңел ял итәрлек иде.

Күңеленең кайсы аулак почмагыннан калкып чыккандыр, шул чорда иҗат ителгән рәсемнәргә кара кош булып сыңар күз кунды. Рәнҗү-үпкә дә, шул ук вакытта янау-кисәтү, ачу уты да бөркелгән ул сыңар күз әле имән тамырыннан, әле болыт эченнән, әле куырылган гөл таҗыннан бозлы ук булып төбәлә дә, һәркемне бу салкын караштан качарга мәҗбүр итә иде.

Үзе кебек үк хыял-уйдырмалар, буяу-пумалалар дөньясына кереп чумган берәү Раянның аркасыннан кага-кага көлде:

— Шайтаннар белән килешү төзедеңме әллә син, дускай? Ахырзаманда бер күзле иблис имансыз бәндәләргә күренә башлый, имеш. Синнән ераграк йөрергә кирәк, ахырзаманны ашыктырасың, малай!

Раян кеше сүзенә карап кына караш-фикерләрен үзгәртә торган затлардан түгел, үҗәтлек-кирелеге җитәрлек иде. Шуңа күрә сыңар күз аның кул тамгасы булып картинадан картинага күчүен дәвам итте. Ә көннәрдән бер көнне күргәзмә залында йөргәндә ике хатын-кызның пышылдап кына сөйләшүен ишетте ул. Үз яше чамасындагы бу икәү колакка колак, авызга авыз куеп аның иҗатын тикшерә-бәяли иде.

— Бигрәк котсыз рәсем! Ниемә кирәк булды икән кәгазь пычратырга? Моннан башка да халыкта депрессия, — диде шадра йөзлесе.

Ахирәте мәрхәмәтлерәк зат иде булса кирәк, авторны аклап-яклап маташты:

— Бәлки ул бик бәхетсез, ялгыз кешедер, аны аңлаучы, яратучы юктыр...

— Ул бәхетсез дип, без дә елап утырыйкмы?! Кара син бу сыңар бәбәккә, төшеңә керсә, куркып уянырсың! Миңа калса, бу художник чын сәламәт кеше түгел, психик авыруга охшаган. Хәер, алар барсы да шундый, ычкынган халык.

Картиналарына карата әйтелгән бу тискәре фикерләр, үзен җүләргә чыгарулары Раянга бик авыр тәэсир итте. Шул ук көнне күргәзмәләр залыннан барча картиналарын җыеп чыгып, — юк, утка якмады, кызганды, ни дисәң дә бу аның хезмәте генә түгел, бүгенге күңел халәте дә иде, — гаражына илтеп куйды.

***

Кәефе кырылып, кысыр хәсрәтеннән төшенкелеккә бирелеп йөргән ямансу көннәрендә аның башына көтелмәгән бәла, чын бәла ишелеп төште: гомер иткән хатыны Ясирә кинәт авырып хастаханәгә кереп ятты. Раянның гомер «трамвае» хәзер өч тукталыш буйлап кына чаба иде: өй — училище — хастаханә — өй...

Өйдә нур сүнде. Элек барлыгына әлләни игътибар да ителмәгән хатынының үзе өчен никадәр кирәкле, кадерле җан булуын Раян шунда гына аңлады. Өйнең бөтен яме хатын-кызда икән. Хатыны сау-сәламәт чакта өйдә тәртип иде, ашарга пешкән, киемнәре юып-үтүкләп эленгән, тамагы тук, өс-башы чиста иде. Инде бу рәхәтләр калмады. Һәм бу рәхәтләр булсын өчен күпме хезмәт кирәклеге дә аңлашылды... Улы Казанда укуда, сабый көткән кызының үз хәле хәл. Раянның пумаладан гайре берни тотмаган йомшак иркә кулларында чүпрәк-тастымаллар, таба-кәстрүлләр «уйный» башлады. Уйлар авырайды, баш иелде, адымнар акрынайды. Ә табиблар өметләрне бер-бер артлы өзә тордылар...

Караңгы көзләр арты салкын кыш килде, кышларны холыксыз яз, яңгырлы җәй алмаштырды... Ләкин Раян өчен вакыт гүя туктаган иде.

Өйдән үз аягы белән чыгып киткән, айлар буе хастаханәләрдә ауный торгач, күгәрчен кадәр генә калган Ясирәсен дүртенче катка Раян үз кулларында күтәреп менде. Хатынын кызганудан күзләренә ачы яшьләр тулды, бар йөрәге елады. Ул артык көчсез, артык чарасыз иде. Әҗәл аяк баскан бу салкын, нурсыз өйдә аңа коточкыч авыр, куркыныч иде. Раянның кулыннан пумаласы гына түгел, бөтен эш төште. Ул, кайгысыннан качарга теләп, шешәгә үрелде...

— Мин киткәнче түз инде, — дип ялварды Ясирә.

— Зинһар, эчмә... — дип ыңгырашты.

Ләкин аның сүзләре үзе кебек үк көчсез иде. Раян да көчсез иде. Ул көн-төн эчте, гик барыбер җанын йолкып, йөрәген чеметеп газаплаган хәсрәттән котыла алмады. Юату эзләп чирле хатынына сыенды:

— Без бергә үләрбез, Ясирә. Шулай яхшырак булыр... Икебезне бер кабергә күмәрләр... Барысы да бетте... Ник яшәргә? Чукынып китсен бу дөньясы, өч көн шатлык өчен туасы да юк. Тугач, үләргә кирәк... Үләсе булгач, ник туарга? — дип сукранды.

Хатыны җан биргәндә, ул аның кырына, идәнгә сузылып ятып гырылдап йоклый иде... Уянгач та, өзек-өзек авыр сулышлар ишетелмәгән коточкыч тынлык аны сискәндерде, куркуга салды. Калтыранган куллары белән караваттан салынып төшкән лимон төсендәге ябык беләккә кагылды, ул боз кебек салкын иде. Җансыз гәүдә янында, әҗәлнең салкын сулышы белән тулган бу бүлмәдә бер минут та каласы килмичә, Раян урамга саф һавага атылып чыкты. Кипкән сары яфракларны таптап әрле-бирле аптырап йөрде-йөрде дә, кибеттән бер шешә алып, эскәмиядә гәп корып утырган ирләр янына юнәлде. Шуларга кайгысын сөйләп, күнелен бераз бушатасы килгән иде. Ләкин аңа игътибар итүче булмады, Рәсәйнең бер төркем эшсез сәрхуше кызып-кызып Америка турында гәпләшә иде.

— Шул кирәк аларга, артыгын кыландылар! Бөтен дөньяга хуҗа булмакчылар, кишеремне тотсыннар! Бушлары да юньле адәм түгел, үзе ата җулик ул.

— Анда калган халыкка хана инде хәзер, братлар. Йөзәр этажлы йортлар ди. Икесе дә убылган, кешеләр тәрәзәдән сикергән икән.

— Артыңа ут төртсәләр, нибуч сикерерсен! Тереләй янганчы, мәтәләп дөмегүен хәерле. Мин дә сикерер идем. Ай-һай, туганнар... Алла сакласын!

— Кыланмышларына күрә бик таман! Маена чыдый алмыйча котыра ул Әмрикә. Хитри-митри, бер дә үзенә ут кертми, Әфганга бомба коя, Вьетнамга коя. Боларда гына корал, имеш. Япунияне нишләттеләр?! Алла җәзасы бу. Берсен дә кызганмыйм, миңа димәгәе, чукынышып катсыннар.

— Алай каты бәрмә, туган. Прастуй халыкның ни гаебе бар? Алар да безнең кебек бәндә инде...

— Булыр Әмрикәдә прастуй халык! Буржуй белән ябрәй оясы бит ул!

— Сугыш чукмарлары диген. Буш бөтен Иракны бомбага тотам, Саддамның муенын борам дип әйтә ди.

Раян сүзнең ни турыда баруын аңламады. Алама киемле, мунчала йөзле сәрхушләрнең кипкән балык суыра-суыра әллә кайдагы Америка турында гәп корулары сәер иде. Безнең халык шундый бит, борын төбендәгесен күрмәсә күрми, әмма диңгез-таулар аша үрелеп ерак офыкларны айкарга ярата.

«Киң масштабта» фикер йөртүче харап эшлекле ирләргә үз кайгысын, Америкада җимерелгән биек йортлар, анда һәлак булган халык белән чагыштырганда бик вак булып тоелган чирле хатын вафаты хакында сүз кузгатырга кыймады Раян. Башын иеп болар яныннан китеп барды. Ул чарасыз, гаҗиз иде. Аптыраган-йөдәгән, зиһене чуалган иде. Өендә ятып калган хатын мәете янына кайтасы килмичә, көне буе шәһәр урамнарын иңләп йөрде дә йөрде...

Юлында коллегасы Анна Борисовна очрамаса бәлки әле төне буе да шулай аңгыраеп йөрер иде. Ул әле аны да күрми үтәсе иде, Борисовна үзе туктап сүз катты:

— Раян Харрасович, хәлләрегез ничек? Хатыныгыз ни хәлдә?

Раян инде ике айлап эшкә йөрми, авыру карар өчен ял алган иде. Ул ни дияргә белми, кашларын җыерып, ык-мык итеп торды да, калтыранган бармаклары белән ирен-сакалын сыпыргалап:

— Минә үлеп китте бит әле ул... — диде.

Гүя үлеп, үзенә җайсызлык, мәшәкать тудыруына хатынын гаепли, ачуы килә иде.

— Шулаймыни?! О Боже, пусть земля ей будет пухом! Кайчан җирләдегез? Ник безгә хәбәр итмәдегез? — диде һәрчак кеше хәленә керә торган йомшак күңелле хатын. — Озатырга ярдәм иткән булыр идек.

Раян нәүмиз карашын аңа төбәп, каударланып кабатлады:

— Ярдәм итегез... Зинһар, ярдәм итегез миңа!!! Ул бит әнә... өйдә ята... Мин белмим нишләргә? Нишләргә миңа хәзер?

— Кайчан үлде соң ул?

— Ну... бер... биш-алты... сәгатьләр элек...

— О Боже, Раян Харрасович! Бу бит коточкыч олы хәсрәт! Ә сез нишләп урамда йөрисез?! Тизрәк участок врачын чакырыгыз, балаларыгызга хәбәр итегез. Татарларда бит мәетне озак тотмыйлар. Бүген үк мәчеткә барып, юу, җирләү мәсьәләләрен хәл итәргә кирәк!

— Минме? Бер үземме? Мин белмим... Минем беркайчан... беркемне...

Чынлап та, Раянга мондый мәшәкатьләр таныш түгел иде. Гаиләне, бөтен хуҗалыкны, төрле документ, справкалар, фатирга түләү мәсьәләләрен — барысын, барысын моңарчы хатыны хәл итте.

Анна Борисовна аның хәлен аңлады бугай.

— Барыгыз алайса, өйгә кайтып врач чакырыгыз, балаларыгызга хәбәр итегез. Ә калганын без кайгыртырбыз.

Күмәк көч, ярдәм белән Ясирәне соңгы юлга озаттылар...

Аны җир куенына сендергәннәрен үз күзләре белән күреп торса да, Раян бу чынбарлыкны кабул итә алмый азапланды. Югыйсә Ясирә аның өчен җан сердәше, күңел юанычы булудан бигрәк, җылы өй, тәмле аш, чиста кием, кыскасы, комфорт иде. Ялгызлыкны ир бик авыр кабул итте. Мәет чыккан шыксыз йорт аның өчен караңгы, салкын зинданга әйләнде. Анда кайтып кермәс өчен һаман саен дус-ишләр арасында чуалырга тырышты. Тик дус дигәннәре кесәләрендә җил уйнаган урам сукбайлары иде. Раян сыйласа, баш кага-кага аны тыңлыйлар, хәленә кергән, үзләренчә юаткан булалар. Сыйламаса, кул селтәп үз юллары белән китеп баралар. Болар хәерче булса да, тәкәббер халык, калай әтәчләр иде. Шул эре хәерчеләрнең күңелен күрә-күрә, өйдән байтак әйбер юк бәягә сатылып бетте...

— Безнең талантлы художнигыбыз алкашка әйләнгән, — дип сөенде дошманнары.

Һәм шешә кыстырып, йөгерә-сөенә «кайгысын уртаклашырга» килделәр.

Рәссамның көлеп торган чиста өе сәрхуш оясына әйләнде. Балаларның туган йортка юлы өзелде. Ишекләр көне-төне ачык булса да, монда аларны беркем көтми, кайнар чәен куеп каршыламый иде...

— Бетә бит бу, коткарасы иде егетне! — дип борчылды элеккеге дуслары.

Һәм, ай-ваена карамый, аны сары йортка илтеп тыктылар...

Шәһәр читенә урнашкан, рәсми рәвештә «Психо-неврологический диспансер» дип аталган ул ярым җимерек өч катлы сары бинаны гади халык «Сәрхушләр йорты» дип йөртә иде...

***

Монда адәмнәрнең нindие генә юк. Ире-хатыны, яше-карты... Ләкин һәркайсының йөзендә «үз чире» ярылып ята. Саргылт, шешенке, нурсыз йөзләр... Карангылык, бушлык оялаган төссез күзләр... Елмаюдан мәхрүм салынкы иреннәр... Битараф, томанлы карашлар...

Һәр вакыйганың, һәр гамәлнең тамыры — сәбәп, жимеше — сабак... Раян диспансердан шуны аңлап чыкты: авыру жаннар йортына ул Альберт белән танышыр, очрашыр өчен килеп эләккән. Язмыш давылларында сынган жан канатын, имгәнгән рухын табиблар түгел, менә шул сәер егет дәвалады.

Карап торышка 30-35 яшьләр тирәсендәге ул егет башка авыруларга бөтенләй охшамаган иде. Бәрхет кебек чиста каратут йөз, киң маңгай, бик тирәннән, күңел төбеннән сынап карый торган күмер күзләр, үткен караш, кылыч борын, калын кырыс иреннәр — бар кыяфәте белән ул рәсем-скульптураларда яшәп калган борынгы грек акыл ияләрен хәтерләтә иде. Егет үз бәясен бик белгән сыман, сынын хәрбиләрчә төз тотып, горур атлап йөри, сөйләшкәндә әңгәмәдәшенең жанына төбәлеп, үтәли тишеп карый.

— Бәхетең, абзый, минем белән бер бүлмәгә эләктең. Мин сине терелтәм, — диде ул Раянга.

Раян дәшмәде. Мондагы халык белән сак булырга кирәк.

Егет гүя аның уйларын укый иде:

— Ышанмыйсыңмы? Ну-ну... Терелтәм дигәч, терелтәм! Син беренчесе түгел.

— Кем соң син? — дип сорады Раян.

Егет бик канәгать елмайды:

— Курыкма, тәжрибәле пациент... Чүт кенә... мондыйрак... Аларча түгел...

Шулай дигәч, эчкә баткан шомырт күзләре белән хәйләкәр елмаеп, Раянга төбәлде. Язмыш сукмаклары сәрхушләр, диваналар йортында кисешкән ике адәмнең дәшми генә, күзгә-күз төбәлеп бер-берсен сынап-өйрәнеп торган бу мизгеле шактыйга сузылды. Ләкин Раянның карашы тыныч, битараф иде. Биредә кем булмас та, ни булмас дигәндәй, иңнәрен генә сикертеп куйды.

Егет тә үз күңелендә: «Миңа бу адәмнән бернинди куркыныч янамый, моңа ышанырга ярый», — дигәнрәк нәтижә ясады бугай, сүзен дәвам итте:

— Минем кебекләргә дәва юк, мин монда акыл жыяр өчен кереп ятам. Иң хикмәтле сүзләр жүләр авызыннан чыга бит, абзый. Чөнки сүзгә киртә куючы тормоз юк, күңел капкасы шыр ачык. Ни уйлый — шуны әйтә! Хакыйкатьне курыкмыйча кычкыручылар — диваналар. Аларны тыңласаңмы, у-у-у... Әллә ниләр ишетәсең, академиктан да болайрак... Мин мондагы философларның әкиятләрен дәфтәргә теркәп барам. Бу йорт диссертация язар өчен бик шәп урын, абзый! Алтын кебек затлы кешеләр жыела монда...

— Ә тегендә — егет кулы белән рәшәткәле тәрәзәгә, урамга төртеп күрсәтте — тере мәетләр дөньясы. Ул бичара зомбилар корсакларын кайгыртып көн-төн чабалар да чабалар. Йөрәгең тук булса, корсак дәшми ул, шуны белмиләр, — диде егет.

Раян елмаеп баш чайкады. Акылы зәгыйфь кеше ни сөйләмәс...

— Көлмә, абзый, — диде егет. — Мин белгәнне барысы да белсәме?! Тик шунысы яман, дару-укол белән агулыйлар монда. Энәләреннән качып булмый, бәйләп куеп булса да кадыйлар. Ә төймәләрен йотмаска, әбрәкәйгә ташларга кирәк. Кирәкми алар сиңа. Мин сине үзем терелтәм. Син алкаш бит, әйеме? Бушлыкны утлы су белән тутырырга азапланасың. Бөтен чир бушлыктан килеп чыга, абзый! Кемдер чамасын белми сыер кебек күши

башлый, кемдер энәгә утыра, кемдер шешә суыра... Бушлык куркыныч ул, бушлык — нуль! Ә нуль, беләсең килсә, гарәп сүзе, сыфрдан килеп чыккан, бушлык дигәнне аңлата. Әкәмәт хикмәтле сан! Сул якка баса, бөтенесен йота, уң якка баса — үрчетә. Менә шулай, абзый, нульне йөрәк ягына бастырырга ярамый. Бушлык төпсез кара упкын ул, черная дыра, анда бөтен галәм сыя, хет күпме тутыр. Вәт шунда кереп югала инде кеше.

Егетнең сүзләре Раянны уйга салды, аларда хаклык бар иде. Чынлап та бушлык ич, өендә дә, җанында да... Аның өчен яшәү мәгънәсе югалып бара, тормышка ябышыр сәбәп, таяныр ноктасы калмады кебек...

— Ә мин башка... Болар өчен җүләр, тегеләргә үз кеше. Алар мине аңлый, анда тел кирәкми. Мин үзем — галәм. Бөтен галәм менә монда! — Егет йодрыгы белән күкрәк турысына сугып алды. — Баш ерунда, барысы да менә монда! Ишегеңне бикләмәсәң, сыя ул! Шуңа күрә миңа кайда да рәхәт. Бушлык юк, нуль юк! Бөтен дөнья үземдә, менә монда... Барысы да үзем белән...

Егет үзалдына мыгырдана-мыгырдана караватына сузылып ятты. Ул көнне башка сөйләшмәде, кулына көрән тышлы калын дәфтәрен алып, болай да мунчалага әйләнгән ручка башын чәйни-чәйни нидер язды, әле үзалдына елмайды, әле эшеннән риза булмагандай йөзен чытты...

Икенче көнне дә аның тавыш-тыны ишетелмәде. Көне буе Раянга артын куеп, диварга борылып ятты, әллә йоклады, әллә үз хәле хәл иде.

Кичке якта аның янына бер иптәше килде. Бик ыспай, зыялы кыяфәттәге чибәр ир-егет. Йомшак кына басып палатага керде, итагатьле итеп Раян белән исәнләште дә, гаҗәпләнеп сорады:

— Ә Альберт кайда? Аны шушы палатада дигәннәр иде.

Раян сораугa сорау белән җавап бирде:

— Сезне монда ничек кертteләр соң?

— Бу илдә бар ишекләрне дә ача торган бер ачкыч бар, белмисезмени?! — дип елмайды сөйкемле кунак.

— Белмим, — диде Раян.

— Димәк, ябык ишекләрне ачарга туры килмәгән. Бәлки сезнең өчен бөтен ишекләр ачыктыр... Шулай да, Альберт кайда?

— Ул лечениедә, ун-унбиш минут көтәсегез булыр.

— Монда хәтле килгәч, көтәрбез инде, — диде кунак һәм алып килгән күчтәнәчләрен сумкасыннан бушатырга кереште. Тумба өсте җиләк-җимеш, тәм-том белән тулды. Кунак караватка утырды, шулчак мендәр астыннан бер почмагы чыгып торган дәфтәргә күзе төшеп, аны кулына алды, иркәләгәндәй сыпырды да:

— Һаман яза икән... — диде.

— Яза инде... — дип көлемсерәде Раян.

— Көлмәгез, Альберт җүләр түгел. Искиткеч талантлы, башлы кеше ул! Белмәгән нәрсәсе юк иде. Шундый егетне әрәм иттеләр.

— Кем әрәм итте?

— Кыйнап имгәттеләр... Гел шулай була бит ул. Маймыллыктан арынмаган надан, сай бәндәләр кешелекнең чәчәкләрен таптый. Ә Альберт бик башлы, талантлы егет иде. Чын шагыйрь ул, сез аның җырларын тыңласагыз! Альберт белән без бергә укыдык, бер бүлмәдә яшәдек, якын дуслар идек. Аннары аралар өзелде. Баесам, китабын чыгарам дип нәзер әйткән идем. Алланың рәхмәте, эшләрем яхшы гына бара. Менә бераз җай чыкты, инде әйткән сүзне үтәргә кирәк. Шул ният белән Альбертны эзләп авылларына кайткан идем, анда юк... Әнисен күреп сөйләштем. Монда икәнен ул әйтте... Башта ышана алмый тордым. Кем уйлаган... Беренче тапкыр гына ятуы түгел икән.

Кунак башын чайкап, иренен кысып куйды:

— Шундый кеше... шундый кешене бит! И-их!!!

Раян дәшмәде. Әгәр Альбертның мондый акыллы, тугры дусты бар икән, һәм ул дус берни белән исәпләшми, башкаладан ук аны эзләп кайткан, янына зурлап килгән икән, бу бик күнелле хәл, күнелле генә түгел, бик шәп бит инде бу, дип уйлады ул. Димәк, Раянның күршесе чынлыкта шыр дивана түгел, ярыйсы гына бәндә булып чыга!

***

Шуннан соң ул сәер күршесенә, анын керделе-чыктылы сүзләренә башкачарак, игътибарлап-сынап карый башлады. Баксаң, алтын тәнкә сыман акыллы-акыллы сүзләр дә тәгәрәп чыккалый икән исәр егет авызыннан...

Ә беркөнне, шаманнарның зур барабаннарын хәтерләткән түм-түгәрәк ай сәрхушләр, диваналар йортының рәшәткәле тәрәзәсеннән үрелеп, моңлы нурларын түккән бер төндә Альберт кулына гитарасын алды. «Гитара минем иң тугры дустым, мәңгелек юлдашым, үлгәч, кабергә дә гитара белән күмәргә васыять иттем», — дигән иде Раянга. Җырдан бернинди зыян юк, ул үзе җан дәвасы дипме, егеткә гитараны үзе белән алырга рөхсәт ителгән иде.

Шулай итеп, айлы, якты бер төндә Альберт тәрәзә төбенә менеп кунаклады да, гитара кылларын чирткәләп, әкрен генә шыншырга кереште:

— Ай нуры үпкән сукмаклар буйлап, мин синнән китәм. Бары бер төнгә уртак учакны, синең кочакны үземсез итәм. Мин синнән китәм, җил булып исәм, тик ышан иркәм, таң ату белән мин кайтып житәм. Сине үбәргә, яшьле күзенә иртәнге нурдай бер тамар өчен. Ә сина, бәгырь, житмәс гомер дә, мин хыялыйны бер аңлар өчен... Жылы йортына, якты утына чакырып торыр ак канат-куллар, ә мине һаман офыкка дәшәр ай нуры үпкән тылсымлы юллар... Караңгы күктә йолдызлар янгач, ялгыз ай байгач, жир йөзе мина кысан тоелыр. Арыган жаным, тынычлык эзләп, ак болытларга килеп сыеныр...

— Үзең яздыңмы? — дип сорады Раян.

Егет карашын тәрәзә артында калган төнге тормышка төбәгән килеш теләр-теләмәс кенә җавап бирде:

— Язмыйм, жырлыйм... Иртәгә онытылачак...

Шулай диде дә шыншуын дәвам итте:

— Минем жырларым күкләрне инләр һәм килеп кунар моңлы йолдызга. Ләкин беркайчан барып ирешмәс йөрәк түремдә утырган кызга... Ах горур булдың, гүзәл Алиһәм, мәңге житәлмәс сиңа буйларым, йолдызлар кебек сүнәр таңнарын синең нурында йөзгән хыялым...

Раян Альбертны гажәпләнеп тыңлады. Егет үзе генә белгән ниндидер сихри көчләр белән гүя күктән сүзләр жыя да, шулардан жыр үрә иде. Уйланып-сайланып тормый, кайсы эләгә, шуны такыясенә тезә бара. Жырны әйтерсең Альберт түгел, сүзләр үзләре, ничек ошый, ничек телиләр, шулай төзиләр дә куялар. Гүя гитара кылларына галәмнең серле почмакларыннан очып килгән сүз-карлыгачлар куна... Талантмы бу, жённәре булышамы? Әмма жыр бар, сүзләре дә күнелгә ята, көе дә. Ялгышмаган Казан кунагы: табигатьнең моңлы баласын харап иткәннәр. Затлы сәхнәләрдә жырлыйсы егет төн уртасында тиләләр йортының тимер рәшәткәле тәрәзәсе төбендә бердәнбер тыңлаучысы, үзе кебек бер авыру бәндә өчен соло концертын куя...

— Сиңа чынлап та китап чыгарырга кирәк.

— Өлгермим, вакыт юк, — диде Альберт. — Китап мин үлгәч чыгачак...

— Алайса тиз генә булмый икән, — дип елмайды Раян.

— Дааа... тагы ике ел бар әле... Караңгы төннәрнең үз яме, сере бар, Әлегә тән яши, үлмәгән, тере җан. Ул тели дөньяның күзенә карарга, ул тели тормышның бар серен аңларга. Ник килгән, ни көткән, ни тапкан бу җирдә? Ничә кат әйттем бит өзелгән күңелгә, син аны эзләмә, эзләмә, эзләмә... Барсы да ачыла иң соңгы мизгелдә, сер куна, нур куна йомылган күзенә...

— Ә минем хатыным үлде, — диде Раян.

— Арыгандыр. Арыганнар китә. Үлем безне түгел, без үзебез аны сайлыйбыз. Кем тели шул кала, арыганнар китә, югала... Мин дә ике елдан китәм. Елама, әнкәем, югалтсаң улыңны, ай тулгач, кукләргә сузарсың кулыңны. Мин сине күрермен, төшеңә керермен, кардай ак чәчеңне толымга үрермен. Битеңнән үбәрмен, моңлы җыр көйләрмен, елама, әнкәем, мин монда, диярмен...

— Төн үтә, йоклап булмый, — диде Раян. — Син дә сагыш кына үрчетеп утырасың. Болай да йөрәкне уй тапый.

— Нинди уй? Синдә берниндә уй юк, абзый. Бушлык кына. Йөрәгеңне бушлык тапый. Син ул бушлыкка шатлык сал.

— Каян алыйм? Юк бит ул.

— Бар, абзый. Шатлыксыз җан булмый. Ул һәркемгә бирелә.

Шулай диде дә, егет тагы җырлый башлады:

— Язмыш сандыгыңны актар, тап шатлык нуры. Гел кайгыдан тормагандыр гомерең юлы. Кояшлы мизгелләр була, исеңә төшер, шул мизгелнең бар рәхәтен янадан кичер. Уяныр шулчак күңелең, җаның сөенер, дөм караңгы төннәрең дә якты күренер. Кайт шул кояшлы мизгелгә, җаның ял итсен. Өмет дигән фәрештәләр йөрәгең үпсен...

— Кояшлы мизгел? — дип кайтарып сорады Раян. — Кояшлы мизгел... Бар бит ул! Булды бит ул! Кояшлы мизгел... Авыр болытлар, дымлы яфраклар, караңгы көннәр астында күмелеп калган якты, нурлы мизгел... Ничек онытты соң ул аны, югыйсә мәңге онытырга тиеш түгел иде!

Күңеленә ишелеп төшкән гүзәл хатирәләрдән гаять дулкынланып, хисләнеп кычкырып җибәргүен Раян үзе дә сизми калды:

— Альберт, тукта! Комачаулама! Мин ул мизгелне таптым. Тоттым мин аны, менә ул, менә! Ә син, дәшмә, зинһар, башка дәшмә! Югыйсә югалтудан куркам. Тыңла, бер шигырь искә төште:

Дулкының килеп кагылды,
Суырып алды кочагына,
Бөтерә-бөтерә алып китте
Ярга, сөю учагына...
Күпме көннәр узган иде,
Узган иде күпме төннәр...
Йөрәгемә йозак элеп,
Мин бит киткән идем синнән...
Мин оныткан идем сине,
Онытырга теләмичә.
Сөю салым бата-чума,
Сагыш диңгезләрен кичә.
Синең ярга ашыгам мин,
Нурлы караш — якты маяк.
Саф фәрештәм, сизәсеңме,
Мин синеке баштанаяк...

— Булды, абзый... Бүгенгә җитәр... Дәшмик. Бәхетле кеше күп сөйләшми. Зар-моңлының гына сүзе бетми.

— Нигә алай?

Ләкин Альберт җавап бирмәде. Гитара да тынып калды. Тәрәзә төбендә тезләрен кочып утырган килеш егет йоклап китте...

Ә Раян йоклый алмады. Ул әле һаман үзенең кояшлы мизгеле эчендә хозурланып йөри иде...

Өстәл артында, зур яфраклы фикус гөлләре арасында, тәрәзәдән төшкән кояш нурларына күмелеп, бер фәрештә утыра. Шикәр кебек ап-ак кофта, шул кофтаның челтәрле нәфис якасыннан калкып чыккан мәрмәр муен, озынча алсу йөз, кояш нурында көнбагыш чәчәгедәй чагылган соргылт-сары каш-керфекләр, иңнәренә таралып төшкән алтын чәчләр... Гүя бу чынбарлык түгел, ә бөек рәссамның талантлы каләм-буялары тудырган, камиллекнең үзе булган илаһи бер картина. Фәрештә, ак кулларын өстәлгә салып, уйчан йөзен тәрәзәгә таба бора төшеп, бер халәттә катып калган. Менә өстәлдәге телефоннарның берсе тынлыкны сискәндереп кинәт чыңлый башлый... Язгы кояшның иркә нурларында коена-коена, хыял дөньясында йөзгән хатын ялт итеп бүлмәгә таба борыла, кабаланып телефон трубкасына үрелә, колакка ефәк җепләр булып арфа кылларында тирбәлеп чыккан ифрат назлы, иркә тавыш килеп ягыла. Менә Фәрештә нурлы карашын Раянга төби, матур күзләре, тулы иреннәре белән, үз итеп, бик йомшак итеп елмаеп куя. Болай да кояш нурлары белән тулы бүлмәдә, бар төсләре белән уйнап, гүя салават күпере балкый...

Бу мизгелне югалтмаска, бүгенгегә кайтарырга кирәк! Күңел түрендә кояш булып балкысын, үзенең илаһи нуры белән барча кара тапларны юып алсын. Сары йорттан тизрәк чыгарга да, кабат шунда, кояшлы мизгел яшәгән хансарайга йөгерергә!

Аны, гүзәл Фәрештәне эзләп табарга, каршына тезләнергә...

Нурлы күзләренә багарга...

Шул якты караштан мәхәббәт тамчылары эчәргә, көч алырга...

Һәм яшәргә, яшәргә, яшәргә!

***

— Мине чыгарыгыз, — диде ул икенче көнне.

— Дәвалау курсы әле бетмәде, тагы бер атнагыз бар, — диде табиб.

— Юк! Миңа берниндиә дәва кирәкми. Мин терелдем! Миңа моннан тизрәк чыгарга кирәк!

— Тагы бер атна...

— Юк! Бер көн дә кирәкми! Чыгарыгыз, бүген үк! Югыйсә мин аны югалтам.

— Кемне?

— Аны... Бәхетемне.

— Бәхетне бу кыяфәттә каршыламыйлар. Әүвәл кеше рәтенә керегез.

— Алексей Макарович, зинһар! Үтенәм, чыгарыгыз! Ант итәм, башка тамчы да капмаячакмын. Гомерем белән ант итәм! Балаларым белән! Бетте, точка!

— Кирәкми, ант итмәгез. Ант итүчеләр күп булды... Тик кабат киләләр...

Табиб авыр сулап куйды:

— Ант итү җиңел ул... Мин ант итмим, бары үз эшемне эшлим. Комачауламагыз миңа, карышмагыз. Бер атна ничек тә сабыр итәрсез.

Ул атна Раянга ай булып тоелды. Көннәр шундый акрын үрмәләде. Иртәләрен кояш чыкмый аптыратты, ялындырып кына чыкты да җир өстенә мәңгегә килгән сыман кыланды. Вакыт ашыктыручыларны үчекләп баш очында бик озак эленеп торды. Раян гасабиланды, кыбырсыды, җанына урын табалмыйча үрле-кырлы йөренде.

— Йокласаң вакыт тиз үтә, — дип киңәш бирде Альберт. — Мин эч

пошканда учлап йокы даруы йотам. Ике-өч сутки йоклыйм аннары. Берни сизмисең, матур төшләр күрәсең, ә вакыт үтә... Уянасың, инде бөтенләй башка көн! Яңа кояш, яңа ай... Түлке баш миңгери инде, абзый, үзенә кара.

Раянның миңгерисе килми иде. Чөнки алда аны ифрат җаваплы һәм шатлыклы гамәл көтә, киләчәк язмышы хәл ителә!

***

Шыксыз йорттан чыкканның икенче көнендә үк кырынып, чистарынып, өс-башын рәткә китереп, Раян мәрмәр баскычлы затлы бинага юнәлде. Атламады, очты. Барып җиткәч кенә икеләнеп, куркыбрак калды. Ул ашкынган белән түгел, монда бит аны беркем көтми. Фикус яфраклары арасында кояш нурларына күмелеп утырган Фәрештәкәй Раян дигән исәр гашыйкның дөньяда барлыгын да белмидер. Хәтерләмидер дә ул аны. Хәтерләмәсә, исенә төшеребез, кыюрак бул, Раян! — дип үзенә көч бирә-бирә, ир хыялы бусагасына якынайды. Таныш ишекне ачты... һәм таныш түгел бүлмәгә килеп керде. Фикус гөлләре дә юк, Фәрештә дә... Монда барысы да үзгәргән, җиһазлар да башка, кешеләр дә... Алдындагы компьютерга кереп китәрдәй булып, өстәл артында кып-кызыл иренле, кара күлмәкле ят кыз утыра иде. Бик матур, бик гүзәл, ләкин Ул түгел... Ул түгел! Курчакларның берсе икәне боз чәчкән карашыннан, кырыс тавышыннан, ягымсыз сүзләреннән үк аңлашылды:

— Вас сюда звали?!

Раян аңа шактый текәлеп торды. Җанын иркәләп, ашкындырып торган татлы хыялының юлы шулай кисәк бүленүгә ул аптырап калган иде. Нишләп монда бу курчак утыра, ник аның Фәрештәсе түгел?

— Ә ул... Ул кайда?

— Кем?!

— Монда элек башка хатын иде...

— Булса ни? Хәзер мин! И вообще, ни кирәк сезгә?

— Ул... Миңа ул кирәк!

— Кем?

Ах һәм ух... Раян бит аның исемен дә белми! Теге чакта сорарга башына да килмәде. Инде менә аптыраашта калды.

Бәлки Ул монда гынадыр? Башка бүлмәдә? Ә нәрсә, шулай булуы бик мөмкин бит, секретарь итеп яшьрәк кызны утырталар, ә тәҗрибәле хезмәткәрне җаваплырак эшкә күчерәләр. Бәлки шулайдыр, ул монда гынадыр... Ләкин исемен белмәгән килеш аны ничек табасы?! Шулчак Раянның башына өметле уй килде: «Мин аның портретын ясаячакмын!» Әйе, шулай итәр, сурәтен ясар, аннары кабат монда килер, кешеләргә күрсәтер. Ул чакта аны танырлар, табарга ярдәм итәрләр...

Максат бар, теләк бар. Раян илһамланып кабат эшкә чумды. Ләкин... Ләкин ни гаҗәп, ул Фәрештәсенең йөзен яза алмады. Бүлмә бар, мул яфраклы фикус гөлләре бар, тәрәзәдән сузылган алтын нурларга күмелеп утырган хатын бар... Тик йөз юк. Сызды, бозды, газапланды, ләкин йөз ят иде... Йөрәгендә уелып калган кадерле, газиз йөз кәгазьгә күчәргә теләмәде... Ахыр чиге Раян хатынны тәрәзәгә караган халәттә төшереп куйды. Фәрештәнең алсу яңаклары һәм шул нәфис яңакны кытыклаган алтын бөдрәләре генә күренә иде. Хыялындагы образга якынаю, аны күнеленә ошаганчы камилләштерү өчен җиде портрет язарга туры килде. Җидесе дә Раянга карамыйча тәрәзәгә борылып утырган иде...

— Бу бүлмә синеке булыр,— диде Раян. — Чөнки монда иртүк кояш төшә. Син бит яктыны яратасың, шулай бит, бәгърем?

Бәгырь җавап бирмәде, үпкәләгән сыман артын куеп утыра бирде.

— Мин беләм, син гөлләр яратасың. Мин сине гөлгә күмәчәкмен, кадерлем.

Раян өйдәге бөтен гөлләрне шушы кояшлы бүлмәгә күчерде. Дөресе, гөл савытларын. Чөнки Ясирә апалары авырганнан бирле су күрмәгән гөлләр кибеп-үлеп беткән иде. Раянда моңарчы гөл кайгысы булмады. Ә хәзер Фәрештәсен шатландырасы килгән иде. Нияте барып чыкмады, Фәрештәсе үлгән гөлләргә борылып та карамады... Әмма бу бүлмәдә гөлләр булырга тиеш! Фикус гөлләре! Раян өйне актарып акча эзләргә кереште. Соңгы вакытта ул акчага карата артык саксыз иде, керә торды, чыга торды. Аның каравы Ясирәсе һәр тиенне санап тотты. Хатыны акчаны гадәттә китаплар эченә яшереп саклый иде. Раян шкафтагы барча китапларны ишеп төшереп акча эзләде... Һәм тапты. Тапты да чәчәкләр кибетенә йөгерде. Матур савытларда үскән купшы фикус гөлләрен такси белән китереп бирделәр. Һәр портрет янына бер гөл куелды. Кояшлы бүлмәгә ямь керде. Инде моннан чыгасы да килми иде. Башка бүлмәләр тузанга батса батты, ләкин биредә һәрчак чисталык, пөхтәлек иде. Раян өчен бу бүлмәгә керү бәйрәмгә әйләнде. Ир һәр портретка озаклап карап утыра һәм могҗиза көтә иде. Көннәрдән бер көнне кадерлесе, күңел кояшы йөзен аңа таба борыр да сөеп-назлап елмаер төсле иде. Башка берни кирәкми, борылып карасын да елмайсын гына! Зәңгәр нур сипкән күзләренә багып онытыласы иде. Раян ул күзләрне ясый алмады шул... Булдыксыз рәссам ул, булдыксыз! Сөеклесенең йөзен ясый алмады.

— Син акылдан язып барасың, — диде аңа бер танышы.

Ул кояшлы бүлмәгә керергә тиеш түгел иде. Гомумән Раян соңгы вакытта беркем белән аралашмый, аңа үзе тудырган хыялый дөнья житә, анда тыныч һәм рәхәт иде. Танышы чакырмыйча керде, бер үк төсле жиде портретны күрде, шаккатып баш чайкады.

— Син акылдан язып барасың, — диде...

Әле Раянның шул портретлар белән сөйләшеп яшәгәнен белмәгән килеш шулай диде.

Бу куркыныч диагноз иде. Шулай булса Раянны кабат сары йорт көтәчәк иде. Ә танышы энәле сүзләр белән аның болай да яралы җанын камчылавын дәвам итте:

— Кыргыйланып беткәнсең. Сиңа срочны өйләнергә кирәк, туган. Өстенә еламый карарлык түгел. Давай, өйлән! Мин сиңа менә дигән хатын табып бирәм. Шәп, во! Яшь, чибәр! Кочагында май кебек эрисең дә бетәсең, валлаһи газыйм!

Раян чакырмаган кунакны ду китереп сүгеп куып чыгарды:

— Башка күземә күренмә! Миндә эшең булмасын, идиот!

«Идиот» китте, ләкин күңелдә шик калды. Раян ул шомлы шикләрне бүлешер-таратырдай танышларын барлады. Эзләде, ләкин тапмады. Барсы да ят, жанга ерак иде. Шулчак Альберт искә төште. Әйе, ул, бары ул гына аңлаячак Раянны! Йә Хода, нинди бәхет, бу жирдә бит Альберт бар! Ирнең әрнеп сызлаган йөрәгенә шатлык нуры кунды. Ләкин икенче мизгелдә ул кабат суырылып төште: ә Альбертны кайдан табарга? Кем ул, кайда яши? Раян аның турында берни белми ләбаса... Шулкадәр эгоист, гамьсез кешемени ул, ник шулай игътибарсыз булды соң әле? Фәрештәне таба алмады, чөнки исемен белми, ә Альбертны табачак. Теге йортта аның турында мәгълүмат булырга тиеш.

***

Дөрестән дә, егетнең эзенә төшә алды Раян. Альберт моннан егерме өч чакрым ераклыктагы Куш Тирәк авылында яши икән.

Әмма Раянның юлы уңмады. Барды ул Куш Тирәккә, Альберт яшәгән йортны да эзләп тапты, әнисен дә күреп сөйләште.

Ләкин Альберт өйдә юк иде...

— Беренче тапкыр гына түгел инде. Ай туды исә чыгып югала, — диде хәсрәтеннән сыгылып төшкән ана. — Кайларда йөридер... Кайткач та әйтми бит. Исән генә була күрсен инде. Ходаем, үзең сакла, яңа казалар күрергә язмасын. И Аллам... Кайтып күземә күренгәнче ут йотып торам, ашым аш, йокым йокы түгел. Мәктәптә иң алдынгы укучы иде Албиртым, үз көче белән институтка керде. Гел стипендия алып укыды, урнашкан эше дә акчалы, дәрәҗәле иде... Әй әрәм дә иттеләр баланы... Имансызлар! Мәңге рәхәт күрмәсеннәр, әниләр рәнҗеше төшә ул. Терелтә алмыйлар улкаемны, үзенә урын табалмыйча бәргәләнеп йөри... Житмәсә, үләм дип тә куркыта. Аннан башка мин нишләргә тиештер?! Бердәнберем бит ул минем.

— Миңа аны күрергә кирәк иде. Бик кирәк иде. Бәлки кайтыр. Сездә генә калсам? Көтсәм... Ни диярсез? — диде Раян.

Ләкин хатын теле белән дә, кулы белән дә кунагын куа башлады:

— Юк-юк! Буламы соң?! Ялгыз хатын янында чит ир... Бер гөнахың булмаса да, күзеңне ачырмаслар. Юк-юк! Син үз юлыңда бул инде. Кит син, кит!

Ләкин Раян китмәде. Бердән, соң иде. Икенчедән, аның китәсе килмәде. Альбертның туган авылы аның өчен дә якын иде. Башта ул авыл урамнарын инләп йөрде, аннары чирәмле тыкрыктан су буена төшеп китте. Жәйге төн жылы, тыныч иде. Анда-санда эт өргәне, сыер мөгрәгәне ишетелеп куя. Ә гармун, гитара тавышы юк. Беркем моңаймый, жырламый. Моңаер, жырлар өчен Альберт та никтер авылыннан чыгып киткән, кешеләрдән качкан. Әнә ул, Альбертның тынычлыгын алып, жырлаткан, моңайткан, ерак юлларга ашкындырган тулы ай... Караңгы төпсез күк йөзеннән жиргә аптырап карап тора. Галәмнең сыңар күзе. Ялгыз булганга адәм жаннарын үзенә чакырадыр да әле. Аңа да жылы кирәктер. Салкын көмеш нурлары меңнәрчә чакрымнарны үтеп жиргә төшкән, тал кызларының бөдрә чәчен үбә, инеш суында коена... Дөнья матур, искиткеч матур! Бу гүзәллекне эчеп бетерә торган түгел. Бу гүзәллек миллион еллар буе жирнең күпме кешесен иркәләгән. Кешеләр килә торган, китә торган, ә матурлык калган.

Тик ай ялгыз. Гомере буе ялгыз. Раян да ялгыз. Ясирә исән чакта да ялгыз иде... Альберт кайларда йөри икән? Бәлки ул да берәр ярда ялгызы моңаеп утырадыр. Учак яккандыр. Гитарасының нечкә кылларын чырткәләп, сыңар күзле галәмгә йөрәк сагышын түгәдер. Их, аның янында буласы иде, рәхәтләнеп сөйләшәсе, күңел бушатасы иде. Бәлки ул ерак та түгелдер. Атларга кирәк. Әкрен генә атларга да атларга... Бәлки юлында Альбертны очратыр. Шулай дип уйлады Раян һәм калага илтүче олы юлга таба юнәлде...

Арып-талып, хәлдән таеп калага кайтып житкәндә инде таң беленә башлаган иде. Раян шәһәр кырындагы гаражына кереп бераз хәл жыеп алырга булды. Жәяү йөрүне күптән оныткан аяклары сызлап-сыкрап ял сорый иде. Әмма аруның соңгы чигенә житсә дә йоклый алмады. Чөнки гараж капкасын ачуга күзенә картиналар чагылды. Караңгылык тантана иткән сыңар күзле картиналар... Ни дип саклый соң әле аларны Раян?! Кемгә, нигә кирәк алар? Бу дөньяда караңгылык үрчетмәсәң дә хәттин ашкан... Аруын онытып Раян аларны урамга чыгарып атты. Якында гына чүп контейнеры юк иде, шуна күрә яндырасы итте. Бу арада көннәр коры торган иде, буяу сеңгән картиналар шырпы сызуга дөрләп кабынып та китте. Көчле учак иде бу. Раян күңелендәге бар шыксызлыкны үзләренә сеңдергән күңелсез картиналар юк ителүләренә сукранган-ачуланган сыман шатырдый-шытырдый яндылар. Учак ялкыннарын күреп шикләнүче булган күрәсең, сиреналарын улатып янгын машинасы килеп житте. Инде

болай да сүнеп барган учакка су сиптергән булдылар, нинди дер документ тутырдылар, кул куйдырдылыр. Кирәкмәгән жирдә учак яккан өчен штраф түләтәчәкләр икән. Раян карышмады, һәр сүз белән килешеп баш кагып торды, ни кушсалар шуны үтәде. Аңа барыбер иде. Янгынчылар китәргә җыенгач:

— Егетләр, мине шәһәргә ала кайтыгыз әле, — дип үтенде.

Тыңладылар тагы...

Өенә кайту белән кояшлы бүлмәгә атылып керде. Ул Фәрештәсен сагынган иде. Керде, жиде рәсеменә берьюлы карап, бәхетле елмайды:

— Кадерлем, мин карангылыкны яндырдым!!! — дип кычкырды.

Аннары юынып-чишенеп тә тормый диванга ауды...

***

Чынбарлыктан аерылып йокы куенына кереп барган бер мизгелдә ишектә кыңгырау тавышы яңгырады. Ачмыйм, дип уйлады Раян. Килмәгез, йөрмәгез, миңа беркем кирәкми! Ләкин ишек ачык иде. Ул аны бикләргә оныткан иде. Шуңа күрә килгән кеше сак кына басып бүлмәгә керде. Диванда йоклап яткан ирне күрде. Нишләргә белми икеләнеп шактый басып торды. Аннары әкрен генә дәште:

— Исәнмесез...

Колагын иркәләп үткән шул әкрен, назлы тавышны ишетеп Раян күзләрен ачты... Иң башта алсу яктылык күрде... Сискәнеп сикереп торды. Аның каршында язгы таң балкышыдай алсу күлмәкле Ул басып тора иде. Раян үз күзләренә үзе ышанмады. Бу мөмкин түгел! Ничә айлар буе эзләгән кадерле кешесе аның бикле ишеген ачып кергән дә каршысында басып тора... Бу саташудыр, ләкин нинди күңелле, рәхәт саташу. Күз алдында шулай ап-ачык булып, нәкъ тормыштагыча пәйда булган Фәрештәсен кабат югалтудан курыккандай, Раян тын да алмый, сагынудан сусаган карашы белән нурлы йөзне эчте. Бу кадерле йөзне истә калдырырга, күкчәчәк күзләрне, гәрәбә каш-керфекләрне, сусыл җиләк иреннәрне тизрәк тукымага төшерергә кирәк! Бүген үк, хәзер үк!

— Исәнмесез, — дип дәште хатын. — Гафу итегез, ишегегез ачык иде. Мин «горсеть»тән, Фирдәвес Йосыпова булам.

Раян аның сүзләренә төшенмәде, бары елмайды гына. Ул бинниһая шат иде. Теге котсыз сыңар күзле картиналарны күптән яндырасы булган! Бер могҗиза булып, таң нурларына уралып аның өенә Фәрештәсе килеп керде!

— Мин сезнең бусаганы инде күптән саклыйм. Кайчан килсәм дә, ишегегез бикле. Ут өчен түләмисез, счетчик күрсәткечләрен дә хәбәр итмисез. Бурычларыгыз шактый җыелган. Нигә түләмисез?

Раян дәшмәде, елмаеп басып торуында булды.

— Нигә елмаясыз? Мин бит чынлап сөйләшәм. Түләмәсәгез, утыгызны өзеп китәчәкләр. Аңлыйсызмы шуны? Бәлки сез бире дә яшәмисездер? Ул чагында торак идарәсенә гариза языгыз. Болай ярамый бит инде... Ни гомер... Нигә түләмисез соң?

Ләкин Раян җавап бирмәде, елмайды гына. Бу хатын аны: «Сез җүләр, алкаш, оятсыз, кабахәт!» — дип сүксә дә, ул барыбер елмаячак иде. Чөнки ул аңлады, бу саташу түгел, аның каршында чынлап та Фәрештәсе басып тора, сөйләшә... Аның карашы, аның тавышы...

— Бәлки түли алмыйсыздыр, җаегыз юктыр? — дип сорады ул тавыш.

— ...

Хатын квартир хуҗасының һаман бер сүз дәшмичә исәрләрчә елмаеп торуына тәмам гаҗиз булып:

— Бәлки сезгә ярдәм кирәктер? — диде.

Ниһаять, ир авызыннан бер сүз тәгәрәп чыкты:

— Кирәк!!!

— Нинди ярдәм? Врач чакырыйммы? Бурычка акча биреп торыйммы?

Раян аның бу сүзләренә әлләни әһәмият бирмәде. Аның уйлары башка дөньяда гизә иде.

— Миңа син кирәк! — диде ул. — Мин сине күптән эзлим!

Ят ир авызыннан шундый сәер сүзләр ишеткәч, хатын аптырап, шикләнеп калырга тиеш иде. Ләкин эчке куркуын йөзенә чыгармады. Карашында кызгану хисләре генә чагылды. Күңелендә әллә ничә сорау бөргәләнсә дә, йөзе тыныч иде. Чөнки аның бу йортка беренче килүе түгел. Сары дермантин белән тышланган, маңгаена «57» санлы калай сугылган бу ишеккә көн саен диярлек кагыла торгач, ул квартир хуҗасы турында шактый мәгълүмат җыйды. Хатын белә иде: биредә шәһәрнең танылган художнигы яши, училищеда укыткан. Хәзер беркайда да эшләми. Хатыны үлгәч, эчүгә сабышкан, машинасын саткан. Квартирын эчмәкләр оясына әйләндергән, сәрхушләр йортында ятып чыккан. Үз акылында түгел бугай. Өендә бикләнеп ята, беркемне кертми, беркем белән аралашмый. Хәтта балаларын да кертмәгән, әтиләре янына кайтып, күршеләрдә кунып киткәннәр...

Хатын боларны белә иде. Шуңа күрә өйдәге кот очмалы тәртипсезлеккә дә, айлар буе су күрмичә җир төсенә кергән идәнгә дә исе китмәде. Ир өстендәге таушалып-бөгәрләнеп, керләнеп беткән күлмәк-чалбарга да тыныч карады. Дөрес, тузгыган чәчләренә кунган көлсу көрпәләр, корымга буялган бит-куллар бераз аптыраштa калдырды калдыруын. Җитмәсә, ирдән учак исе килә иде. Инде менә бу сүзләр...

Хатын аларны аңламаганга сабышып елмайды гына.

Ләкин елмаерга кирәкми иде шул!

***

Фирдәвес эштән үзе теләп китмәде. Башлыгы, бүлек мөдире пенсиягә чыккач, аның урынына яшь-яшь егетне китереп утырттылар. Фәләннең туганы икән, дигән чыш-пышлар ишетелде. Соңгы вакытта гел шулай булды: алар оешмасына эшкә гел кемнендер кемнәре урнашты. Чөнки мондагы кебек югары хезмәт хаклары шәһәрдә башка юк та иде.

Яңа түрә тәкәббер затлардан булып чыкты. Җылы кәнәфигә утырган беренче көнне үк, аннан башка биредә эшнең берниндн рәте-чираты булмагандай, җил-җил атлап күрсәтмәләр биреп йөргән булды. Тик ул күрсәтмәләрнең эшкә бер катнашы юк, барысы да кабинетларны яңарту, ремонт ясау, җиһаз алыштыруга кайтып калган иде. Аннары кешеләргә чират җитте...

— Китәргә гариза языгыз, — диде ул Фирдәвесне кабинетына чакырып алып.

— Ник? — дип сорады хатын.

— Сезгә ничә яшь?

— Пенсиягә ерак әле, тагы унсигез ел эшлисем бар.

— Еллар хатын-кызны бизәми, однако.

— Ир-атны да бизәми, — диде Фирдәвес.

Борын астында маңкасы да кипмәгән малайның сөйләшү тоны аңа ошамый, мин-минлегенә тия иде.

— Сез мине яшем аркасында эштән куасызмы? — дип сорады ул.

— Мин сезне кумыйм, ә прошу! Прошу! Аерма бар, аңладыгызмы?!

— Аңламыйм, чөнки берниндн аерма күрмим. Мине эшсез калдырырга

хакыгыз юк, — диде Фирдәвес үҗәтләнеп. — Бу дискриминация дип атала, кеше хокукларын бозу була.

Егет ялгышын тиз аңлап алды:

— Яшь непричем монда, белем, диплом юк! Мәктәп катыргысы белән хәзер идән юарга да алмыйлар! Ә монда солидный оешма, лицо города!

Яңа түрә хаклы иде. Фирдәвеснең, чынлап та, дипломы юк, ул бирегә урта мәктәпне тәмамлауга кереп урнашкан иде.

— Әгәр кирәк икән, укырмын...

Хуҗа аны ярты сүздә бүлде:

— Миңа эш ташлап йөрүче заочниклар кирәкми!

— Акыл, сәләт катыргы белән генә үлчәнми. Мин үз эшемне беләм, тәҗрибәм бар. Һәр вазифаны җиренә җиткереп башкарам. Әлегәчә бернинди кисәтү алганым булмады. Нигә мине куасыз? Чын сәбәп нәрсәдә?

— Хәзер башка заман, башка таләпләр.

Ләкин Фирдәвес чигенергә теләмәде. Үзеннән башка аның таяныр кешесе, яклаучысы юк. Куркып торыр чак түгел, иртәгәге көн турында уйлыйсы бар. Бик яхшы белә: урам тулы эшсез халык. Эшсез кеше — ашсыз кеше...

— Мин заманнан калышмыйм, компьютерны да, кирәкле программаларны да беләм. Эш документларым тәртиптә.

Аяк терәп сөйләшә Фирдәвес. Бүген аның гына түгел, тагы бер ятимнең язмышы хәл ителә. Соңыннан үкенеп, елап йөрмәс өчен соңгы чиккә кадәр көрәшергә кирәк!

— Сезнең белемегез юк! Китәргә гариза языгыз!

— Язмыйм! Кая барыйм? Мин — ялгыз ана, кызым быел мәктәпне тәмамлый... Мин эшсез кала алмыйм, баламны кеше итәсе бар.

— Алдашмагыз! Үз балагыз түгел!

— Әгәр аны мин тәрбиялим, үстерәм икән, димәк, минем бала!

— Ну и характер сездә!

— Һәр кешенең үзен якларга хакы бар! Бер сәбәпсез моннан куасыз икән, башка эш табып бирегез. Мин урамда кала алмыйм.

Тәрбиясе болай да чамалы булган яңа хуҗаның сабырлыгы шунда төкәнде, кисәк кенә «сез»дән «мин»гә сикереп, кызарынып-бүртенеп җикеренә башлады:

— Бәлки сиңа ир дә табып бирергәдер?! Слишком умная!!! Миңа скандалистлар кирәкми!!! Гариза язмасаң, статья белән озатам!

Бу түң җан белән сөйләшүнең файдасы юк иде. Фирдәвес бар нәфрәтен учына йомарлап чыгып китте. Ләкин гариза язарга ашыкмады. Дөреслек эзләп профсоюз комитеты рәисенә керде. Пенсия яшен күптән тутырган, ләкин өендә утырасы килмичә, һаман кеше арасында селкенеп йөрүче Якимов агай Фирдәвесне йомшак җәеп катыга утыртырга кереште:

— Син аларга каршы барма, сеңел. Көчленеке замана. Кушканны эшлә, яхшылык белән кит. Ызгышып киткәннәргә бөтен ишекләр ябыла. Хезмәт кенәгәңне пычратмагайлары. Йөрерсең аннары...

— Ни хаклары бар? Нәрсә, без коллармыни хәзер? Бернинди хокуксыз коллармы? — дип гаҗәпләнде Фирдәвес. — Бер гаебем булмаган килеш, ник әле мин яраткан, белгән эшемнән китәргә, урамда калырга тиеш ди?!

Якимов үз эшендә шомарган таш иде, ике якка да ярый белә, беркайчан өстәгеләргә каршы бармый. Бу юлы да низаг оештырасы килмәде, шуңа гаделсезлектән ярсыган хатынны үгетләп-тынычландырып мәташте:

— Кайгырма, башка эш табарбыз. Танышлар аша үзем урнаштырырмын. Яхшы рекомендация бирербез. Конфликт беркемгә дә кирәкми, акыллы булырга кирәк.

Фирдәвес акыллы булды, үз теләгем белән китәм, дип гариза язды. Якимов та сүзендә торды, хатынны электр челтәре оешмасына контролер итеп урнаштырды...

Ә бала, чынлап та, аныкы түгел иде. Апасы белән җизнәсе автомобиль һәлакәтендә һәлак булгач, аларның бердәнбер кызларын, балалар йортына бирмәс өчен, Фирдәвес үз канаты астына алды. Алсу аңа үз сабыедай якын, кадерле иде. Шул балага җил-яңгыр тидермәс өчен, иреннән аерылды... Моңарчы килешеп-яратышып, матур гына яшәгән гаиләгә ятим бала кергәч, Басыйрның холкы күзгә күренеп үзгәрде, вакланды, кырысланды. Ул көнләшә иде. Фирдәвесне шул сабыйдан көнләшә иде! Чөнки әлегә кадәр алар бер-берсе өчен генә яшәделәр, балалары булмады. Басыйр үзе теләмәде, өлгерербез, бераз үзебез өчен яшик, ашыкмыйк диде. Алсу килгәч, иргә генә тиясе наз-игътибар икегә бүленде. Фирдәвес үзе дә гүя икегә бүленде, җаны да, тәне дә ике яр арасында бәргәләнде, ә ярлар исә көннән-көн бер-берсеннән читләшә-ерагая иде. Ике як та Фирдәвесне үзенә тартты, бары үзенеке генә булуын теләде. Басыйр Алсуның һәр кимчелеген күпертеп Фирдәвескә җиткерсә, Алсу елый-елый Басыйрның тупаслыгыннан зарланды. Кайсын тыңласаң, шул хаклы кебек тоелды. Алсу да апасын Басыйрдан көнләшә, һаман үзенә игътибар сорый иде. Әти-әнисен югалтканнан соң ул үтә дә холыксызланды, авыр сүз әйтү түгел, тавышны күтәреп дәшсәң дә бәргәләнеп еларга тотына иде. Йортта яктылык, җылылык кимеде, ул гүя тарайды, кечерәйде. Анда кайтасы килми башлады. Утызы да тулмаган Фирдәвес йөрәк дарулары эчә башлады. Өч җан бер ояга сыя алмый интекте... Кемгәдер китәргә кирәк иде...

Көннәрдән бер көнне кесә телефонын югалтып, Басыйр Алсуга ябырылды:

— Син генә урладың, башка беркем түгел! Син! Кайтар телефонны, җәфа капчыгы!

Алсу сулкылдап, ярсып елый-елый, гаепсезлеген исбатлап маташты:

— Мин тимәдем!!! Күрмәдем! Белмим... А-а-а, сез мине яратмыйсыз, сез мине үги итәсез! Минем монда яшисем килми! Минем бөтенләй яшисем килми! А-а-а, әнием, бәгырькәем, нигә мине ташлап киттең?!

Фирдәвес ике арага кереп, әле ирне, әле кызны тынычландырмакчы булды. Ләкин ике як та үзенекендә терәлеп каткан иде.

— Ул гел минем телефонда казына иде! Тагы кем тисен, монда башка кеше юк. Мин тапканны ашап ятканы җитмәгән, инде телефонны чәлдергән! Хәерче калдыгы! Тап телефонны, хәзер үк кайтар! Тап дим мин сиңа, оятсыз! Карак! Бир телефонны!!! — дип дулады ир һәм кызның яңагына китереп сукты.

Бу вакыйгадан соң, Фирдәвеснең сабырлыгы өзелде. Уртак тормышка нокта куелды. Әйберләрен җыеп, икәүләп Алсу квартирына күчтеләр. Дөрес, Басыйр гафу үтенеп йөргән булды. Ләкин Алсу: «Мин анда мәңге кайтмыйм!» — дип бик нык каршы торгач, Фирдәвес ире белән араны бөтенләйгә өзде. Ике елдан рәсми рәвештә аерылыштылар, Басыйр башкага өйләнде. Шуннан соң Алсу Фирдәвескә серен ачты... Телефонны чынлап та ул алган һәм балконнан аткан икән. Чөнки Басыйр абыйсы башка апага мәхәббәт хатлары язган, «сагынам, яратам» дип сөйләшкән, имеш... Кечкенә генә ялган да зур ышанычны үтерә. Алсуның бу сүзләре Фирдәвесне бик рәнҗетте. Ул аңлады: үз бәхете, үз рәхәте турында гына уйлаган ятим кыз ир белән хатынның тормышын җимереп ташлады, аны ялгыз калдырды. Ләкин кире борылырга соң иде инде.

Шулай да бу бала аңа иптәш иде, Алсу янында булганда Фирдәвес ялгызлыкны әлләни сизмәде. Яшь, чибәр хатынга кызыгучылар, сүз

кушучылар шактый булды. Ләкин Фирдәвес баш тартты, җайлы-көйле генә барган тыныч тормышына ят кешене кертәсе килмәде. Өченче кешенең артык буласын ул яхшы аңлый иде.

Инде менә тагы ниндидер ир аны кирәксенеп маташа...

***

Фирдәвес бу сәер кешене үпкәләтми, ярсытмый гына чыгып китәргә ниятләде. Шуңа елмайды. Ләкин елмаерга кирәкми иде шул! Каршында басып торган ир бу елмаюга биниһая сусаган, бу мизгелне көннәр-төннәр, айлар буена көзелеп көткән иде бит.

Раян каударланып-хисләнеп Фирдәвесне кулыннан алды. Хатынның кулы салкын һәм дымлы иде.

— Син миннән куркасыңмы? — дип сорады ир.

— Юк...

— Курыкма, кадерлем. Әйдә, мин сиңа бүлмәнне күрсәтәм.

Фирдәвес шикләнсә дә карышмады, иргә буйсынып аның артыннан атлады.

— Менә, таныш бул, бу синең бүлмән. Кояшлы бүлмә. Бу — минем тормышымның иң якты почмагы. Монда җиде кояшым яши, җидесе дә син! Без инде күптән бергә яшибез. Үзең генә юк. Мин сине көттем. Аңлыйсыңмы син мине? Мин сине көттем!

— Аңлыйм... — дип пышылдады Фирдәвес.

Ләкин алдашты. Нинди аңлау булсын ди?! Бу көтелмәгән сәер сүзләрдән, ирнең кыланмышыннан ул тәмам аптырап калган иде.

— Сиңа ошыймы? — дип сорады ир.

— Ошый, — диде Фирдәвес.

Бу юлы алдашмады, дөресен, күңелендәгесен әйтте. Чөнки җен оясына әйләнгән шыксыз залдан соң монда бөтенләй башка дөнья иде. Тәртип, чисталык, пөхтәлек, матурлык... Иртәнге кояш нурларында коенып утырган гөлләр дә күңелгә якты ямь өсти. Ләкин бу портретлар... Сәер иде, барысы да сәер иде. Бер үк төсле җиде картина, андагы хатын... Таныш та кебек үзе, нәрсәнедер, кемнедер хәтерләтә дә кебек... Ә-ә-ә, әлек эшләгән оешмадагы кабул итү бүлмәсе бит бу. Тәрәзәгә төбәлеп утырган хатын бәлки Фирдәвес үзедер... Аның кофтасы, аның чәчләре бит. Ник аны ясаган соң ул?

Шулай да, сүзне икенче юнәлешкә борырга теләп, белмәмешкә салынып сораган булды:

— Бу сезнең хатыныгызмы?

Үлгән хатынын искә төшергәч, бәлки ашкынуы кимер, ярсу хисләреннән бераз айнып-тынычланыр дип өметләнгән иде, ләкин өмете акланмады. Ир кайнарланып кабатлады:

— Юк! Син ул, син!!! Мин сиңа бер күрүдә гашыйк булдым! Мин сине шундый озак эзләдем! Инде өметемне өзгән идем. Син миңа кирәк, бик кирәк! Аңлыйсыңмы? Ышанасыңмы? Китмә, яме! Мәңгегә янымда кал!

Хатын иргә төбәлде. Төн кебек дөм кара күзләрдә үзенең чагылышын күрде. Бу караш аны үз биләмәсеннән, Алсуыннан, иялләнгән тормышыннан төбе-тамыры белән йолкып алып, төпсез упкынга суыра иде. Бу үҗәт-таләпчән караш аны изеп, сытып китәр төсле иде. Бу карашның хуҗасына буйсынса, Фирдәвес үзен, иреген мәңгегә югалтачак иде...

Йотардай булып үзенә төбәлгән бу тынгысыз күзләрдән качу-сыену урыны эзләгәндәй, хатынның кыюсыз карашы әле диварга, әле тәрәзәгә сикерде, бүлмәдәге портретлар буйлап йөгерде... Үзе елмая-елмая ишеккә таба чигенде. Аптыраулы, кызгану катыш гаепле, чарасыз иде бу елмаю...

Ир йөзендәге балкыш сүнде. Өмете өзелүгә ышанырга теләмичә гаҗәпләнеп сорады:

— Син китәсеңмени?!

— Әйе...

— Ник?!

Хатын елмаеп иңнәрен генә җыерды. Үзе һаман артка чигенде.

— Китмә, зинһар, китмә! — дип гасабиланды ир.

Юлына аркылы төшеп, алдына тезләнде, кабаланып-шашып кулларын үбә башлады:

— Син мине ташларга тиеш түгел! Мин синсез үләчәкмен!

— Гафу итегез... Бу мөмкин түгел. Минем үз тормышым... Мин сезне белмим...

Хатын ишекне ачык калдырып, ашыга-кабалана чыгып китте...

***

Мәхәббәт ни ул: шатлыкмы, газапмы? Ни белән үлчәнә, күләме-авырлыгы бармы? Уч кадәрле йөрәккә күпме мәхәббәт сыя? Һәрхәлдә зилзилә-ташкын булып өстеңә ябырылган ят хисләрнең, көтмәгән-чакырмаган, күңел тансыкламаган сөюнең шатлыгы аздыр... Һәм ул күңелгә кояш нуры булып тулмыйдыр, ә бәлки бәгырьне каезлап торучы авыр сөңге булып кадаладыр...

Фирдәвес эшләгәндә кабул итү бүлмәсе һәрчак ачык иде. Бусагадан атлап кергән һәр кешегә якты йөз, тәмле сүз булды. Эш кабинеты үз йортың түгел, ләкин шунда ярты гомерең уза, казна йорты икенче йортыңа әйләнә. Бәлки «Мин» һәм «Без» арасындагы нечкә чикләр шунда югаладыр... Бәлки казна бусагасын атлап кергән һәр кешегә елмаерга кирәкмидер? Ягымлы караш, эчкерсез елмаю синнән ерак йөрергә тиешле җиде ятка җан капкасын ачадыр? Шуннан файдаланып, яктыга, җылыга сусаган җаннар яшерен дөньяңа килеп керә дә, тормыш мизгелеңне урлап үз биләмәсенә күчерә, ниндидер көчләр белән үзеңне дә кочагына суырып китерә...

Юк инде... кирәкми!!! Фирдәвес бу ир бусагасына башка аяк та басмаячак! Моннан соң хәтта йортын да урап-читләп үтәчәк! Ләкин шулчак исенә төште — әй, башсыз хатын, хәтерен мәче урлаган! — ул бит счетчик күрсәткечен язып алмады! Ай буе шул максат белән бу бәндәнең ишек төбен саклады-таптады да, инде бүген — ниһаять! — ниятенә ирешәм дигәндә генә, онытты... Исәр, хыялый рәссам аны да саташтырды, юлыннан яздырды, гүя күзен бәйләде, акылын томалады. «Бүтән участокка күчәргә кирәк. Бу тирәдә башка күренмәскә!» — Раян яшәгән дүртенче каттан төшкән арада Фирдәвес шулай уйлады. Аннары ул тагы шуны да уйлады: исәр булса да, рәссам аның портретын ясаган бит, аңа гашыйк булган! Кемгәдер иҗат итәргә илһам бирү саваплы эштер ул... Бәлки Фирдәвеснең портреты тарихка кереп калыр, бәлки кайчан да булса... кемдер... кемнәргәдер... бу сәер картиналарның туу тарихын сөйләр... Вәт кызык булыр иде! Ул җиде портретның берсен булса да үзенә истәлеккә сорап аласы калган. Аңаниемә шул хәтле...

Әле иртә булса да, ишек төбендәге эскәмиядә бер ялгыз карчык утыра иде. Башка кеше булмагангамы, Фирдәвескә дәшәсе итте. Әллә зарланды, әллә акланып маташты: «Өйдә тынчу, тын житми... йоклап булмый...»

— Әйе шул, тынчудыр, таш йорт бит. Иртәнге һава шифалы, рәхәтләнеп сулагыз, — диде Фирдәвес. Аннары елмаеп:

— Һава өчен әлегә акча сораучы юк, — дип өстәде.

Анысын әйтәсе булмаган икән, шул сүз карчыкка ярсып китәргә җитә калды, әлегәчә тыныч йөзе җыерылып китте, бәсле кашлары арасына кай арада нәфрәт кошы килеп кунды:

— Ут-суга да түләп бетермәле түгел, пинсенен яртысы шунда китә... Акыртып талыйлар, имансызлар! Үләт кырган кавем, безнен өлешләр бугазларына кадалсын!

Әбекәйнең тынлаучы барында рәхәтләнеп зарланыр-сукраныр исәбе бар иде. Олы кешегә игътибар-хөрмәт күрсәтеп бәлки Фирдәвес тә аны бераз тынлап торыр иде... Тик шулчак артында ашыгыч, нык адымнар ишетеп, ул сискәнеп китте. Төшүченең исәр гашыйк булуына шиге юк иде. Шуңа күрә бу урыннан тизрәк ерагаерга ашыкты. Турыдан, таш җәйгән тротуардан китмичә, почмакка борылды. Аулакта, йорт буенда мул булып үскән чирәмлек буйлап, учлап сибелгән нәни кояшчыклар — көләч тузганакларны таптый-таптый Олы Урамга ашыкты...

***

Баскычтан төшүче Раян түгел иде...

Фирдәвес артыннан йөгерергә аның уена да килмәде.

Ул гомумән ни дә булса уйларлык хәлдә түгел, чөнки өзелеп көткән кешесенен күз алдыннан шулай кинәт югалуына бик аптыраган, гаҗиз калган иде. Аның өчен бу гаять зур тетрәнү булды. Әле генә Кояш нурларына күмелеп җанын иркәләгән гүзәл дөнья кабат бушап, карангыланып калды...

Байтак шулай тораташ катып, аңгы-миңге хәлдә басып торды Раян. Бик сәер халәт иде бу. Гүя Фәрештәсенә ияреп тормыш үзе дә бу тәнне ташлап качты... Әйтерсең, тере тәннән шашып, яратып типкән кайнар йөрәген суырып-йолкып алдылар... Түрендә өмет нуры сибеп балкыган Кояшы белән бергә... Ул үткәненең, бүгенгесенең генә түгел, киләчәгенең дә Кояшы иде бит!!! Ә Кояшсыз киләчәк булмый. Бу мөмкин түгел. Кояшсыз киләчәккә, караңгы офыкка таба атлауның бер яме юк...

Мәрткә киткән хәтер төбендә актарынып, ир әле генә булып узган вакыйгаларны, гомеренең бу бәхетле дә, бәхетсез дә бер таңына асылташтай сибелгән кадерле мизгелләрне бер җепкә тезеп, үз халәтен аңларга азапланды. Ләкин юкка! Күпме тырышса да, берни хәтерләми, аңламый булып чыкты. Уч кадәрле вакытка сыйган бу мизгелләр бербөтен булып оеша алмыйча йөдәтте. Дөресе, күренеш бар. Күренеш ап-ачык иде! Тик эчтәлек юк... Эчтәлек булмагач, яктылык юк, барысы да куе томан эчендә... Гомер арбасын тартып баручы Өмет атлары шул томанга кереп югалган...

Әйе, шулай булды, язның иртәнге саф нурларына күмелеп аның өенә Бәхет үзе килеп керде! Бәхетнең диңгез дулкыннарында коенган зәңгәр күзләре, каен җиләгедәй сусыл иреннәре, таң балкышыдай алсу яңаклары әле дә ап-ачык булып күз алдында тора. Раян бик яхшы хәтерли: Бәхет алсу нәфис күлмәккә төренгән иде. Аның тавышы бик-бик назлы, сихерле иде. Тик ни әйтте соң ул? Раян ни әйтте? Ни турында сөйләштеләр алар? Барча сүзләр онытылган... Бәлки Раян үзе гаепледер, сөеклесенең хәтерен калдырырлык берәр ярамаган, урынсыз сүз әйткәндер? Шул саксыз сүзе белән Бәхетен рәнҗеткәндер? Бәлки Ул шуңа ашыгып-кабаланып аны ташлап чыгып киткәндер?!

Күренеш бар, әмма шул күренеш эчендә ике җанны тоташтырып тәгәрәшкән сүзләр юк, гүя булмаган, барысы-барысы эреп югалган. Аныкы да, үзенеке дә. Раян белә: кайчакта күзләр күбрәк сөйли. Тик Бәхетнең карашы аңа төбәлмәгән иде... Ул сөйкемле күзләр аның комсыз карашыннан куркып гел читкә карады...

Ах, нигә шулай булды соң?!

Үз аягы белән каршына килеп баскан Бәхет кошы нигә аны шулай бик тиз ташлап китте?!

Раян куллары белән башын учлады. Уйлау сәләтен югалткан баштан бары бер фикер саркып чыкты: «Идиот!!!»

Бу аңгы-миңге халәттән котылырга, билгесезлек томаныннан тизрәк чыгарга теләп, ул салкын су белән юынып чыгасы итте. Шул ният белән ванна бүлмәсенә керде. Шунда карашы дивардагы тонык көзгегә төште. Болай, очраклы гына. Бәлки аптыраганнан, адашып... Ачык булгач, ул күзләр каядыр төбәлергә тиеш бит... Көзгегә карагач, ир сискәнеп китте: абау-бай-бай... бу бәндәдән кем куркып качмас?! Менә бит сәбәп нидә булган!!! Ул бит Бәхете каршына биниһая котсыз кыяфәт белән чыгып баскан икән! Фәрештәсе шуңа качкан...

Гасабиланган җанын юаткан бу шатлыклы ачышыннан, күңеленә килгән өметле уйлардан Раян кычкырып көлеп җибәрде. Салкынча су астында чайканып алгач, баш бераз ачылып, уйлар яктырып киткәндәй булды. Диванга сузылып ятты да, күзләрен йомды. Күңелендә кабат иртәнге мизгелләр яңарды. Искитмәле татлы, рәхәт мизгелләр булды ич бу! Бүген аның өенә Ул аяк басты! Бу өйдә Аның назлы тавышы яңгырады, бу диварларга Аның якты карашы сеңеп калды. Тузанлы идәндә Аның җылы эзләре ярылып ята... Бу дөньяда Ул бар...

Шулчак Раян күңелендә Альбертның өметле җыры яңгырады:

— Язмыш сандыгыңны актар, тап шатлык нуры.
Гел кайгыдан тормагандыр гомереӊ юлы.
Кояшлы мизгелләр була, исеңә төшер,
Шул мизгелнең бар рәхәтен яңадан кичер.
Уяныр шулчак күңелең, җаның сөенер,
Дөм караңгы төннәрең дә якты күренер.
Кайт шул кояшлы мизгелгә, җаның ял итсен.
Өмет дигән фәрештәләр йөрәгең үпсен...

Альберт хаклы, йөз-мең кат хаклы: һәр мизгелне кадерләп саклыйсы, чөнки алар куенында киләчәкнең серле нуры, туар көннәрнең якты кояшы яши! Һәр мизгел күңел түрендә Өмет булып балкысын, үзенең илаһи нуры белән барча кара тапларны юып алсын, узасы яңа юлларны яктыртсын! Гомер такыясе мизгелләрдән үрелә...

Бүген Раянның гомер такыясенә тагы бер кояшлы мизгел өстәлде.

Бу мизгелне югалтмаска, йөрәк түренә салып куярга да, киләчәккә ияртергә!

Караңгылык ишекләрен мәңгегә ябарга һәм кояшлы мизгелләр кочагына йөгерергә!

Аны, гүзәл Фәрештәсен эзләп табарга, каршына тезләнергә...

Нурлы күзләренә багарга...

Шул якты караштан мәхәббәт тамчылары эчеп, яшәү дәрте алырга...

Һәм яшәргә, яшәргә, яшәргә!

Чөнки бу дөньяда Ул бар!

Ул бар!!!

Илүсә
Исмәгыйлева

# ЙӨРӘК АША УЗА ВАКЫТ...

## Татарга

**Төркем–төркем аерылдык —
Таш аттың туганыңа,
Дошманга — аш.Таңнар калам
Тар аңлы булганыңа.**

**Туганыңны кыралмыйсың –
Ятның телеме татлы?
Татар каны бер Казанда
Дошман кулыннан акты.**

**Бәр башыңны шул ташыңа,
Ятлар һәрчак ят кала.
Сөй туганың! Син татарны
Сөйсә, татар сөя(а)ла.**

## Уяну

**Мин концертта булып кайттым бүген...
Казан килде, Казан, моң булып!
Чапкан, шашкан ташкын кочагыннан
Тартып алды, таныш нур сузып.**

**Ташкын йоткан булган мине, тойдым,
Таш йөземне тамчы эреткәч,
Үрмәкүчтән качкан күбәләк кук,
Жан терелгәч, сагыш сүрелгәч.**

**Юк, мин ташкын түгел, таш та түгел!
Аңлау өчен кирәк уяну,
Чапкан, шашкан ташкын уртасында
Үз–үзеңне табып куану!..**

Илүсә ИСМӘГЫЙЛЕВА – *БДПУ аспиранты. Стәрлетамак шәһәрендә яши. Журналыбызда беренче тапкыр басыла.*

## Кызым ача яңа дөнья

Кызым ача яңа дөнья —
Күзәтәм үзен.
Әллә ниләр белмим икән!
Өйрәнәм үзем.
Мин, карап та, күрмәгәнне
Ул күрә белә.
Бөҗәкне дә, гаҗәп күреп,
Куанып көлә.
Кызым ача яңа дөнья,
Ә мин искесен.
Кайсыбыз белемлерәктер,
Әйтүе читен.

***

Телебезне яклар идек,
Көч, акыл күбрәк булса.
Их!.. моңнарне җиңәр идек,
Тагы бер Тукай туса.

## Ачыш

Калмады —
Кичләрнең сере,
Төннең сихере.
Калганы —
Дөньяның кере,
Яшәүнең бетүе.

***

Вакытның кая чапканын
Белмәсәм дә, мин аның
Йөрәк аша узганлыгын
Үтеп киткәч аңладым.

## Авылда төн

Яңа сауган сөтме әллә
Авылда бу төн?
Эчкән кебек, йөзгән кебек
Эчендә бу тән.

## Калада төн

Таш калада төн күлмәге
Ертылып беткән.
Бизәген кала утлары
Уңдырган күптән.

***

Күбәләк ул — гөнаһсыз җан,
Юк кара уй-теләге...
Бу җырны яратып җырлый
Кәбестә күбәләге.

***

Иртә таңнан эт аттылар —
Тәртип хәзер калада.
Эт көненә калдырсалар,
Ни көтәр безне алда?

***

Диңгез төбе булган монда,
Хәзер, әнә, тау диләр.
Яңа мизгел нәрсә итәр,
Хәтта таулар белмиләр.

***

Милләт бүген шундый хәлдә:
Кемгә сүз ул, кемгә үз.
Һәр татар да Татар булса,
Мескен булмас идек без.

***

— Йолдыз! — диде кар бөртеген,
Нәни кызым, куанып.
Тәү күргәндәй карга карыйм,
Уйларымнан уянып.

***

Кояшлы көн. Күккә карап:
— Ай! — дип кычкыра бала.
— Кояш, — димен, онытылган:
Анда — айлы манара.

## Гашыйк булгач

Һәрнәрсәдән мәгънә эзләп
Газапламыйм көннәрне.

## Данга омтылучыга

Ат-исемнәр максатың да,
Күтәрер микән атың?

## Синең тавыш

Дөньяның ыгы-зыгысын
Оныттырган музыка.



Фарсель Зыятдинов

# АВЫЛДАШНЫҢ АВЫР ЮЛ БАШЫ

ДОКУМЕНТАЛЬ БӘЯН

Бөтенләй көтмәгәндә генә килеп чыкты безнең табышу. Бервакыт шулай Тукай музеена керсәм, анда күңелләргә бик якын «Пар ат» картинасын күреп алдым. Ул мине үзенә җәлеп итте. Кызыксына торгач, аны рәссам Кәримов бүләк иткәнлеген ачыкладым. Хәләл җефете белән Уфадан килгәч, әлеге картинасын татар халкына бүләк итеп калдырган. Шуларга өстәп, аның нииндидер фәннәр докторы булуын да әйттеләр. Бүтәнен ачыклап булмады, адресы билгесез иде.

Ә менә Татар энциклопедиясе институтында эшли башлагач, ул кабат исемә төште, чөнки энциклопедия өчен без татар халкының танылган кешеләрен, зыялыларын, галимнәрен бөтен Җир шары буйлап бөртекләп җыябыз. Уфаның төрле институтларына, фән үзәкләренә яза торгач, ниһаять, «Пар ат» картинасының авторы химия фәннәре кандидаты, геология-минерология фәннәре докторы, профессор Әхим Кәримов икәнен ачыкладым. Шунысы куанычлы вә хикмәтле: ул минем авылдашым булып чыкты.

Баксаң, якташымның язмышы да XX йөздә яшәгән татар халкының язмышына охшаш икән. Туган җиреннән сөрелү, чит җирләрдә бәхет эзләү, ачлы-туклы авыр балачак — әмма югалмау! Кеше булырга, белемгә омтылу һәм мең төрле бәлаләрне җиңеп — дөньякүләм танылу, кайда гына булса да — халкыңа хезмәт итү!.. Икенче Баку, Ромашкино, Маңгышлак нефть ятмаларын барлауда, запасын ачыклауда, киләчәген билгеләүдә авылдашым Әхим агай үзеннән шулкадәр зур өлеш керткәндер, дип кем уйлаган?!

Танылган галим, геолог, химик, рәссам Әхим Кәримовны бүген туган авылы Качкында беркем дә белмидер инде. Хәер, гаҗәпмени, үзен күрсәләр дә танучы булмас иде. Чөнки Качкын авылында аның яшьтиләреннән беркем дә калмаган инде.

Йортлары мәчет артында булган. Ул мәчетне хәтерлим. Манарасын сугыштан соң гына кисеп төшерделәр. Онытырлык кына булмады ул көн. Манараны кисеп бетердек дигәндә генә, Минзәлә ягыннан кап-кара болыт килеп чыкты да, яшен укларын уйнатырга кереште. Манараның гөрселдәп

---

Фарсель ЗЫЯТДИНОВ (1937) — *язучы һәм галим; «Яшәү мәгънәсе», «Тагын язлар килде», «Безнең гомер» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

жиргә авыы булды, бөтен авылны дер селкетеп күк күкрәде, яшен уйнады, тагын күкрәде, тагын... Авыл кешеләре, шомланып-куркып, кайсы кая кереп посты. Тиздән Әхимнәрнең йорт урыны белән янәшә генә мәчет урыны да бушап калды... «Мәчет манарасын кем кистерде?» — дисезме? Ярар, исемен искә алып тормыйк инде, дөньялыкта рәхәт күрә алмады ул мәрхүм, тормышы әче фаҗига белән төгәлләнде.

Әйе, берәүләр җимерә, тузгыта, талый, ә икенчеләр төзи, халкы өчен хезмәт итә. Гомер-гомергә шулай булган. Әхим дә туган җирен, туган авылын калдырып китсә дә, туган халкына хезмәт итте. Аның туган авылы Качкыннан чыгып китүенә дә инде сиксән ел тулды. ...Туган йортын, яшьтиләре белән уйнап үскән Баҗана елгасы буйларын, балыклы Озынкуак, Низам күлләрен, Кырынтау һәм шифалы Әреш чишмәләрен калдырып китү ана җинел булмый, билгеле.

### Хуш, авылым

... 1930 елның язы иде. Кулга алынып, Казан якларына урман кисәргә җибәрелгән әтисе көтмәгәндә генә кайтып төште. Әхимнең куанычы эченә сыймады.

— Ничек кайттың, әткәем? Ничек җибәрделәр?

— Булды инде, улым. Нәчәлник үзенә чакырды да: «Ничек эләктең?» — ди.

— Ә син ни дидең?

— Ни әйтәем, улым? Бернәрсә дә белмәем, мин әйтәм. Әйтеп-нитеп тормыйча алдылар да киттеләр. Менә алтынчы ай биредә эшләем,— дидем.

— Шуннан, шуннан...

— Агай, — ди нәчәлник, — толком беркем дә белмәй ни өчен сине кулга алганнарын, просто куркытмакчы гына булганнар, бар, кайт син өенә, — ди. Шуннан тид арада кирәкле документларны да бирделәр. Менә мин инде өйдә, синең янда, улым...

Сәбәбен тапмыйлармы соң, тапканнар. Әхимнең әтисе Кәрим авылда өч ел буена мулла вазыйфасын үтәгән бит. Шуңа күрә кулга алган булганнар. Өстәвенә, бер аты һәм бер сыеры гына булса да, аңа «кулак, Совет властеның дошманы» дигән исем дә тагалар. Аның укымышлы булуы, фәнни журналлар алдырып, алдынгы тәҗрибәне эштә кулланырга тырышуын беркем дә исәпкә алмый. Алай гынамы? Әтиләре кулга алынгач, Әхимнәрне үз йортларыннан чыгарып, ташландык бер кечкенә өйгә кертәләр...

Дөрес, әтиләре кайткач, үз йортларына күчәргә рөхсәт итәләр итүен, тик әти кешенең башын инде бүтән уйлар били.

Авылдагы башбаштаклык, хезмәт сөючән, хәллерәк крестьяннарны авылдан куу — урта хәллеләрне пошамангa сала. Әнә Зәйнулла да йортыннан куып чыгарылган, сөргенгә җибәрмәгәннәр җибәрүен, кызганганнар... Халыкка бик игелекле булган карт. Шулай да бар байлыгын тартып алганнар. Янгын каланчасында кунып йөри икән, бетләп беткән үзе, бичара... Шуңа күрә күпләр туар көннәргә дә ышанычын югалта бара...

Кулга алыныр алдыннан гына Кәрим абзый Уфада үзенең өлкән кызы янында кунакта булып кайта. Шәһәр тормышы бик тә ошаган үзенә, күрәсең. Шуннан бирле аңа гаиләсе белән Уфага китү уе тынгылык бирми башлый. «Китәргә, акча эшләргә, балаларга төпле белем бирергә», — әнә шундый карарга килә ул.

Әтисенең авылдан китү хәбәрен Әхимгә дә җиткерәләр. Бу вакытта ул Пучы мәктәбендә укуын дәвам иттерә. Ә инде язын укуын тәмамлап кайтканда өйдә беркем дә булмый. Үги әнисе дә (үз әнисе 1921 елгы ачлыктан үлә) балаларын алып Кәриме янына Уфага киткән була. Йортларына инде Әбүбәкерләр гаиләсе кереп оялаган. Шулай итеп, Әхим бу көннәрне авыр

кичерә. Кайда туры килсә, шунда ашап, кунып йөрергә туры килә. — Дөрес, Әбүбәкер һәм аның хатыны булдыра алганча ашатырга тырышалар, ә өйгә кайтмый калса кызыксынмыйлар, эзләмиләр. Туган авылында, үз йортында артык кашык, чит кешегә әверелә ул.

Тора-бара ул авылның танылган хулиганы Сәлим белән дуслашып китә. Көннәрдән бер көнне Сәлим Әхимне үзе янына чакыра да:

— Мәйтәм, тамакны чылатып алсак зыян итмәс. Өлкәннәргә генә кыланырга димәгән бит, — ди.

Әхим ялындырып, кат-кат әйткәнне көттерми, ризалаша. Йомырка саткан акчага алынган «чәкүшкә»не тотып, авыл читендәге салам өеме янына юнәләләр болар. Авылның иң ярлы, хәтта, тавыклары да булмаган Сәлимгә йомырка каян эләккән соң? Билгеле инде, кемнендер тавык оясын туздырган.

Очрашуның инициаторы Сәлим салам өеме янына житкәч, чәкүшкәнең яртысын Әхимгә салып бирә дә, егетлеккә миннән өйрән дигән кебек, калганын «эһ» дигәнче бугазына аударып та куя. Әхим дә калышмаска тырыша. «Бәй, бу өлкәннәр сүләгәнчә бик үк күңел кайтаргыч нәмә түгел икән», — дип авызын җайлап кына сыпырып ала. Ул гына да түгел, бөтен тәне буйлап «рәхәт» изрәү тоеп, кылган гамәле күңеленә хуш килгәч, Сәлим белән дуслыкны өзмәскә була. Ә бу дуслыкның хәтәр «җимеш»ләре өлгереп килүен ул әле сизми. Моның ахыры нәрсә белән беткән булыр иде, әйтүе читен. Ярый әле, Яхшый авылына килен булып төшкән бертуган Мәликә апасы килеп, аны үзләренә алып китә. Бу мизгел Әхимнең тормышында нинди урын тотканын ул соңыннан гына абайлый.

***

Яхшыйда яшәргә яхшырак иде, билгеле. Янәшә генә урман. Сөн елгасы да ерак түгел. Бирегә килгәч, Әхим өчен трай тибү бетте. Берсеннән-берсе кечкенә өч баласы белән апасы тәмам хәлдән тайган иде. Менә хәзер кул арасына керердәй энесе килгәч, Мәликә дә иркен сулап куйды. Гаилә колхозда исәпләнсә дә, әлегә колхоз эшенә чыгучы юк иде. Мәликә үзе бала караудан, йорт-җир эшеннән арына алмый. Ире тоткынлыкта. Шуңа күрә дә гаилә исеменнән колхоз эшенә Әхимгә катнашырга туры килде. Өлкән яшьтәге колхозчылар белән ул теләсә нинди эшкә чыкты: җир сөрде, урман кисте, имән кайрысы әзерләде, терлек карады, тирес чыгарды. Шуның өстенә апасы бирәр эш белән киткәндә балаларга да күз-колак булды...

Колхозның буйсынмас яшь тае да күп мәшәкать китерде Әхимгә. Дөресрәге, ул нининдер ят малайга баш бирергә теләмәде. Болай ачыктан-ачык бәрелешләр килеп чыкмады чыгуын. Ләкин... көннәрдән бер көнне Әхим арбага тирес төяп басуга юнәлде. Көн ифрат та матур, тайның кәефен кырырлык нәрсә юк, барысы да тәртиптә иде кебек. Тик... тайның басу капкасын чыгуы булды, башта юртаклап, аннары исә кушаяклап чабарга тотынды. Кырынтауга житкәч, бөтенләй дулап чапты. Әхим аны тыя алмады. Үч иткәндәй, шулчак көтелмәгән хәл булды: озын чыбыркының бер өлеше аягына уралып, икенче очы тәгәрмәчкә эләгүгә, ул тартылып Әхимне арбадан алып атты. Ярый әле, җиргә төшкәч аягы чыбыркыдан ычкынды. Юкса зур бәла киләсе иде...

Тау итәгенә житкәч, тай кинәт кенә борылды һәм шунда арбаның арткы өлеше әйләнеп капланды. Тай исә, арбадан бушауга, колакларын торгызып, «кем җинде» дигән кебек, баскан урынында Әхимгә карап тора иде. Инде бирелергә әзер иде ул. Әхим исә, суерылган җирләрен сөрткәләп алды да, аксый-аксый, горур тайга таба атлады...

Ничек кенә булмасын, Яхшыйда әйбәт яшәде Әхим. Бар вакыты хезмәт белән үтте. Йорттагы ир-ат эшен берүзе башкаргангамы, күңелен нининдер

горурлык хисе дә били иде. Тик, Нәҗип җизнәсе тоткынлыктан срогын тутырып кайткач, хәлләр үзгәрде.

Дөрес, Нәҗип начар хуҗа түгел иде: эш рәтен белә, хуҗалыкта һәр нәрсәне тәртиптә тота. Тик кирәгеннән артык вакчыл, кирәгеннән артык бәйләнчек иде шул. Кайтуының тәүге көннәреннән үк ул Әхимне тәмам кол итте. Күпме әче сүз, күпме мәсхәрә ишетте ул аннан. Арт чүмеченә менеп төшәргә дә күп сорамый җизнәкәй. «Нибары 2-3 ай эчендә җизнидән эләккән каһәр-тукмакны мин башкалардан гомер буена да күрмәдем», — ди үзенең бер истәлегендә Әхим.

Көннәрдән бер көнне, аның уйларын сизгәндәй, әтисеннән: әйе, иң яраткан, иң ягымлы, иң кадерле, иң күп белә торган, иң олуг күңелле әтисеннән хат килеп төшә. «Фатир ягын бераз көйләдек, безнең янга Уфага кил, улым», — дигән иде әтисе ул хатта.

Юлга җыену озакка сузылмады. Юл хәлләрен кем белә, дигәндәй, бераз сохари киптерделәр. Мәликә апасы эчке җылы киемнәр, оекбаш хәстәрләде. Ә китәсе төнне Нәҗип җизнәсе колхозның ат абзарыннан «үз» атын, «үз» тарантасын алып кайтты. Хатынына тиешле күрсәтмәләр биргәннән соң, каенешенә боерды: «Тот атны, Әхим!»

Бу утыз беренче елның салкын сентябрь ахыры иде. Алар Агыйдел ярындагы пристаньга элдерттеләр. Әхим — кучер, ул алга утырган, ә Нәҗип җизнәсе артта — баринны хәтерләтеп, кучерны өйрәтеп, акыл сатып бара, ара-тирә ачуланып та ала. Әле сентябрь генә булса да, үзәк өзгеч әче җил исә, вакыт-вакыт салкын яңгыр сибәләп ала. Көтмәгәндә авыр болытлар арасыннан кояш елмаеп куя да, бу хәшәрәт дөньяны күрмәвең хәерлерәк дигәндәй, тагын болытлар артына кереп югала...

Менә ул — Әхимне туган якларыннан гомерлеккә аерасы пристань. Нәҗип җизнәсе атны үзе белгән кеше аркылы авылга җибәргәч, ничектер йомшарып калды. Әллә аерыласы булганга, әллә башына бүтән уй кереп, ул Әхим белән ягымлы сөйләште, юлда сак булырга өндәде. Инде аерылалар бит: Нәҗип аска — Казанга, Әхим өскә — Уфага...

Менә Казанга китәсе пароход пристаньга килеп тә туктады. Әхим күргән беренче пароход иде бу ике палубалы «Г.Тукай». Авыл малаен ул тәмам әсир итте, Әхим аңа күз алмыйча сихерләнеп карады. Юк, палубада урнашып өлгергән Нәҗип җизнәсеннән түгел, ә «Тукай»дан ала алмады ул күзен. Ничектер ак пароход аны ерак җирләргә, чиксез киңлекләргә әйди кебек иде...

Менә пароход кузгалып та китте. Әхим Сабирҗан җизнәсе белән яр буенда басып калды. Әйе, ул ялгыз түгел иде. Гомумән, ул хәерле юлга чыккан иде. Пристаньга төшкәнче Миңлекамал апаларына кереп, алар хәл җыеп чыктылар. Нәкъ шунда Миңлекамал апасының ире Сабирҗан Уфага барырга җыенуын әйтте. Алар да гаиләләре белән Уфага күчәргә җыеналар икән. Бер уңайдан ул Әхимне үзләренекеләр янына илтеп тапшырырга уйлады. Егетнең куанычы эченә сыймый иде. Ул Сабирҗан җизнәсен бик тә яратып өлгерде. Бәхетенә, бу әле генә аерылышкан Нәҗип җизнәсе түгел иде инде. Үзе шаян, үзе ягымлы, үзе күп белә, сине үз тиңе итеп сөйләшә. Менә аларның пароходы да килеп җитте. Әхим Сабирҗан җизнәсе белән бергә билет алып, дүртенче класска урнашты. Шулчак Әхим җизнәсенең җиңеннән тартты:

— Кара әле, кара, маяк аска йөзеп китте!

— Маяк түгел, ә без кузгалып киттек, — диде Сабирҗан һәм энесенең җилкәсеннән кагып куйды.

Агыйдел өстендә яңа көн туып килгәндә, Сабирҗан сак кына Әхимне уятты:

— Уфага житеп киләбез, энекәш. Әнә, кара, нинди шәп шәһәр ул!

Әхим сикереп торды да тәрәзәгә ташланды. Тау башында көлтә-көлтә утлар җемелди. Шәп!.. Шәһәр дисәң дә шәһәр! Минем язмыш, минем киләчәк...

## Саумы, Уфа каласы!

Тар, пычрак урамнардан шактый атлаганнан соң (ул чагында Уфада трамвай да, автобус та юк әле), ниһаять, Нижгородканы, Әхимнең әтиләре яшәгән урамны, йортны эзләп таптылар. Йорт дигәне пычрак күл буендагы Котельный урамына урнашкан иде. Йорт дисәң, хәтерең калыр: биредәге йортлар авылныкыннан һич тә аерылмый, түбәләрен генә салам белән япмаган. Тик әле монысы да бит Кәримгә бирелмәгән. Моны алу өчен аңа иң элек Салихҗан дигән кешегә төзергә ялланган йортны салып бетерәсе бар. Шуннан бу иске йортның хуҗасы яңага күчәчәк һәм искесен арзан бәягә Әхимнең әтисенә сатачак.

Йорт дигәннәре 16 квадрат метрлы бер бүлмәдән гыйбарәт. Ишек катында мич, ә мич артында бер өстәл сыярлык 4 квадрат метрлы аш ягы. Анда озынча киштә-сәндерәләр эшләнгән. Балаларның төп яшәү урыны шул. Биредә Әхим сәндерәне сандыкка алыштырды. Әнисе Рабига өч баласы белән һәм Кәрим шунда йокладылар. Күптән көткән шәһәр тормышы Качкын малае өчен әнә шулай башланды.

Шәһәргә килеп берникадәр вакыт үткәннән соң шимбә көнне кич белән Кәрим Әхим янына керде:

— Улым, Мәдинә апаңнарга кунакка барырга теләйсеңме? Ничек яшәйләр икән, танышырсың, Наил һәм Фаил исемле энекәшләрең белән уйнарсыд.

Мондый тәкъдимгә кем каршы килсен, ди. Әхим куанып бетә алмады. Кунакка бик тиз җыендылар. Ә менә аякка нәрсә кияргә? Чабата кисәң, шәһәрдә ничектер уңайсыз, яланаяк барсаң, салкын. Киңәшләшкәннән соң Әхимгә кемнендер иске итекләрен бирделәр.

Шәһәрдә транспорт йөрми. Бигрәк тә үзле балчык белән капланган Лесопильный урамы буйлап атлау бик тә кыен. Әхимнең болай да чамасыз зур итегенә үзле балчык потлап дигәндәй ябышты. Аны сөйрәп бармалы түгел иде, авыр итек аягын каны чыкканчы кырды.

— Ну, ничек? — диде шулчак әтисе Әхимгә, — шәһәр тормышы ошаймы?

Шундый чакта ничек сер бирсен инде:

— Әйй-бә-әт! — дигән булды ул, елмаерга тырышып.

Менә ул — Цюрупа урамы, кырык икенче йорт. Мәдинә апасы шунда яши бит.

Мәдинә кунакларны шатланып, ачык йөз белән каршы алды. Егерме тугыз яшьлек ханымның ачык йөзендә яшьлегенең, саулыгының, бәхетенең куанычлы чаткылары уйный иде.

— Ии-и, нинди куаныч, әткәем килгән. Керегед, кер, бүлмәгә үтегед, — дип тезеп китте Әхимнең апасы,— О-ой, карале, кемне күрәм? Бу бит беднең Әхимчик, нинди үскән!.. Аякларын, итеген генә күр син. Миргасыйм, әтисе, карале син энекәшемнең аякларына! Ай, Аллаһым, каян эдләп таптыгыд мондый үденнән дә дур итекләрне? Ачуым килмәгәе, һәркайсына пот ярым әчегән кәбестә сыярлык. Нигә дип бу котсыд ялгашларны кидердегед минем энекәемә?! Һичтә, чабата кидерсәгед ни булган? Бед үдебед дә чабата киеп үстек бит. Әле дә ярты Уфа чабатадан йөри.

Апасы күбрәк сөйләгән саен Әхимгә рәхәтрәк була барды. Шулай ачык йөз белән кабул итүләрен, чиста, әйбәт тормышта яшәүләрен күреп куанып бетә алмады ул. Мәдинә барысын да өстәл янына чакырды. Кунаклар хөрмәтенә сирәк очрый торган ризыклар да өстәлгә чыкты. Соңыннан хуҗабикә өстәлгә өстенә юка гына итеп баллы май ягылган икмәк телемнәре куйды:

— Бисмиллагыдны әйтеп ашагыд, балалар, тамагыгыд туяр, — диде ул.

Арада иң кечкенәсе, әмма иң кыю улы Фаил:

— Балны калынрак яксаң, бисмилланың көче икеләтә арта,әнкәй, — дип куйды шаяртып.

Барсы да җинелчә генә елмаеп алдылар.

... Чәйдән соң малайлар Әхимне үз бүлмәләренә алып керделәр. Мондагы китап... чуты-чамасы юк. Бик кечкенәләре дә, күтәрә алмаслыклары да. Әхим аларга кул тидерергә дә базмады. Малайлар аны шунда ук аңлап алдылар:

— Телисеңме, картиналар күрсәтәм, — диде Наил.

— Телисеңме, менә бу кызык әкиятне укыйм үзеңә, — диде Фаил.

— Кызык, имеш, — диде Наил тегене бүлеп,— барыбер картинага, рәсемгә житми инде ул, шулай бит Әхим абый?

Кем белә, рәсем ясау сәнгатенә мәхәббәт, бәлки, шул мизгелдән, шул көннәрдә тугандыр Әхим күңелендә...

Икенче көнне дә китап диңгезендә йөзде Әхим. Бу кадәр байлыкның сере дә бар икән. Миргасыйм инде шактый еллар тәржемәче булып эшли, бик күп фәнни китаплар тәржемә иткән ул.

Әхим пот ярымлы итекләрен киеп өенә кайтышлый туктаусыз энекәшләре турында уйлады. Алар бик бәхетле яшиләр төсле тоелды аңа. Ләкин болар барысы да өстә, күренеп ятканы гына иде шул. Аларны да заман хәсрәте читләтеп үтмәгән иде. Мәдинә апасы әнә никадәр гомер инде эшсез... Балалар бакчасына эшкә алмый җәфалыйлар үзен. Ышанычлы кеше булуына белешмә таләп итәләр, ди.

Шундый коточкыч көннәр килде халыкка. Кешеләр бер-берсеннән курка башлады. Күрше-күләнгә генә түгел, туганнарга да ышаныч бетте. Намуссызларның шикаяте белән бер гаепсез кешеләрне кулга ала тордылар ул чакта. Туганнарның да бер-берсе белән очрашуы, кунакка йөрешүләре кысылды.

***

Кәримнәр гаиләсенә дә Уфада яшәү җиңел түгел иде. Киенергә кием юк, ашарга икмәк житми. Моны Әхим яхшы аңлый, шуңа күрә дә әтисенә ул:

— Мине эшкә урнаштыр, әткәй, кайда да ярый, заводта булса тагын да әйбәтрәк, — диде.

— Юкны сөйләмә, улым! — диде әтисе кискен генә, — син укырга тиеш. Аңлайсыңмы? Тугыдынчы мәктәпнең директоры белән инде сөйләштем. Бишенче класска барасың. Вәссәлам!

Икенче көнне инде Әхим мәктәпкә — 5 «б» классына укырга килде. Укуы кызык, әмма, авыр. Татар мәктәбе булса да, күп кенә фәннәр рус телендә алып барыла... Заманында Г.Ибраһимов, М.Гафури кебек танылган шәхесләр укыган Галия мәдрәсәсе бинасы бу. Совет властеның әлеге татар мәдәнияте үзеген дә руслаштырып барган көннәре иде ул. Бигрәк тә русча аңлатыла торган немец телен үзләштерү авыр бирелде Әхимгә. Пучыда укытмадылар бит бу фәнне, ә шәһәр малайлары инде укыган булганнар...

***

Кыш якынлашкан саен Әхимгә бил каешын кысыбрак буарга туры килде. Талон-карточкага бары тик икмәк кенә бирелә иде. Калганын хәттин ашкан бәягә базардан алырга туры килде. Бәяләр исә ай үсәсен көн үсте. Хәер, җан башына бирелә торган ипи паегының күләме дә көннән-көн кысыла барды. Баштарак эшләүчегә 800 грамм, ә эшләмәүчегә 300 грамм бирсәләр, кимәтә торгач, эшләүчегә 500, ә эшләмәүчегә 100 грамм гына бирә башладылар. Үсеп килгән егетләргә йөз граммга утыру, ай-һай, җиңел түгел иде. Ярым ач халдә яшәделәр алар бу көннәрдә... Эч буш булгач, баш шуны тутыру турындагы уйлар белән генә тула иде. Бөтен фантазия, бар хыял — бары тик ипекәй табуга юнәлтелде. «Анны яшәү-көнкүреш билгели», — ди материалистик философия. Чынлап та, дөрес әйтелгән бит. Карынны ачлык борып-борып ала башлагач, кешенең башында намус дигән төшенчәгә дә караш үзгәрә, ә кайчакта бөтенләй юкка чыга...

Әхим яшәгән йортта әтисенең абыйсы Госман да тора иде. Ул шәһәргә вакытлыча акча эшләргә килгән. Үзе генә булгач, ашау ягы алай ук начар түгел. ...Бервакыт шулай Госман бер кирпеч икмәк алып кайтты да шүрлектә калдырды. Шуннан соң ул әллә аны онытты, әллә кирәге чыкмады, икмәк шүрлектә ята бирде. Тынгылык бирмәде ул малайларга. Киләләр дә икмәкне кулларында әйләндерәләр-әйләндерәләр дә, берәр чеметем генә булса да китеп алалар. Аннары икмәкне урынына куеп читкә киткән булалар. Әллә авыздагы тәме, әллә магниты тарта, ипекәйгә ничек кенә карамаска тырышсалар да, ара-тирә күз төшермичә түзә алмыйлар. Уйный-уйный акрынлап икмәк яткан шүрлеккә якынаялар да, «очраклы гына» ипекәйгә килеп кагылалар. Тагын кулларына алалар да, әйләндерә-әйләндерә һәркайсы берәр генә чеметем булса да китеп каба.

Әнә шулай өчме-дүртме көн дәвам итте. Шүрлектәге икмәккә үрелгәч, Госман аптырап калды. Ипекәйне инде танырлык түгел иде. Бу хәлне күргәч, малайлар бер-берсенә елышып, күзләрен кысып йомдылар: менә хәзер эләгә..., Госман абыйлары кирәкләрен бирә инде!.. Әхим исә кулындагы китабы белән битен каплады да, күз кырые белән генә Госманны күзәтте.

Госман абыйлары, тышы булмаганга катып ярылган һәм йомгакка охшап калган икмәкне кулына алды да малайларга таба атлады. Тегеләре бер-берсенә тагын да ныграк елыштылар. Госманның аягындагы кирза итеге ялтырап китте. Итек белән китереп типкәнче дипме, Әхим китабын идәнгә ыргытты да үзе Госманга каршы атлады:

— Гафу ит, Госман абый, мин гаепле, Гомәргә тимә, ярыймы?! Мине кыйна! Мин гаепле, мин бит өлкәнрәк. Аңарга мин әйтергә тиеш идем...

Бу хәлне күргәч, Госман да ни әйтергә дә белми аптырап калды, аның йөзендәге ачуы да юкка чыкты һәм үзе дә сизмәстән Әхимнең ике иңеннән тотып кочты да:

— Сез гаепле түгел монда, Әхим энем. Заман гаепле. Ә менә шундый заманда да кешелек сыйфатларын саклап гафу үтенә белгәнең өчен рәхмәт. Менә, монысын да бүлеп ашагыз, — Госман абыйлары йомгакка охшап калган, инде катып беткән икмәкне Әхимгә сузды...

## Эшкуар малайлар

Яна җирдә яна дуслар да табыла. Әхим өчен ул Фоат Юмашев иде. Янәшә генә яшәп бергә укыгач, укырга да бергә йөргәч дуслык тагын да ныгыды. Кыскасы, Фоат чын мәгънәсендә шәһәр малае. Иң мөһиме — ул намуслы, яхшы күңелле.

Көннәр язга авышкач, ашау ягы тагын да такырайгач, Фоат дустына болай диде:

— Әйдә, базарда бераз акча эшләп алабыз!

— Ничек итеп?

— Бүген үзең күрерсең. Дәрестән соң туп-туры базарга (бу урында хәзер Уфа авиация институты комплексы) китәбез. Анда безне Рәис көтеп торачак. Килештекме?

Килешми нишлисең ди. Бәлки, гаиләгә дә аз булса да ярдәм итеп булыр? Төштән соң базарда аларны классташлары Рәис каршы алды һәм озын сакаллы урыс карты белән таныштырды. Сакалбай бераз гына төшереп алган булса да, малайлар белән бик ягымлы сөйләште:

— Шулай, — диде ул, — димәк, сез, балалар, азрак акча эшләп алырга уйладыгыз? Ярый, ярый, әйтер идем, әйбәт эшләгәнсез монда килеп. Сезнең егет булып җиткәнне, замананың авыр булуын исәпкә алсак, сезне мактаудан башка ни әйтәсең. Эти-әниләрегез бармы соң? Ярый, ярый, аларга да әйбәт булыр, азмы-күпме акча эшләп алып кайта башласагыз, күңелләре булыр...

Сакалбай сөйләгәннәрне Әхим ярыйсы гына әйбәт төшенде, чөнки бу кышта инде ул шактый гына рус сүзләрен өйрәнеп өлгергән иде.

— Булгач булсын инде, мин сезгә бераз акча эшләргә булышырмын, — диде Сакалбай, — сезгә хәзер йөз бит папирос кәгазе бирәм, сез аларны тәмәке тартучы мужикларга сатарсыз, һәрберсен биш тиеннән. Йөз бит сатсаң биш сум, дүртесе мина, берсе — сезгә булыр. Кем мең бит сата, ул ун сумлы була. Килешсәгез, бирегез кулыгызны.

Малайлар борыннарын тарткалап, урыннарында таптанып алдылар:

— Безнең ул йөз битне сатып алырга акчабыз юк шул...

— Башлап җибәрү өчен йөзне бирәм мин сезгә. Тик качарга уйламагыз тагын, — диде бабай, утлы карашы белән сөзеп,— юкса муеныгызны борырмын. Аңладыгызмы?

Шуннан соң карт алдан әзерләп куелган йөз битне алып малайларга сузды. Тегеләр исә кәгазьләрне сүзсез генә алдылар да, бүрекләрен төзәткәләп урамга чыктылар. Сәүдә эше менә шулай башланды.

Бер мужиктан икенчесенә килеп берсе татарча, икенчесе урысча:

— Абый, папирос кәгазе алыгыз, әйбәт тә кәгазь инде, Рәсәйдә бер генә, мондый кәгазьне бүтән бер җирдән дә таба алмассыз, — дип мактый-мактый үз «товар»ларын тәкъдим иттеләр.

Мужиклар да төрле шул. Берсе икене, икенчесе бишне ала, ә өченчеләре бәйләнеп йөрмәгез әле эч пошырып, дип куып җибәрә. Берәүләр алу белән акчасын түли, икенчеләре озаклап кесә капшый, ә өченчеләре, акчасын чыгаргач та биримме-юкмы дигәндәй кулында әйләндерә...

Ә берсе барысыннан да уздырды. Бик озаклап акча эзләде. Ниһаять, тапты, кулына алды. Аны әйләндерде-әйләндерде дә кире кесәсенә салды, ә карашын шул тирәдә чүпләнеп йөрүче чыпчыкларга юнәлдерде.

— Абый, абый, — диде Әхим,— ә акча?

— Ак-ча-мы?,— дип сузды тегесе,— нинди акча?

— Папирос кәгазе өчен биш тиен.

— Ә-әә, кәгазь өчен... биш тиен... — дип ашыкмыйча гына кабат кесәсенә тыгылды, аннан ул акча түгел, ә папирос кәгазен тартып чыгарды һәм Әхимгә сузды. Аннары икенче кесәсеннән гәҗит кәгазе алып, самосад салып төрде дә чыпчыклардан күзен алмыйча гына тәмәкесен көйрәтә башлады.

Сәүдә бу көнне бик акрын барды. Йөз бит папирос кәгазен бары тик базар таралганда гына сатып бетерә алдылар. Кесәләре тәңкә белән тулган иде. Аны Сакалбай янына килеп бушаттылар. Хуҗа кеше акчаны санады да малайларның һәркайсына берәр сум акча биреп аларны мактап алды, аннары өйләренә озатты.

Икенче көнне дә шуны ук кабатладылар, табыш инде бер сумнан артып китте. Өченче көнне берни дә булмас әле дип дәресне калдырырга һәм иртәдән үк базарга төшәргә булдылар. Ул көнне нык тырыштылар, ә кич белән Әхим үги әнисенең өстәленә бер өем бакыр тәңкәләр куйды. Бу кадәр акча бер күнлек ипи паегы һәм башка ашамлыклар алырга җитәрлек иде.

Тик малайларның бу эшен Кәрим ага тиз төшенде. Ул көнне ул озак кына эндәшми йөрде, уйланды. Ә кич ятар алдыннан Әхимне үзе янына чакырып алды һәм йөрәккә үтәрлек итеп болай диде:

— Бу көннәрдә синең нинди эш белән шөгыльләнгәнегедне яхшы беләм, улым. Синең авыр көннәрдә ата-анаңа болай булышырга теләвең яхшы, мактауга лаек... Ләкин, бу эш синең өчен түгел. Авырлыкларны ничек тә үткәреп җибәрербез. Ә син укы. Базарда бүтән күренәсе булма!

Икенче көнне дусты килгәч, Әхим:

— Мина әти базарга бүтән бармаска кушты. Укырга туры киләчәк, — диде.

## Бәхет эзләп Наманганга

Хәтәр көннәр иде бу. Ачлык үзен көннән-көн ныграк сиздерә барды. Бигрәк тә авылдан шәһәргә килеп, әле шәһәр тормышына күнегеп житмәгән, һөнәрсез, төшемле эш урыны булмаган кешеләр ачыкты. Әхимнәр гаиләсе нәкъ менә шундыйлардан иде. Аннары гаиләдә «артык кашык»ларның күбрәк булуы белән дә хәл мөшкелләнде. Ни әйтсәң дә, икәү эшләгәнне жидәү ашый бит...

Шуна күрәдер инде, Әхимнең әтисе: «Урта Азиядә яшәү рәхәт, икмәк житәрлек», — дигән сүзләргә бирелеп, шунда китәргә карар кылды. Аннары электәнрәк таралган «Ташкент — икмәкле кала» дигән сөйләм дә аңа мәсьәләне хәл иткәндә көч һәм рух өстәде. Ферганә үзәнендә урнашкан Наманган каласына китәргә дигән карарга килде гаилә башлыгы. Анда алдан разведка ясарга дип Әхимнең абыйсы Әсхәт китте. Аңа инде унсигез тулган иде. Калганнар Әсхәттән хәбәр килгәч кенә кузгалырга булдылар.

Әсхәт Наманганга барып бер төзелешкә эшкә урнашты, шәһәр читендәге балчыктан салынган бер үзбәк йортын алып торды, аннары Уфага хат жибәрде. «Бар да тәртиптә»,— дип язды ул хатында.

Шуннан, озак уйлап тормыйча гына, гаилә юлга чыгарга жыенды. Барлык булган әйберләрен алып вокзалга юнәлделәр. Әмма Мәскәүдән ул якларга баручы поездларга утыру мөмкин түгел иде. Ә менә Кинель стансасына элəксән, бу инде Урта Азиянең капкасы исәпләнә. Әмма Әхимнәр гаиләсе шушы стансага барып житкәч, китә алмыйча озак вакытка шунда калды. Мәскәү ягыннан килүче поездларның кайсы гына булмасын, берничә кешене генә ала алды. Алары да бай, акчалы кешеләр... Әхимнең әтисе көннәр буе билет компостирлый торган касса чиратында торды. Поезд килгән саен этеш-төртеш башлана, куллар кассага сузыла. Бу вакытта кесә караклары, бурлар үз эшләренә керешә. Поезд кузгалып киткәндә инде алар күпләрнең соңгы ашамлыкларын алган, кесәләрен чистарткан була. Бер кисәк икмәксез калган хатыннар үкереп елый, балалар кычкыра, һәр почмакта әче күз яше түгелә...

Вагонга үтү жиңел булмады. Шулай да, тырыша-тырмаша торгач, караңгы идәнгә кереп урнаштылар. Алар өстеннән сандык-чемоданнар, зур-зур төенчекләр очты. Кәрим абзый боларны урнаштыргач, урамда калган Фәиз янына омтылды, ләкин соңарды шул...

Ул килеп житкәнче берәү:

— Ваня, ә Ваня, монда йомшак мендәрләр! — дип кычкырды.

— Нәрсә карап торасың, китер монда! Кирәге чыгар, — диде икенчесе.

— Өстендә нindидер карапуз утыра...

— Утырса соң, селкеп төшер үзен!

Әмер үтәлде. Фәиз тәгәрәп төште, ә ул утырган — аның астындагы төенчекләр карангылыкка кереп күздән югалды. Куркудан коты алынып кычкырган баланы, билгеле, ишетүче дә булмады. Әтисе килеп житкәндә, ул жирдә яткан килеш үкереп елый иде. Кәрим абзый эшне шунда ук төшенде һәм тиз генә малаен элəктереп вагонга ташланды. Юкса, анда да шундый ук хәл булуы мөмкин иде. Бәхеткә каршы, вагонда барысы да исән-сау иде.

Озакламый вагондагылар тынычлана төште. Каяндыр кондуктор килеп чыкты һәм керосин лампасын яндырып куйды. Тирә-юнь бераз гына шәйләнә башлады.

Мең жәфалар күргәннән соң, ниһаять, поезд кузгалып китте. Тик әле күрәселәр алда да житәрлек иде. Ташкент һәм Урсатьевта икенче поездга күчеп утырулар дисенме, кайбер урыннарда көннәр буе туктап тору дисеңме... Наманганга алар бары тик унжиденче тәүлек тулганда гына барып життеләр.

***

Уфада калган Әхимгә дә яшәү бик рәхәт түгел иде. Башта шул Салихҗаннар йортында яшәде. Һәр атна саен апасы бер кирпеч икмәк китереп торды... Шулай да әле яшәргә була иде. Тик менә яз житкәч хәлләр мөшкелләнде. Апрель ахырында Агыйдел ярларыннан ташып чыкты. Котельный урамы янындагы күл тулды. Су Әхим яши торган йортка якынлашканнан-якынлаша барды һәм ул өй астына да тулып сайгактан өскә бәреп чыкты. Биредә яшәүчеләрне өстәрәк урнашкан туганнарына, якыннарына күчерделәр. Өендә исә Салихҗан үзе генә калды.

Күченүчеләр ул төнне, урын житмәгәнгә, барысы да идәндә йокладылар. Әхим ике ханым арасына эләкте. Берсе яту белән диярлек йоклап китте, ә икенчесе нигәдер йокларга уйламый. Әхимнең кулын сакланып кына ала да күкрәгенә куя. Күкрәк бу вакытта бер күтәрелә, бер төшә, йә дерелдәп куя. Тыйнак һәм оялчан Әхим исә, сулыш алуын да сиздермәскә тырышып, йоклаганга салышып ята. Бәй, бу бит Салихҗан абзыйның яшь хатыны Зәйтүнә ич! Менә ул тагын Әхимнең кулын йомшак кына тотып күкрәгенә кысты, ә үзе еш-еш сулый, калтырана...

Тиздән күкрәкнең тирбәлүе кими төште һәм Зәйтүнә Әхимнең кулын җибәрде. Янәшәдәге икенче хатын бу вакытта инде гырлап йоклый иде.

Икенче көнне ике ханым да торып эшкә китте, ә Әхим Салихҗан йортына юнәлде. Су инде Салихҗан яткан караваттагы мендәрләргә якынлашып килә иде. Каникул вакыты булганга, Әхим көнен табак-көймәгә утырып йорт белән күл арасында йөзеп үткәрде. Салихҗан абыйсына ул сунын кичкә таба аз гына кимегәнен хәбәр итте. Кич житкәч, Салихҗан ялан аяк кына ятагына килде дә йокларга ятты.

«Капитан»га бу юлы да урынны шул ук ике ханым арасыннан бирделәр. Ике ут арасында иде ул. Ни әйтсәң дә, унбиш яшькә житеп килә бит. Зәйтүнәнең күкрәге тагын вулкан кебек кайнаша башлады, Әхимнең куллары тагын шул күкрәк өстенә куелды. Егет тагын йоклаганга салышты һәм кулын акрын гына шудырып төшерде. Бераздан исә кул тагын күкрәк өстендә иде. Дүрт көн, дүрт төн шулай дәвам итте. Ничек кенә булмасын, Әхим бу көннәрдә бәхетле иде. Шулай каникуллар да үтеп китте, су да кимеде, күл дә үз чикләрендә генә калгач, тынычланды...

***

Укулар әйбәт кенә барса да, ярым ач карын төрлесен уйларга мәҗбүр итте. Ни генә эшләмә, мондый шартларда базардан башка яшәү мөмкин түгел иде. Базар бит инде ул бик күптәнге заманнардан бирле туклану чыганагы, бигрәк тә шәһәр кешесе өчен — тормышның үзе.

Шундый уйлар белән Әхим базарга юнәлде. Дусты Фоат Юмашев озата барды. Озакламый алар отышлы эш таптылар. Базар территориясе янында аяк киеме эшләү предприятиесе бар икән. Вак-төяк күн калдыкларын якындагы зур бер чүп тартмасына чыгарып түгәләр. Әхим белән Фоат шунда килделәр. Казына торгач, ярыйсы гына күн кисәкләре дә килеп чыккалый башлады.

— Ә нигә бу күн кисәкләрен итек төзәтүчеләргә тәкъдим итеп карамаска?! — диде Әхим.

— Шулай эшлибез дә аны! — диде Фоат.

Актарына торгач күн кисәкләре шактый табылды. Кисәләрен күн белән тутыргач, товарларын күрсәтергә дип итекчеләр янына киттеләр.

Кулланучылар товарны җентекләп карады, һәркайсы үз бәясен куйды. Утыз тиеннән алып бер сумга кадәр. Артык таммаса да, әгәр дә сөтнең литры ике сум икәнен исәпләсәң, ярап тора бит бу!..

Аннары «сәүдәгәрләр» артык сатулашып та тормады. Тизрәк сату ягын

карадылар. Тизрәк һәм күбрәк сатарга кирәк. Чүп тартмасы янәшәдә генә бит.

Шулай эшләделәр дә. Сәүдә базар ябылганчы дәвам итте. Күлмәк табыш өчәр сумга житә иде. Бу көннәрдә малайлар үзләрен бик бәхетле сизде, алар өчен өч сум зур капитал бит. Шулкадәр баеп киттеләр, хәтта бергәләп беренче тапкыр фоторәсемгә дә төштеләр.

Тик һәртөрле эшкуарлыкның чәчәк аткан чагы һәм бөлгән чагы — кояш баешы була. Боларга да килде ул. Күн табуның «җаен» башка малайлар да сизенгәннәр. Берничә көннән күн сатучы малайлар белән базар тулды. Сатучы күп, алучылар санаулы гына. Итекчеләр дә инде аласын алган, җыйган... Шулай итеп, күн кисәкләре сату табыш китерми башлады. Малайларга бу һөнәрне, телиләрме-теләмиләрме, ташларга, онытырга, башка һөнәр табарга кирәк иде.

Анысын да тиз тапты малайлар. Тимер юл станциясендәге бер тупикта болар кукуруз чәкәннәре төялгән составка тап булдылар.

Шулай итеп, әле генә күн белән сату иткән эшкуарлар сак кына вагонга күтәрелеп, капчыклардан кукуруз чәкәннәрен суырып чыгаралар да кесәләренә тутыралар. Кесәләре тулгач, бернәрсә дә булмагандай, үз юллары белән китеп баралар.

Кыздырылган кукуруз — деликатес. Сәүдә кызды. Тик, монысы инде намуслы сәүдә түгел иде... Әмма ярым ач малайлар бу хакта уйлап тормадылар һәм тимер юл милициясе тотканчы шулай дәвам итте.

***

Көннәрдән бер көнне Әхим янына урта яшьләрдәге бер Фатыйма исемле хатын килде. Баксаң, Үзбәкстан белән Уфа арасында сату итеп йөри икән. Үзбәкстанда ситса, текстиль әйберләрен арзан бәягә сатып ала икән дә, танышлары аша Уфада сата икән. Әйтүләренә караганда бу «бизнесмен» тере «тауар» белән дә сату итә икән. Татар авылларында булып, ачтан үлеп яткан аналардан, аларның үсеп җиткән кызларын юк бәягә алып китеп, Урта Азиягә алып китеп җирле байларга саткан. Татар кызларын ул нибары 5-10 герәнкә онга сатып алган. Ә көньякта кыз башына 3-4 пот он биргәннәр. Карт кызларны түгел, ә яшьләрне әнә шулай бу хатыннан сатып алып, үзбәк агалары соңыннан аларга өйләнә торган булганнар. Мескен кызлар гомер буе туган якларын сагынып, өзгәләнеп газаплансалар да шунда калганнар, үзбәктән үзбәк балалары үстергәннәр. Татар әнә шулай комга сеңә торган...

Фатыйма Салихҗаннарга килгәч, Әхимне үз янына чакырды да катгый шарт куйды:

— Миңа сине Урта Азиягә әтиеңнәр янына алып кайтырга кушылды. Ә мин сине пай-малай булсаң гына юлга алырга килештем. Үзеңнекеләр янына кайткач, хет башыңда йөр,— диде ул мул итеп пудраланган җыерчыклы йөзендәге кашын төзәткәләп,— юлда исә син мине тыңларга, колым булырга тиешсең. Югыйсә, сезнең братны беләм мин... Аңлашылдымы?

— Ә нәрсә? Әгәр дә мин пай-малай булмасам, кирәксә-кирәкмәсә дә сине тыңламасам, нәрсә була?

— Ул чакта мин сине юлда төшереп калдырам. Миңа синнән башка да начар түгел. Үзем генә юл йөрергә мин инде күнеккән.

— Мин пай-малай булмаячакмын, — диде Әхим катгый итеп, — ә әтием янына үзем барырга тырышырмын.

Эшкуар бу сүзләрдән соң югалып калды. Ул мондый җавапны көтмәгән иде һәм бу хәл аның барлык планнарын җимереп ташлады.

Әхим Фатыйма ханымның миңгерәп калуыннан файдаланып, болай дип сорап куйды:

— Сезнең белән бара калсам, юлда мине кем ашатачак соң? — Малай кесә төбендә шалтырап йөргән соңгы тиеннәрен капшап куйды.

— Билгеле инде, мин ашатачакмын сине,— диде Фатыйма ашыгып һәм ягымлырак итеп, — миндә акча бар.

— Ул чакта мин сезнең белән бара алам,— диде Әхим, — хәтта пай-малай да була алам. Хәер, монысы инде минем кәефкә бәйле, ягъни сезнең юмартлыкка.

Шулай итеп уртак килешүгә ирешелде. Юлга җыену өчен Әхимгә бер атна вакыт бирелде.

Җыену дигәннән, поликлиникага барып белешмә алды: ул вакытта белешмәсез поездга кертмиләр иде. Аннары әйберләрен барлады. Кышкы кием дигәне аерым-аерым кисәкләргә таркала башлаганга, аны Җучкага калдырды. Багаж дигәне бер кечкенә мендәр булып чыкты.

Уфадагы соңгы көннәрен ул хушлашуга багышлады. Күңеленә иң якын булган урамнарда булды. Агыйделдә туйганчы су коенды, тын Дим буенда хозурланды. Апалары, сеңелләре белән хушлашты, кунакчыл булулары, аны якын итүләре өчен рәхмәт әйтте. Мәдинә апасы әле юлга дип ана зур кирпеч ипи дә пешереп бирде.

Соңгы кичне ул якын дусты Фоат белән үткәрде. Нижегородка күле буенда төн уртасына кадәр утырдылар, тагын очрашырга сүз куештылар. Әмма, бу — соңгы очрашулары, соңгы сөйләшүләре булуын уйларына да кертмәделәр алар. Икенче көнне Фоат иртә белән пионер лагерена ялга китте, ә Әхим үзенең юлдашы белән вокзалга юнәлде. Җучка озата барды.

***

Икенче көнне алар Кинель стансасына килеп төштеләр. Халыкның күплеге!.. Баш төртмәле түгел. Әтиләре киткән чактагыдан аерма юк иде. Әмма бу юлы озак көтәргә туры килмәде: бер тәүлек дигәндә кузгалып та киттеләр. Моның сере бик гади — Фатыйма ханымның акчалары үз эшен эшләде. Шулай да юлда озак барылды. Товар-пассажир поезды булганга, ул чат саен тукталды, озаклап нәрсәдер бушаттылар, төяделәр... Акрын гына көньякка таба барды да барды ул. Оренбург каласы, Арал диңгезе... артта калды, буш казакъ далалары сызылып үтте... Менә шау-шулы Ташкентка да килеп җиттеләр. Бирсдә икенче поездга күчеп утыру артык күп вакыт алмады. Ниһаять, җиденче тәүлек дигәндә, алар Наманганда иде инде.

## Үзбәк бакчасын саклаганда

Көннәр бик эссе торды. Җәй буена бер тамчы яңгыр таммады. Рәсәйдә мондый көннәр булса, соңгы үлән тамырына кадәр корыр иде. Ә биредә, юмарт Фергана үзәнендә арыклар бар. Көнен дә, төнен дә үләннәргә, мамык кырларына, җиләк-җимеш бакчаларына, терлекләргә һәм кешеләргә тормыш биреп, яшәү көче өстәп арыклар буйлап бераз гына тоныкъ су ага. Чиксез күп эреле-ваклы арыклар кырлар буйлап, шәһәр һәм авыллар буйлап та ага, бакча һәм паркларга керә, урамнар аша үтеп ишек алларына юл ала. Тормыш булган, җан иясе булган һәр җирдә ул арык. Үзбәкнең уңган куллары арыкны кечкенә генә җир кисәге булган урыннарга да сузган. Әхимнең әтисе арендага алып торган йортның ишек алдында да арык бар. Арык янында чәчәкләр, берничә төп йөзем куагы үсә. Әхим эсседән тәмам әлсерәп, ял итәргә йөзем куагы төбенә утырып, ялан аякларын арыктагы салкынча суга төшереп мондагы хозурлыкка сокланды. Ишек алды шундый пөхтә итеп җыештырылган, тирә-якта барысы да ямь-яшелгә төренгән. Һава сулап туймаслык саф, чиста. Гаҗәеп матур чәчкәләрнең исе дөньяга аңкып тора.

— Биредә яхшыдагыдан да яхшы, — диде Әхим үзенчә куанып, — үзбәкләр

үз тормышын начар кормаган. Әгәр дә кояш болай ук кыздырмаса, гомергә монда яшәргә риза булыр идем...

Ишек алдында ике түтәл җир дә бар. Анда Әхимнең үги әнисе помидор утырткан. Ләкин бу участок бик кечкенә, зур гаилә өчен помидор төпләре бик аз иде. Шулкадәр аз иде ул, монда бер генә помидор да өлгерә алмады. Балалар аны әле яшел чагында ук иртә дә, кич тә өзә тордылар... Ашарга җитмәү монда да үзен нык сиздерде. Ни әйтсәң дә, биредә дә шул ук карточка системасы. Эшчеләргә 600 әр грамм, ә гаилә әгъзаларына 200 әр грамм икмәк бирәләр. Бу — бик аз. Эшләп тапкан акчага да ашарга күп алып булмый. Рабига апа эшкә урнаша алмады. Шулай да ул тик тормады: күршеләргә булышты, аларның керләрен юды, тегүен текте. Тегү машинасы бик ярдәм итте аңа.

Тора-бара Әхимгә дә эш табылды. Күршедә яшәүче яшь бер үзбәкнең зур җимеш бакчасы бар иде. Нигездә, ул анар (гранат) плантациясеннән тора. Шуның янында берничә өрек агачы, йөзем, инжир, шәфталу һәм бик зур бер чикләвек агачы да үсә. Үзбәк үзе кайдадыр эшләгәнгә бакчасын юньләп карый алмый. Әхимнең эше — бакчаны чүптән арындыру, сугару. Иң мөһиме: ул бакчаны төрле малай-шалайдан, караклардан сакларга тиеш. Эшләгән өчен аңа үзбәк хатыны көн дә ашарга китереп торды.

Ә менә төннәрен начар иде. Хуҗа кеше бик саран булганга, бакчага кермәгәннәрме дип җиде төн уртасында да сикереп тора да Әхимне уята. Бер куак төбен дә калдырмый карап чыгалар. Инде тынычланды бугай дисәң, хуҗага тагын бөтен бер шайка-карак кергән сыман тоела башлый һәм ул тагын Әхимне уята. Алар тагын бөтен бакчаны әйләнәләр, һәр куак, һәр агач төбен җентекләп тикшереп чыгалар. Хуҗаның кулында зур пычак. Шулай итеп төн үткәнче бакчаны кимендә сигез тапкыр әйләнеп чыга ул. Кайчан гына йоклый торгандыр...

Эшкә китәр алдыннан тагын Әхимне уятып, наказларын биреп калдыра. Әхимгә ышанып та җитми бугай ул. Бакчада бер анар кабыгы гына күрсә дә, шунда ук бәйләнә башлый:

— Кем анар ашады? Минем җимешләргә кул сузарга уйлый күрмә. Юкса, чеби суйган кебек суярмын үзеңне, тының да чыкмас. Җимешләр барысы да исәптә.

Аннары, әйткәннәре үтемлерәк булсын өченме, пычагын чыгара да, үткенлеген тикшереп караган була. Хатынына, хәтта кызларына да тынгылык бирми ул: «Бакчага ешрак чыгыгыз, теге юньсез «чеби»нең нәрсә эшләгәнен күзәтегез». Янәсе, җимешләрне таратмасын, бурлар кермәсен...

Бервакыт, көз җитәрәк, хуҗа бакчага керде дә: «Әчтерхан чикләвегенең уңышын җыябыз бүген», — диде. Ял көн иде. Иртәдән алып кичкә кадәр чикләвек койдылар. Чикләвек исә агачыннан бик үк аерылырга теләми. Хуҗа Әхимгә иң өстәге ботакларга менәргә, чикләвекләрне сугып төшерергә кушты. Ботактан-ботакка сикереп хәлдән тайды ул көнне Әхим. Тегесе исә һаман кычкырынуын гына белде: «Әнә бит, күзең чыкканмени, ник күрмисең?» Астан күренгән чикләвекләр, өстә йөргән Әхимгә күренеп бетми иде шул.

Кич булганда, ниһаять, агач җимешләреннән арынды. Ике зур капчык һәм алты чиләк чикләвек җыеп алдылар. Чама белән, ун пот чамасы. Уңышның мул булуына хуҗа канәгать калып, куанып елмайды. Ә Әхимнең сөмсере коелды. Мул уңыштан ике-өч кило чикләвек бирер әле дип өмет иткән Әхимгә хуҗа нибары дүрт чикләвек бирде. Әйе. Батрак булып, хуҗаның өметсез чыраена караулары рәхәт түгел шул...

Ә анар тагын да мулрак уңыш бирде. Барысы бер йөз чиләк кенә анар чыккандыр. Дөресрәге, Әхим исәпне югалтты. Хуҗа бу юлы да Әхимне куандырмады. Эш беткәч, ярты чиләк чамасы гына, сатарга ярамаслык вак кына булган җимешләрне сайлап бирде.

Шунын белән Әхимнең батраклык хезмәте төгәлләнде. Күршесенә инде анын хезмәте бүтән кирәк түгел иде.

***

Көннәрен инде Әхим энеләре һәм кечкенә сеңлесе янында үткәрде, өй эшләрендә әнисенә булышты.

Бервакыт шулай ишек алдыннан өйгә йөгереп кергәч, идәндә елан шуышканын күреп алды. Бу анын күзлекле елан белән беренче очрашуы иде. Әхимне күргәч, елан качмакчы булып берәр тишек эзләргә керешге. Үзе, әледән-әле кара телен чыгарып, дошманын куркытты. «Дошман» дигәне инде болай да нык курыккан һәм бөтенләй югалып калган иде. Бераз исенә килгәч Әхим урамга йөгереп чыкты һәм кулына беренче эләккән ташны алып кире өйгә керде, һәм ташны еланга таба тондырды. Тегесе бер җыерылды, бер сузылды да тынып калды һәм башка бер хәрәкәт тә ясамады. Әхим сакланып кына еланга якынлашты. Таш еланнын башына тигән... башы яньчелгән иде. Очраклы хәлме? Билгеле, очраклы! Алай дисәң, соңрак тагын нәкъ шундый ук хәл кабатланды.

Эссе җәй акрынлап сүрәнләнде. Төннәрен, хәтта салкынча була башлады. Анын каравы, хәзер рәхәт иде. Дөресрәге, черкиләр беткәч яшәү җиңеләйде. Тиздән мәктәптә укулар да башланды. Әхим үзбәк урта мәктәбенең алтынчы классына укырга килде. Бу вакытта ул инде бераз үзбәкчә сукалый башласа да, әле бик авырлык белән сөйләште. Анын сөйләме үзбәк һәм татар сүзләреннән торган кишмишне хәтерләтә иде. «Кишмиш» еш кына класста пырхылдап көлүгә сәбәпче дә булды. Усал малайлар тәнәфес вакытында Әхим әйткән «кишмиш»не кабатларга тырышып карыйлар, тик булдыра гына алмыйлар һәм кабат көлешәләр.

Әхимнең кигән киеменә карап та малайлар хәйран калдылар. Ул укуга ниндидер каешланып беткән плащ киеп йөри иде. Билгеле, шәп тормыштан түгел инде, җитешмәгәннән, ярлылыктан, башка кием юклыктан. Бигрәк тә классташы, ике метр гәүдәле, кысык күзле Жура исемле малай тынгы бирми иде Әхимгә:

— Минем танышым бу, май заводы директоры, — ди ул Әхимнең иненә кагылып,— менә ул маен күбрәк сыкса, без инде яшибез. Сезгә яларга гына туры киләчәк.

Бераздан ул классташларының көлгән тавышына кушыла:

— Менә, күрәсезме, — ди ул Әхимнең борын астына күрсәтеп, — мае инде күренә, тиздән эш тә булыр.

Әхимнең укырга тырышлыгы, дөрес һәм төгәл җаваплары укытучыларда аңа карата хөрмәт уятты. Моны күреп, шаян малайлар да көлүдән туктадылар, Әхимгә башка бәйләнмәделәр. Малайның абруе үскәннән-үсә барды. Бигрәк тә артта калучы иптәшләренә сизелерлек булыша башлагач, аңа карата хөрмәт тагын да артты.

Ниһаять, кыш уртасында Әхим үзен шундый итеп күрсәтте, педсоветның карары белән аны алтынчы класстан җиденчегә күчерделәр. Монда уку җиңел булмаса да, Әхим чигенмәде, һаман да алдынгылар рәтендә булды. Шулай итеп, ул бер уку елында ике сыйныф — алтынчы һәм җиденче сыйныфларны тәмамлады.

### Бәхил бул, сеңлем!

1933 елның хәтәр кышы Әхимнәр гаиләсен дә читләтеп үтмәде. Читтән килгәннәр өчен монда яшәү аерата читенләште. Ни дисәң дә, җирле халыкның үз хуҗалыгы, бакчасы бар. Ә бит Качкыннан монда күчеп

килгәннәрнең аз гына да запасы юк. Булган әйберләренең дә шактый өлешен юлда килгәндә Кинель стансасында урлаттылар шул.

Икмәкнең бәясе хәттин ашты. Киям дисәң кием, ягыйм дисәң утын юк. Алай да ашарга пешерү әмәлен тапты Әхим. Беркөнне ул арык читләрендә җыелып торган нефть һәм майлы чүп-чарны күрде. Алар шуларны җыеп алып кайтып яга башладылар. Аннары су өстендәге нефтьне иске чүпрәкләргә сеңдереп җыеп яктылар. Аны яккан вакытта өй эче сөрем белән тула, хәтта сулыш алу читенләшә, әмма беркем дә өйдән чыгарга ашыкмый, чөнки тышта суык, ә кияргә кием юк.

Корым, сөрем һәм ачлык, өстәвенә суык үзенекен итә. Балалар көннән-көн ябыга, аннары авырый башладылар. Бигрәк тә арада иң кечкенәсе, алтын чәчле Хәмидәгә каты авыру эләкте. Бернинди дә дару ярдәм итмәде, бала көннән-көн эреп югала бара иде... Зәңгәр күзле бу кызчыкны гаиләдә бик яраталар иде, әнисе исә аны саклап калыр өчен җанын да фида кылырга әзер иде. Һәркайсы үз өлешен бүлеп Хәмидәгә бирергә тырышты. Ләкин кызчык инде ашый да алмас хәлгә килгән иде. Түм-түгәрәк алсу битле, шат күңелле кыз танымаслык хәлгә килде. Ул сөяк белән тиредән генә тора иде. Күзләре дә сүнгәннән-сүнә барды. Ул күзләрдә сагыш, үкенү чаткылары чагылып ала, сирәк кенә булса да хәлсез кулларын туганнарына суза... Бәлки, ул шулай кулларын сузып, нигә мине бу якларга алып килдегез, туган авылыма — Качкыныма кайтарыгыз, димәкче булгандыр...

Бу кызның язмышы, ул — татар язмышы. Чит җирләргә таралып, үз җиреннән, кендегеннән аерылган меңнәрчә, күп меңнәрчә Хәмидәләр язмышы иде бу.

Аның соңгы минутлары... Янына Әхим килгәч, ул күзләрен ачты һәм нәрсәдер пышылдады. Аңлашылмады. Аннан бераз хәл алды да:

— Бәхил бул, абый... Качкынга кайтсаң... — аның сүзләре шунда өзелде.

— Бәхил бул, Хәмидә.

Кызның үлемен барысы да бик тә авыр кичерде. Әнисе туктаусыз яшь түкте. Кәрим абый ничектер картаеп китте, сыгылып төште... Бу кадәр зур гаиләне читкә китеп тә туендырып булмавына ул инде төшенгән кебек иде. Үзен көчсез итеп сизә башлады, барлык балаларын да укытып олы юлга чыгару теләге дә сүнә-сүрелә барды...

Әхимнең иң яраткан ел фасылы — яз да бу юлы куаныч китермәде. Икмәк паегы эшләүчеләргә 400 граммга, ә гаилә әгъзаларына 50 граммга калды. Моңа яшәү мөмкин түгел иде. Балаларның һәркайсы базар тирәсендә, чүплекләрдә калдык-постык эзләргә мәҗбүр булды. Ә базар тирәсе инде андый малай-шалайлар, карт-коры, карчык-корчыклар белән тулган икән. Калдык-постык табу да читенләште. Беркөнне шулай Әхим базарга чыккан иде, үзеннән берничә яшькә генә өлкәнрәк, алама киемле бер егеткә тап булды. Ул малай көлчә сатучылар янына яшеренеп кенә килде дә, бер зур көлчәне тиз генә эләктереп авызына тутыра башлады. Юк, ул качмады, качарга да уйламый иде. Качса, барыбер аны тотып, көлчәсен тартып алачаклар иде. Ә хәзер алып карасыннар! Сатучы моны күреп корт чаккандай сикереп торды да егеткә ташланды һәм бар көченә аны тукмакларга тотынды. Тегесе исә уйлап та карамады, моңа гына түзәргә күнеккән инде, күрәсең. Сатучы аны кыйнаган арада, көлчә инде бөтенләе белән аның карынында иде. Теләсәң дә кайтарып биреп булмый...

Әхимнең хуҗасыз калган көлчәләр янына якынлашуын күреп, сатучы кыйнаудан туктады. Көлчәләрен сакларга ашыкты ул. Ә теге малай исә, яңа калҗа эзләп акрын гына базар буйлап китеп барды.

Сатучы Әхимнән куркып ялгышты. Урлашу әле аның канына кермәгән иде. Аннары нинди йодрык төшә бит, ә хәлсезгә күп кирәкмени? Гомерлек

гарип булып калуын да бар. Шуна күрә ул әлегә калдык-постык жыеп туклану белән канәгатьләнде. Тик кайчакларны гына берән-сәрән өрек яисә чикләвек эләктергәләде...

## Турды йодрыгы

Беркөнне Әхим шулай иртүк торды да, өйдә ач карынын тынычландырыр ризык тапмагач, урамга чыкты һәм үзе дә сизмәстән сул яктагы тыкрыкка борылды. Караса, балчык койма артында өлгергән эре жиләкләрен асылындырып тут агачы утыра. Әхимнең авызына сулар килде. Инде ул үз-үзен тотып калырдай хәлдә түгел иде. Аннары тыкрык буш, якын-тирәдә беркем дә күренми. Озын-озак уйлап тормады, ул сикереп балчык койма өстенә менде һәм аз гына баллы жимешләрне ашыга-ашыга авызына тутыра башлады. Тик туйганчы ашый алмады, кемдер аның тәпиеннән эләктереп алды. Әхим балчык кисәкләре белән бергә жиргә мәтәлде. Куркуыннан калтыранып өскә таба караса, каршысында таза гәүдәле бер үзбәк басып тора иде. Үзбәк итеге белән Әхимгә каты итеп типте дә сүз катты:

— Нигә дип син чит кеше коймасына менәсең, паршивый бур, нигә минем койманы жимерәсең?

— Абый, жибәр мине, — диде Әхим ялынып, — мин ике генә жимеш өздем. Башка тимәм. Сезнең койма икәнен белмәдем...

— Менә хәзер күрсәтәм мин сина ике жимешне. Һәр жимеш өчен мин синең биш тешеңне коям, эт баласы, — дип кулын күтәргән иде, тик туры китерә алмады. Малай куркуыннан ук кебек читкә таба атылды.

Нәкъ шулчак балчык койма артыннан бер хатынның ягымлы йөзе күренде һәм ул муен тамырлары бүртенгән үзбәккә дәште:

— Вой дост... Турды, ә Турды, тукта, тукта, кыйнама аны, жибәр. Күрәсең бит малайның болай да коты алынган, дер-дер килә. Ул беркайчан да коймага менмәячәк. Син бит болай да әнә ничек куркыттың. Шунысы да житкән, жибәр, Турды, жибәр, тимә!

Үзбәк нәрсәдер әйтмәкче булып хатыны ягына борылган иде, Әхим иң кулай мизгел житкәнен сизеп тиз генә табан ялтыратты. Үзбәк аның артыннан йодрык күрсәтеп калды:

— Кара аны, кечкенә күсе, башка минем кулга эләгәсе булма, шунда ук сугып үтерермен!

Яшәргәме? Әллә... Бу сорау Әхимне көннән-көн ныграк уйландыра башлады. Ачлык аңны тәмам томалап килә, күрәсең.

Атна да үтмәде, Әхим тагын теге таныш тыкрыкта иде инде. Нәкъ теге вакыттагы кебек, сусыл тут жимешләре аңа карап торалар. Бераз гына икеләнеп торганнан соң ул түзмәде, жимешләргә үрелде. Тик, ике жимеш тә өзеп кабарга өлгермәде, үзе дә сизмәстән, ул инде жирдә аунап ята иде. Бу юлы Турды әкәнең муен тамырлары элеккедән дә битәр бүртенгәннәр, мыегы тартышып-тартышып куя:

— Әһә, эләктеңме?!

Тыкрыкта алардан башка беркем дә юк иде. Турды куркудан калтыранган малайның өстенә менеп атланды да пычагын тартып чыгарды. Кулдагы пычак иртәнге кояш нурларында атакага әзерләнгән казакның кылычы кебек ялтырап китте. «Хәзер инде беттең, — диде Турды, тынычрак булырга тырышып,— элекке очрашуда килешкәнчә, мин сине чеби урынына суям. Житәр миннән!..»

Малайның бөтен тәненә салкын тир бәреп чыкты. Ул кычкырмакчы булды, мәгънәсез генә үләсе килми иде. Тик тавышы чыкмады, бугазына тыгылган ниндидер төер кычкырырга комачаулый иде.

Ул арада мыеклы үзбәк бармагы белән пычакның үткенлеген капшап карады да, малайның башын артка каерып, пычакны аның бугазына китерде...

Шулчак колак яргыч әче тавыш тыкрыктагы тынлыкны бозды:

— Турды, Турды, Турды, дим! Тукта, каргыйм үзенне! Мондый явызлыкны эшли күрмә! Юкса, мине бүтән беркайчан да күрмәссең. Мин сине бу бичара малайның канына буялган кулларың белән беркайчан да үземә якын китермәм. Әй, җаным, җибәр аны, интектермә! Күрәсең бит, ул нинди ябык. Ачтыр ул, гафу ит аны, үтенәм синнән...

Койма артындагы хатын-кыз шулай кызу-кызу сөйләнде. Ә мыеклы исә, пычагын малайның бугазына терәгән килеш һаман аның өстендә утыра иде. Ниһаять, ул хатынына таба борылды. Аның күзләрендәге кызгану чаткыларын күрепме, суына төште.

— Эт баласы, — диде ул Әхимгә, — бәхетеңә, хатыным игелекле. Юкса!.. Югал күземнән!.. Тик соңгысы булсын!.. — Ул малайның биленә каты итеп тибеп алды.

Әхим ни үле, ни тере хәлдә акрын гына торды. Яшьсез генә елап алды: исән калуына куана идеме ул, әллә язмышның шундый аяныч хәлгә китерүенә рәнҗи идеме? Моны ул үзе дә анык кына әйтеп бирә алмас иде.

Әмма үлем әле барыбер артка чигенмәде. Яшәү өчен көрәш көннән-көн читенләшә барды. Беркөнне өчәүләп гаилә әгъзаларына бирелә торган 50 шәр грамм икмәкне алырга дип киттеләр. Ипи сорап куларын сузып торган ач балаларга:

— Башка килеп йөрмәгез, бүгеннән паек бетерелә, — диделәр.

Бу коточкыч хәл иде. Алар өчәүләп еларга тотындылар:

— Соңгы тапкыр булса да бирегез инде шул 50 граммны, зинһар! — дип ялындылар.

Нишләсеннәр соң, сатучы апалар үз икмәкләрен бирә алмый бит инде... бирмәделәр. Шул көннән бөтен гаилә «аяк асты» азыгына күчте. Базардан ризык сатып алу турында инде уйлыйсы да юк. Онның поты 600 сумга җитте. Өйдәге сатыласы әйбер күптән сатылган, ашаласы ризык ашалып беткән...

Шәһәрдә нинди дә булса ашар әйбер табу мөмкинлеге бетте. Нишлисең, беркөнне Әхим үги әнисе белән чиләк алып басуга китте. Мамык басулары буйлап озак йөрделәр алар, бернәрсә дә тапмадылар. Тик, кайтырга чыккач кына межада үскән тут агачына тап булдылар. Анда җиләк шактый иде. Чиләк тулгач, куанышып өйгә юнәлделәр. Кайткач ач балаларга җиләк ашатып, аларны йокларга яткырдылар. Икенче көнне дә шул ук хәл кабатланды. Бу юлы инде җимешләрдән аш та пешерделәр. Шулай тагын берничә көн үтте.

Әмма, көннәрдән бер көнне, ашказанында каты авырту тоеп, Әхим аяктан ук егылды. Аннары күзән җыера башлады, бернәрсә булышмады. Кәрим абзый, ни эшләргә дә белмичә, улы янына ятып, аны үзенең дә инде кимеп бара торган җылысы белән җылытырга тырышты:

— Әхим, улым, син терел, син... яшәргә тиеш... Яшәвемнең дә бөтен мәгънәсе шунда! Син укырга, кеше булырга тиеш!..

Барысы да тынып калдылар. Әхим белән нәрсә булыр? Ул да үләр микәнни?!. Әхим еш-еш сулыш ала... тартышуы кинәт туктагандай да була... аннары тагын кабатлана... Менә, акрынлап ул бөтенләй тынычланды һәм йокыга да китте.

Әхим исән калды. Яңадан инде тут җиләген бүтән алай күпләп ашарга кыймады. Башка төр азык эзләргә, ачы үлем белән көрәшүнең башка юлын табарга кирәк иде...

## Ишәккә рәхмәт инде

Беркөнне әтисе Кәрим абзый кемнәндер тимер юл буенда поезд бәреп киткән ишәк турында ишетеп алган.

— Авыр тормыш шартларына яраклаштырып куллана белмәгәч, шәригать

кануннарын нәрсәгә өйрәндем соң мин? Балаларны ач үлем тырнагыннан йолып алырга кирәк ич!.. Барыгыд, алып кайтыгыд ишәкне. Тик, ашаганда Аллаһ исемен генә телгә алмагыд, — диде ул.

Әхим белән Рабига апа бер капчык алып, үлгән ишәкне эзләп киттеләр. Ишәк әйткән урынында ята иде. Әйбәтрәк кисәкләрне аерып алып капчыкка сала башладылар.

Боларны күреп торган бер үзбәк кызыксына калды:

— Поезд аны өченче көн үк бәрдергән иде, этегез ашамас дим.

— Безнен «эт» талымлап тормый, нәрсә бирсәң дә ашый, — диде Әхим, үзбәктән тизрәк котылырга теләп.

Үзбәк озак төпченеп тормады, тагын бер тапкыр боларга шикләнебрәк карап алды да, үз юлы белән китеп барды. Әхимнәр исә, капчыкны үзләре күтәрә алырлык итеп тутыргач, өйләренә юнәлделәр.

Әхим өйгә кергәндә, яшәүгә өмет чаткылары әле сүнеп бетмәгән күзләр капчыкка текәлде. Ә ничек тамакларын туйдырырга соң аларның тизрәк? Учакка ягарга да әйбер юк. Итне кычыткан белән самавырда пешерергә булдылар. Өйдә өч көн бәйрәм кебек булды. Ишәккә рәхмәт инде, каян тимер юл буена килеп чыккан да, ничек барып бәрелгән диген, бичара... Ачлыктан балаларга аз гына булса да хәл керде.

Бу вакытта балаларның Әхимнән өлкәнрәге Әсхәт, тиф авыруы эләктереп, хастаханәдә ята иде. Аның авырып китүе дә гаиләдәгеләрнен ачыгуын куәтләде. Ни әйтсәң дә, ул әле эшли иде, үзенә тиешле 400 грамм икмәкне алып кайта иде, ара-тирә капкалап алырдай коры-сарыларын да юнәтә иде. Менә ул терелеп чыкты. Танымаслык булып ябыккан, хәлсез Әсхәт шул көнне үк эшкә китте. Бик тә авыр булды аңа хәлсез килеш утын кисүче (пильщик) булып эшләүләре...

Ә икенче көнне инде Әхимне салдылар хастаханәгә, ул да тиф авыруы йоктырган иде. Атна-ун көн каты гына авырып ятканнан соң хәле җиңеләя төште. Моны күреп әтиләре сөенеп бетә алмады:

— Улым, тагын бер үлемне җиңдек. Болай булгач, яшибез әле, яшибез, — диде ул.

Бик тә ярата иде шул Кәрим абзый Әхимне. Ни өчен? Бу сорауга ул үзе дә кистереп кенә җавап бирә алмас иде, мөгаен. Бу хис бала тугач ук Кәрим абзыйның күңеленә салып куелган, күрәсең. Бөтен яшәешен, бөтен барлыгын, бөтен омтылышын Әхимне югалтмауга, кеше итүгә юнәлткән иде ул. Бу балада булган талант чаткыларын сизгәндер, тойгандыр ахры ул. Һәм аның таланты ачылып китүе өчен үзен җаваплы хис иткәндер...

Авырудан соң Әхимнең аппетиты шундый ачылды, биш тәлинкә аш бирсәләр дә, барысын да ялт иттереп куярга әзер иде. Ашау дигәннән, күрше ятакларда ятучылар авыр хәлдә чакта, әле ярыйсы иде. Өйдән аларга аш китерәләр, ә боларның тамагыннан үтми. Димәк, Әхимгә дә өлеш чыга иде. Ә менә алар да терелеп аппетитлары ачылгач, Әхимгә алар сыйланганда авыз суын йотып утырырга гына калды.

Озакламый Әхимне хастаханәдән чыгардылар, әмма аны алырга килүче булмады. Юлда ял итә-итә көч-хәл белән генә өйгә кайтып җитте ул. Аның кайтуына беркем дә артык сөенмәде. Үги әнисе дә, әтисе дә урын өстендә иделәр. Авырулары тиф булмагач, аларны хастаханәгә алмаганнар.

Инде нәрсә эшләргә? Ничек тамак туйдырырга? Әхимнең дә азык эзләр хәле юк, шулкадәр беткән иде ул, чак-чак кына кыймыллап йөри. Ә торабара шәһәр тормышы тагын да читенләште. Урам чатларында аунап яткан мәетләр күренә башлады. Ачлыктан шешенгән кешеләр танымаслык булып үзгәргәннәр иде. Әхим дә акрынлап шешенә, инде таяк белән генә йөри

башлады. И-и, язмыш, Актаныш якларыннан кайларга кадәр бәхет эзләп кил дә, унбиш яшьлек «бабай»га әверел инде...

Нәкъ шул вакыт, аның янына бер сыйныфташы сугылды. Әхимне күргәч, ул хәйран калды, аннары хәбәрен җиткерергә ашыкты.

— Иртәгә уку елы тәгәлләнү уңаеннан мәктәптә аш пешерәләр, — диде ул, — килергә тырыш.

Икенче көнне Әхим иртүк торды, исәбе ничек тә ашка соңармыйча, бер тапкыр булса да кеше төсле ашап карау иде. Шуңа күрә ул мәктәпкә дә гадәттәгедән бик иртә кузгалды. Таягын алды. Туктый-туктый, ял итә-итә ярты юл да үтелде. Үтеп баручылар аңа игътибар итәләр, кызганалар, ләкин шундый хәлдәгеләр күп булганга күрә ярдәм итә генә алмыйлар иде шул. Наманганда 1933 елның язы шундый кырыс килде.

Әхим мәктәпкә унбер тулганда гына килеп җитте. Укучылар да, укытучылар да инде җыелып беткәннәр. Соңгы ике айда күбесе нык үзгәргән: ябыклар, хәлсезләр. Укучылар гына түгел, укытучылар да... Аз сөйләшәләр, елмаймыйлар...

Класс житәкчесе Турсун апа сүзен:

— Нигә мәктәпкә йөрмисең? — дип башласа да, таяк тоткан баланың, иң яхшы укучысының аягында чак басып торуын күргәч, тыелып калды. Ул уңайсызланып китте, мәктәп карауччы Сөләйман әкә янына килеп, пышылдап кына нәрсәдер әйтте һәм таягына таянып торган Әхимгә таба күрсәтте.

Сөләйман әкәгә шундый авыр көнне саваплы эш йөкләгәннәр иде. Ул ботка пешереп, барлык укучыларны да сыйларга тиеш. Моңа ул сөенеп бетә алмады, куанычы аның җыерчыклы йөзендә балкып тора иде.

Ул Турсун апаны тыңлаганнан соң Әхим янына килде һәм зур сер әйткән сыман:

— Аштан соң беркая да китмә, минем янга кил, печтек кенә эш бар,— дип пышылдады.

Әхим, нәрсәгә икәнен белмәсә дә, куанып риза булды. Иң мөһиме, ул үзенә шундый игътибар булганга куанды. Юкса, соңгы вакытта кешеләр бер-берсен күрми-белми башлаганнар, җаннарын битарафлык салкыны баскан иде.

Сыйлану башланды. Сый дигәннәре — бер тәлинкә тары боткасы. Чын ботка иде. Бераз гына көйгән булса да, күпчелек балалар аны иң кадерле сый, яшәү көче биргән дару итеп кабул иттеләр. Әхимнең хәтерендә шул тары боткасы мәңге онытылмас иң кадерле ризык булып калды.

Сыйдан соң мәктәп директоры укучыларга карап сүз башлады:

— Кадерле балалар, — диде ул, — бүген без уку елы тәгәлләүне билгеләп үтәбез. Барыгыз да диярлек бер баскычка югары сыйныфка күчерелдегез. Ел авыр килде, әмма сез авырлыкларга бирешмәдегез, сынатмадыгыз. Барыгызны да уку елын уңышлы тәмамлавыгыз белән котлыйм. Укытучыларыбызга рәхмәт, ничек кенә читен булса да, уку елын уңышлы тәгәлләделәр.

Бераз дәшми торганнан соң ул завучтан бер бит кәгазь алды да дәвам итте:

— Кадерлеләрем, күзләрегездән күрәм, сезнең бик күбегезгә яшәү җиңел түгел. Ирләрчә булыгыз, түземле булыгыз. Ышанам, тормышыгыз җайланыр. Җәйге ялыгызны яхшырту максатыннан, шәһәр мәгариф бүлеге безгә пионер лагерена 18 путевка бирде. Тугызар бала ай буе ике сменада ял итәчәксез. Путевкаларны тормыш шартлары иң авыр булган балаларга бирәбез.

Директор исемлекне укыганда үзенең фамилиясен ишеткәч, Әхим куанып бетә алмады. Бу, чын мәгънәсендә, ач үлемнән котылып калу юлы иде.

Укучылар таралып беткәч, Әхим акрын гына Сөләйман әкә янына килде.

Тегесе исә, малайның иннәреннән сөеп, ана гәҗит кисәгенә төрелгән тары боткасы бирде. Казан төбеннән кырып җыелган иң тәмле ботка иде бу.

— Мә, улым, ал, сиңа бик кирәкле, ах, бик кирәкле өлеш бу... Исән бул!

Малай сөенеченнән нәрсә әйтергә дә белмәде, башы күккә тиде аның. Димәк, сыйны ул азрак өйгә дә алып кайтачак, үзенең ачыккан энеләрен, әтисен, үги әнисен дә сыйлаячак...

Өйдәгеләр сыйга Әхимнең үзеннән дә ким куанмадылар. Пионер лагерена китәчәген дә ишеткәч, Кәрим абзый җинел сулап куйды: «Бер айга булса да бер тамак кимрәк булачак».

## Яшим икән әле

Икенче көнне иртүк торып Әхим пионер лагерена юнәлде. Ул килгәндә мәгариф бүлеге янында лагерьга китүчеләр инде җыелып беткән иде. Күпчелеге Әхим кебек үк ябык, начар киенгән. Шулай да арада яхшы киенгән түгәрәк малайлар, алсу битле кызлар да бар.

Озакламый бина янына ЗИС-5 маркалы яңа машина килеп туктады. Мәгариф бүлегеннән чыккан кыз команда бирүгә, балалар машинага ашыкты. Пөхтә киенгән кыз, пионервожатый булса кирәк, машинага менгәндә барысы да урнашып беткән иде инде.

Кыз балаларны берәмләп барлап чыкты да, елмаеп:

— Барысы да урыннарында, Назар, кузгалырга була,— дип кычкырды.

— Хәерле юл, Надя, кузгалыгыз,— диде Назаров. Пөхтә киенгән бу төз буйлы егет пионер лагеренең директоры булып чыкты. Чыгышы белән әллә татар, әллә үзбәк шунда, үзе дә төгәл генә белми икән, балалар йортында тәрбияләнгән.

Лагерь — шәһәрдән унбиш чакрым ераклыкта, бакча эчендә урнашкан иде. Биредә җимеш агачлары белән бергә декоратив куаклар да хәйран күп, бөтен җир чәчәкләргә күмелгән. Һавасы шундый чиста, саф, агач күләгәсендә шәһәрдәге кебек эссе дә түгел иде.

Килеп бер сәгать тә үтмәгәндер, төшке ашка дәштеләр. Әхим башта бер тәлинкә ашны ялт иттерде, аннары зур гына кисәк ит салынган икенчене чыгарып куйдылар, өстәвенә, компот китерделәр.

Бер бирсә бирә икән Ходай. Янәшә утырган кечкенә генә кызның үз өлешен ашап бетерергә хәленнән килмәгән. Итне ул Әхимгә тәкъдим итте. Монысы исә кызга бик теләп булышты. Аннары байларча үз палаткасына таба атлады.

— Ә бит тормыш дигәне алай ук начар нәрсә түгел икән ләбаса, — диде ул, фәлсәфи уйларга бирелеп.

Палаткага керү белән үк урынына барып ятты. Шул вакыт бер бәйләнчек Атаулла дигән малай (малайлар аны холкына күрә Шакалулла дип йөртәләр иде) сүз башлады:

— Карагыз әле моны, күпме сукты, өстәвенә әле күршесендәге кызныкын да ялмап йотты, ә эче һаман да бүренеке кебек эчкә береккән. Менә убыр дисәң дә убыр. Мондыйлар юньле кеше кулын юганчы бер сарыкны ботарлап ашап бетерер, диләр. Хактыр.

— Әй, син, тизәк капчыгы, туктыйсыңмы-юкмы? — дип икенче берсе Әхимне яклап сүзгә кушылды. — Әгәр дә син ул күргәнне күрсәң, синең капкорсагыңнан ни калыр иде икән?

Әхим боларга игътибар итмәде. Ул инде татлы йокыга чумган иде.

Лагерь тормышы Әхимне бөтенләй үзгәртте. Ике көннән инде ул таяксыз йөри башлады. Уйнады, йөгерде, су коенды, экскурсияләрдә катнашты. Кыскасы, лагерь Әхимгә икенче яшәү бүләк итте, аның күзләрендә кабат яшәү чаткылары кабынды.

Лагерьдан кемнәр җәяү кайта? — дигәч, ул беренче булып кул күтәрде.

Машинада урын барлык укучыларга да җитәрлек түгел иде. Ифрат та эссе көн булса да, Әхим 15 чакрым араны җәяү үтте. Өйгә бөтенләй икенче — сәламәт, кояшта янган, шат күңелле Әхим кайтып керде. Барысы да бик куанышты. Бу арада өйдә дә үзгәрешләр булган, гаилә әгъзаларына теге 50 грамм икмәкне тагын бирә башлаганнар һәм иң мөһиме — инде җәй, ризыклы вакыт җиткән иде. Юк-юк дисәң дә, өйдә кыяр, өлгерер-өлгермәс өрек, бүтән төр җиләк-җимешләр күренгәли башлаган иде. Аз сүзле Әсхәт тә гаиләгә шактый булыша башлаган, эштән кайтканда да ашарга нәрсә дә булса алып кайтмый калмый.

Шулай да әле тук яшәүгә ерак иде. Шуңа күрә Әхим дә беренче көннән үк яшәү өчен көрәшкә кушылды.

## Кыргыз далаларына — башак эзләп

Кыргызстанның Учкурган далаларында ашлык өлгергән, коелган башакларны җыеп та шактый бодай әзерләп була икән, дигән хәбәр таралды Наманганда. Кәрим абыйның мондый мөмкинлекне кулдан ычкындырасы килмәде. Бу якларны белә торган кешеләрдән сорашып, кайда, ничек барырга тиешле маршрутны билгеләделәр алар. Шуннан соң Рабига белән Әхим юлга җыенды: дүрт капчык алдылар, тимер юл билетына җитәрлек акча юнәттеләр. Тик, китәргә җыенгач кына өстәмә хәбәр килеп җитте: Кыргызстан белән Үзбәкстан арасындагы күпер аша бодайлы кешеләрне үткәрмиләр, теге якка чыгарга мөмкин, ә бу якка ярамый икән.

— Ни булса — шул булыр, тәвәккәллик! Аллаһы кушмаган эш булмас, — дип Кәрим хатыны Рабигага, улы Әхимгә хәерле юл теләде.

Учкурганга җиткәч, Әхимнәр поезддан төшеп, стансадан биш чакрым чамасы ераклыкта булган күпергә юнәлделәр. Менә ул, Үзбәкстан белән Кыргызстанны аерып торучы, ярларына тулып, ургылып, шаулап аккан салкын сулы тау елгасы — Нарын. Элек бик үк күзгә ташланып тормаган бу елга, хәзер кыргыз далаларында үскән бодайны күп халыклы Ферганәдән ышанычлы саклый.

Күпер аша икмәк белән чыгу чынлап та тыелган иде. Кыргызстан ягына чыгарга мөмкин, беркем дә тыймый. Әхимнәр дә күпер аша тоткарлыксыз үттеләр. Күперне чыккач ук бодай кырлары башлана. Инде аның шактый өлеше җыеп алынган. Ә бу исә, «башак җыю» кампаниясен башлап җибәрергә мөмкинлек бирә иде.

Безнең юлаучылар, тәртип саклап булса кирәк, Нарын елгасы буйлап 8-10 чакрым чамасы аскарак төштеләр.

— Кеше күзеннән читтәрәк булуың хәерле, — диде Рабига түтәй эшкә керешкәндә.

— Шулай, әнкәй, — диде Әхим һәм чиләген кулына алып башак җыя башлады.

Башта бер капчык башакны җыеп, аны шунда ук суктылар. Аннары Рабига Нарыннан ярты чиләк су алып килде һәм боткага охшаган үзенчә бертөрле аш әзерләде. Дөресен әйтергә кирәк, ботка әйбәт кенә килеп чыкты. Дөрес, лагерьда ял итеп кенә кайткан Әхимне бу ботка белән шаккаттырып булмаса да, Рабиганың мондый тәмле ботканы әле ашаганы юк иде. Ашау дигәндә Әхим дә сынатмады, анысы. Ни дисәң дә, лагерьдан кайтканга инде дүрт көн үткән иде бит.

— Бүгенгә җитеп торсын, — диде Рабига, — калганын иртә белән ашап эшкә керешербез, улым.

— Хак әйтәсең, әнкәй, — диде Әхим, әнисен хуплап.

Иртә белән чиләктә калган ботканы ашап эшкә керешкәннәр генә иде, болар янына атлы ике кыргыз килеп чыкты. Берсе, өлкәнрәк яшьтәгесе:

— Миндә эшләргә теләмисезме? Бодай урасы бар. Монда тавык кебек чемченгәнче, кеше кебек эшләп табарсыз, — диде.

Рабига апа улына карап куйды:

— Әллә ризалашабызмы соң, улым?

— Мин каршы түгел, — диде Әхим.

Хуҗа кеше боларны ашатырга, эчертергә, хезмәтләре өчен бодай бирергә булды.

Кыргызның иске өе янәшәдәге калкулык артында гына икән. Бер сәгать тә үтмәде, килеп тә җиттеләр.

— Өйгә керсеннәр, — диде хуҗа кеше, өйдәгеләргә дәшеп, — татарлар болар, мөселманнар, үз кешеләребез...

Хуҗаның хатыны булса кирәк, тыйнак, киң күңелле хатын кунакларны әчегән сөт һәм икмәк белән сыйлады. Ә хуҗа исә, һаман сорашуын дәвам итеп:

— Ә менә сез нигә «кешечә» сөйләү телен белмисез? Башка татарлар белә бит, — диде.

Моңарчы Әхим «кеше теле» белән таныш булмаса да, эшнең нәрсәдә икәнен шунда ук төшенеп алды. Юртасыннан беркайчан да читкә чыкмаган бу кешегә, чынлап та, кыргыз теленең бердәнбер «кеше теле» булуы бер дә гаҗәп түгел иде.

...Шулчак гайрәтле генә бер чаян койрыгын күтәреп җир идән буйлап горур гына үтте дә, келәм астына кереп шылды. Шулчак шаулашып юртага бер төркем бала-чага килеп керде.

— Болар барысы да үзегезнекеләрме? — дип сорады Рабига апа, балаларның күплегенә гаҗәпләнеп.

— Әйе, үзебезнекеләр, — диде хуҗа, Рабиганың бик үк урынлы булмаган соравына җавап итеп, — җидесе дә үзебезнеке. Аллага шөкер, ач тотмыйбыз үзләрен.

Бодай басуы янәшәдә генә иде. Барысы да шунда юнәлде. Боларга тагын дүрт хатын кушылды. Урак дигәннән, монда безнекеләргә житүче юк иде. Бигрәк тә бу эштә Рабига осталык күрсәтте. Аның оста һәм житез эшләвен күреп, хуҗа кеше, хәтта телен шартлатып куйды:

— Шәп табыш бу, болай булса уракны кыска тотачакбыз!

Ләкин кояш күтәрелгәннән-күтәрелә барды, көн кызганнан-кызды, хәтта тын алулары читенләште. Иреннәр кипте, авызда дым әсәре калмады. Рабига ара-тирә билен турайтып, тирә-ягына каранды. Тагын эшкә тотынды... Тагын турайды... Аның башы әйләнә башлаган иде. Ул бар көчен, түземлеген җыеп тагын эшкә керешге. Шул башы әйләнү аркасында эштән колак кагасы, балаларын икмәктән мәхрүм итәсе килми иде. Рабиганың бөтен тәне тиргә батты, куллары калтырый, хәлсезләнә башлады. Үзе исә, һаман саен җан тиргә батып, яна учманы эләктереп, калтыранган уракны үзенә таба якынрак китерергә, күбрәк урырга тырышты.

Бераз гына җиле булсын иде, ичмасам. Калтыранган кулларына, ялкынсынган башына кагылып, кызарган күзләрен җилләтеп үтсен иде... Юк шул, юк... Ниһаять, ул соңгы көчен дә җуйды, аягүрә басты... бер мизгел селкенгәләп торды да... кискән агач кебек җиргә ауды...

Рабига көчле хатын иде: һәрчак аз сүзле, һәрчак эш белән мәшгуль булды ул. Нинди генә кыенлыклар килсә дә башын имәде, горур булды, балаларын таза, исән-сау итеп үстерергә тырышты. Шулай да, аның белән сәер генә хәлләр булгалый иде. Корттан курка иде ул. Корт чакса, шунда ук җиргә ава, үлем белән көрәшкәндәй тартыша башлый иде. Мондый чакларда Кәрим аны салкын су белән коендыра һәм Рабига апа шуннан соң гына аңына килә торган иде...

Игелекле кешеләр һәркайда була, алар монда да бар иде. Хатыннар

эшнең нәрсәдә икәнен тиз төшенделәр, соңгы кружка сулары белән аның башын чылаттылар һәм эчерделәр. Аннан Рабига аңына килде һәм үксеп елый башлады.Хатыннар күлтәләрне өеп күләгә ясадылар һәм Рабиганы шунда яткырдылар. Аягына ул кичкә таба гына баса алды.

Ә хуҗаның көнеле төшкән иде инде.

— Килгән җиреgездә эшләү уңайрак булыр сезгә, — диде кыргыз боларга бераз бодай биреп, — анда елга да якын, җиңелрәк булыр.

Әхим белән Рабига үзләре сайлап алган урынга кабат кайттылар. Хәзер алар анда иртәдән кичкә кадәр башак җыйдылар. Бераз гына җыялар да елгага киләләр. Нарын елгасы алар өчен, чын мәгънәсендә, эсседән коткаручы булды. Елга үзенең салкын суы белән сыйлый, эсседән саклый, тәннәрен иркәли. Аз гына хәлләре читенләшә төштеме, елгага йөгерәләр. Су коенып, тагын көч җыялар.

Шулай беркөнне, алар ике капчык башак җыйганнан соң, аны җиргә таратып ике яклап суктыра башлаганнар иде, әллә кайдан гына бер зур үрмәкүч килеп чыкты да, бодай суктыручылар каршында ике әйләнеш ясап, салам астына кереп посты. Әхим корт чаккан кебек урыныннан сикереп торып Рабигага кычкырды:

— Әнкәй, тизрәк тор урыныңнан! Фаланга!

Әнисе шунда ук урыныннан торып читкә тайпылды:

— Фаланга дисеңме, улым, нәрсә соң ул?

— Ул тешләсә, әнкәй, төзә алмаслык авыртуга дучар буласың, хәтта үлүең дә мөмкин. Биредә бит табиб юк.

— Безнең янга килмәсме соң ул?

— Ул куркыныч үрмәкүч тарантулдан аерылып тора, үзең тимәсәң, һөҗүм итми. Кем белә бит, акылы китеп, һөҗүм итүе дә бар. Иң яхшысы, моннан китик без.

Шуннан соң алар Нарынга тагын да якынрак бер урынга килеп урнаштылар. Шулай ун көн вакыт үтеп тә китте. Бодай үзләре күтәреп алып кайтырлык кадәр җыелган иде инде. Хәзер юлга да җыенырга була. Тик аңа кадәр бер мәсьәләне хәл итәсе бар: ничек итеп күпер аша чыгарга? Ничә көн буе туплаган бодайны алып калсалар, өйдәгеләр һәммәсе ризыктан мәхрүм була бит.

Барысын да күпер төбендә торучы сакчы хәл итәчәк. Кешелекле булса, кызгана белсә, бәлки, үткәреп тә җибәрер. Шулай да, бу ышанычлы юл түгел иде. Кеше дигәннәре арасында кемнәр генә юк хәзер. Андыйлар өчен «кеше» һәм «кешелеклелек» дигән төшенчә юк, алар бары тик үз «тиреләре» турында гына кайгырта беләләр. Менә шундыйларга очрау куркынычын абайлап, сак булырга кирәк иде.

— Күперне төнлә үтәбез, — диде Әхим, — ул чакта күпердән эт тә йөрми. Каравылчыларның да йоклавы ихтимал.

Кояш баеганда гына кузгалдылар. Йөк дигәннәре шактый авыр иде, капчык баулары иңне сытып кергән. Шулай да алар сүзсез, тын гына атладылар.

Әхим егылыр хәлгә җитсә дә, әтисе әйткәннәрне исенә төшереп, көч алды. Ниһаять, алар күпергә якын ук килделәр. Хәзер нәрсә эшләргә? Тотсалар, барысын биреп калдырыргамы? Авыру әтисенә, балаларга нәрсә диярләр?!

Күпердә тынлык иде. Аның башында гына будка торганын, анда каравылчы барын да беләләр белүен. Әмма «сакланганны саклармын» дигәнне искә алып, эшне болайрак хәл иттеләр.

— Башта син чыгасың үзеңнең бодаең белән, — диде Әхим әнисенә, — әгәр дә ул-бу булмаса, син күперне чыгу белән мин кузгалам.

— Әгәр дә мине тоткарласалар? — диде Рабига.

— Башка юл юк, — диде Әхим, — барлык бодайдан берьюлы колак кагып булмый. Һич югында миндәгесен кая да булса яшерербез.

Рабига бераз алга бөгелә төшеп, сак кына күпергә атлады. Иртә таңның аз гына сызылып киткән яктылыгында аның гәүдәсе күренер-күренмәс кенә алга кыймылдый. Менә ул күпер уртасына да житте. Бер мизгелгә тукталып та алды. Күрәсең, алга барыргамы, бармаскамы дип уйлагандыр. Шуннан соң аның шәүләсе алга талпынды һәм караңгылыкка кереп юк булды. Әхим колагын торгызып тыңлана башлады: сөйләшкән тавышлар ишетелмиме, эт өрмиме, менә-менә бодайсыз калган әнисе елап жибәрмәсме?..

Юк. Тынлык. Бер генә тавыш та ишетелми. Инде ун минут вакыт үтте. Кара исәп белән дә, әнисе инде күперне чыгып күренмәслек дәрәжәдә ераклашкан булырга тиеш.

— Аллаһыма тапшырдым,— диде Әхим үз-үзенә һәм күпергә юнәлде. Күпер такталары буйлап ул ялан аяктан тавыш-тынсыз гына үтте. Мәче дә алай йөри алмас. Тагын бер, ике... өч... адым... Менә ул — каравылчы. Күпергә аркылы яткан, нәкъ уртасында, акрын гына гырылдап йоклый. Әхим сак кына атлап аңа якынрак килде. Мыеклы. Мыегының бер очы күпер тактасында. Күз алдына башка мыек — теге вакыттагы Турды мыегы килде. Менә ул сикереп торыр да, аны күпер тактасына егып салыр, өстенә менеп атланыр да, пычагын чыгарып Әхимнең бугазына китерер...

Әхим мондый уйларны башыннан куды да гырлап яткан каравылчыны читләтеп үтте. Ә каравылчы һаман йоклый. Мылтыгы кулыннан төшкән, читтәрәк ята. Бары тик башындагы түбәтәе генә нык утыра.

Әхим адымнарын тизләтте һәм артына борылып карады. «Аллага шөкер, барысы да тыныч, барысы да тәртиптә», — дип күкрәген тутырып бер сулады: каравылчы янынннан үткәндә сулыш алудан да туктаган булгандыр, күрәсең...

Аннары әнисен куып житте һәм бергәләп Учкурганга юнәлделәр. Поселокка килеп житкәндә, кояш үзенең тәүге нурларын юлчылар өстенә сирпеде. Күңелләр ышаныч белән тулды. Тик авыр йөк, йокысыз төн үзенекен иткән, тизрәк стансага йөгерәсе урында, беренче чәйханәне күргәч тә туктап калдылар. Кайнар чәй белән көлчә исе аппетитны кузгатты.

Юлчыларның күзләре очрашты: әнисе ышанычлы урынга яшергән акчасын чыгарды. Финанс ягы тәртиптә иде. Билетка исәпләгәннән соң да бер көлчә һәм чәй алырлык акча кала.

Иртәнге чәйдән соң көч кереп киткәндәй булды. Стансага кадәрге араны тиз үттеләр. Тик бу юлы эш уңмады: алар стансага килеп житкәндә генә поезд кузгалып китте. Тәүлек буе ничек эшсез утырмак кирәк? Көлчә алырга да акча юк иде. Чи бодай белән канәгатьләнергә туры килде. Хәер, моңа алар күнеккәннәр иде инде.

Менә төн дә житте. Иртәнге поезд белән китәргә теләүчеләр вокзалда инде шактый жыелган иде. Күп кенә олаучылар вокзал каршындагы жирдән урын алдылар. Әхимнәр дә шунда үзләре кебек пассажирлар янына урнаштылар. Биредә куркынычсызрак тоелды аларга, югыйсә, кыйммәтле бодайдан колак кагуың бар. Капчыкларны уртага урнаштырдылар да, икесе ике яктан урын алдылар. Тик, саклык чаралары ярдәм итмәде шул, бер капчыкны пычак белән ярып, бодаен агызып алганнар иде. Артык кайгырырга урын юк. Биш пот бодайдан, ким дигәндә, өч поты калган иде әле. Боларын өйгә кайтарып житкереп булса, инде рәхмәтле Аллаһыбызга шөкер итәсе генә кала.

Тиздән поезд да килеп житте. Тарткалашып булса да билет алып, алар поездга үттеләр, ә ике сәгатьтән Наманганда иделәр. Станса белән өй арасын, атлый-йөгерә торгач, тиз үттеләр. Өйдәгеләр икмәк походыннан

кайтучыларны куанып, шатланып каршы алдылар. Мондый хәл җинүчеләрне каршылаганда гына була торгандыр, мөгаен...

Әмма әле яшәү өчен көрәш тынмады. Өч пот бодай, ул никадәр генә саклап тотсаң да, озакка житә алмас. Шуңа күрә ризык юнәтү өчен көрәш бер генә көнгә дә тынып тормады.

## Ике чәкән кукуруз

Буш карын Әхимнең башына тынгылык бирмәде. Аннары кирәкмәгән жиргә, байлыкка күз ату да әллә гадәткә әйләнеп бара иде инде... Беркөнне шулай, июль ахырлары булса кирәк, эзләп-эзләп тә ашар әйбер тапмагач, шәһәр читенә борылды һәм кукуруз чәчелгән буш урынга килеп чыкты. Юан булып үскән кукуруз сабаклары арасыннан инде алтынланып килгән кукуруз чәкәннәре күренә башлаган.

— Ике чәкәннән берни дә булмас әле, — дип уйлады ул һәм өзеп тә алды. Тик күлмәк эченә яшерим дигәндә генә, бер сакаллы абзый (каян гына килеп чыккандыр) Әхимне эләктереп алды да эчкәрәк басуга алып кереп китте.

— Бер уңмагач унмый инде, — диде Әхим үз-үзенә, — атаң бояр булмагач, байбичәдән тумагач... Бу сакалбай мине нәрсәдер эшләтергә җыена, ахрысы. Ярый ла куркытып кына калса...

Шулай да сакалбайның кыяфәте куркыныч түгел, тыныч иде. Сакалы үзбәкләрчә матур, тигез итеп кырылган, соры күзләре дә усал күренми. Шулай булса да, ул Әхимне һаман эчкәрәк этәрде. Күп тә үтмәде, кукуруз басуы бетте һәм алар кечкенә генә бер аланга килеп чыктылар. Анда өрек агачы астында берничә ир-ат басып тора иде.

Сакалбай малайны шул агайлар янына алып килде һәм тыныч кына:

— Моны кукуруз урлаганда тоттым, үзегез хәл итегез, телисез икән, чарасын да үзегез күрегез, — диде һәм аяк астына ике кукуруз чәкәнен ыргытты.

— Әп-пә, — диде арадан әрмәвердәй тазасы, — колхозный добро воруем, дисең. Ә мин работай, горячий пот проливай, как сукины коты жаркий кояш астында ишачь...Ә син плоды наших трудов красть!

Сөйләүченең сүзе дә үзе кебек тупас, ямьсез. Бите нәкъ имчәкле зур бәрәңге инде. Тик бәрәңгедән аермалы буларак, негр кебек кап-кара. Негр да түгел, чөнки күзләре кысык, нәкъ бәрәңге күзләре кебек кеп-кечкенә. Бу күзләр сиңа хәтта карамыйлар да, ә зәһәрләнеп яналар! Әхим баскан жирендә сүзсез катып калды. Каршында бәрәңге битле, кысык күзле һәм гаҗәеп юан беләкле әзмәверне күрү теләсә кемне куркуга салыр иде.

...Кинәт аның кысык күзләре тагын да кысыла төште һәм ул арыслан кебек ике сикереш ясады да, кувалдадай йодрыгы белән бөтен көченә селтәнеп җибәрде. Йодрык Әхимнең нәкъ колак төбеннән генә выжылдап үтте. Малайга эләкми калу сәбәбе — Сакалбай Әхимне әле кулыннан ычкындырып өлгермәгән иде. Теге бәрәңге бит селтәнүгә, ул малайны җәһәт кенә читкә тартты.

Бу хәл кысык күзнең ачуын тагын да ныграк кабартты. Сакалбай, күрәсең, хәлнең мондый ук борылыш алуын көтмәгән иде, үзе дә куркып калды. Әхимне бераз читкәрәк этәрде дә калтыранган тавыш белән пышылдады:

— Йөгер, егет, тиз бул! Югыйсә, ул сине тычкан урынына сытачак.

Моны ишетүгә, Әхим бөтен көченә кукуруз басуына таба элдертте. Әзмәвернең кулына шулчак каерып ташланган юан агач тамыры эләкте. Шуннан ул сикереп торды да, бер-ике сикереш ясап, тамырны йөгереп киткән малай артыннан шундый көч белән томырды ки, эләксә Әхим шунда ук җан тәслим кылган булыр иде... Ботак, бәхетенә, Әхимгә тимичә күлмәк

жинен генә ертып, выжылдап узып китте һәм карт агачның корган ботагына килеп бәрелде. Ботак сынып арыкка төште һәм качып барган Әхимне пычрак су белән коендырды. Алай гына да түгел, егет кабаланудан ялгыш ботакның икенче башына эләгеп егылды да, тирән бер чокырга мәтәлде. Ике аягының да баш бармаклары сыдырылган, бите канга буялган иде. Артыннан килгән булса, әзмәвер аны инде күптән тотып изгән булыр иде, тик ул күренмәде, шаулаган тавышы гына ишетелде. Күрәсең, малайны йомып калырга теләп, колхоз агайлары әзмәверне тоткарлаганнардыр...

Әхим хәлне төшенеп, тиз генә чокырдан чыкты да, калын тузан каплаган юлдан шәһәргә элдертте, артыннан тузан болыты гына өерелеп калды.

## Рәхмәт, әткәй, барсы өчен дә...

Август башлары. Әхим базар тирәсендә тамак туйдырырга план корып йөри иде. Шулчак, әллә кайдан гына мәктәп дусты — сыйныфташы Хөснетдин Игамбездиев килеп чыкты.

— Әхим, нәрсә син монда селкенеп йөрисең? Телисеңме, бер яңалык әйтәм?!

— Өйдә утырып туйдым да, һава суларга чыктым әле менә, — диде Әхим, — йә әйт, нинди яңалык ул?

— Беләсеңдер, чәйханәдә бер яшь кенә егет укырга теләге булган кешеләрне теркәп утыра, диләр. Ни генә сөйләмиләр анда, хәтта ул мәктәптә, кайдадыр Ферганәдә диме, укучыларга барысын да бирәләр икән, анда ашаталар да, киендерәләр дә ди... Теләсәң, әйдә, барып карыйк!

Сөйләшә-сөйләшә алар янәшәдәге чатка борылдылар. Чәйханә моннан ерак түгел, үзләре укыган мәктәп белән янәшәдә генә иде. Халык белми сөйләмәгән икән. Чыннан да, иске келәм белән капланган диванда егерме биш яшьләр тирәсендәге бер егет нидер язып утыра иде. Башы ачык, чәчләре көдрә, кыяфәте — эшлекле. Ул чәй эчә-эчә янәшәсендәге егетләргә тырышып-тырышып нәрсәдер аңлатып маташа. Әхимнәр дә шулар янына килеп басты.

Егет үзбәкчә сөйли иде. Әхимгә дә хәзер инде бу телдә барысы да яхшы аңлашыла, тик үзе сөйләшкәндә сөйләме бераз татарчарак килеп чыга иде.

— Менә нәрсә, — дип дәвам итте егет кайсыныңдыр соравына җавап биреп, — безнең пединститутта укытучылыкка укыталар. Кем булырга телисең, барысы да бар: физика укытучысы булырга телисең икән, рәхим ит, физика бүлегенә языл; тарихчы буласың килсә, тарих бүлеге бар; химик буласың килсә, химия бүлегенә кер. Җаның кайсын тели, күңеленә кайсы якын, шунысын сайла. Уку вакыты 4 ел. Ә беренче курска керә алмаганнар өчен әзерлек курсы да эшли. Кыскасы, әйбәт бездә, баргач үзегез күрерсез. Яшәр өчен тулай торак бар, урын-җир бирәләр. Ашарга: харчо, ботка, чәй...

— Болар барысы да кем исәбенә соң?— дип сорады Әхим, сөенепме, кызыксыныппмы.

— Кем исәбенә булсын, бушлай, халык исәбенә, совет исәбенә! Аңлашылдымы, егетләр? Ә хәзер кем язылырга тели, әйдәгез, — дип егет кесәсеннән яулык чыгарды, битен иплэп кенә сөртте, пиалада калган чәен эчеп куйды һәм кулына кәгазь-каләм алды.

— Мине языгыз, минем фамилиям Кәримов, — диде Әхим һәм зур эшкә алынган житди кыяфәт белән өстәп куйды, — дөрес, әле мин әти белән сөйләшмәгән, минем уемча, ул каршы килмәс, иртәгә җавапны килеп әйтермен.

Бүген ул үзен әтисе канаты астыннан чыгып күлгә таба тәүге адымын

ясаган үрдәк бәбкәсе итеп тойды. Ни генә булса да, йөзәр өчен туган бәбкә, барыбер йөзеп китә инде ул.

Шундагыларның берсе язып утыручы егеткә:

— Син үзең кем буласың соң, директормы, укытучымы? — дип сорау бирде.

— Юк, — диде егет бераз уңайсызланып, — мин студент кына, дүртенче курста укыйм. Өлкән курста укучы студентларны менә шулай яшьләрне укырга җыярга урыннарга җибәрделәр. Укучылар җитми, кабул итү планы үтәлми.

Билгеле, бу гаҗәп хәл түгел иде. Ул елларда күп санлы махсус урта һәм югары уку йортлары ачылды. Аларны урта белемле яшьләр белән тулыландырырга кирәк иде, бигрәк тә хезмәт халкы арасыннан чыккан яшьләр исәбенә. Шуңа күрә аерым очракларда урта белеме булмаганнарны, җиденче, сигезенче сыйныфны тәмамлаганнарны да кабул иттеләр. Әхимнең бәхетенәме, менә шундый чак туры килде. Дөрес, институтның ни икәнен төшенеп бетмәсә дә, аның күңеленә ике нәрсә кереп урнашты: уку һәм харчо, харчо һәм уку.

Чәйханәдәге сөйләшүдән соң ук Әхим өенә юнәлде.

Улын тыңлаганнан соң, Кәрим абый шундый куанды, шатланды, моны сүз белән генә аңлатып бирү дә мөмкин түгел иде.

— Дөрес, мин синең табиб булуыңны теләгән идем, — диде ул бераздан, — болай да ярый. Барлык һөнәр дә әйбәт. Тик, бөтен күңелеңне биреп, тырышып укырга һәм эшләргә генә кирәк! Укытучы булу әллә мактаулы эш түгелме?!

Икенче көнне Әхим чәйханәгә барып әтисенең ризалыгын җиткерде. Җыенырга вакыт тар иде. Тагын бер көннән әтисе белән икәүләп вокзалга юнәлделәр. Икесе дә бик начар киенгән: иске түбәтәй, инде күп киюдән таушалып беткән чалбар, яланаякка кигән брезент ботинка...

Әтисе эндәшми, әмма аның карашында улы әткәсенең үзенә карата мәхәббәте чиксез булуын тоеп тора. Ата улына хәерле юл юрый, очып китәргә җыенган кошчыгының һәрчак бәхетле булуын тели.

Шул арада Кәрим абзый поездга билет юнәтте дә, калган акчасына бер кило йөзем һәм көлчә алып, Әхимгә сузды:

— Мә, ал, улым! Юлда ашарсың. Бүген шундый онытылмаслык көндә үдеңә күбрәк тә бирер идем... юк бит... Моны син үдең дә аңлайсың, улым, үпкәләмә инде. Ышанам, әле безнең урамда да бәйрәм булыр!..

— Рәхмәт, әткәй, барысы өчен дә. Мин синең игелегеңне беркайчан да онытмам, — диде Әхим һәм әтисенең агарып калган йөзенә, бөкрәя төшкән иңнәренә карап, аның Качкындагы чакларын исенә төшерде. Әтисенең таза гәүдәсе, ут чәчеп торган зәңгәр күзләре, пөхтә итеп кыркылган куе сакалы, һәрчак игелекле, ачык йөзе — барлык гүзәл сыйфатлары әле ул чакта кайгы һәм ачлыктан җуелмаган иде. Шунда аңа бүгенге әтисе ничектер кызганыч булып тоелды һәм ул елап җибәрде...

Ул арада китәргә сигнал булды. Пассажирлар вагоннарга керә башлады. Әхим дә үзенең әтисе биргән «багаж»ын алып тамбурга менде. Янәшәдә генә вагон янында әтисе басып тора. Кинәт аның иреннәре кыймылдап куйды. Сүнеп барган карашында ниндидер очкын чагылып үтте. Әхим аңлады: әтисе нәрсәдер әйтергә тели иде. Тамбурдан ике баскыч аскарак төште дә әтисенә таба иелде. Кәрим абзый да якынрак килде һәм ачык итеп:

— Шулай аерылышабыз, улым...әйбәт укы. Укуның бик тә җаваплы булуын онытма. Уку көннәрендә, хәтта әтиең үлсә дә, син укуыңны калдырырга тиеш түгел. Аңладыңмы? Бу минем накад сиңа. Сәламәт бул!

Кәрим абзыйның күзләреннән яшь бөртекләре тәгәрәде. Болар кызгану түгел, ә горурлык яшьләре иде...

## Ферганәгә — укырга!

Поезд Горчаков стансасына житте. Әхим үзенең сыйныфташы Хөснетдин белән поездан төшеп читкәрәк китеп утырдылар. Ферганәгә әле биш чакрым барасы бар иде.

Барысын да исәпкә алгач, шәһәргә таба җәяүләп кузгалдылар. Менә алар Ферганәдә. Институтны эзләп таптылар, аннан канцеляриясе. Егетләрне институтка килергә өндәгән студент Умурзиков үзе дә биредә утыра иде. Документларны тапшырганнан соң, икесен дә институтка керергә теләүчеләр исемлегенә теркәделәр, икмәк алу һәм ашханәгә йөрү өчен карточка бирделәр. Соңрак тулай торакка ордер да тапшырдылар.

Күп сөйләшүчән бер күзле комендант малайларны бик сагаеп каршы алды. Дөресрәге, үзләре яшь, үзләре начар киенгән малайлардан шикләнде. Ордерларына күз йөртеп чыкты да, бер бүлмәгә алып керде, ике буш ятакка күрсәтте:

— Болар — сезнең урыннар. Тик, карагыз аны, шаярасы булмагыз. Куып чыгарырга да күп сорамам. Ә хәзер — марш мунчага! Урын-жирне мунчадан соң алырсыз.

Комендант «шикле» малайларга тагын бер тишәрдәй итеп карады да, сөйләнә-сөйләнә китеп барды:

— Каян гына китерә Аллаһы Тәгалә бу кадәр йолкышларны? Карар жирләре юк. Кызлар — менә бөтенләй икенче. Алар белән сөйләшүе дә рәхәт. Ә болар?.. Йә сугышалар, йә шаяралар...нәрсә дә булса уйлап чыгаралар.Үзе бер бәла. Аллам сакласын инде...

Ул арада егетләр мунча кереп чыктылар. Шуннан соң комендант Гега түтәй аларның һәркайсына берәр матрас, ике җәймә, мендәр һәм одеял бирде.

Бу вакытта инде бу бүлмәдә яшәүче егетләрнең дүртесе дә кайткан иде. Болар: зур башлы үзбәк Касыймов, күп сөйләшергә яратучан Оренбург татары Әбүбәкерев, зирәк акыллы, гаделсезлектән жаны әрни торган Ташкент татары Мостафин һәм орчык кадәр генә буйлы Әндижан үзбәге Турдыев.

Яңа студентларны бүлмәдәгеләр куанып каршы алды дип булмый. Бары тик Мостафин гына сүз катты аларга:

— Менә ерак илләрдән кунаклар да килде... — диде ул. — Өегездәге кебек булыгыз, оялмагыз. Озак көттек үзегезне, сыйлар да суынды. Иртәгә сыйланырсыз инде. Хәер, сезнең чәчәк кебек йөзгә карасаң, сыйның кирәге бармы икән?

Мостафинның бу соңгы сүзләре нәкъ «үзәк»кә эләкте. Барысы да көлешеп алдылар. Танышу шуның белән тәмам булды. Касыймов китабына капланды, нindидер мәсьәлә чишә башлады. Ә яңа килгән безнең егетләр йокларга әзерләнеп урын җәяргә керештеләр. Тик, Әбүбәкерев кенә үзенең тарихи «әсәрләрен» сөйли бирде. «Шулай рабфакта укып яткан чак, — диде ул. — Иске татар мәдрәсәсе бинасына урнашкан идек. Көннәрдән бер көн нәчәлникләр яңа тәҗрибә уйлап таптылар. Яңа тәртипләргә, коммунизмга киң юл, диделәр алар. Димәк, барыбыз да: ирләр дә, хатын-кызлар да тигез хокуклы. Шулай булгач, нигә егетләрне бер бүлмәгә, ә кызларны икенче бүлмәгә урнаштырып интектерәбез? Тигезлек икән, тигезлек булсын, бер бүлмәдә яшәсеннәр. Барысын да бер бүлмәгә нигә урнаштырмаска?.. Әйттек, эшләдек. Бүлмәләр безнең зур иде, егермешәр кеше сыярлык. Мәсьәләне капитально хәл иттек. Юк, бүлмәне яртылаш бүлеп тормадык. Кызлар ятагы белән рәттән егетләрнекен урнаштырдык. Шулай яши башладык. Эшләр шәп кенә барганда, беләсезме, нәрсә булды? Кызлар берәм-берәм күзгә күренеп тазара башладылар... Бу эшне уйлап тапкан житәкчеләр куркуга калды. Безне тиз-тиз генә аерым-аерым бүлмәләргә күчерделәр. Коммуна

килеп чыкмады. Анык каравы, кайбер нәчәлникләрнең башына суктылар. Каты суктылар, мәйтәм. Кайбер кызларга да укуларын калдырып торырга туры килде.»

Турдыев авызын ябарга да онытып тыңлады егетнең хикәясен. Һәр сүзгә ышана иде шул. Ә менә Мостафин каш астыннан гына елмаеп, үзенчә: «Әйдә, әйдә, ялганлый бир тыңлаучы барда», — дип әйтә сыман иде. Әбүбәкерев исә берсен тәмамлауга икенчесен башлады. Ул арада безнең юлчылар инде тәмле йокыга талдылар.

***

Икенче көнне Әхим иртә уянса да, ипигә чират торып, дәрескә соңга кала язды.

Класс шыгрым тулы иде. Бүлмәдәше Турдыев аны күреп алып, буш урынга — үзе янына чакырды. Әхим тиз генә шунда үтте. Әбүбәкерев белән Мостафин да рәттән генә утыралар иде.

— Әһә, якташ та килде, молодец — диде Мостафин елмаеп, — хәзер алгебраны чәйнибез, диләр. Теге чират торып алган пешер-пешмәс икмәккә ябышмаса ярый инде. — Мостафин, ишектән кергән укытучыны күрмичә, сөйләвен дәвам итте. — Алгебра пешмәгән икмәк түгел, чәйнәмичә йотып булмый...

Шулчак укытучы аның җиңенә җинелчә генә китап белән кагылды. Егет куркып китте, сикереп куйды, урынына утыргач кына тынычланды.

Моңарчы гөж килеп торган класс тынып калды. Дәрес башланды. Мостафин әйткәнчә алгебра түгел, геометрия иде. Укытучы үзбәк Астаханов ак костюмнан, гарип кулы комачауласа да, бер сәгать эчендә формулаларны тезде генә... Аңлатуы ачык һәм аңлаешлы иде. Икенче сәгатьтә исә тикшереп карады: ничек үзләштерделәр икән, янәсе. Әхимгә бу бик ошады, мәктәптәге укытучылардан көчлерәк күренде ул.

Аннары физика дәресе иде. Анысын яшь укытучы татар Урманов алып барды.

Зур тәнәфестә барысы да урамга чыктылар. Киң арык буендагы чирәмгә тезелешеп яттылар.

— Лекцияләрне без кайсы класста тыңладык? — дип сорады Хөснетдин бүлмәдәше Турдыевтан.

— Кайсы класс дисеңме? Монда бернинди класс та юк. Бу бит мәктәп түгел, институт. Аның да әзерлек курслары. Беренче сентябрьгә кадәр кемнең беренчедә укый аласын менә шунда билгелиләр инде. Кемнең әзерлеге әйбәт, шуны алачаклар.

— Ә алынмаганнар кайтып китәчәкме?

— Юк, Хөснетдин, юк, — диде Турдыев, — андыйларны бер ел әзерлек курсларында укытачаклар. Шуннан соң гына беренче курска алачаклар. Безгә шулай аңлаттылар.

Ул арада озын тәнәфес бетеп, барысы да рус теле дәресенә җыелды. Дәресне үзбәк түбәтәе кигән өлкән яшьләрдәге укытучы алып барды. Тыштан караганда тупасрак күренгән бу абзый үз дәресен шундый итеп аңлатты ки, дәреснең үткәнен дә сизми калдылар. Бу — профессор Чистяков иде.

Ниһаять, дәрес бетте. Илле кешелек группа, команда булгандай, берьюлы урыннан купты һәм җир тетрәгәндәй ишеккә ташланды. Профессор чыгарга кыймады, ул тәрәзә төбенә таянып укучыларның чыгып беткәнен көтеп торды.

— Йөгердек! — диде Турдыев һәм шунда ук халык арасына кереп чумды.

Әмма Наманган егетләре, эшнең нәрсәдә икәнлекләрен анламаганлыктан, ашыкмыйча, иң соныннан гына чыктылар. Чыксалар, үзләре дә хәйран калдылар, алар группасы гына түгел, бөтен институт студентлары йөгерә иде. Ашханә янына килсәләр, гаҗәеп озын чират җыелган. Вакыт вакытны саклар, дигәндәй, бераз ашыга төшсәләр, бу кадәр зур чиратта торырга туры килмәс иде. Метр артыннан метрны саный торгач, ниһаять, Әхим ашханә эченә дә эләкте. Өстәлләр арасында түгәрәк йөзле бер сылу кыз савыт-саба җыеп йөри иде. Кыз үзенең зәңгәр күзләрен кыса төшеп, шундый мөлаем итеп елмайды ки, егет сүзсез калды. Бу — Аня иде...

***

Тулай торакка кайттылар. Касыймов инде дәресләрен карарга да утырган, ә Әбүбәкерев әүвәлгечә нәрсәдер сөйли, Турдыев аны тыңлый. Мостафин гына юк. Әбүбәкеревны беренче булып Хөснетдин бүлде:

— Ни эшләп сез сөйлисез дә сөйлисез, ә дәресләр карамыйсыз?

— Нигә кирәк ул, без болай да беләбез.

— Монда нәрсә белән шөгыльләнергә икәнен эт тә белми, — дип сүзгә Төпчек кушылды, — ни расписаниесе, ни тәртибе юк. Барысы да нәкъ кинодагы кебек...

— Шулай да, егетләр, иртәгә нинди дәресләр буласын белмисезме? — дип сорады Әхим.

— Иртә белән алгебра була дип сөйләнделәр, — диде Касыймов, беренче мәсьәләсен чишкәннән соң.

— Алгебраны сездә кем укыта?

— Канкаев. Сезнең брат. Кечкенә буйлы, ябык кына бер абзый. Ә телгә дигәндә... пулеметтан сиптергән кебек. Берни дә әйтеп булмый, әйбәт укыта.

— Үзе болай уш китәрлек булмаса да, хатыны бик чибәр, — диде Әбүбәкерев, — Ферганәдә беренче сылу, шулай бит, Турдыев?

Үзе дә сизмәстән Турдыев кызарып чыкты.

— Дөрес сүзгә җавап юк, — диде Касыймов, икенче мәсьәләсен дә чишеп бетергәч.

— Әй, егетләр, егетләр, — диде Хөснетдин, — безнең укытучылар арасында профессорлар да бар, дип сөйләнәләр бит әле.

— Сөйләнәләр генә шул, — диде профессор хакында китаплардан гына укып белгән Әхим,— кайда гына укыталардыр инде алар? Кара костюм, ак күлмәк, күбәләк галстук таккан, пөхтә киемле укытучыларны бу тирәдә очратканым юк. Бәлки, бөтенләй дә юктыр алар.

— Бар, бар профессорлар биредә! — диде Төпчек, кармагына профессор эләктергәндәй, — бүген рус телен кем алып барды дисең? Ул бит — профессор Чистяков.

— Ә үзбәк теленнән профессор Гайнуллин укыта,— диде Касыймов, өченче мәсьәләне чишеп, — профессорга охшамаганмени? Үзе татар, үзе үзбәк теле профессоры. Кирәк бит, ә? Бу татарларның кермәгән җире, булмаган урыны, эшләмәгән эше юктыр, мөгаен.

— Дөрес әйтмисең, туган, татарның булмаган җире дә бар, — диде Әбүбәкерев, үзенең хикәясе өчен шуны гына көткәндәй. — Бер яһүд үзенең урынбасары белән поездда кайта икән. Бервакыт шулай поезд тоннельгә кергәч, купеда дөм караңгы булып киткән. Яһүд шунда: «Ай-яй, караңгы, нәкъ тараканның арт тишеге кебек», — дип куйган. Урынбасар да моментны ычкындырмаган, нәчәлниген күтәреп алган: «Әй Абрам Ильич, кайларда гына булмыйсың да, кайларга гына кермисең син!» — дип мактарга тотынган... Төшендегезме инде? Анда әле татарның булганы юк, булырга да язмасын.

Бүлмәдәгеләрнең кайсы көлеп җибәрде, кайсы, аңламаганы аптырап калды.

— Ни катнашы бар монда тараканның? — диде Турдыев.

— Алайса, яһүднең дә катнашы юк.

Инде барысын аңлап, тагын бер көлешеп алдылар.

— Ә-ә, Леоновны оныткан быз ич, география профессорын. Шундый модный, сакалы дулкын-дулкын...Белмисезме?

— Әйе, әйе, — диде Төпчек, — ник белмәскә, беләбез.

Әйе, профессорлар шактый иде Ферганә педагогия институтында. Тагын әле педагогика профессоры Днейко, физика профессоры Коротин. Менә болары инде тышкы кыяфәтләре белән дә профессорга охшаганнар... Әхим уенча, билгеле.

Тора-бара Әхимдә, нәрсәсе беләндер, институт директоры Ишбулдин белән һәр очрашу зур тәэсир калдыра башлады. Ул утыз биш яшьләр тирәсендәге уртача буйлы, һәрвакыт кырынган, яхшы һәм пөхтә киенгән булыр. Аның интеллигентлыгы, ирләрчә ачык йөзе — очрашканда сиңа ничектер яшәргә көч бирә, рухландырып җибәрә кебек. Киләчәк тормышның яхшырак, әйбәтрәк булырына ышаныч арта, яшисе килә, кешеләргә, сине урап алган укучыларга карата ярату хисләре кабына... Ул озак сөйләми, күрәсең вакыты тар, эше дә күптер... Әмма шул кыска гына вакыт эчендә дә ул синдә очкын кабызырга өлгерә...

— Йә, ничек, улым, хәлләр? — ди ул Әхимне туктатып, аның иңеннән кагып.

— Акрынлап кына бара, Ишбулдин абый, — ди Әхим, зур канәгатьлек тоеп.

— Әйбәт! Ә син булмас дип уйлаган идең. Тырышсаң, барсы да була ул, улым. Укы, тырыш. Олы туганыңның телен өйрәнү энә белән кое казу белән бер ул. Ә ансыз сиңа юл юк, ябык. Аңладыңмы?

Әхим директорның сүзләреннән хәйран калып, әле үзе киткәч тә аңына килә алмыйча басып торды: «Нинди гүзәл кеше! Нинди кешелекле кеше!»

Тик, ул бирәдә бик аз эшләп калды шул. Чорның әче җилләре аны да каядыр очыртып алып китте. Ишбулдин төнлә белән юкка чыкты...

***

Яңа уку елы алдыннан «иләктән үткәрү» башланды. Билгеле, инде җиде, сигез сыйныф бетереп килгән балаларның күбесе бу кыска гына вакыт эчендә институтның беренче курсында укырлык дәрәҗәгә җитә алмады, иләктән бары тик яртысы гына үтте. Әхимнәр бүлмәсендәге барлык егетләр дә үтүчеләр арасында иде.

Бу Әхим өчен зур бәйрәм булды. Ул — бүген югары уку йорты студенты! Аңа бит әле, югыйсә, унбиш яшь тә тулмаган, урта белеме дә юк, алтынчы-җиденче сыйныфларны бер елда бетерде ул. Әле моннан берничә ай гына элек ачлыктан шешенгән, хәлсезләнгән, күзләрендә инде яшәү чаткысы да сүнеп барган Әхимне бары тик пионер лагере гына коткарып калган иде, шуның аркасында гына ул студент та була алды.

Әхимне озатырга килгәч тә әтисе: «Юньләп, тырышып укы, улым!» — дигән иде бит, хәзер менә аның кушканы, аның теләге чынга ашты.

Иләктән үтүчеләрне факультетларга бүлгәндә, геометрия укытучысы Астаханов Әхимне математика бүлегенә кодалады. Тик, егетнең күңеле тартмады, коры фән кебек күренде аңа математика. Ни өчендер тарих бүлегенә керәсе килде аның, ә ул бүлеккә ни сәбәптәндер сайлап алу булмады. Озаклап уйлагач, ул химия бүлегенә керергә булды. Беренче тапкыр Татарстанда Пучы мәктәбендә укыганда ясаган химик реакцияләр

исенә төшепме, укытучысы ошагангамы, бу фәнне инде якын күрә иде ул. Күрәсен, ялгыш түгел, ә язмыш шулай кушкандыр...

Менә беренче дәрес. Аудиториягә ишек ачып керсә, үзе дә сизмәстән, артка чигенеп куйды. Бүлмә тулып түп-түгәрәк, алма кебек пешкән, өлгереп җиткән кырык кыз утыра. Бер генә егет тә юк дисә, берәү бар икән. Бу кырык кызның сөйләшүе болындагы каз көтүен хәтерләтә иде. Аның әле беркайчан да бу кадәр кызлар арасында калганы булмады. Һәммәсе диярлек әйбәт киенгәннәр, тук һәм чибәрләр. Алар арасында Әхим бер генә танышын да очратмады, алар ничектер чит иде аңа. Аннары аудиториядә Әхимгә таныш булмаган рус сүзләре генә хакимлек итә.

Нинди дә булса өлкән курслар янына эләккәнмендер дип, таймакчы булган иде, аңа бер кыз игътибар итте:

— Син кая, иптәш, беренче курскамы?

— Әйе, — диде Әхим, тагын да югала төшеп, — беренчегә.

Моны ишеткәч, кызның йөзендә ниндидер канәгатьсезлек билгеләре чагылып үтте. Ихтимал, ул унай җавап ишетергә уйламагандыр. Аның зур кара күзләреннән: «Шундый юк-бар малайлар да керә алган факультетта уку... нәрсә инде ул?! — дигән сүзләрне укырга була иде.

— Биредә химия бүлеге! — дип дәвам итте кыз, — ә сезгә нинди кирәк?

— Мин дә химия бүлегенә,— диде Әхим ишетелер-ишетелмәс кенә, гүя бу кыз аны куып чыгарырга җыена иде.

— Химия бүлегенә булса, кер, утыр, хәзер укытучы да керәчәк,— диде кыз.

Аның сүзләрендә үзен өстен сизү төсмерләре чагыла иде. Әхим моны сизми кала алмады.

Эчкә үткәч, ул класстагыларны тагын барлап чыкты һәм танышына тап булды. «Бәй, почмакта Ганиев түгелме соң? Шул, үзе!»

Ош шәһәреннән килгән кечкенә буйлы, ябык, битен бетчә баскан бу малай бер дә кеше белән аралашмый, һәрчак үз эченә бикләнгән халәттә яши иде. Әхим аның янына килеп утырды. Аккошлар арасындагы ике көзге әтәчне хәтерләтәләр иде алар.

Шулчак кызларның берсе ишетелер-ишетелмәс кенә:

— Безнең коллективның бөркетләре! — дип куйды.

Бөтен аудитория шаркылдап көлеп җибәрде. Моның сәбәбен егетләр төшенсәләр дә, үпкәләмәделәр, чөнки алар хаклы иде. Алар бит инде өлгереп җиткән кызлар. Мондый аерманың сәбәбе дә бар иде. Кызларның барысы да инде урта мәктәпне тәмамлап килгәннәр, тормыш тәҗрибәләре дә юк түгел.

Шул арада химия укытучысы — илле яшьләр тирәсендәге Александр Кузьмич Кудреватов керде. Уртача буйлы, бераз бөдрәрәк чал чәчле бу укытучыны Әхим үз итте. Тәмәке тартуын гына ошатмады ул аның. Ни өчен дисәң, бер дәрестә унар папирос тартырга өлгерә иде. Кулында һәрчак тәмәке булды, шунсыз лекция укымады. Көннәрдән бер көнне ул папирос урынына леденец тотып керде. Баксаң, ул тәмәкене ташларга уйлаган икән. Дөресрәге, бер табиб туганы аңа шундый киңәш биргән. Тик, аңа леденец ярдәм итмәде шул. Өч көннән аның кулында тагын папирос иде.

Аннары ул төрле хикмәтле хәлләр, тарих сөйләргә ярата иде. Кызларга шул гына кирәк, дәфтәр-каләмнәрен читкә этәрәләр дә, бирелеп Александр Кузьмичны тыңлыйлар. Шулай итеп кайчакларны дәрес башланырга да өлгерми, тәмамланып та куя. Ул начар укытучы түгел иде. Кирәк чакта таләпчән дә була, укыта да белә.

Шулай көннәр үтә торды. Кышкы имтиханнар вакытында Ганиев

булдыра алмады. Шуннан беркемгә дә әйтмичә әнисе янына кайтып китте. Ул гына түгел, шактый кызлар да коелды кышкы сессиядә. Хәзер инде Әхимнең берүзенә 33 кыз иде.

## Ак сакаллы карт киңәше

Җәйге каникуллар җиткәч, Әхим әтиләре янына кайтты. Бай балаларын каршылаган кебек булмаса да, аның кайтуына һәммәсе дә сөенгән иде, бигрәк тә Кәрим абзый. Ни дисәң дә, Әхим — институтка кереп укыган беренче баласы бит, Качкын авылында туганнар арасыннан да — беренче студент.

Утыз өченче елның ачлык дулкыны бераз гына кими төшсә дә, өйдә әле бик ярлы яшиләр. Олыгая барган әтисенә бу кадәр баланы туендыруы җиңел түгел иде. Дөрес, гаиләгә өлкән улы Әсхәт шактый булыша, тик быел әнә анда да укырга керү теләге уянган.

Кәрим абзый улының укуы белән кызыксынганнан соң, бигрәк тә институтта профессорларның, доцентларның булуын ишеткәч, үзе дә сизмәстән кызып китте һәм Әхимгә мондый сорау бирде:

— Улым, нәрсә ул — атом?

Бу сораудан Әхим үзе дә бераз сәерсенеп калды. Шулай да әти кешене җавапсыз калдырып булмый бит инде.

— Атоммы? Ул — элементның иң кечкенә һәм бүленмәй торган кисәге,— диде Әхим.

Кәрим җаваптан канәгать түгел иде:

— Һмм, бүленмәй торган кисәк, дисең алайса, — дип каршы килде ул, — менә үдең уйлап кара әле, синең атом бит аскы һәм өске өлештән, уң һәм сул яктан тора. Шулаймы? Шулай икән, атом бүленмәенчә кала алмай. Ул бүленә һәм тагын да ваграк кисәкләргә дә бүленә...

Әхим аптырап калды. Каян уйлап чыгарган соң ул бу фәлсәфәне? Берәр җирдән укыганмы? Алай дисәң, андый китапны каян тапсын ул? Бармы икән әле ул андый китап?..

***

Каникулга кайттым дип тик утырып булмый бит инде. Нәрсәдер эшләргә, гаиләгә булышырга кирәк. Беркөнне Хакулабадта пильщик булып эшләүче абыйсы аны Зөфәр Тазин исемле татар егете белән таныштырды. Ул шәһәрдән ерак түгел Макови исемендәге колхозда сәркатиб вазыйфасында икән. Икенче көнне иртә белән алар шунда юнәлделәр. Әхим анда вакытлыча хисапчы ярдәмчесе булып эшкә урнашты.

Колхозда эш күп. Көне буе гына түгел, кичләрен дә калып эшләделәр. Хисапчы яшь кенә үзбәк үзе дә күп эшли, башкаларга да нык таләпчән.

Ике ай чамасы эшләгәнгә күп түләмәсәләр дә, бик кирәк әйберләрне алырга ярап куйды әле ул.

Бу матур эш гадәткә керде. Әхим һәр елны каникулларны хезмәттә үткәрде. Ә өченче курсны тәмамлагач, җәйге айларда укытучыларның белемен күтәрү курсларында укытырга да батырлыгы житте аның. Ни дисәң дә, курсларда кем генә юк: яшь укытучылар белән рәттән дистәләрчә еллар буе тормыш тәҗрибәсе җыйган аксакаллар — мәктәп директорлары, завучлар.

Әндиҗанда укытучыларның белемен күтәрү курсларында укытканда үзе дә чак көлкегә калмады. Биредә ул биология дәресләре алып бара иде. 18 яшьлек егет беренче дәресне программада каралганча тиз тотты. Ике сәгатькә исәпләнгән оештыру мәсьәләләрен бер сәгатьтә хәл итте дә, икенче сәгатендә тыңлаучыларның сорауларына җавап бирергә булды. Дөресрәге,

биологиядән теләсә нинди сорау бирергә рөхсәт итте. Бу анын бераз беркатлылыгы да иде. Ә бит курсларда тынлаучылар арасында кемнәр генә юк. Кайсы, чынлап та, үзен кызыксындырган сорауны бирде, кайберләре Әхимнең белемен сынап карарга булды, ә өченчеләре исә, кызык ясаудан да тартынмады — егетне егып салырга исәпләде. Дистә еллар буе биология укыткан тәҗрибәле укытучылар алдында әле генә тормышка аяк басып килгән Әхимнең сынау үтүе иде бу.

Әнә, почмакта утырган бер төркем яшь укытучылар хихылдаша да башлады, ә өлкәнрәкләре исә, Әхимнең хәленә кереп, аларны тынычландырырга керешә. Шуңа да карамастан класста гүләү көчәйгәннән-көчәя барды, менә-менә ул тоташ көлүгә әйләнер кебек...

— «Саескан йомырканы томшыгы белән саламы?» — диде берсе. Әхимнең моңа кадәр бу хакта ишеткәне булмады. Икенчедән, шул ук сорау: «Халыкта шундый сүз йөри, дөресме ул?» — дип тәгәлләнә.

Нәрсә эшләргә? Мондый хәлнең булуы мөмкин түгел, дисәм, әнә, үзе халыкта шундый сүз йөри, ди бит. Мондый хәл булырга мөмкин, дисәм —көләрләр. Эшсез калуың да бар. Нәрсә дияргә? Уйлана торгач, ниһаять, ул җаен тапты: «Моңарчы андый хәл турында әдәбиятта укыганым юк, шуңа күрә тагын бер кат эзләп карармын, ә нәтиҗәсен иртәгә — икенче дәрестә әйтермен, — диде.

Шуннан соң дәрес тәмамланды. Көлке оештырырга теләгән егетләр яшь укытучы янында әйләнеп-тулганып йөрделәр дә, таралыштылар.

Әхим китапханәдә нинди генә китапларны карап бетермәде! Берсендә дә саесканның ничек йомырка салуы турында бер кәлимә сүз дә юк иде. Ни эшләргә? Нинди җавап әзерләргә сон тынлаучыларга? Әгәр дә күпне күргән фатир хуҗасы — үзбәк картыннан сорап карасам? Аякларын бөкләп чәй эчеп утырган карт Әхимне бик зур игътибар белән тынлады. Аннары тын калып, дулкынланып торган ап-ак сакалын сыпыра-сыпыра озак кына уйланды һәм телгә килде:

— Халык, чынлап та, ялкау кошны йомыркасын томшыгы белән сала, дип сөйли. Әмма халык саесканның бур кош икәнен дә яхшы белә. Әйе, ул чит кошларның йомыркаларын урлый, — диде аксакал һәм бераз уйланып торгач, болай дип өстәде, — саескан йомыркасын томшыгы белән сала дип сөйләү — юк сүз ул, дөрес түгел. Ә дөресе — томшыгы белән ул үз йомыркасын түгел, урланган йомырканы алып килеп ояга сала.

Мәсьәләнең моннан да уңышлырак чишелүенең кирәге дә юк иде. Икенче көнне Әхим дәрескә кыю атлады. Аны тыңлагач күпләр гаҗәпләнде, әмма җавaптан канәгать калды. Класста тынлык урнашты. Әхимгә хөрмәт йөзеннән иде бу тынлык.

*Ахыры киләсе санда*

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез Фарсель Зыятдиновка 75 яшь тула. Аны юбилее белән ихластан тәбрик итәбез, сәламәтлек, иҗат уңышлары телибез.*

Гавриил
Державин

## Сәхрәләргә чыга идек без...

**Җыелышып кайчак дус-иш белән**
**Сәхрәләргә чыга идек без, —**
**Шәһәр ыгы-зыгысын онытырга,**
**Җиләс һавада ял итеп без...**

**Табигатьнең ямьле җирләренә,**
**Утраучыклар, су буйларына.**
**Калкулыклар, яшел куаклыклар —**
**Безгә тансык иде бары да.**

**Дуслар арасында закон катгый:**
**Тигезлекне саклау үзара.**
**Баймы, хакимме ул — беркемне дә**
**Беркем тиеш түгел узарга.**

**Кемдер тапкыр, шат күңелле икән,**
**Андыйларны бигрәк сөябез.**
**Белемле һәм тәрбияле булса,**
**Хөрмәтлибез — «чинсыз» чөябез...**

**Юкка-барга җәнҗал куптармыйбыз,**
**Утырабыз тыныч гөрләшеп.**
**Чәркәләрдән нурлы шатлык эчеп,**
**Чын йөрәктән җаннар берләшеп.**

**Бездә чын герой да оялып тормый —**
**Гүзәллеккә зурлап баш ия.**
**Сугышыр өчен сәбәп кенә эзләү —**
**Хас эш бит ул фәкать вәхшигә...**

**Безнең болай бергә җыелулар**
**Үзе — имин яшәү өлгесе...**
**Бер-берең ә чәчкә өзеп бирү —**
**Бу бит саф татулык билгесе.**

**Кемнәр эзли күңел бердәмлеген,**
**Килсен монда, якын итсәгәр...**
**Кеше өчен шул да бәхет, дуслар,**
**Бер сәгатең рәхәт үтсә дә.**

## Яратканны белдерү

Бар табигать хәзер йокласа да,
Минем мәхәббәтем генә уяу.
Ул гел сиңа гына карап тора,
Һәрбер сулыш—хәрәкәтең тоя.

Сөйләгәннәремә бул дикъкатьле,
Ялгыз чакта уйла мине генә,
Хисләремә җавап бирче сөеп,
Назлап иркә карашларың белән.

Сүзләремне җөпләп, килешеп тор,
Үз фикерең булса, һич яшермә:
Икәү бер җан булып кушылыйкчы,
Шул бәхеттән артык ни бар җирдә?

Гыйшык дәртен күз алдыңа китереп,
Шуны татыр мизгелләрне тизләт...
Ходай белән тиңдәшлекне җирдә
Тик мәхәббәт бүләк итәр безгә...

Лена ШАГЫЙРЬҖАН
*тәрҗемәләре.*

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире иясенә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

*Хөрмәтле милләттәшләр!*

*«Казан утлары» журналының мөхтәрәм авторлары, хезмәткәрләре һәм укучылары!*

*Сезне «Казан утлары» журналының 90 еллык истәлекле юбилее белән чын күңелдән тәбрик итәм!*

*«Казан утлары» журналы — һәрвакыт югары кимәлдәге әдәбият-сәнгать, хасиятле мәдәният, гомумән, олы иҗат дөньясы ул. Шушы үткән тугыз дистә ел эчендә заманалар да, язучы-шагыйрьләрнең, журнал укучыларның буыннары да ничә кат алмашынды, әмма сөекле журналыбызның кыйбласы үзгәрмәде. Ул милләтебезнең бөек язучылары тарафыннан иң беренче саннарына сеңдерелгән игелекле уй-максатларга бүгенгәчә тугры: татарда милли үзаң, милләткә мәхәббәт һәм әдәби зәвык тәрбияләү.*

*Шунысы куанычлы: безнең бәхеткә, журнал редакциясендә элек тә, хәзер дә, тарихи дәвамчанлык учагын саклаган хәлдә, яңа сулыш өреп «Казан утлары»н дөрләтеп җибәрә белүче чын иҗат кешеләре эшләде һәм эшли. Алар шушы еллар дәвамында милләтебезнең әдәбиятын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклауда һәм үстерүдә олы хезмәт куялар. Ә иң мөһиме — татар теленең бөек әсәрләр иҗат итәргә сәләтле бөек тел икәнен һәрдаим дәлилләп килиләр. Бүгенге көндә туган телебезнең иң камил үрнәге «Казан утлары» журналында дисәм, ялгыш булмас, мөгаен. Дөресен генә әйткәндә, хәзерге глобальләшү чорында мондый югары дәрәҗәне саклап калу бер дә җиңел түгел, шуңа күрә журналны чыгаручыларның бу юнәлештәге тырышлыгы тирән ихтирамга, мактауга һәм олы рәхмәт сүзләренә лаек.*

*Журналны укучылар да аңа тугрылык саклый. Безнең күңелләрне җәлеп итә торган кызыклы һәм мавыктыргыч әсәрләр язып «Казан утлары»н тиешле югарылыкта тотучы шагыйрьләребезгә, язучыларыбызга, тел галимнәренә, әдәбият белгечләренә телебезнең һәм әдәбиятыбызның ямен, тәмен һәм кадерен белүче укучылар исеменнән зур рәхмәт әйтәсем килә. Һәрбарчабызга исәнлек-иминлек, бәхет һәм иҗат уңышлары телим.*

*Юлыбызны яктыртып, җаныбызны җылытып торучы «Казан утлары» барында безнең киләчәгебез өметле!*

**Минтимер ШӘЙМИЕВ,**
*Татарстан Республикасының Беренче Президенты*

*Хөрмәтле Равил Габдрахман улы!*

*Сезне, «Казан утлары» журналы редакциясе коллективын һәм аның укучыларын журнал дөнья күрүгә 90 ел тулу уңаеннан чын күңелдән котлыйм! Бу – редакция коллективы өчен дә, республикада яшәүче татарлар өчен дә зур вакыйга.*

*«Казан утлары» 1922 елның май аеннан башлап бүгенге заманда да үз йөзен, укучысын югалтмыйча чыгып килүче санлы һәм данлы басма.*

*Татар язучыларының иң яхшы әсәрләре, күренекле шәхесләребезнең истәлекләре*

*һәм көндәлек язмалары, юмор һәм сатира әсәрләрен бастыручы әлеге басма телне һәм мәдәниятне үстерүдә зур роль уйный.*

*Журналның озын гомерле булуы һичшиксез редакция хезмәткәрләренең профессиональ эшләвенә бәйле.*

*Без журнал редакциясе белән урнаштырылган эшлекле мөнәсәбәтләрне, коллективның һөнәри, иҗади эшчәнлеккә ачык, конструктив каравын югары бәялибез.*

*Сезгә һәм Сезнең хезмәттәшләрегезгә иң бөек морадларыгызга ирешүне, иҗади уңышлар, сәләтле язучылар, рәхмәтле һәм тугрылыклы укучылар телим.*

*Ихтирам белән,*
*Республика матбугат һәм гаммәви*
*коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе*
**Марат МОРАТОВ.**

*Хөрмәтле Равил Габдрахман улы!*

*Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы хокуклы вәкиллеге исеменнән һәм шәхсән үземнең исемнән Сезне һәм коллективыгызны юбилеегыз һәм һөнәри бәйрәмегез — Матбугат көне белән тәбрик итәм!*

*Сезнең журналның татар халкы мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен саклап калу һәм үстерү эшенә керткән өлеше әйтеп бетергесез. «Казан утлары» битләрендә Татарстандагы хәзерге язучыларның иң яхшы әсәрләре басылып чыга, галимнәрнең һәм сәнгать эшлеклеләренең татар халкы рухи мирасы турындагы хезмәтләре нәшер ителә.*

*Чын күңелдән Сезгә һәм мәшһүр журналның хезмәткәрләренә яңа талантлы авторлар, каләм тизлеге, югары тиражлар һәм укучы аудиториянең актив рәвештә кайтаваз бирүен телим! Һичшиксез — онытылмас очрашулар, оптимизм һәм нык сәламәтлек, һәркайсыгызның профессионализмы сөекле Татарстаныбыз һәм Россия җәмгыятенең иминлегенә хезмәт итсен!*

*Татарстан Республикасының*
*Россия Федерациясендәге*
*Тулы хокуклы вәкиле*
**Равил ӘХМӘТШИН.**

*Хөрмәтле каләмдәшләр!*
*«Казан утлары» журналы хезмәткәрләре һәм укучылары!*

*Сезне олуг һәм күркәм юбилей «Казан утлары» журналының 90 еллыгы белән ихлас йөрәктән тәбриклибез. Басма тарихы татар әдәбияты тарихы белән аерылгысыз. Сезнең күренекле, атаклы әдипләрегез шушы журнал битләрендә сынау тоткан, иҗади өлгергәнлеккә үзенчәлекле имтихан тапшырган. «Казан утлары»н Башкортостанда да алдыралар, укыйлар.*

*Әлбәттә, ике милли журнал «Казан утлары» белән «Агыйдел» үткән юл бик тә охшаш. Сезнең юбилей быелга туры килсә, безнең башкорт басмасы 90 еллыгын 2013 елда билгеләячәк.*

*Соңгы чорда безнең иҗади бәйләнешләр күпкә ныгыды. Даими рәвештә әдәби битләр белән алмашып торабыз, коллегаларыбыз белән шәхсән аралашулар көчәя төште.*

*Алга таба да, шөкер, матбугатара, әдәби-мәдәни, республикара элемтәләр дәвам итәр, халыкларыбыз дуслыгы мәңге яшәр, дип телик.*

*Мөхтәрәм кардәшләр! Күркәм тарихи дата белән янә бер тапкыр котлыйбыз, яңадан-яңа иҗади үрләр, яңа җиңүләр телибез.*

*«Агыйдел» журналы редакциясе хезмәткәрләре*
*исеменнән баш мөхәррир*
**Әмир ӘМИНЕВ.**

*Хөрмәтле Равил Габдрахман улы!*

*Сезне һәм Сезнең коллективны халкыбызга рухи тәрбия бирүне кыйбла иткән зәвыклы мәшһүр «Казан утлары» журналы юбилее уңаеннан чын күңелемнән тәбрик итәм. Сезгә игелекле тынгысыз хезмәтегездә иҗади уңышлар, фикер берлеге, яңа ачышлар, укучыларның ышанычын, ихтирамын аклап хезмәтегезнең нәтиҗәсен күреп яшәвегезне телим.*

*Хөрмәт белән,*
*Зәй муниципаль районы башлыгы*
**Татьяна ВОРОПАЕВА.**

*Хөрмәтле «Казан утлары» коллективы!*

*Сезне «Ватаным Татарстан» газетасы исеменнән олы юбилеегыз белән котлыйбыз. Сезнең 90 еллык тарихыгызга әйләнеп карасак, әлеге басма татар әдәбияты тарихында, бүгенге үсеш чорында тирән эз калдырырлык елъязмалары белән истә калырлык журнал булып тора.. «Казан утлары» элегрәк «Безнең юл», «Яңалиф», «Атака», «Советы әдәбияты» исемнәре белән басылып килә. Сез заман шаукымына һәм аның сәясәтенә бирелмичә, үз йөзегезне саклап кала белдегез. Сезнең журнал битләрендә һәрвакыт татар әдәбиятының алтын фондына кертелгән классиклар белән беррәттән яшь каләм тибрәтүче талантларның иҗаты да зур урын алып барды. Саллы, затлы журнал киләчәктә дә халкыбызның рухи байлыгын барлаучы, киләчәк буынны тәрбияләүче басма булып калсын. Редакция хезмәткәрләренә, «Казан утлары»ның даими авторларына иҗади уңышлар телибез.*

**«Ватаным Татарстан»**
**газетасы редакциясе.**

*Уважаемый Равиль Габдрахманович*
*и весь трудовой коллектив журнала «Казан утлары»!*

*Редакция газеты «Казанские ведомости» сердечно поздравляет вас со славным юбилеем — 90-летием со дня выхода первого номера журнала «Казан утлары»! Ваша история неразрывно связана с историей татарстанской литературы.*

*Здесь публикуются лучшие произведения современных писателей Татарстана, труды ученых и искусствоведов, касающиеся духовного наследия татарского народа, переводы знаменитых произведений мировой литературы. «Казан утлары» является*

*своего рода летописью жизни татар. Читая эту своеобразную антологию татарской литературы, заново переживаешь целую эпоху, ощущаешъ дыхание времени, часто непростого, а порой и трагического.*

*И мы, ваши коллеги, желаем вам достойно встретить столетие журнала, сохраняя любовь своих многочисленных читателей и продолжая игратъ ведущую роль на культурном пространстве Татарстана и дальнего зарубежья.*

*С уважением*
*главный редактор*
*газеты «Казанские ведомости»*
**Венера ЯКУПОВА .**
*2012 г.*

*«Казан утлары» журналы коллективын юбилей белән котлыйм. Сау-сәламәт яшәп иҗат итегез, данлы исемегез гасырлардан-гасырларга күчеп татар халкын мәңге рухландырсын.*

*Шагыйрә* **Гөлзада ӘХТӘМОВА.**
*Алабуга*


*Безнең өчен бик кадерле булган яраткан журналыбыз «Казан утлары»!*

*Сине чын күңелебездән 90 еллык юбилееӊ белән тәбрик итәбез. Син – безнең гаиләбезнең иң яраткан журналы. Яраткан журналыбызны чыгаруга зур көч куйган хөрмәтле редакция хезмәткәрләре! Эшегездә уңышлар юлдаш булсын, кайгы-хәсрәт сезне читләтеп узсын. Кәефегез яхшы, күңелегез күтәренке булсын. Киләчәктә дә шулай кадерле журнал булып калырсың ышанабыз. Коллективка саулык-сәламәтлек, гаилә бәхете, озын гомер телибез. Иҗат чишмәләрегез саекмасын, иҗат гөлләрегез һаман шулай шаулап чәчәк атсын!*

*90 ел буе рухи азык булып,*
*Хезмәт иттең район халкына.*
*Бер гасырлык юбилееңны да*
*Шушы изге эштә каршыла.*

*Иң изге теләкләр белән. Апастан*
**Миләүшә, Касыйм һәм Айдар ВӘЛИУЛЛИННАР** *гаиләсе.*

## *Юбилеебыз тантанасы мизгелләре*




*Тантаналы кичә 2012 елның 17 маенда узды.*



*Кичәгә килгән тамашачылар һәм кунаклар.*



*Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы хокуклы вәкиле Равил Әхмәтшинның (уңнан икенче) язучылар арасында дуслары, танышлары күп. Заманында Казан университетында татар әдәбияты һәм теле бүлеген тәмамлаган ул.*



*Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары Нурия Беломоина, «Татмедиа» ААҖ генераль директоры Айдар Сәлимгәрәев юбилей белән тәбриклиләр. Уңда – журналның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин.*




*Безне музыкантлар сәламли.*



*«Печән базары» дигән сатирик конкурста беренче урынны яулаган Зөлфәт Хәким «Казан утлары»на рәхмәт сүзе әйтә. Янәшәсендә жюри әгъзалары Камил Кәримов (сулда) һәм Ләбиб Лерон.*

# ЙӨРӘККӘ ЯШЕРЕЛГӘН СЕРЛӘР

## ФЛЕРА ТАРХАНОВА ИҖАТЫНДА ГАЗӘЛ ЖАНРЫ

*«Газәлләр ятлап үсәсең, ахры, шуңа гүзәлсең!» –*
*Җаныңны күрә белгәннәр, сөеп шулай сөйләсен!*
Рәдиф Гаташ

Соңгы еллар татар әдәбиятында газәл жанры үсешен тикшерү нигездә өч шагыйрь иҗатына барып тоташа. Болар – Рәдиф Гаташ, Мөхәммәт Мирза һәм Флёра Тарханова. Дөрес, аерым газәлләр Равил Фәйзуллин, Ренат Харис һ.б.ларда да очрый, әмма әлеге шагыйрьләр иҗатында газәл жанры системалы күренеш түгел. Гомумән, Алтын Урда чоры әдәбиятында әйдәп баручы жанрларның берсе булган газәл XX гасыр татар шигъриятендә киң планда үсеш ала алмый. Әдәбият белеме сүзлекләрендә дә газәл жанры турында сүз барганда мөселман Көнчыгышы шагыйрьләреннән Сәгъди, Хафиз, Нәсими, Нәваилар мисалга китерелә. Дөрес, соңрак XIX һәм XX гасыр башы шагыйрьләре Ш.Зәки, Г.Кандалый, Г.Тукай, Ш.Бабич, М.Гафури исемнәре өстәлә. Совет чоры әдәбиятында Х.Туфан, Ә.Исхак, Н.Арысланнарның иҗатында газәл үрнәкләре барлыгы билгеле.

Газәл жанры үзенчәлекләре фәнни-теоретик һәм гамәли планда шактый аз өйрәнелгән. Бу уңайдан Х.Миңнегулов, Р.Ганиева хезмәтләрен атап китү урынлы булыр. Аларда Р.Гаташ, М.Мирза газәлләренә этрафлы күзәтү ясала. Ә инде әлеге жанрда уңышлы иҗат итүче Ф.Тарханова шигърияте игътибардан читтә калып килә. Шул сәбәпле әлеге язмада журнал укучыларына шагыйрәнең газәл жанрына бәйле эзләнүләре, аерым шигъри табышлары тәкъдим ителә.

Гарәп алынмалары сүзлегендә газәл сүзенең ике төрле мәгънәсе билгеләнә. Беренчесе, «гыйшык-мәхәббәт шигырьләре, бәетләре» булса, икенчесе, «сөйгән кызга карата язылган мәдхия», диелгән. Димәк, сүзлек буенча барсак, газәл жанрында иҗат итүче шагыйрь ир затыннан булырга тиеш. Әдәбият белеме сүзлекләрендә бер генә хатын-кыз язучының исеме дә аталмау факты шул турыда сөйли булса кирәк. Әлеге мәсьәләгә төгәлрәк аңлатма тюрколог галим Х.Курбатовта гына очрый. Ул «бер-бер мәгъшук яки мәгъшуканы ярату, мәхәббәт хисе белән сугарылган» шигырьне газәл дип атый. Димәк, газәлне хатын-кыз затыннан булган шагыйрь дә язарга мөмкин, дигән нәтиҗә ясап була, һәм бу уңайдан XIX йөзнең беренче яртысы үзбәк әдәбиятында үзбәк һәм фарсы-таҗик телендә язган газәлләре белән күренекле урын тоткан шагыйрә Махлар айым Надирә (1792–1842) исемен мисалга китерү улай булыр.

Р.Гаташ газәлләре узган гасырның 90 нчы елларында иҗат ителсә, М.Мирза газәлләре XXI гасыр башында күренә башлый. Ф.Тарханова да газәл жанрына шул елларда килә. Дөрес, беренче газәлендә «1993 ел» датасы күрсәтелеп, газәлләренең күпчелеге соңгы елларга карый. Шулай да бу өлкәдәге беренче тәҗрибәләре алдарак та ясалган булса кирәк. Шулардан «Мин Ходайдан күпме үтендем...» газәле (1993) эчтәлеге, «яшьлек эзе калган сукмаклар»дан йөреп, лирик геройның үз тинен көтү, хәтта көтеп ару халәтен чагылдыра. Шагыйрәнең газәле укучыдан да билгеле бер әзерлек «сорый», шигырь юлларының озын булуы интонацияне гаруз ритмына көйләп куюны таләп итә:

*Мин Ходайдан күпме үтендем, йолдызларны урап мең килдем.*
*Күз яшемне гөлгә эчердем – тиңем мине күрми микәнни?! (...)*

*Юлларыма чыккан күп лә ул, шашып сөйгәннәр дә сер түгел.*
*Тик канатым һаман ул түгел – үз насыйбым кылмәс микәнни?!*

*Кай тарафта икән эзләре, күрмәс булды мәллә күзләре?*
*Теләкләрем нигә үтәлми – зарыкканны белми микәнни?!*

Ф.Тарханованың күпчелек газәлләренә риторик пландагы сорау интонациясе хас. Дөрес, Р.Гаташ газәлләре дә сорау интонациясенең күплеге белән игътибарны җәлеп итә. Ә менә М.Мирзада алар күп очрамый. Ул, гадәттә, сорауны иҗтимагый-фәлсәфи эчтәлекле газәлләренә генә кертеп җибәрә. Ф.Тарханова белән Р.Гаташ газәлендә охшаш сыйфатлар шактый җыела. Соңгысында сорау йә сорау кушымчасы аша, йә эчке интонация аша белдерелә. Ә Ф.Тарханова турыдан-туры сорау кисәкчәсе белән «сорый», шунын өстенә шагыйрә сорау алмашлыгына сорау кушымчасы да өстәп куя. «Мин Ходайдан күпме үтендем...» газәле генә түгел, аның кайбер башка газәлләре дә сорау кисәкчәле рифма системасына нигезләнә.

*Чын сөюне татымаган, мәхәббәттән шашынмаган кеше дә була икән.*
*Кызык: андый адәмнәрнең күңелләре, йөрәкләре ни белән тула микән?*

*Гашыйклар янында йөреп, өзелеп сөюләрен күреп, көнчелек уты кабынса,*
*Бөтен җанын-тәнен биреп, үлеп яратасы килеп, кызыгып куя микән?*

Ф.Тарханова газәлләренә беркадәр мөнәҗәт жанры үзенчәлекләре дә килеп керә. Дөрес, аларда Аллаһны мактау яисә Аңа ялвару күзәтелми, биредә дини эчтәлек язмыш мотивына үрелеп китә. Нәтиҗәдә лирик геройның Ходайга мөрәҗәгать итеп, сабырлана төшүе, үз насыйбын көтеп яшәве үзәккә чыга.

Бер төркем шигырьләре эчтәлегендә «үз-үзен белән сөйләшү» сизелә, моңзар да бар, трагик башлангычны, аерылу газабы мотивын тоймый калу мөмкин түгел. Бу газәлләрнең мөнәҗәт жанры белән уртаклыгы шунда тәмамлана да. Ф.Тарханова шигырьләрендә һәрвакыт ике объект «яши»: берсе лирик мин булса, икенчесе – лирик миндәге хисләрнең сәбәпчесе. Беренчесенең һәр сүзе сурәтләү объектыннан мәхәббәт, наз таләп итүе белән үзенчәлекле. Эчтәлек исә даими үзгәреп тора, бер урында ул үткәнне искә төшерсә («Гөлчәчкә, алдана күрмә», дип кисәтә), икенчесендә сабыр бул дип, үз-үзен юата.

Ф.Тарханова, газәл таләпләреннән чыгып, шигырьнең соңгы строфасында үз исемен тәрҗемәдә «Гөлчәчкә» рәвешендә кертеп җибәрә һәм әлеге кануни таләпне һәр шигырендә диярлек саклап кылә:

*И Гөлчәчкә, ташкын хистән күңелләрең туламы –*
*Синең дә челтер чишмәңдә су кипкән чак буламы?*

Шагыйрәнең күпчелек газәлләре 15 ле үлчәм белән язылган. Арада 16 лы, 18 ле, мисраглары бүленгән газәлләрендә хәтта 23–24 иҗектән гыйбарәт шигырь юллары да күренә. Нәкъ менә шул үзенчәлек аның газәлләренең аһәнлелеген тәэмин итеп, музыкальлеген көчәйтә булса кирәк, икенче төрле әйткәндә, гаруз табигате Ф.Тарханова газәлләрендә көчлерәк килеп чыга. Әлеге «шигырь кору» үзенчәлеге белән ул үзбәк шагыйрәсе Надирә газәлләренә якыная.

Газәл жанрындагы шигырьләрен Р.Гаташ та, М.Мирза да 11 ле үлчәм белән язалар. Билгеле булганча, 11 ле үлчәм силлабик шигырь системасында гына түгел, төрки гарузда да бар. Гаруз һәм төрки классик шигырь элементларының үзара якынлыгы турында М.Бакиров болай яза: «Гарәп-фарсы гарузындагы кебек, борынгы төрки язма шигырьдә дә 11–11 үлчәме киң таралган булган, һәм «иҗекләр тигезлеге өлкәсендәге охшашлык төркиләргә үзләренең 11ле үлчәмен фарсыларның шул ук үлчәмдәге үрнәкләргә ияреп язу өчен кулланырга сәбәп булган, ягъни фарсы йогынтысына эләккән беренче төрки әсәрләр нәкъ менә 11 иҗекле үлчәмгә төренгәннәр». Галим гаруз системасында көчәйтелгән басым белән музыкаль басымның туры килүенә игътибар итә һәм әлеге

гипотезаны исбатлаган вакытта квантитативлык күренешенең озын һәм кыска сузыклы иҗекләрнең чиратлашуына гына корылмавын дәлилли. Шулай да, «заманча газәл»нең татарда иң еш кулланылган варианты 11 ле шигъри үлчәмгә корылса, Көнчыгыш классик поэзиясенең без өйрәнгән газәл формалары арасында 15, 16, 17 һ.б. иҗек үлчәмле газәлләренең дә булуын танырга туры килә. Р.Гаташ газәлләрендә дүртәр иҗекле ике ритмик буыннан соң өч иҗекле соңгы ритмик буын күзәтелсә, М. Мирза газәлләрендә дә нигездә ритмик буыннарның күрсәтелгән тәртибе саклана.

Ә менә Ф.Тархановаҥың барлык газәлләренә хас бердәм һәм тотрыклы ритмик буыннар тәртибен ачыклавы шактый авыр мәсьәлә. Үлчәмнәр төрле булган кебек, шигырь юлларындагы цезураларның урнашуы да төрлечә килеп чыга. Менә халык җырын хәтерләткән 15 ле үлчәмле бер газәлен алып карыйк:

*Суга иелгән талларга | былбыл килеп| кунамы – ||*
*Тал былбылсыз, | былбыл талсыз| бу дөньяда| буламы? ||*

*Каен белән чагыштырма | сылу кызның |гәүдәсен – ||*
*Төз үскән матур кәүсәнең | хәрәкәте |буламы? ||*

Мисалдан күренгәнчә, газәл мисрагларының икенче яртысында ритмик буыннар тәртибе тотрыклы булса да, беренче яртысында цезураларның урыны үзгәреп тә ала. Гаруз шигырь системасы кануннары буенча цезура, силлабикадагы кебек сүз беткәч түгел, ә сүзне бүлеп тә килергә мөмкин. Шагыйрәнең тагын бер газәленә игътибар итик. Бу юлы шигырь юлындагы иҗекләрнең саны 16 га тула.

*И Гөлчәчкә, | сөю – ләззәт. | Табып мең төрле әмәлен, ||*
*Сөйләсен сөю турында | синең чарланган каләмең. ||*

Гадәттә, татар шагыйрьләре газәлнең бар таләпләрен дә үтәп бетерми. Әйтик, Р.Гаташның бик сирәк газәлләрендә генә «рәдиф» дигән стилистик чара кулланыла. М.Мирзада да бу сирәк күренеш. Шигырьгә әлеге поэтик синтаксис элементы килеп кергән очракта да, кануни таләп тулысынча үтәлеп бетми: йә рәдиф элементы ярдәмче сүз яисә сорау кисәкчәсе формасында гына килә, йә ул алдагы җөмлә составына керешеп китә. Ә менә Ф.Тарханова әлеге «җитешсезлек»тән азат. Аның газәлләрендә рәдиф бөтен кагыйдәләренә туры китерелгән рәвештә һәм еш кулланыла. Шагыйрәнең мондый типтагы газәлләрендә «рәдиф»кә кадәр үк рифмалашкан сүзләр килә, димәк, икеләтелгән рифма килеп чыга дигән сүз.

*Иреннәрең балдан татлы – мондыйлар сирәк, дидең.*
*Беркемне дә кагылдырма – үземә кирәк, дидең.*

*Күзләреңне каймалаган керфегең – тирәк, дидең.*
*Сыендырма башкаларны – үземә кирәк, дидең.*

Шигырьдән күренгәнчә, биредә газәли рифма «керфегең – тирәк / үземә кирәк» рифмалары, «диден» сүзе алдында килеп, рәдиф кушылмасыннан гыйбарәт. Әлеге газәлнең буеннан-буена сигез иҗектән соң килә торган цезураның катгый тәгаенләнгән урыны бар, ул һәр алты строфада да үзгәрешсез кабатланып, ритмик яңгырашны бик нык көчәйтә.

Ф.Тарханова газәлләрендә сурәтлелек көчле. Ул горизонталь рифмалардан да уңышлы сүз-сурәт ясый белә, халыкта киң таралган, аеруча җырларда җырлана торганнарын таба, шуңа да чагыштырулары, эпитетлары «җырлап» тора. Шагыйрәдә борынгы суфичылык поэзиясенә хас образлар очрый, шундыйлардан «талга кунган былбыл», «бәхет кошы», «балдан татлы иреннәр», «чәчкә аткан роза гөле», «кара күмергә калган гашыйк» кебек детальләрне атап китү урынлы булыр. Шигырьләрдә хисләр йөгәнләнми, шагыйрә алар турында яшермичә яза. Газәл юлларында эмоциональлек, аһәңлелек югары дәрәҗәдә, шигъри гармония төгәл саклана. Шагыйрә газәлнең

буеннан-буена төп кичереш белән бәйле бер рифма таба да игътибарны аңа аваздаш сүзләргә юнәлтә, шул рәвешле шигъри бербөтенлек тудыруга ирешә. Ф.Тарханова шигырьләрендә «лирик мин» генә түгел, «лирик син» дә катнаша.

*Затлы күлмәгемне кидем, матур буламын диеп,*
*Син бәгырьдә булган чакта дөньям да торды көлеп.*

*Балдай әчтем сулышыңны, таралды тәнгә бәлзәм,*
*Авыр минутларымда да яшәр өчен дәрт биреп.*

*Киттең дә баттың җиһанга – әйләнеп кайтырсыңмы,*
*Син китүгә җаннарымны борчулар басты килеп.*

Шагыйрә «Чын сөюне татымаган...» газәле юлларын 23-әр иҗектән формалаштыра. Һәр уналты иҗектән соң ул калган сүзләрне яна юлдан урнаштыра. Шунысын да искәртеп үтик, гаруз шигырь системасында язылган газәлдә мисрагларның икегә бүленүе гадәти күренеш буларак кабул ителә. Газәлнең бер строфасы болай яңгырый:

*Гашыйклар янында йөреп, (8) өзлеп сөюләрен күреп, (8)*
*көнчелек уты кабынса, (8)*
*Бөтен җанын-тәнен биреп, (8) үлеп яратасы килеп, (8)*
*кызыгып куя микән? (7)*
*И Гөлчәчкә, мәхәббәттә (8) яндың, көйдең, хисләреңне (8)*
*мәңге сүлмас гөлгә тердең – (8)*
*Күңелләрең, бәгырьләрең (8) сөюнең илаһи көчен (8)*
*һаман да тоя микән? (7)*

Газәлнең мисалга китерелгән беренче строфасында биш синтаксик берәмлек бер-бер артлы килә. Рифма таләбеннән чыгып, шагыйрә өченче синтаксик бөтеннен кушымчасын үзгәртә, шуның белән алдагы ике ритмик буында әйтелгән фикергә нәтиҗә ясагандай була. Шул рәвешле, әлеге газәлдә «артык» ритмик буын шигырьнең аһәңлегенә зыян салмый. Бер үк төрле хәл фигыль кушымчасына тәмамланган синтаксик берәмлекләр, градациягә әйләнеп, фикерне көчәйтүгә ярдәм итә. Әлеге уңайдан шунысын да искәртеп үтү урынлы булыр: хәзерге шагыйрьләр шигырьне болай озын юллы итеп язмыйлар. Силлабик шигырь системасының «мөмкинлекләре чикләнгән» булуның да тәэсире бардыр дип уйлыйк. Ә Ф.Тарханова газәлләренә килгәндә, шагыйрәнең гаруз һәм силлабиканы берләштереп язуы күзәтелә.

«Дистәләгән еллар элек...» дип башланган газәлгә килик. Биредә лирик геройның бала югалту хәсрәтен кичерүе сурәтләнә. Газәли рифмаларга игътибар итсәк, алар болай яңгырый: «башым хәсрәткә тарып»; «өзлексез яшем тамып»; «йөрәккә уелып калып»; «бер тәүлек уттай янып»; «тирән кайгыга салып»; «күз алмасында калып»; «бәгырьне меңгә ярып»; «башкадан гыйбрәт алып». Әлеге газәлнең һәр строфасындагы беренче мисрагының ахыры шулай ук сагыш тулы ана образын чагылдырырга сәләтле булып чыккан. Менә нинди сурәтләр куллана шагыйрә: «колагымда – ыңгырашу», «күзләремдә – тилмерү». Шигырьдә хәсрәтнең гомерлек булуы, моңа китергән җан әрнеткеч күренешләр сурәтләнә.

Газәлдә рифма 5–6 бәет строфасын берләштерә торган хиснең бөтенлеген дә тәэмин итә. Традицион газәлдә кануни рифма тәртибе сакланырга тиеш. Ф.Тарханова кайбер газәлләрен мәснәви рифмасы белән дә яза, ягъни һәр икеюллыкның үз мөстәкыйль рифмасы була. Мондый шигырьләрне, гәрчә шигырьдә газәлнең башка традицион үзенчәлекләре сакланса да, газәлгә стилизация дип карау дөрес булыр. Менә шундый шигырьләрнең берсе:

*Матур җәйдә корган оям көтмәгәндә таралды –*
*Бәгырем шартлап ярылды, ак йөзләрем каралды.*

*Оям белән килеп төште кеп-кечкенә кошчыгым –*
*Кан тамчысы сарган иде миңа сузган томшыгын.*
*...*
*И Гөлчәчкә, һәр көн таңнан түзем сора Ходайдан,*
*Әҗере: үскәч кошчыгың ярдәм салыр һәркайдан!*

Мәснәви рифмасы татар шагыйрьләрендә еш очрый, мондый типтагы шигырьләр Ә.Синугыл иҗатының нигезен тәшкил итә иде. Күрәсең, бәет строфасы төрки халыкның табигатенә бик тә туры килә. Ә газәл ул – ни генә әйтсәң дә, гарәп-фарсы шигыре.

Тематик төрлелеккә килгәндә, Ф.Тарханова традицион газәл темасыннан читкә китми: сәясәткә керми, иҗтимагый өлкәне дә читләтеп үтә. Арада «Үзенне өстенгә санап...» (2007) газәле генә башкалардан аерылып тора. Ул бер хөсет кешегә җавап рәвешендә язылган. Шагыйрә биредә ачу хисләрен белгертә, нәзәкатьлелек саклап тормый.

Ф.Тарханова Көнчыгыш шигъриятенең башка жанрларында да үзенең көчен сынап карый. Аның әлегә башка шагыйрәләрдә күрелмәгән һәм аерым күзәтүне көткән «мөсәммәннәр» исемле сигезьюллыклары, катлаулы үлчәмдәге классик поэзия үрнәге булган «мөстәзад», бишьюллык строфалар булган «мөхәммәсләр», дүртьюллык строфалардан төзелгән шигырь – «мөрәббәгъләр», тагын үзенчәлекле рифма системасына нигезләнгән «тәрәҗҗибәнд», алтыюллыклардан гыйбарәт «мөсәддәс», җидеюллыклардан торган «мөсәббә» формалы шигырьләре бар. Шагыйрә аларда катлаулы метафоралар белән мавыкмый, сурәтләү рәвеше халык җырларына якыная. Көнчыгыш стилендәге шигырьләрендә катлаулы фәлсәфи проблемалар күтәрелми, чынбарлык ачык, аңлаешлы сурәтләрдә бирелә. Фикер белән түгел, хис белән алдыра. Үзенчәлекле эпитетлар куллана, халыкның җанлы сөйләменә таяна. Бер мөрәббәгънең беренче строфасы менә ничек яңгырый:

*Сөя дип әйтеп буламы – газабында көймәсә,*
*Бар дөньясын оныттырып сөелмәсә, сөймәсә,*
*Үзе янып, сөйгән ярын ялкынына төрмәсә? –*
*Ярата дип әйтеп булмас, бу хисләрне белмәсә.*

Ф.Тарханованың мәхәббәт шигырьләрен, газәлләрен укыганнан соң, аны «Сөю шагыйрәсе» дип исемлисе килә. Бер караганда, хатын-кызларның мәхәббәт шигырьләре язуы – табигый күренеш. Шагыйрь Р.Харисның да С.Сөләймановага багышланган «Сөю Шагыйрәсе» исемле шигыре бар (тезмә сүзнең икесе дә баш хәрефтән!). Дөрестән дә, С.Сөләймановадан мәхәббәт лирикасының кабатланмас матур үрнәкләре калды. Ә Ф.Тарханова әлеге юнәлешне эчтәлек һәм поэтика ягыннан баетып кына калмый, бәлки нәкъ менә шул эчтәлеккә тәңгәл килә торган шигъри форманы эзли. Әдәбиятта форма белән эчтәлекнең туры килүе әсәргә куелган төп шартларның берсе булып тора. Мәхәббәт лирикасын газәл жанрында язу әсәрне икеләтә үтемлерәк итә. Шунысын да кабат искәртик: беренчедән, газәл – ул шигъри жанрлар арасында матурлык өлгесе булса, икенчедән, катлаулы рифма һәм ритмик системалы сирәк очрый торган шигъри формалы жанр.

Хәзерге кырыс чынбарлык шартларында, хатын-кыз шагыйрьләр иҗатына хас булган дидактизмга иярмичә, көнкүреш ваклыкларыннан зарланмыйча гына Ф.Тарханова шигырьдә төрле тәҗрибәләр ясап карый, эзләнә, кызыксынып укырлык шигырь үрнәкләре тудыра.

**Фәридә ХӘСӘНОВА,**
*КФУ доценты*

**Редакциядән:**

*Бу көннәрдә каләмдәшебез Флера Тарханованың юбилее. Аны гомер бәйрәме белән ихластан тәбрик итәбез, иҗат уңышлары теләп калабыз.*

# ТУКАЙНЫҢ ОСТАЗЫ һӘМ ОСТА МАТБАГАЧЫ

XIX йөз ахырларында Закир Рәмиев-Дәрдмәнднең, татар вакытлы матбугатының булмавыннан зарланып, хәзерге заманда үз матбугаты булмаган әдәбиятның үсеш ала алмавы турында фикер әйтүе билгеле. Ул вакытта әле татар телендә газета һәм журналлар нәшер итү турында күпләр хыяллана гына. Патша хакимияте вакытлы матбугат ачу ирегән бирми. Надан халык, мәгълүматтан бихәбәр милләт белән идарә итүне өстен күрә. 1905 елгы халык күтәрелеше генә татар матбугатына юл ача. Шул елның февралендә Казанда татар зыялылары, Әхмәд бай Хөсәеневнең Кабан күле буендагы өенә «аш мәҗлесенә» дигән сылтау белән җыелып, патша җәнапларына исеменә атап хат-петиция яза. Аларның төп таләпләре Россиядәге барлык милләтләрнең дә тигез хокуклы булырга һәм, шул исәптән, татар милли матбугатын нәшер итүгә ирек бирелергә тиешлеге турында була. Сонрак хатка Россиядә зур абруй казанган ике йөзләп кеше (арада бертуган Хөсәеневләр, Рәмиевләр, Юнусовлар, Акчуриннар, Дибердиевләр h.б. бар) кул куя. Ул хатны башкалага илтеп тапшыру бурычын фабрикант Ибраһим Акчурин, Йосыф Акчура һәм Рәшит казый Ибраһимов үз өсләренә ала. 1905 елның көзендә матбугат ирегә дә вәгъдә ителгән патша манифесты чыгуга татар зыялылары язган әлеге хатның йогынтысы да булмый калмагандыр шәт.



Россиядә саф татар телендә беренчеләрдән булып «Фикер» газетасы чыга башлый. Беренче саны 1905 елның 26 ноябрендә нәшер ителә. Аның нашире һәм мөхәррире Камил Мотыйгый — бөек Тукаебызның остазы һәм укытучысы була. Камил Мотыйгулла улы Төхфәтуллин минем күз алдыма милли азатлык һәм хөррият көннәре килеренә өметләнеп яшәгән татар яшьләренең бер вәкиле буларак килеп баса. XX гасыр башында аның исеме зыялы татарлар арасында бик тиз тарала. Милләттәшләребез оешыбрак яшәгән төбәкләрдән бер читтәрәк торган Уральск (Җаек) шәһәрендә туып-үскән бу халфәгә дан-шөһрәт ничек килә соң? Гасыр башында ул моңа берничә данәдә үз кулы белән чыгарган кульязма «Әлгасрел җәдит» («Яңа гасыр») журналын таратуы белән ирешә. Шәһәр яшьләре һәм мәдрәсә шәкертләре арасында К.Мотыйгыйның кульязма «Мәгариф» газетасы да таратыла. Боларны ул 1903 ел башыннан ук атасы җитәкчелек иткән «Мотыйгия» мәдрәсәсе шәкертләре һәм үзенең якын дус-ишләре булышлыгы белән башкара, һәм бу эшне 1905 елгы патша манифестыннан соң басма газета-журналлар нәшер итүгә рөхсәт бирелгәнче үтәп килә. Камил Мотыйгыйның бу эшчәнлеге Габдулла Тукайның башлангыч иҗат чоры белән тыгыз бәйләнештә булганлыгы, кем әйткәндәй, безнең һәр мәктәп укучысына таныш. Кульязма «Әлгасрел җәдит»тә дә, 1906 елның башыннан шул ук исемдә таш басмада чыга башлаган беренче татар журналында да бөек шагыйребезнең иҗат үрнәкләре еш очрый: ул анда шигырьләре белән дә, укытучысы тәкъдим иткән темаларга язылган кечерәк мәкалә вә тәрҗемә хезмәтләре белән дә теркәлгән. Кайбер әдәбият галимнәре фикеренчә, шул елларда

Камил Мотыйгый белән аралашмаган, ул нәшер иткән газета-журналлар эшендә катнашмаган булса, Г.Тукай әдәбият мәйданына алай тиз генә кереп китә алмаган булыр иде.

Камил мәхдүм, шул елларда аралашкан шәкертләреннән өч-дүрт яшькә генә олы булуына карамастан, шактый тирән белемле, мәгълүматлы шәхес була. Ул яшьли Төркиягә китеп Истанбулда, аннары Каһирәнең югары уку йортларында үз чорының олуг зыялылары укыткан лекция-дәресләрне тыңлый. Европа тарафыннан искән «җылы агымнар» йогынтысында булган яшьләр белән аралаша. 1902 елда иленә кайткач, милләттәшләренең аң-белемен үстерүгә булган ихтыяҗын канәгатьләндерү буенча тырышлык куя. Мөхтәрәм атасы Мотыйгулла ахун хәзрәтләре тоткан мәдрәсәдә шәкертләр укыту белән бергә, бу шәһәрдә мәдәни кичәләр оештыруга да керешә.

Хәтеремдә әле, 1960 елларда Камил Мотыйгыйның улы, элекке опера җырчысы Хәмит ага Төхфәтуллин атасының шул чор җәмәгать эшчәнлеген чагылдырган кайбер истәлекләрне консерватория студентлары белән очрашуга алып килеп күрсәткән иде. Анда матур итеп кулдан язылган «ахшам кичәләре»нә чакыру кәгазьләре дә, әлеге кульязма газета һәм калын кульязма журнал нөсхәләре дә бар иде. Белүемчә, ул кульязма журналның берничә санын һәм башка язма истәлекләрнең кайберләрен соңыннан Дәүләт музеена да тапшырырга тырышкан. Кызы Надия апа сөйләвенчә, музейга исә аларның бер өлешен – күренекле шәкерте Г.Тукайның кул тамгасы булган нөсхәләрне генә алганнар. Әле XXI гасыр башында да ул тарихи ядкарьләрнең зур бер өлеше, шулай ук истәлекле фотолар Хәмит аганың кызы Надиядә сакланалар иде. Соңрак ул истәлекле әйберләрне бәлки Олы Кайбычка алып киткәннәрдер. Әлеге район үзәгендә ачылган музейда Төхфәтуллиннар нәселеннән булган шәхесләргә багышланган аерым бүлек оештырылуы хакында матбугатта хәбәрләр булды. Әмма Казанда консерватория тәмамлаган музыка белгече Надия ханым белән очрашкан елларда ул «булачак музей экспонатлары» әле анарда саклана иде. Форсаттан файдаланып, күренекле галим Гыйлем Камай җәмәгатенең дә Мотыйгулла хәзрәт нәселеннән икәнлеген әйтеп китү ярыйдыр, шәт.

1905 елның көзендә, С.-Петербургтан рәсми рөхсәт килгәнен дә көтеп тормастан, К.Мотыйгый «үз типографиясе»ндә «Фикер» газетасын, ә 1906 елның гыйнварыннан «Әлгасрел-җәдит» журналын чыгара башлый. Шул ук елның июнендә инде татарча көлке-сатира журналы «Уклар»ны нәшер итүгә керешә. Шулай итеп, берүзе татарның беренче карлыгачлары саналган өч басманы берьюлы нәшер итә. Бу басмаларның мөхәррире һәм әдәби, мәдәни, тарихи вә сәяси темаларга язучысы да үзе була. Хәмит ага истәлекләренә караганда, «Уклар» журналын чыгаруда ул, башлыча, шәкерте Тукайга таяна, аны журналның рәсми булмаган мөхәррире итеп саный.

Моның кадәр өлгерлек, зыялылык һәм инде, әлбәттә, берничә газета-журнал чыгару өчен таләп ителгән шактый ук зур матди байлык Камил әфәндегә каян килгән соң? Акча мәсьәләсендә, беренче нәүбәттә, бу төбәктә шөһрәт казанган атасы Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллинның ярдәме зур була. Тумышы белән хәзерге Кайбыч районының Кече Кайбыч авылыннан булган бу кеше, Казан артындагы Кышкар мәдрәсәсендә белем алганнан соң, кардәш казакъ халкы җирләрендә калкып чыккан яңа калага – Җаекка барып төпләнә. Гадәти вәгазьләр, «мулла бәлешләре» белән генә канәгать булмыйча, XIX гасырның җитмешенче еллар ахырында казакъ һәм татар балаларына белем бирердәй мәдрәсә ачып җибәрә. Мотыйгулла хәзрәтнең заманы өчен ярыйсы ук белемле, зыялы булганлыгын раслаучы мисаллар байтак. Зирәк кеше булган ул. Зирәк, тырыш балалар тәрбияләгән. Моның шулай икәнлеге «Мотыйгия» мәдрәсәсенең даны елдан-ел арта баруыннан да күренә. Мотыйгулла хәзрәтнең мәдрәсәләргә хас дәресләрдән тыш әдәбият укытуга җитди әһәмият биргәнлеге истәлекләрдә теркәлгән. Үзе ул урта гасырлар гарәп-фарсы шагыйрьләреннән, әдипләреннән тыш замандашлары иҗатына, бигрәк тә төрки телле әдәбиятка мөкиббән булган. Кавказ, Төркия төбәкләрендә басылып чыккан газета вә журналларны даими алдырып торган.

Г.Тукайга багышланган бер истәлектә хәзрәтнең шәкертләргә «гыйльме гаруз (шигырь төзелешен) өйрәтүе» бәян ителә. Шәкерте Г.Тукайны күз уңында

тотып хәзрәт 1914 елда: «Госманлы (төрек) китапларыннан, бәгъзән гәзитә, журналларыннан, шулай ук рус әдәбиятыннан бәгъзе нәрсәләр тәрҗемә итә башлады... Унайлык өчен йә «Мөхәммәдия», йә «Бакырган» кебек әсәрләрдән вәзен үрнәкләре ала иде»,– дип яза. Аның Тукайга карата аеруча якын мөнәсәбәте, әлбәттә, булачак шагыйрьнең атасы Мөхәммәтгариф белән Кышкар мәдрәсәсендә бергә укуына да бәйле булгандыр.

Алдарак Камил Мотыйгыйның үз басмаханәсе булган кебегрәк фикер әйтелгән инде. Ул басмаханәнең тарихы болайрак тасвирлана. Шәһәрдә «Уралец» исемендә чыгып килүче русча газета типографиясенә унлап кеше хуҗа икән. «Уртак малның иясе юк» дигәндәй, беркөнне ул басмаханәнең бөлгенлеккә төшүе мәгълүм була. К.Мотыйгый әле менә чаклы да казанлы Ш.Шәһидуллин, Оренбургта янарак кына үз басмаханәсен булдырган Ф.Кәрими кебек кешеләр белән шундый ук эшне Җаек каласында да оештыру мөмкинлеге хакында сөйләшүләр алып барган була. 1905 елның башында үзләрендәге басмаханәнең кыен хәлдә калуын ишеткәч, күпмедер акча туплап, ул «Уралец» пайчылары сафына баса. Аны шунда ук бу басмаханәнең җитәкчесе итеп сайлыйлар. Бу вакытта К.Мотыйгыйга шәһәрнең бай сәүдәгәрләре рәтендә йөргән каенатасы да, алыш-биреш белән көн күргән дус-ишләре дә булышлык итми калмаганнардыр, әлбәттә. Уртак типография дип тормый Камил мәхдүм, тиз генә Казанга барып татарча хәрефләр алдыра, хәреф җыючы ике остаңы да яллап, үзләренә алып кайта. Җаек каласында шул рәвешле татарча басмаханә бүлекчәсе – «Тәрәкъкый» барлыкка китерелә. Өстәп шунысын да әйтергә кирәк, «Уралец» газетасы журналистлары арасында да аның абруе зур була. Берара шул русча газетада мөхәррирлек вазифаларын да башкара. Ә үзенә ул вакытта әле 25 яшь тә тулмаган була (Ул 1883 елның 25 февралендә туа).

Бакчачылар телендә «иртә шыткан тинәккә кырау сугучан» дигәнрәк әйтем йөри. Безнең очракта да шулай килеп чыга. 1907 елда Камил әфәндегә үз эшләре арасындагы көнчелек, хөсетлек шаукымын да, башка төрле киртә вә каршылыкларны да «татырга» туры килә. Белгәнебезчә, шушы елдан элегрәк яуланган хөррият вә сүз иркенә дә тиздән чик-киртәләр куела башлый. Патша чиновниклары К.Мотыйгый мөхәррирлегендә чыккан газета-журналлардагы һәрбер мәкаләне, шигырьне энә күзе аша үткәреп, тикшереп торалар. Әйтик, аның чордашы һәм фикердәше, казакъ зыялысы Бәхтиҗан Каратаевның «Фикер» газетасында 1906 елның башында басылган мөрәҗәгать-мәкаләсен алар шик-шөбһәсез ничек кабул итсеннәр ди? Анда бит казакъ адвокаты үз халкына автономия шартлары тудырылуын таләп итә. Әгәр казакъ халкының таләбе үтәлмәсә, мондый хокукны безгә сугышып алырга туры киләчәк, дип белдерә[1].

Кайбер надан мулла-мәзиннәрне, кара байларны тәнкыйтьләп, чеметкәләп алгалаулар, Г.Тукайның «Сорыкортларга», «Пыяла баш» кебек шигырьләрен газета-журналларда урнаштырулар да эзсез калмый. Камил мәхдүмгә һәм аның туганнарына карата янаулар, яман гайбәтләр тарату очраклары ешая. Аның басмаханәсен ватып-җимереп ташларга, үзен кыйнап үч алырга ниятләүчеләр дә табыла. Аңа каршы бер-берсен котыртучы милләттәшләре саны айдан-айга ишәя бара.

Хәтта ки ерак Казанда нәшер ителүче «Бәянел-хак» газетасы да шушы төркемгә ияреп «өрә» башлый, явыз ниятле кискен мәкаләләр бастыра, демократик яшьләр фикеренә киң мәйдан биргән яшь мөхәррирне кяферлектә, дәһрилектә гаепли. Шундый шартларда Г.Тукай, остазын яклап, «Мөхәрриргә» исемле шигырен язып бастыра. Сүз уңаеннан Гаяз Исхакыйның башлангыч чор иҗат үрнәкләренең дә Камил мәхдүм матбагасында дөньяга чыгуын әйтеп үтәргә кирәк.

Губерна хакимияте вәкилләренең күпсанлы кисәтү һәм штрафларыннан соң, ниһаять, 1906 елның ноябрь ахырларында, алты саны нәшер ителгәч, «Уклар» журналын ябу турында карар чыгарыла. Ә тагын берничә айдан соң, кайбер милләттәшләренең «ярдәме белән» К.Мотыйгыйның «җитди» бер ялганын ачыклыйлар. Матбага ачарга рөхсәт сораган кәгазьләрендә ул туган елын дөрес күрсәтмәгән икән ләбаса. Нашир вә мөхәррир вазифасын башкару өчен 25 яшь чик булып торган. Дәүләт карарында ул шулай күрсәтелгән икән. Ә «Фикер» белән

[1] Бу хәбәр Хәмит Төхфәтулланың «Камил Мотыйгый» китабында китерелә. Казан. 1992. Л.Х.искәрм.

«Әлгасрел җәдит»не нәшер итәргә үтенеп гариза язган вакытта әле Камилгә егерме биш яшь тулмаган була. Мотыйгулла хәзрәт, улы үтенгәч, ялган белешмә бирә. Кемдер шул хакта губерна идарәсенә белдерә. Аталы-уллы Төхфәтуллиннарны судка бирәләр. Ә Камил мәхдүм губернатор карары белән наширлек вә мөхәррирлек хокукларыннан мәхрүм ителә.

Күп көч куеп барлыкка китерелгән басмаханәне һәм матбаганы харап итмәс өчен, ул һәм аның якыннары Җаек шәһәренең иң зур бае саналган Мортаза Гобәйдуллинга, әлеге «сорыкортлар»ның берсенә ялынырга мәҗбүр булалар. Бай наширлек вазифасын үз өстенә алырга ризалык бирә һәм К.Мотыйгыйның «Тәрәккъый» типографиясе дә, «Фикер» газетасы белән «Әлгасрел җәдит» журналын да берничә ай үз исеменнән исән-сау яшәтеп килә. Бу басмаларга мөхәррир итеп М.Гобәйдуллин шәһәрнең элекке Хәйрия җәмгыяте башлыгын, кульязма журналда ук Тукаебыз тарафыннан мактап телгә алынган Вәлиулла Хәмидуллинны билгели. Ләкин... кара байга, сәүдәгәргә милләтнең хөрлеге, бәйсезлеге өчен көрәш кирәкми бит, акчалата керем генә булсын. Мортаза бай да, табыш тәтемәвен, чыгымнар артуын тойгач, 1907 елның урталарында газета белән журнал чыгаруны туктата.

К.Мотыйгый, эшсез калгач һәм губернаторның «Себергә сөрү» белән янауларын ишеткәч, туган-үскән шәһәрен ташлап китәргә мәҗбүр була. Мөхәррирлек эшенә тотыну мөмкинлеге булмаганлыктан, патша җәнапләре тәхетеннән бәреп төшерелгәнче, ягъни 1917 елга чаклы тамагын җырчы-артист буларак, шәһәрдән шәһәргә йөреп туйдыра башлый. Әүвәл, бер ел чамасы, Саратов шәһәрендә яши. Саратов консерваториясе профессорлары ярдәмендә җырларга өйрәнә. Камил Мәхдүмнең тәүге тапкыр сәхнәгә чыгуы да Саратовта — «Корш» исемендәге театр бинасында була, дип яза соңыннан сеңлесе Галия Кайбицкая. Галия Төхфәтуллина-Кайбицкая белән улы Хәмит аганың матур, тынлаган саен тынлыйсы килеп торган тавышлы җырчылар булуын искә алганда, Камил Мотыйгыйның да тавышы моңлы булгандыр, мөгаен. 1928 елда Казанда, дан-шөһрәт казанган артист дуслары катнашында, аның егерме еллык артистлык юбилее зур тантана рәвешендә уздырыла. Ә 1935 елда, пенсия яшенә җитмәвенә дә карамастан, Татарстан хөкүмәте тарафыннан персональ пенсия билгеләнүен дә шул җырчы хезмәтен һәм татар матбугатының карлыгачы, беренче журналистларыннан икәнлеген дә искә алу нәтиҗәсе булгандыр дип уйларга кирәк. Бу вакытта улы Хәмит ага Мәскәүдә яши, яңарак ачылган татар опера студиясенең җитәкчесе дә, арияләр башкарырга өйрәнүчесе дә була. (Туганы Галия Кайбицкая да шунда опера җырчысы булырга әзерләнә.)

Әмма Камил Мотыйгыйның язмышы барыбер бик аяныч тәмамлана. 1937 елның ахырында сөекле улы Хәмитне, «мулла онығы»н Мәскәүдә кулга алалар. Элек үзенә тантаналы рәвештә билгеләнгән пенсиясен дә түләми башлыйлар. Соңгы елларда иҗат ителгән өч сәхнә әсәреннән берсе генә басылып чыга. Танылган җырчы, татарның вакытлы матбугатына беренчеләрдән юл ачкан олы яшьтәге кеше яшәү чыганакларыннан мәхрүм ителә. Ул һәм карчыгы, элекке «бай сәүдәгәр кызы» авыр хәлдә калалар. Шушы хурлыкларга түзә алмыйча, Камил Мотыйгый 1941 елның 26 гыйнварында үзенә үзе кул сала. Бу вакытта алар хәзерге опера театры бинасы артындагы ике катлы искерәк йортларның берсендә яшиләр. Аның үле гәүдәсен шул йортның чормасыннан табып алалар.

Улы Хәмит Төхфәтуллинның язмышы исә чак кына үзгәрәк: унҗиде елдан соң ул Казанга әйләнеп кайта, аклана. Дөрес, сугыш елларында инде ул Казанга бер кайткан була. Опера театрына җырчы артист буларак кабул да ителә. Әмма 1948 елда аны яңадан Норильск лагерына алып китәләр һәм ул илленче еллар уртасында гына бөтенләйгә котылып кайта. Соңлабрак булса да ата-бабасының мирасын барлауга керешә. Музейларга тапшырылачак газета, журнал нөсхәләренең байтагы аның тырышлыгы белән тупланган. Бәлкем әле атасының әдәби иҗат җимешләрен дә барлый башлаган булгандыр. Хәтерем ялгышмаса, Хәмит ага Төхфәтуллин сиксәненче еллар башында вафат булды. Үләре алдыннан аны телевизордан да күрсәтеп алганнар иде. Ул анда, яткан килеш бер кулын өскә чөя-чөя, көр тавыш белән опералардан арияләр башкарды. Әлеге тарихи күренеш телестудия архивында бәлки сакланадыр әле...

Алдарак без К.Мотыйгый өч сәхнә әсәре иҗат иткән дип белдергән идек. Егерменче-утызынчы елларда язылган бу әсәрләрдән «Тозак» исемлесе аерым китап буларак басылып чыга, «Шайтан өне» белән «Көрәш» пьесалары кульязма килеш кала. Аның әдәбият өлкәсендәге эшчәнлеге Төркиядә укып кайткач та башланган. Күпсанлы көндәлек мәкалә, очерк, фельетоннары үзе нәшер иткән газета-журналларда чыкканлыкка шик белдерүчеләр юктыр, мөгаен. «Әлгасрел җәдит» журналында аның Төркиядән кайткач язган күләмле «Мисырга сәяхәт» кульязмасы, кайбер хикәяләре укучыларына житкерелә. 1903 елда С.-Петербург каласында, кырымлы И.Бораганский басмаханәсендә «Бәхетле Мәрьям» романы, 1906 елда «Мөнкарыз» исемле хикәяләр тупламасы басылып чыга. Үз мөхәррирлегендә чыккан газета-журналлар тыелгач та якын дусты Гали Мусин исеменнән нәшер ителгән «Яна тормыш» газетасында (1907 – 1909) аның «Төш күрү», «Төш юрау» исемендә сәяси памфлетлары басылганлыгы хакында да Хәмит ага хәбәр итә.

Шушы мисаллар җирлегендә К.Мотыйгыйның XX гасыр башында ярыйсы ук актив язучы булганлыгын да танырга хаклыбыз. Әмма әлегә аның әдәби мирасы нигәдер барланмаган. Г.Тукай һәм Г.Ибраһимов томнарында урын алган искәрмәләрдәге мәгълүматтан башка, XX гасыр әдәбиятына багышланган бер генә хезмәттә дә язучы Камил Мотыйгыйның исеме һәм әдәби хезмәтләре искә алынмый диярлек. Ни өчен алай эшләнә? Ул әсәрләрнең сыйнфый көрәшне чагылдырмавы сәбәплеме? Әллә соң әдәби эшләнешләре ягыннан йомшаграк булганлыктанмы? Әдәбият сөюче укучы буларак минем, мәсәлән, боларны бик тә беләсем килә. Театр өлкәсендә Ильяс Кудашев-Ашказарский, С.Волжская, Г.Кариев, К.Тинчурин, музыкада С.Сәйдәш, С.Габәши беренче карлыгачлар булган булса, вакытлы матбугатны тудыручы Һади Максуди, Фатыйх Кәрими, Йосыф Акчура, Г.Исхакый һәм бертуган Рәмиевләр белән бер сафка басардай шәхес итеп күзаллыйм Камил Мотыйгый-Төхфәтуллинны. Бу хезмәттә, патша хөкүмәте төшерелгәч, аның берничә яңа газетага нигез салуы да барланмады. Алай да 1917 елның көзендә С.-Петербургта чыга башлаган тәүге «Ярлы халык» турында Г.Ибраһимовның бер хезмәтендәге кыска гына җөмләне китерү урынлы булыр: «Мәркәз мөселман комиссариаты төзелде, «Ярлы халык»ны бетереп, зур, житди бер газета кую хакында ризалык-фикер алынды», – дип яза ул. Димәк, «житди бер газета»ның – «Чулпан»ның нигезен Камил әфәнде Петроград Советы карамагындагы Мөселман комитеты исеменнән нәшер иткән әнә шул газета тәшкил иткән, ләбаса. 1917 елдан соң К.Мотыйгый Самарада һәм кабат Җаек шәһәрендә тагын берничә газетага җан өргән.

Камил Мотыйгый исеме аталгач, никтер күз алдына Чыңгыз Айтматовның «Беренче мөгаллим» әсәрендәге садә, эчкерсез күңелле, тиктормас җанлы баш каһарман Дүшән килеп баса. Ул да бит, авылдашларының дөньяга күзен ачыйм, аң-белемен күтәрим дип, үз-үзен аямый кон-төн чаба, төрле кыерсытуларга дучар була, хәтәр хәлләрдә кала. Әмма үз юлыннан тайпылмый, үз җилкәсенә алган «йөген» ярты юлда ташлап калдырмый. Тормыш авырлыкларына бирешмәстән, тоткан юлын дәвам иттерә. Бөек Тукаебызның остазы Камил Мотыйгый да шундый зат булган. XX гасыр башында беренчеләрдән булып газета-журналлар нәшер итәргә керешкән. Саратов консерваториясе профессорлары ярдәмендә җыр сәнгатен үзләштереп, егерме елдан артыграк гомерен татар сәхнәсенә багышлаган шәхес тә ул. Тукайның беренче остазларыннан булган милли җанлы Камил Мотыйгыйның халкыбыз мәдәнияте тарихында үз урыны, мактаулы урыны бар.

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН**

## Фәнис Яруллин

# ХӘТЕР ТӨПЛӘРЕНДӘ УТЛЫ КҮМЕР

КӨНДӘЛЕКЛӘР

**2001**

**15 март.** «Мәхәббәт упкыны»н өченче кат карап чыктым. Шактый күләмле әсәр. Кая бирермен, белмим әле. Һич югы китапта чыгар, әсәр бик укыла торган. Яшьләр турында. Бездә яшьләр темасын минем кадәр белгән язучы юктыр да. Гомумән, язучылар яшьләр психологиясен белми. Миңа бит бик күп яшьләр килә. Интим мөнәсәбәтләре хакында да сөйлиләр. Хәзер егетләр белән кызларның йоклап йөрүе гадәти хәл санала. Егет белән кыз икесе бер фатирда торалар да: «Бу безнең гражданский брак», — диләр. Тормышта конфликтлар килеп чыкса, кыз бер фатирга, егет — икенчесенә күчә. Кызлар белән йоклап йөрү безнең заманда да юк түгел иде. Элек бу нәрсә яшертенрәк эшләнсә, хәзер ачыктан-ачык эшләнә. Кайбер ата-аналар кызлары бер генә егет белән йөрсен өчен егетне үз өйләренә чакырып, бергә йоклаталар.

**17 март.** Тимер ишек куйдырырбыз дигән идек. Бүген анда шалтыраттым. Дүшәмбе килеп үлчәмен алып китәргә булдылар. Ул ишеккә йозак кирәк әле.

Без Казанда яши башлаган чорларда мин көне буе ишекне бикләтми идем. Өйдә берүзем калган вакытларда кеше килсә керә алсын өчен. Ишек күпвакыт төнлә дә ачык, бикләргә онытылып кала иде. Квартир караклары миңгә бер генә булгандыр.

1963 елда безгә Казанда бер бүлмәле фатир биргәч, шатлыгыбыз эчебезгә сыймаган иде. Язучылар союзы йөз сум акча да биргәч, әни тизрәк кибеткә чапты. Ул йөз сумга бер тимер карават, бер өстәл һәм ике урындык алдык. Минем 50 сум пенсиягә бер җыйнак кына китап шкафы алдык. Үземнең шәхси китапханәмне булдыру күптәнге хыялым иде. Тагын бер карават алсак, шуннан артык берни кирәк булмас кебек иде. Аппетит үсә торды. Ләкин моны комсызлык дип булмый. Караватка матрасы, мендәре, ябынырга одеялы, юрганы; ашарга пешерергә кәстрүле, ашны бүлеп ашарга тәлинкә-кашыклар кирәк. Яшәгән саен таләпләр арта...

**18 март.** Кичә КГУның журналистика факультетында укучы ике кыз килде. Саба кызлары. 4нче курста укыйлар. Берсе Эльмира, икенчесе Рәсимә, Эльмирасы чибәр. Ансына күзем төште. Үптерде дә. Бүген шул тәэсирләр белән «Яз бүләге» дигән шигырь яздым.

*Тәрәзәмнән бер кош очып керде*
*Томшыгына чәчәк кыстырып,*

— дигән юллар үземә ошады.

Иҗат кызык әйбер инде. Аны учакка ошатырга мөмкин. Күңел бакчасындагы бөтен чүп-чарларны гел өеп яндыра торасың, чүп-чар җыела тора. Бер учак сүнсә, икенчесе кабына.

**29 март.** Өченче көн Ә.Хуҗиәхмәтов килгән иде. Мирсәет Сөнгатуллин турында мәкалә язмассыңмы, ди. Аны Г.Тукай премиясенә тәкъдим иткәннәр. М.Сөнгатуллинның тавышы көчле. Теләсә-нинди залда микрофонсыз җырласа

*Ахыры. Башы 2011 елның 1нче санында.*

да, бөтен кеше ишетәчәк. Билгеле, тавыш көчлелеге җырчы өчен беренче урында тормый. Халыкчан моң, менә шушы моңны күңел урамнарында уратып синең янына китереп салу осталыгы бар М.Сөнгатуллинда. Тавышын бераз түбәнрәк төшереп җырлаганда аны Илһам Шакировмы әллә бу дип куясың. Мондый тавышлы җырчылар күбрәк булса, көнлекче җырчыларга сәхнә тараер иде.

**6 апрель.** «Восточный экспресс» газетасының бүгенге санында Резидә Даутованың Аяз Гыйләҗев белән әңгәмәсе бирелгән. Анда Аяз 20нче гасырның иң күренекле ун кешесе исемлегенә үзен дә керткән. Татар әдәбиятында минем кебек прозаик юк дигән. Шунсы кызык: бер 15-16 еллар элек бездә Минзәлә театры режиссеры Фаил Ибраһимов һәм тагын берничә кеше барында пьесалар турында сүз чыккач, бездә минем кебек драматург юк, дигән иде. Шунда мин аңа: «Сез яхшы прозаик, ләкин драматург түгел», — дигән идем. Ул бик үпкәләде, әлбәттә. Ә менә бүгенге интервьюсында, кырык пьеса язсам да, үземне драматург дип санамыйм, дигән. Димәк, бик озаклап булса да, минем белән килешкән. Билгеле, тәнкыйтьне беребез дә, шул исәптән мин дә, шатланып кабул итми. Ләкин ул эчне кимерә-кимерә әкрен генә үз эшен эшли. Рухы белән бик түбәннәр генә һәр тәнкыйть сүзенә чәчрәп чыга.

**14 апрель.** Кичә «Моя газета»дан Владимир Гаранин дигән кеше интервью алып китте. Кич белән Гөлчәчәк апа белән Әхмәт абый Галиевләр килде. Алар белән Гөлфания Фатыйховна дигән врач та бар иде. Ул 1959 елда мине Баулы больницасына кайтарганда янарак кына хирург булып эшли башлаган кеше. 41 елдан соң күрешү. Ул хәзер рак белән авыручы кешеләрне дәвалый. Катлаулы операцияләр ясый. Медицина фәннәре кандидаты. Нинди түрәләрне дәвалый, ә үзе бер бүлмәле фатирда яши. Ришвәт алмагач, фатирын да ремонтлата алмый.

**26 апрель.** Сәүиягә операция ясадылар. Нурсөя аның янына барганда Сәүия аңына килгән булган инде. Миңа Нурсөя бер тәүлек торырлык ашарга-эчәргә калдырып китте. Кичкә Гөлүсә безгә куна килергә тиеш. Нурсөя төнне Сәүия янында уздырыр инде. Хәзер без бер Нурсөягә ике бала булдык. Ул аяктан егылса, безгә капут.

**28 апрель.** Сәүиягә операцияне Алексей Кудрявцев дигән кеше ясады. Аяк сеңере юанайган, сырланган ди. Шул авырттырган булган. Хәзер шуны артроскоп дигән аппарат аша карап, сеңерен нечкәрткәнче кырганнар һәм тезне бик каты итеп бөкәннәр. Якуб Хәмзиевич лангетка салдырткан иде, бусы алдыртып ташлаткан. Тезең катмасын, хәрәкәтләндереп тор, дигән. Врачларның да төрлесе төрлечә эшли шул. Кайсына ышанырга белмисең.

**10 май.** Быел бакчага барган юк әле. Сәүиягә операция ясаткач, ул үзе генә оекбаш, чалбар ише нәрсәләр дә кия алмый. Кая барса да киендерергә, кайткач чишендерергә кирәк. Шуңа күрә Нурсөя беркая чыга алмый.

**31 май.** «Казан утлары»нда (4-5 саннар) Фоат Садриевның «Бәхетсезләр бәхете» дигән романын укып яттым. Әле яртысы гына басылган. Әйбәт укыла торган әсәр. Бу егет соңгы елларда нык кына үсте...

**21 июль.** Өченче көн М.Шабаев 50 сум акча алып чыгып китте. Куллары дер-дер калтырый. Әйбәт кеше иде бит. Безнең авылга 62нче елда килгән вакытта кызыл аракы да эчми иде...

**2 август.** Бүген врач чакырткан идек, үзебезнең Семенычева ялда икән, яңа врач килгән. Наталья Тимофеевна исемле сары чәчле бер маржа. Мин кулмәксез ята идем, тәгәрәпләр китә язды. «Что с вами случилось?» — ди. «Ничего не случилось», — дим. Сөйләшә торгач, аның аптыравы аңлашылды. Ул минем ябыклыктан курыккан икән. «Это у вас нормальное состояние?» — ди. «Да, сорок лет в таком состоянии», — дип өр-яңадан шаккаттырдым бу маржаны. Эчне баскалап карады, кан басымын үлчәде. Минем дарулар беткән иде, шуңа күрә чакырттым дип кенә тынычландырдым. Шушы хәлдә ничек яшәп була икән дип бик аптырады, мескен. Бу врачлар кеше организмының мөмкинлеген, аның эчке ресурсларын белеп бетерми шул.

**7 август.** Кичә һәм бүген берәр шигырь яздым. Авылга китәргә иде исәп, ләкин безнең йортка караклар ияләште, берничә фатирны бастылар инде. Сигнализация бар барын, ләкин безнең телефон кабельләре коридордан узган. Аларны кисеп ату бер секундлык эш.

**22 август.** Баулыда да шул йокысызлык интектерә мине. Унда ятсак та,

уникедә ятсак та дүртенче яртыларда сикереп торам. Таза чакта да йокы начар иде. Кызлар куып уникегә кадәр йөреләә. Кайтып яткач та йоклап китеп булмый. Озак боргаланып ятам. «Көндез йоклаштырып аласыздыр», — диләр. Көндез мин үлгәч кенә йокларлмын инде. Армиядә хезмәт иткәндә дә йоклый алмый идем. Шул йокысызлыгым белән Нурсөяне интектереп бетерәм. Мин йокламыйча тик кенә ята алсам, ул интекмәс иде. Мине бит бер яктан икенче якка гел борып яткырырга кирәк. Аннары шунсы да бар: йокыдан тору белән мине юындырырга, ашатырга, эчертергә кирәк. Аһ, бу йокысызлык минем үземне дә хәлсезләндереп бетерә.

**11 сентябрь.** Кичә Кызылъяр укытучылары (пенсиядәге) килгән иде. Кайчандыр безне укыткан Роза апа, мин укыганда мәктәптә завуч булган Фәһимә апа һәм безнең авылда бераз соңрак укыта башлаган Нәкыя апа.

Теге яки бу язучының иҗатын ныклап белмиләр (Фәһимә ападан калганнары), шуна күрә сүз бүтән темага күчте. Нәкыя апа:

— Мин үзем мәхәббәтне, ягъни кемне яратуны башкаларга сөйләү кирәк түгел дип саныйм. Мәхәббәт изге нәрсә ул, — диде. — Әгътәскә мин дөнья көтә алырдай кеше булганга гына чыктым. Яратып түгел, — ди.

Китә бәхәс. Кем кемне яраткан. Кем ничә кат иргә чыккан. Һәм башкалар, һәм башкалар.

Роза апа:

— Гомер үткәч, кемне яратуыңны яшереп маташасы юк, — дип, кайчандыр Мәгъсүм Латыйфуллинны яратуын, М.Латыйфуллинның үзенә багышлап җырлар язуын әйтте.

**13 сентябрь.** Баулы иң чуар милләтле шәһәр.

Телнең чуарлануы 1946 елда нефть чыга башлагач булды. Төрле яктан төрле милләт кешеләре килеп тулды. Андый вакытта караклар да йоклап ятмый: кемнең сарыгын, кемнең сыерын урлап суя башладылар. СССР таркалгач, бу караклык тагын да ныграк җәелде.

**23 сентябрь.** Кичә Әлмәт больницасыннан Ринат Галиев шалтыратты. Иртәгә безгә киләм дигән көнне аңа инфаркт булган. Биш көннән соң аякка баскан һәм килә алмавы өчен гафу үтенеп шалтырата. Ничек кенә әйтмә, бик эчке культуралы, чын зыялы кеше. Андый дәрәҗәле башка кеше булса шундый хәлдә мондый пүчтәк вәгъдәләрне исенә алып торыр идеме?

**29 сентябрь.** М.Җәлил исемендәге залда әйбәт кенә очрашу булды. Зал тулы ук түгел иде. Кандыздан Кызылъярга килгән теге балалар монда да килеп шул әсәрләрне укыдылар. Бик сәнгатьле укыйлар. Алып баручы хатын (исеме Сиринә иде бугай) шулай ук Кандыздан иде. Җырлар, шигырьләр һәм котлаулар аралашып барды. Гадәти кичә инде.

Кичәдә бер кызык хәл булып алды: сәхнәгә залдан бер ханым күтәрелде дә минем турыда сөйли башлады. Мин 9нчы класста, Фәнис 8нче класста укыган чакта без Кызылъярга кунакка барган идек, ди. Шунда Фәнис клубның ишегенә кулларын җәеп аркылы басты да, безне чыгармый, кайсыбызныдыр тотып каласы килә иде бугай, ди. Бәләкәй генә, бик аккуратно киенеп йөри иде, ди. Кыскасы, күп сөйләде. Ләкин үзенең кем икәнен әйтмәде. «Таныйсыңмы?» — диде. Аның сөйләве буенча мин аны аңладым. Һәм: «Сез Лена бит, — дидем. — Тик сез бер детальне искә төшерергә онытгыгыз — без бит ул көнне сезнең белән бер кич кунган идек», — дидем. Бу хатын кып-кызыл булды. «Монда залда минем ирем утыра. Андый хәл булмады бит», — диде. Билгеле, миңа бу эпизодны искә төшереп, аны кызартырга кирәк булмагандыр. Ләкин әйткән сүз — аткан ук. Без бит аның белән начар итеп кунмадык. Хәзер генә ул кызлар белән куныны ир белән хатын булу мөнәсәбәтенә тиңләштерәләр.

**7 ноябрь.** Күзгә бал салдыра башладым. 5 ноябрьдән. Ни күзлексез, ни күзлек белән укып булмый. Газета-журналларны өстән-өстән генә карап ыргытам.

**12 декабрь.** Иҗатчы каршылыклар аша, кыенлыклар аша үз-үзенә килә. Әгәр дә минем нинди дер әсәрләремне укуга яки исемне атауга минем үземне күз алдына китермиләр икән, димәк, мин шәхес буларак җитлекмәгәнмен. Фәнис Яруллин диюгә минем әсәрләрне, андагы геройларны күз алдына китерә алмасалар да

шулай дияргә кала. Ә исем астына халык шагыйре, Тукай премиясе лауреаты дигән әйберләр алар безнең күңел өчен генә. Халыкка алар берни бирми. Фәнис Яруллин икәнсең, димәк син яхшы язарга тиешсең. Бары шул таләп.

**2002**

**25 гыйнвар.** Өченче көн «Мәгариф» нәшриятыннан «Урман кызы»н китерделәр. 2 мең данә. 30 мең түләдем. Бик кыйммәткә төшмәде. Мөдәррис Вәлиев егетлек күрсәтте инде. НДС налогы да түләтмәде.

**28 июнь.** Шушы йокысызлыгым белән Нурсөяне вакытсыз үтерәм инде. Бүген дә сәгать өчтә торып утырдым. Кофе кайнаттырып, бер чынаяк кофе эчтем. Нурсөя кире яткан булды булуын. Ләкин мин кәгазьләр белән кыштыр-мыштыр маташкач, рәтләп йоклый алмый инде ул.

**2003**

**23 гыйнвар.** Беркөнне (20сендә) больницага «Идел»дән килделәр. Журналның 1нче санына әңгәмә һәм минем шигырьләрне әзерли. Шәп егет! Честный кеше.

**10 февраль.** 65 яшьлек бәйрәмем белән котлаучы иң беренче «Идел» булгандыр, мөгаен. Журналның 1нче санында минем белән әңгәмә һәм минем шигырьләр чыккан. Алар туган көнгә өлгерсен дип ашыктырып чыгарганнар һәм аны табадан төшүгә үк китереп тә житкерделәр. Әйбәт кешенең әйбәт эше.

Хәтта телеграммалар өләшеп йөрүче һәм подъезд жыештыручы хатыннар да чәчәк кертеп, котлап чыгып киттеләр. Бер белмәгән кешеләрнең котлавы шәп бит. Димәк, мине укыйлар. Сарманнан, Чистайдан, Яшел Үзәннән, Октябрьскидан, Азнакайдан, Баулыдан һәм тагын әллә кайлардан шалтыраттылар.

**25 июль.** Бүген Башкортстанның Төрекмән авылыннан кунаклар килде. Кайчандыр, ягъни армиягә кадәр йөргән Флера үзенең ире, онычкасы һәм бер иптәш хатыны белән килгән. Ире Зиннур исемле. 1937нче елгы. Флера бөтенләй кайчандыр мин йөргән Флерага охшамаган. Күзендә очкын юк. Сөйләшми. Чыгып киткәндә ире: «Икегез генә калып бераз сөйләшеп утырыгыз», — дип, безне Флера белән генә калдырды. Нурсөя дә чыгып китте. Ә бу таш курчак кебек утыра. «Яшь чакларны исенә төшерәсеңме соң?» — дим. «Нәрсәсен төшерәсең инде аның», — ди. «Мине госпитальдән Урыссу больницасына кайтаргач, жиңгән белән килеп, миңа чиккән кулъяулык калдырган идең», — дим. «Аның нәрсәсен саклыйсың инде», — ди. Кыскасы, бөтенләй сүнгән бу. «Нишләп болай сүндең соң син?» — дип сорадым аптырап. «Син армиядән шушылай булып кайткач ук сүндем мин. Кабызырлык кеше очрамады. Беренче тәкъдим ясаучыга кияүгә чыктым. Менә шул».

Ул тынып калды. Мин дә аңа карап тордым да: «Бар инде, алайса, ирең әллә нәрсә уйлар», — дип чыгарып жибәрдем.

Шундый моңсу гына очрашу булды. Ике кызы, өч оныгы бар икән. Оныгы бик тиз арада табын әзерләшә башлады. Бик пөхтә. Соңыннан өстәлдәге әйберләрне жыеп, өстәлне сөртеп куйды. Әле аңа күп булса 10-11 яшьләр тирәседер.

Болар белән бергә килгән хатын ут инде. Әүфә исемле. Шигырьләр бик ярата икән. Аңа «Шәфәкъ вакыты» дигән китапны, Флерага «Урман кызы»н бүләк иттем. Анда «Якты сагыш» дигән хикәядә Флера белән безнең мөнәсәбәтләр юмор аша чагылдырылган иде. «Монда сиңа багышланган хикәя дә бар, укырсың», — дидем. Ул ни «а», ни «б» димичә китапны алды. Иҗатка карата бернинди кызыксыну юк. «Хәлең ничек соң?» дигән сорау гына да бирмичә китеп барды.

**31 июль.** ...Хәзерге «Татнефть» житәкчеләре моның әһәмиятен аңлап бетермиләр бугай. Р.Галиевнең эшләгән эшләрен әкрен-әкрен юкка чыгара бару нияте ята кебек монда. Р.Галиев Мәскәү белән көрәшә-көрәшә «Татнефть»не банкротлыктан саклап калды. Нефтьнең бер барреле 7 долларга төшкән чакта да бер эшчене дә эштән чыгармады. Хәзер нефть бәясе 30 доллар тора һәм берничә ел рәттән штатларны кыскарту бара. Байлык аерым кешеләр кулына туплана. Шәхси компанияләр ачу нефть чыгаруның күләмен арттырса да, урлашу шактый. Күп кенә шәхси компанияләрнең житәкчеләре — НГДУ начальникларының малайлары. Шулай булгач, дәүләт чыгарган нефтьне шәхси компанияләргә перекачать итү авыр эш түгел. Караклар да тотылмый.

**21 август.** 19 августта Баулыдан кайттык. Кайтыр алдыннан бик каты чирләп, бер атна уколлар алган идем. Шуның нәтиҗәсе булдымы, кайтып житеп өйгә алып кергәндә анны җуйганмын. Лифтка керүгә кап-караңгы булып киткән иде, өйгә кергәннәрне хәтерләмим. Мин анга килгәндә Сәүия «Скорый»га шалтырата, Нурсөя мине күтәреп тора иде. «Мин кайда, нишләп мине күтәреп торасыз?» — дигән сораулар белән анга килдем.

**8 октябрь.** Бүген иртәнге сәгать 6да, әле без иртәнге чәй дә эчмәгән идек, электр щитлары замыкать итеп, пожар чыкты. Ун машина килде. Ике сәгатьләп маташтылар. Әгәр ут фатирларга үрләп, кешеләрне урамга чыгара башласалар нишләрбез дип куркып тордык. Мине анда урамга чыгарып җиргә яткырып куеп булмый. Ярый әле ут өйләргә үрләмәде. Шулай да утсыз калдык. Аш та пешереп булмый, чәй кайнатыр мөмкинчелек тә юк. Иртән Нурсөя термос тотып күрше йорттагы бер танышларда чәй кайнатып чыкты. Ут берничә көн булмаса, суыткычтагы ашамлыклар бозылып бетәр инде. Ут бөтен йортта юк. Телефоннар эшләми. Кесә телефоныннан кайбер кешеләргә шалтыраттым. Ләкин аның аккумуляторына да ут кирәк. Дөнья утсыз, сусыз, һавасыз тора алмый шул.

**20 октябрь.** Ун көнгә цивилизациядән мәхрүм калдык...

Бүген Нурсөянең туган көне. Иртәдән бирле пешеренә, ләкин пешергән ризыкларын үзебезгә атна буе ашарга туры килер. Безнең туган көннәрне кеше белми дә. Гомумән, Нурсөя үзен күрсәтергә, мактатырга яратмый. Телевидение килсә дә, берәр эш табып, күләгәдәрәк калырга тырыша.

## 2004

**7 февраль.** Нурислам Хәбипов Баулының хакимият башлыгы булып эшли башлаганнан бирле туган көнгә күчтәнәч җибәрми калганы юк.

**17 февраль.** Туган көн шаукымы һаман бетеп житми. Йә кемнәрдер шалтырата, йә килеп чыгалар.

Президент аппараты җитәкчесе Ә.Гобәйдуллин туган көн белән котлап миңа хат җибәргән. Ләкин хатны нишләптер өй адресы белән түгел, Язучылар союзына җибәргәннәр. Союзның секретаре бер кыз, Фәнис абый, сезгә президент аппаратыннан хат бар, килеп алыгыз, ди.

Нурсөя авырый иде, мин үзем бара алмыйм бит инде. Хатны өйгә китерергә куштым. «Безнең курьер юк, кеше өенә хат илтеп йөртергә», — ди бу. «Алайса председательнең машинасы китерсен», — дидем. Ләкин беркем дә китермәде. Туган көн белән котлап өйгә килү яки телефоннан шалтырату дигәнне Язучылар союзы гомумән белми инде. Минем бик каты ачу килде. Президент аппаратына шалтыратып, башта хат өчен рәхмәт әйттем. Аннары хатны өйгә китерүче юк бит тәки, дидем. «Без ул хатны махсус Язучылар союзына җибәргән идек. Хатны китереп, сезне котлап китсеннәр дип», — диделәр. Аннары алар Союзга шалтыратып, хатны өйгә китерергә кушканнар. Тегенең килергә йөрәге җитмәгән, замы Шаһинур Мостафинны җибәргән.

Шагыйрь Гакыйль Сәгыйревнең дә 15 февральдә туган көне. Ул Дмитровградта яши. Әнисе дә инсульт белән ята икән. Үзе хәзер авызга ручка кабып та яза алмыйм ди. Гакыйльгә шалтыратып, бер ярты сәгатьләп сөйләштек. Союздан ана да шалтыратмаганнар. Нинди дә булса матди ярдәм күрсәтү турында әйткән дә юк инде. Былтыр мин инсульт белән ике атна больницада яттым. Язучылардан беркем дә килмәде.

**4 апрель.** «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә барырмын дип уйламаган идем. 5 елдан бирле чакырып йөриләр инде. Ниһаять, кичә тәвәккәлләп шунда бардык. Шәкертләр һәм укытучылар белән очраштык. Очрашуны намаз укый торган залга әзерләгәннәр иде.

Барып туктауга ук бинаның шактый ук иске кыяфәте эчне пошырды. Бинага «Монда 1902-05 елларда М.Гафури укыган», — дип мемориаль такта куелган. Мәдрәсә 1882 елда ачылып, анда Фатих Әмирхан һәм башка күренекле шәхесләр дә укыган. Нигә Ф.Әмирханны язмаска. Ул бит М.Гафуридан күпкә көчлерәк. Ә М.Гафури: «Юктырсың ла, Алла?» — дип, бу бөек затның барлыгына шик белдергән кеше... Шундый данлыклы мәдрәсәне мескен кыяфәттә күрү йөрәкне әрнетте, әлбәттә. Узган ел 155нче мәктәптә булган идем. Ялт итеп тора... Югыйсә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе дә мәктәп, мәктәп кенә дә түгел, югары уку йорты ролен үти. Анда күп төрле фәннәр

укытыла. Шәкертләр дәүләт университетларындагы студентлардан белем ягыннан калышырлык түгел. Хәтта күбрәк тә беләләрдер әле. Кызыксынучаннар. Җырлар да җырлыйлар, шигырьләр дә сөйлиләр, сораулар да бирәләр...

**14 май.** Без бик катлаулы яшибез, ахры. Безнен бервакытта да эшебез бетми. Нурсөя бер яклап чаба, Сәүия икенче яклап, мин телефоннан «эрерәк балыклар» белән сөйләшәм. Шунсыз дөнья бармый.

5 томлык сайланма әсәрләрем чыгып ята. Өч томы чыкты инде. Дөньяда ин матурлар — китап белән кызлардыр. Яна чыккан китаптан бер өч көн күзне алып булмый. «Боларны бит мин яздым», — дигән горурлык та түгел бу. Моның без белеп бетермәгән сере бардыр, күрәсең.

**8 июль.** Быел инфляция котыра. Былтыр 100 сумга алган әйберне быел 200-300 сумга алырга кирәк. Үзләре инфляция елына 8-10 проценттан артмаска тиеш диләр.

Татарстан хәзер үз байлыгына үзе хуҗа түгел. Шәймиев тешсезләнде. Парламентта оппозиция юк. Татар конгрессы кунаклар җыеп, шуларны ашатып-эчертеп йөрүдән башка эш эшләми кебек. Милләтнең сулышы кысылганнан-кысыла бара. Халыкка аракы белән сыра житәрлек булса, башкасын таләп итми.

**10 октябрь.** «Казан утлары»ның 8-9 саннарында Равил Фәйзуллинның «Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» дигән зур күләмле язмасы чыкты. Язучылар союзының 70 еллык юбилеена багышланган язма-эссе. Бик дәлилләп, документларга, фоторәсемнәргә таянып язылган... Гомумән, Р.Фәйзуллинның бу язмасы бер фәнни диссертациялек әсәр. Әгәр Р.Фәйзуллин шагыйрь булмаса, яхшы публицист була алыр иде.

**21 октябрь.** Кичә кичке 8 тулып 10 минутлар үткәч утны сүндереп йокларга яткан идек, тимер ишеккә нәрсә беләндер шарт-шорт бәргән тавышлар ишетелә башлады. «Ни бар икән?» — дип Нурсөяне карарга чыгардым.Ә анда электр щиты янып ята икән. Атыш тавышлары чыгарып электр чыбыклары яна. Халыклар документларын, акчаларын алып өйләреннән чыгып кача башлады. Нурсөя балкон тәрәзәсен ачып: «У кого есть сотовый телефон, позовите пожарников», — дип кычкыра. Чөнки өйдәге телефоннар эшләми, чыбыклар бит шул щитка тоташкан. Өйгә әшәке төтен исе тулды, сулап булмый башлады. Нурсөя бөтен тәрәзәләрне ачып ташлады. Пожарниклар килгәч: «У меня там человек прикован к постели, надо его вынести», — диюгә карамастан, беркем дә кермәде. Ярый инде янгын өйгә үк үтеп житмәде. Сүндерделәр. Биш машина килгән иде. Өйдә ут булмагач, чәй кайнатып эчеп тә булмый. Иртән торгач Нурсөя кемдә ашарга әзерләргә мөмкин булыр икән дип кәстрүлләрен-термосларын күтәреп чыгып китте. 2-3 сәгатьтән кайтты. Ашадык, эчтек. Инде менә термоста чәй дә бетеп килә, ә ут өч-дүрт көнсез булмаячак әле диләр. Суыткыч тулы ит, тышта 5-6 градус җылы. Тиздән сүнгәнгә бер тәүлек була. Ит эри башлады. Көн тудымы бер яманлык. Совет властен сүксәк тә, ул чорда тәртип каты иде. Хәзер беркем беркемне тыңламый. Кая барып торырга? Кешеләргә суыткычлар күтәреп барып булмый бит әле. Телефонны эшләсәләр, кая да булса шалтыратыр идең, ансы да юк. Безнең бу Мусин урамындагы 14 катлы йортта газ юк. Бөтен нәрсә электрга көйләнгән. Ә щитларга сузылган кабельнең чыбыклары нечкә. Мондый зур көчәнешкә көйләнмәгән.

**25 октябрь.** Өч тәүлектән соң ут бирделәр, ләкин әле бөтенләй эшләп бетерә алмыйлар. Электр розеткалары кыза. Бүген диспетчер аша электрик чакырткан идем, монтер килгәндә үк, 25 сум түлисез, дип квитанциясен язып килгән. Бер розетканы карады, звонокны тоташтырмады, коридордагы лампочка да янмаган килеш калды. Антенщик чакырттык, иртәгә килер, диделәр.

**31 декабрь.**

*Менә тагын бер ел үтеп китте,*
*Очып кына уза бу еллар.*
*Сафларыбыз сирәгәя бара,*
*Арабыздан китте Ю.Илдар.*

Әйе, Илдар Юзеев очышта үлгән кош кебек, эшләп, хәтта үзеннән яшьләрне көнләштерерлек дәрәҗәдә эшләп йөргән чагында инфарктан үлеп китте. Зур язучыларны югалттык инде. Нурихан Фәттах, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Гамил Афзалларны искә алырга гына калды. Һәрберсенең нинди дер кимчелекле якларын

белсәң дә, алар зур шәхесләр иде. Әдәбият әкрен-әкрен сыеклана. Дөрес, бушлык артык нык сизелми. Факил Әмәк, Фоат Садриев кебекләр бар әле бездә. Ләкин, зур исәпкә салып уйлансаң, бу язучылар, трилогияләр язуга карамастан, халык өчен зур шәхес булып өлгермәгән әле. Илдар Юзеевнең беренче поэмасы — «Таныш моңнар»ыннан ук укучы аны күз уңыннан ычкындырмады. Шәриф Хөсәенов та студент чакта ук «Профессор кияве» белән Камал театрына менде. Аларның шәхес булып тиз формалашуына совет чорының каршылыклары да ярдәм иткәндер, бәлки.

Бер төрле система озаграк яшәгән саен анда каршылыклар да күбәя. Язучы иҗтимагый тормышны тулаем тәнкыйтьләмәсә дә, күнеле белән, хисләре белән әнә шул заман тудырган әчке каршылыкларга керә. Заманның әчке каршылыкларын күрә һәм шуны иҗатында ниндидер формада чагылдыра алган язучылар шәхес буларак үсәләр. Аларның иҗатына халыкның игътибары арта. Мәсәлән, Гамил Афзалның сатирасын беркем кабатлый алмый инде.

## 2005

**19 февраль.** Бу көннәрдә Айдар Хәлимнең «Казан утлары»ның 1-2 саннарында басылган мәкаләсен укып яттым. Бик тә кыю, усал яза. Проза турында сөйләшүнең темасын кинәйтеп, ул татарның бөтен әдәбиятын «сөреп» чыккан. Бик кискен фикерләр әйтсә дә, күбесе хаклы. Дәреслекләргә кергән күп кенә әсәрләр бернигә яраксыз шул. Дәреслек төзүчеләр ялкау, һәр язучыны өйрәнеп тормый. Кул астына нинди әсәр керә, шуны дәреслеккә кыстыра.

Ә.Еники, А.Гыйләҗевка биргән бәяләре дә, Г.Исхакыйга карата әйтелгән фикерләре дә дөрес шул. Бу мәкалә генә түгел, тулы бер хезмәт. Моңа карата төрле фикерләр булыр әле. Тетеп салучылар да, мактап язучылар да булыр. Нык бәхәс кузгата торган әсәр бу.

**30 апрель.** 27се көнне нотариальный конторга барып, безнең бу квартирны регистрацияләү хокукын Сәүиягә бирү турында икебез исеменнән дә доверенность язган идек. Прихожий ишеген бикләмичә, документлар салынган сумкасын ишектән кергәч тә ботинкалар янында калдырганбыз. Мине чишендереп, чәйләр эчтек. Берике сәгать ишек биксез торган һәм шул арада Сәүиянең сумкасын кемдер алып чыгып киткән. Ә анда түбәндәге документлар бар иде:

1. Сәүиянең паспорты.
2. Сберкнижкасы.
3. Машина йөртер өчен минем тарафтан бирелгән һәм нотариустан раслаткан доверенность.
4. Водитель таныклыгы.
5. Машинаның техпаспорты.
6. Страховое свидетельство.
7. Эшенә керә торган электрон карточка.
8. Университетта укытучы икәнлеген раслаучы таныклык.
9. Пенсионер таныклыгы.
10. 500 сум тирәсе акча.
11. Машина йөртер өчен врачлардан алынган справка.
12. Медицина полисы.
13. Үзенең һәм безнең квартир ачкычлары.

Тагын нәрсәләрдер.

Өч көн шул документларны эзләү яки яңаларны алу турында баш ватабыз. Участковый милиционерга әйтүдән башладык. Ләкин ул берни дә эшләмәде. Мин Зилә Вәлиевага чыктым. Ул МВД министры Әсхәт Сафаров исеменә хат язарга кушты. Хатны үзем тапшырырмын диде...

**5 май.** 3 май көнне Сәүия «права» алып кайтты. Бу бик кин колачлы казаны Зилә Вәлиева ярдәме белән ерып чыгып киләбез бугай инде...

**19 август.** Бүген Нәдия белән Мәдинә килергә тиеш. Нәдия минем элек йөргән кыз. Мин армиягә киткәнче үк мине ташлап бер очучыга тормышка чыккан иде. Летчигы поезд астына эләгеп, ике аягын өздерде. Хәзер Октябрьскида яшиләр. Кызылъярда да йортлары бар. Нәдия минем «Җилкәннәр»дәге Фәүрия образына да кайбер штрихлары белән керде. Ләкин Фәүрия образы җыелма образ. Анда ике-өч кызның характерлар синтезы.

Иртәнге 9ларда Мәдинә белән Нәдия килде. Безнең икебезне генә калдырып, Нурсөяләр базарга киттеләр. Нәдиянең күңелен бушатасы килгән. 4-5 сәгать сөйләшеп утырдык. «Гомерем буе сине сагынып, сине яратып яшәдем, — ди. — Еш кына ак күлмәк киеп төшләремә керә идең. Син мине ташладың», — ди. Ә мин ул мине ташлады дип яшәдем. Житмеш яшькә житкәндә элекке мөнәсәбәтләрне ачыклау кызык та, кызганыч та. Ул бик күп вакыйгаларны искә төшерде. Мин инде кайберләрен хәтерләмим дә. Яшьлеккә, ул чактагы мәхәббәткә икебез ике яссылыктан карыйбыз икән. Нәдиянең күңелен ачтырасы килә иде. Аның мина, минем ана үпкәләребез күп булган икән, барсын да сөйләштек.

## 2006

**22 гыйнвар.** «Мәдәни жомга»да (17 гыйнвар саны) минем «Жан» турындагы шигырьләр циклым чыкты. Аны Гөлчәчәк Галиева, Зиннур Мансуровлар мактап шалтыраттылар. Гөлчәчәк апа белән Әхмәт абый хәтта шампанский белән өчпочмаклар алып килеп, сыйлап киттеләр.

**7 апрель.** «Казан утлары»ның 3нче санында Рәйсә Юсупованың врач һәм драматург Шәриф Хөсәенов турында бик матур истәлекләре чыкты. Минем дә Шәриф Хөсәенов турында әйтер сүзләрем бар иде. Рәйсә Юсуповага шалтыратып, Шәриф турында үзем белгәннәрне сөйләдем. Ул: «Әй, алданрак белгән булсам, синең истәлекләреңне дә китапка кертеп була иде бит. Мин бит аның турында кешеләрдән язмалар җыеп истәлекләр китабы әзерләп нәшриятка тапшырдым», — диде.

Мин шул сөйләшүдән соң, ягъни кичә бер хикәя яза башладым. Бүген инде хикәямне дәвам итәргә дип эшкә тотынган гына идем, Рәйсә Юсупова шалтырата: «Фәнис, — ди, — кичә синең белән сөйләшкәннән соң төне буе уйланып яттым. Яз син ул истәлекләреңне. Мин нәшриятка барып китапны чыгаруны туктатып торырга куштым. Синең язманны китапка кертәбез. Анда кызыксыз язмалар бар, шуларның берәрсен алып ташлап булса да кертәбез», — ди. Шуннан мин яза башлаган хикәямне ташладым да Шәриф Хөсәенов турында истәлек-хатирә яза башладым...

**19 апрель.** Кичә Шәриф Хөсәенов турындагы истәлекне язып бетереп, Сәүиядән компьютердан чыгартып, Рәйсә Юсуповага биреп жибәрдем. Бер табаклык әйбер. Рәйсә бүген иртән: «Әйбәт булган бу, мин хәзер нәшриятка, китапны ботарларга киттем», — дип шалтыратты. Минем әйберне кертер өчен берничә кешенең язмасын алып ташларга кирәк була. Чөнки китапның күләме чикләнгән. Минекен артка гына өстәп куеп та булмый. Әзер китапны таркатып кире жыю жиңел эш түгел. Ләкин Рәйсәнең ни өчендер минем истәлекләрне керттерәсе килде.

**12 июнь.** Беркөнне Гөлнара бер жыр сораган иде, көе кайсыдыр халыктан урланган. Шуңа яңа сүзләр кирәк. Хәзер жырчылар Азия халыкларының жырларын отып алалар да, шуны үз музыкасы итеп жырлап йөриләр. Шулай итеп күпме жырчылар «композитор» булып бетте инде.

**14 июль.** Нурсөя больницада... Кызык һәм кызганыч: бөтен Казан буйлап эзләп, ничә министрны һәм баш врачларны шушы эшкә тартып та Нурсөя өстендәге йөз мәшәкатьнең берсендә Нурсөяне алыштырырлык кеше табып булмый. Ә шул кешегә нибары 1400 сум пенсия бирәләр!

**29 сентябрь.** Бүгенге «Мәдәни жомга» газетасында «Нурсөя» поэмасының беренче яртысы басылып чыкты. Икенче яртысы киләсе жомга санында чыгарга тиеш. Поэманы илтү белән Зиннур Мансуров: «Бик шәп поэма язгансың, Фәнис абый. Котлыйм. Без аны киләсе санга кертеп тә жибәрербез», — дигән иде. Сүзендә торган. Поэманың әле яртысы гына басылган булса да, Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов: «Фәнис абый, бик шәп поэмагыз белән котлыйм. Бу поэма, бәлки әле, елның иң яхшы әсәре булыр», — диде.

## 2008

**9 октябрь.** 7 октябрьдә шагыйрь Харрас Әюпов үлгән. Иртән йөгереп кайткан да, кинәт үлгән. Ул шулай йөгерә торган иде. 8е көнне Мөслимгә, туган авылына жирләргә алып киттеләр. Үлемнән йөгереп кенә котылып булмый шул. Шагыйрьләргә, язучыларга, кыскасы, күренекле шәхесләргә Казан зиратында

урын юк. Зөлфәт белән Наис Гамбәрне дә Мөслимгә җирләделәр. Марс Шабаевны — Юдино поселогына, Габделхәй Сабитовны Минзәләгә җирләгәннәр иде. Сугыш кырында һәлак булган ата-бабаларыбыз шикелле төрлебез төрле җирдә ята.

Харрасның үлемен мин бәхетле үлем дип уйладым. Чөнки бер көн дә чирләп ятмыйча, якыннарын борчуга салмыйча, карау мәшәкате тудырмыйча, эшләп йөргән килеш кинәт үлү очышта үлгән кошлар үлеме кебек матур үлем.

**15 октябрь.** Үзеннең иҗатыны һәм яшәү рәвешеңне киләчәк буыннар өчен үзең исән чакта эшләп калмасаң, күзең йомылуга барсы да онытыла.

Менә Харрас Әюпов үлде, исеме инде онытылып бара. Ә бит китап нәшриятының баш мөхәррире чакта аңа ялагайланучылар күп иде. Марс Шабаевларның, Илдар Юзеевларның ник бер шигыре радиодан яңгырасын! Татар шигъриятенең алтын баганалары булган Хәсән Туфан, Сибгат Хәкимнәрне дә искә төшерүче юк. Татарның хәтере кыска.

**13 ноябрь.** Халыкта шундый фикер бар: имеш мин чирләп, башка эш эшли алмагач, аптыраганнан гына шигырь язарга тотынганмын. Алай булса бөтен авыру кешеләр шигырь язар иде. Һәр эшкә Ходай биргән сәләт һәм шуның өстенә бик нык тырышлык кирәк. Язучылык эше сабырлык, тырышлык һәм бик күп белем сорый торган эш. Монда нервыларыңны учыңа кысып, учың янса да авыртуыңны әсәрләреңә кертмәскә кирәк. Язган кеше үзе авыру булса да, әсәрләре сәламәт булырга тиеш! Минем кредо шундый.

**5 декабрь.** ...Министрлар алар бүген бар, иртәгә юк. Ә шагыйрьләрне юк итә алмыйлар. Бөтен китапларын яндырган очракта да барыбер кемнәрдәдер кала ул.

**9 декабрь.** Казанның 103нче мәктәбендә минем музей ачылырга тиеш...

**12 декабрь.** Кичә 103нче мәктәптә ачылган музейны карарга бардык. Кешеләр җыелганчы музейны карадык... Минем дәүләт музейларында булганым юк, шулай да дәүләт тарафыннан бер тиен ярдәм күрсәтелмәгән килеш мондый эшне шундый зәвыклы итеп эшләп чыгар өчен бик күп акча һәм минем иҗатны чын-чынлап ярату кирәктер... Бу зур эш бигрәк тә мәктәп директоры Дилбәр Наилевна тырышлыгы белән эшләнгән.

## 2009

**7 гыйнвар.** Яна елның бер атнасы үтеп китте. Бөтен Россия халкы ике атна ял итә. Быел Үгез елы. Илдә кризис котыра: завод-фабрикалар ябыла, эшсезләр арта, квартирга түләү бәяләре атналап, айлап үсә, ашау-эчү әйберләре кыйммәтләнә. Болай булса, Үгезебез коры сөяккә калыр. Элек без яшь чакта җырлый торган җыр искә төште:

Алай да безгә нужа,
Болай да безгә нужа.
Ач булсаң да, тук булсаң да
Узасы гомер уза.

**16 гыйнвар.** Өченче көн КГУда 4нче курста укучы бер кызның минем шигърият турында язган курс эшен укып чыктым. Шактый күләмле, компьютерда баскан 40 биттән торган хезмәт. Әгәр үз башыннан гына язган булса — әйбәт билгесе куярлык. Ләкин лириканы бик үк дөрес бәяләмәгән урыннар да бар. Ул Нурсөягә багышланган шигырьләрне генә чынбарлыктан алынган ди. Ә башкалары хыялдагы мәхәббәт кенә, янәсе. Ә бит минем мәхәббәт турындагы һәр шигырь конкрет бер кешене күз алдында тотып язылган. Хыялый мәхәббәт яшь малайларга гына хас ул.

**31 март.** Беркөнне Башкортстаннан шалтыраттылар. Анда минем әсәрләрне сәнгатьле уку буенча конкурс уздыралар икән.

**18 апрель.** Баулыда минем иҗат буенча конкурс уздырганнар. Барлык авыл һәм Баулыдагы җиде мәктәп катнашкан.

**26 апрель.** Өченче көн Әдип Маликов үлгән. Минем беренче шигырьләрем республика матбугатында күренә башлагач ук ул минем иҗатымны хуплап, күнелемне дәртләндереп хат та язган иде. Элеккерәк буын язучылары татар әдәбиятына яңа кеше килүенә шатланганнар. Аларны үстерү өчен иҗатларын хуплаганнар. Хәзер кешеләрнең күңеле тарайды, көнчелек артты. Яхшырак әсәрең басылып чыкса, дус дигәнең дошманга әйләнә. Мескен булсаң гына «башыңны тагын да түбәнрәк и», — дигән кебек башыңнан сыйпап китәргә мөмкиннәр.

**13 май.** Динаралар китеп 1-2 сәгать үтүгә Апас районы Каратун авылыннан бер автобус укучылар килеп төште. 2 укытучы, 30 лап бала бар иде. Алар ике сәгать ярым утырып киттеләр. Араларында шигырь язучылар, рәсем ясаучылар да бар иде. Бик күп сораулар бирделәр. Фотога төштек. Эт булып арып калдым. Күбесе: «Янадан килсәк ярыймы?» — дип сорады. Бер кызның икәүдән-икәү генә калып сөйләшәсе килгән иде. Жай чыкмады. Шулай да, ул башкалар чыгып киткәч кырыема килде дә, суырып үпте. «Сезнең белән бер генә сәгатькә ялгыз кала алсам, миннән дә бәхетле кеше булмас иде», — дип чыгып китте. «Сез психолог икән», — диде берәү. Ансында хаклык бар. Мин кешеләрнең күнел төрләренә карый беләм.

**18 май.** Кичә Сәүияне больницага салдык, дөресрәге, 2нче роддомга.

**11 июнь.** 10 июнь көнне иртәнге 10 сәгать 35 минутта Сәүиянең баласын ярып алдылар. 3 кило 700 граммлы кыз туган...

Бүген көндез Сәүиянең кызын палатага алып кереп күрсәткәннәр. Зәнгәр күзле ди. Яктыга таба боргач, күзен кысыбрак куйган.

**29 июнь.** 26сына кадәр Сәүияләрдә булдык. Сәүия, бераз хәл керүгә, баласына документлар артыннан чаба башлады. Сәүия документлар артыннан чапканда без бала карап яттык. Елак бала түгел үзе. Әнисе имезеп яткырса, тыныч кына йоклый. Асты юешләнсә генә бераз тавыш биреп ала. Астын алыштыргач, бераз минем белән «сөйләшеп» ята. Мин аңа: «Үсү авыр инде, әле алда тагын да авыррак хәлләр булырга мөмкин. Яшәү бөтенебезгә дә авыр», — дим. Ул аңлаган шикелле миңа карап тыныч кына ята бирә. Минем аяк очында караватка аркылы салабыз. Шул урынны бик яратты. Минем монотон тавыш белән сөйләвем аны тынычландыра булса кирәк.

**8 август.** Менә Гакыйль Сәгыйрев тә үлеп киткән. Ул нәкъ минем белән бер яшьтә иде. 1938 елның февралендә туган. Авылларына кайтарып күмгәннәр. Ул да гомер буе урын өстендә ятып язды. Авызына карандаш кабып, үз китапларына үзе рәсем ясады. Шуңа Казаннан квартир да бирмәделәр. Ә бит ул начар шагыйрь түгел иде. Һаман да шул авыру кешенең мәшәкате күп була дип куркалар.

**25 август.** Нурсөя 18 августтан бирле больницада ята. Әчем бик авырта дип йөри иде. Практолог тикшергән. Авыр күтәрмәскә кушкан. Бөтен врач та аңа авыр күтәрмәскә куша. Ничек күтәрмәсен? Минем белән бергә бөтен дөньябызны ул күтәреп бара бит. Йөрәге, бөерләре, ашказаны, туры эчәге, веналары, кыскасы, бөтен организмы эштән чыккан инде аның. Бары тик мине карыйсы булганга гына Ходай яшәтә инде аны. Аллаһы Тәгалә аңа мине гомерлек бурыч итеп йөкләгән, ахры.

**15 сентябрь.** Әлмәт главасы Ришат Әбүбәкеров үзенең кызы Резидә белән килгән иде. Кызы финанс-экономика институтын бетергән. Әлегә әйбәт эшкә урнашмаган. Ришат үзе экономика буенча докторлык диссертациясе яклады. Белемле дә, кешелекле дә, кыскасы, әйбәт кеше. Зур урыннарда утырып кеше булып калучылар сирәк бит. «Татнефть»нең элекке генераль директоры Ринат Галиев, язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиев, безнең районда ун ел глава булып эшләп киткән һәм хәзер Министрлар Кабинетында экология бүлеге начальнигы Нурислам Хәбипов шундыйлардан.

**23 октябрь.** Айзиләбезгә 4 ай да 12 көн булды инде. Авырлыгы 8 кг 800 г, кичә үлчәгәннәр. Авырлыгы 6 айлык баланыкы кадәр, кимрәк ашатыгыз, дигәннәр. Туйганчы ашатмасаң елый, көйсезләнә, төнлә йокламый бит ул. Айзилә туганнан бирле мин шигырь язуны ташлап, бала караучының ярдәмчесе булып эшлим. Ләкин бармаклар тотмагач, авызына имезлек тә каптырып булмый. Тормыш хәлләре турында гына «сөйләшеп» ятабыз.

**28 октябрь.** Нурсөя больницада, ансыз өйдә яктылык, җылылык ким. Күнелдә бушлык. Югыйсә Сәүия дә әйбәт карый. Яши-яши мәхәббәт, бәлки, бетәдер, ләкин кешеләрне бергә бәйләп торучы башка бик күп нәрсәләр бар. Без аларга әле атамалар да уйламаганбыз. Без «аяләшү», «уртак гамь» дибез. Ләкин болар гына мәхәббәт сүзен алыштыра алмый.

**26 ноябрь.** ...Берничә көн элек Ш.Мәрҗани исемендәге 2нче татар гимназиясе директоры Кәмария Зиннуровна шалтыраткан иде. Аңарга да шул ук сорауны бирдем. Ул: «Аллага шөкер, быел гимназияне саклап кала алдык. 600дән артык бала укый. Чыгарылыш имтиханнарында БДИны бирә алмаучы булмады. Ә рус мәктәпләрендә шактый укучылар бирә алмаган», — диде.

**10 декабрь.** Кичә бәләкәчебез Айзиләнең аркасын пешердек. Кайнар чәй түгелде. Пешкән жире зур түгел дә, бик елады инде, балакай. Алты ае тулган көндә шундый хәл килеп чыкты. Әнисе поликлиникага, анализларын белешергә киткән иде. Гел әнисе кочагында гына үскән бала әнисе югында бик каты борчылды. Минем янга салсаң да елады. Аптырагач, Нурсөя аны гел күтәреп йөрде. Миңа чәй алып чыкканда бала чәбәләнеп киткән. Аркасына чәй түгелгән. «Скорый» чакырттык. Алар перевязка ясап киттеләр.

## 2010

**15 гыйнвар.** «Минем» Айгөл 12 гыйнварда бәби тапты. «Кыз бала тап, юкса яратмаячакмын», — дигән идем, кыз тапкан. Заманында Айгөл белән бик каты дуслашкан идек. Нурсөя авылларына кайтканда бер-ике тапкыр минем янда да калып торган иде.

Минем янда калып бер-ике көн мине карап торучы кызлар булгалады ул. Яшь, матур кызларны минем яратуым гадәти хәл инде, ләкин яшь кызларның мине яратулары гаҗәбрәк. Бу минем фантазиям тудырган фикер түгел. Алар яратуларын исбатлыйлар бит.

**9 апрель.** Бу дүрт-биш көн эчендә гел врачлар белән мәш килдек. Башта 2нче республиканскийдан уролог Галина Александровна килде. Әлбәттә инде, главврач аша гына. Ул Галина Александровна мине күптән үлемгә хөкем иткән инде: «Столько лежите, что же хотите?» — дип кенә җиффәрә. Үләргә мин каршы түгел, ләкин шешеп, череп түгел.

Гомумән, мин бервакытта да озак яшәргә тырышмадым. Кулдан килгәнне эшлим дип, эшләгән эшем кешеләргә ошасын иде дип тырыштым. Гомерне без еллар белән исәпләргә гадәтләнгәнбез. Ә бит ул синең ничек яшәвенә, үзеңнән соң нәрсә калдыруыңа карап исәпләнергә тиеш. Әнә Тукай 27 ел гына яшәгән, ә шул гомер эчендә күпме үлемсез әсәрләр иҗат итеп калдырган.

Галина Александровна берни эшли алмагач, 18нче больницадан уролог чакырттым. Әлбәттә инде, главврач аша. Ул ялт-йолт карап китте. Аның кинәшләре бернигә яраксыз булып чыкты. Төне буе косып чыктым. Нурсөяне дә йоклатмадым, үзем дә йокламадым. Иртән бик каты температура күтәрелде. Участок врачын чакырттык. Әлфия Курмаева дигән сөйкемле генә хатын икән. Бик игътибар белән тикшерде. Аның мөлаем йөзе, сине кызганып, кешегә кеше итеп каравы тәэсир итте ме, бүген температурам төшкән.

**28 апрель.** Укытучылар арасында да наданнар күбәя.Әдәби әсәр белән тормыш чынбарлыгы арасындагы аерманы алар укучыларына аңлатырга тиеш иде югыйсә.

— Телне югалту сезнеңчә нәрсә ул? Кайсы телдә сөйләшсәң дә барыбер түгелмени? — диделәр.

— Туган теленне югалту — үз-үзенне югалту ул, — дидем. — Рус, инглиз телендә генә сөйләшә башлыйсың икән, телисенме-юкмы син аларның гореф-гадәтләрен, хәтта диннәрен дә кабул итәсең. Син алар жырын жырлыйсың, ләкин бит синең күңел төбеннән саркылып торган моң бар. Син алар жырын да жиренә житкереп жырлый алмыйсың, ата-бабаларыңнан саркып кергән моң да өскә калкып чыга алмый. Чөнки телнең артикуляциясе үзгәргән. Син инде үз йөрәгең урынына ясалма йөрәк куйдырган кеше кебек рухи дискомфорт кичергәнсең.

Минем сүздән соң уйланып калдылар.

**27 май.** Айзилә кичә безнең ярдәмнән башка берничә адым атлады. Тиздән бер яшь тула, бәлки, шул вакытларда йөреп тә китәр.

**27 июль.** Язучылар күбәя. Һәркемнең үз китабын чыгарасы килә. 1968 елда, мин Язучылар союзына әгъза итеп алынганда, Татарстанда нибарысы 60 язучы бар иде. Хәзер союзда әгъза булып торучылар 250 кеше. Китап нәшрияты 250 китап чыгара алмый. Шуна усаллашу, кычкырышу китә.

**3 август.** Минем тормыш гел көрәштән торды: яшәү өчен көрәш, китапларымны чыгару өчен көрәш, дөньяда бер мескен бәндә булып калмас өчен көрәш һ.б.лар, һ.б.лар.

«Идел» журналында өч бит шигырьләрем чыккан. Анда хәзер баш редактор булып Рифат Фәттахов утыра. Ул «Татарстан» журналында эшләгәндә: «Мин кайда гына эшләсәм дә, синең шигырьләренне басмаячакмын», — дигән иде. Хәзер үзләре сорап алдылар.

**9 август.** 7-8 көн бакчада булдык. Анда кайнар. Температура 38дән төшми. Яңгырлар юк. В.Путин Россия икмәген чит илләргә чыгаруны тыйды. Бөтен Россиядә 45 миллион тонна икмәк җыеп алыныр дип көтелә. Былтыр 110 миллион тонна иде. Дөрес, монын өчтән бере кәгазьдә генә. Үзебезнең Татарстаннан беләм: главалар яки колхоз председательләре белән сөйләшкәндә һәрвакыт шул сорауны бирәм: «Гектардан күпме уныш чыга?» Икмәк унган елларда алар 18-20 чыга диләр иде.

— Ә Президентка ничә дип рапорт бирәсез?

— 35-48 центнер дип.

— Ә ул кәгазьдәге икмәк нәрсәгәдер «тотылырга» тиештер бит.

— Икмәк бит йә чери, йә урлана. Хәзер алдашырга мөмкинлекләр күп. Икмәкнең кәгазьдәгесе «үзебездә кала». Без сыерларга фураж итеп бирәбез. Сыерның теле зур булса да: «Безгә коры печән яки салам гына ашаталар», — дип әйтә алмый.

Шәймиев былтыр гына әле: «Бездә өч еллык запас бар», — дип мактанган иде. Быел инде икмәкне төрле төбәкләрдән сатып алалар.

**2 октябрь.** Безгә начар булып тоелган кешеләрнең дә яхшы яклары була. Начарлык эшләгәндә аны кызулык белән язып куясың, ә яхшылык эшләсә, язарга онытасың. Көндәлекләремдә кемнәрдер турында ачулы сүзләр язылган икән, бу әле ул кеше бөтенләй яман дигән сүз түгел. Миңа начар булган кеше кемнәргәдер бик күп яхшылык кылгандыр. Кемнәрдер бу көндәлеккә керми калса, үпкәләмәсеннәр. Көндәлек ул тарих дәреслеге түгел. Анда бөтен нәрсәне язып барып булмый. Көндәлектә кемнәргәдер каты сүз әйтелә икән, күңеле киң кешеләр моны кичерер. Ә инде кичерә алмаучылар гаепне үзләреннән эзләсеннәр. Мин бары тик булган фактларны гына теркәп барам. Монда берни дә уйлап чыгарылмаган.

**16 октябрь.** Төрле кеше төрлечә язучының абруен төшерә. Тормышның минә шундый чүп-чарлары язу дәртен сүндерә. Хәзер бик язып та булмый инде. Хәлсезлек. Укырга күз арый. Күзнең аруы тәнгә күчә. Кеше шулай башта рухи яктан, аннары физик яктан бетәдер, күрәсең. Кинәт кенә, өреп сүндерелгән шәм кебек сүнеп куеп та булмый. Минә Фәридә Кудашева 90 яше тулыр алдыннан, җырлап йөргән җирдән үлде. Галим Миркасыйм Госманов кинәт үлде. Мондый бәхетле үлем миңа тәтемәс инде. Гомер буе интегеп яшәп, үземне караучыларны үземнән биздереп үләрмен.

**30 октябрь.** Кичә беренче кар яуды. Минем урамга чыкмаганга айдан артты бугай.

*Бу дәфтәрне минә бүген тәмамлыйм,*
*Инде хәзер шигырьләр дә язалмыйм.*
*Гомеремнең офыгына җителде,*
*Йөрәк инде парә-парә тетелде.*

*Үтте гомер тартышып һәм көрәшеп,*
*Кешеләргә байлыгымны өләшеп.*
*Яр читенә килеп җиттем, хушыгыз,*
*Шигырьләрем, кошлар булып очыгыз.*

*Монда уйлар, монда хисләр дәрьясы,*
*Монда бар да гел чынбарлык, ялган юк.*
*Каләмемне атам бүген еракка,*
*Көрәшергә, ярышырга чамам юк.*

**7 ноябрь.** Сәүияләр килеп китте. Айзилә, Аллага шөкер, үсеп килә. Сөйләшә генә белми әле. «Мәммә», «әннә» — бар белгәне шул.

**31 декабрь.** Көндәлекне күпме сузсаң да сузыла.

*Каләмемә әйттем: тукта!*
*Көндәлеккә куям нокта.*
*Кемдер ягар аны утка.*
*Сүзләр янар дөрли-дөрли,*
*Ялкын әйтер: тукта, тукта...*

Фирдэвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Кылачы

Кылачы авылы район үзәге Арча эшчеләр бистәсеннән — 15, җирле үзидарә советы үзәге Урта Атыдан 5, якындагы тимер юл станциясе Коркачыктан — 9, Казаннан 58 чакрым ераклыкта урнашкан.

Кылачы атамасы тарихи чыганакларда да искә алына. Д.А.Корсаков белешмәсендә (XVIII йөз) авыл Ключи (Калачи) дип бирелә һәм анда 125 йомышлы, 1 керәшен татары яшәве искә алына. А.Артемьев нәширләгән тарихи белешмәдә дә авыл Ключи (Калачи) дип бирелгән. Авылдагы 77 хуҗалыкта 309 ир-ат һәм 315 хатын-кыз көн иткән, мәчет эшләгән. Н.Н.Вечеслав белешмәсендә авыл Ключи-Калачи (Ключи пучинкәсе) дип бирелә. Халкы Ключи-Калачи авылы җәмгыятенә берләшеп көн иткән. Андагы 127 хуҗалыкта 295 ир-ат һәм 294 хатын-кыз яшәгән. Авылда агач мәчет һәм жил тегермәне булган.

Кылачы авылы табигатьнең матур урынында урнашкан. Олылар сөйләвенә караганда, авылның исеме дә «ключи» — чишмә сүзеннән килеп чыккан. Шушы сүздән клачы — кылачы тәгъбире барлыкка килгән. Татар телендә авазлар кучешен исәпкә алганда да бу үзгәреш дөреслеккә туры килә.

Авыл янында гына зур үзәнлек җәелеп ята. Аның исеме Тугызай. Кылачы авылы яңа оешкан заманаларда әби-бабалар шушы үзәндә 9 ай буена яшәгән. Ни өчендер бу урынны халык килештермәгән һәм авылның хәзерге урынына килеп урнашкан. Түбән Аты авылы ягындагы күл Балыклы күл яисә Төмәнәй күле дип атала. Әйшә авылы ягындагы юл өстендә бер ялгыз имән агачы үсеп утыра, кышкы буранлы көннәрдә бу агач юлчыларга адашмас өчен маяк хезмәтен дә үтәгән. Ул ике авыл арасының нәкъ уртасында үсә. Бу агачны Маяк агач, Ялгыз агач дип тә йөртәләр.

Авылның югары очында бик тәмле, шифалы чишмә бар. Исеме Хәйрүк бабай чишмәсе. Ул елга янындарак урнашкан. Елга яры буйларына Хәйрүк бабай тополь агачлары утырткан. Бу агачлар үскән урынны Хәйрук бабай бакчасы дип йөриләр. Авыл уртасында тирән генә чылбырлы кое бар. Үз хуҗалыкларында һәркемнең коесы булуга карамастан, һәркем эчәргә суны шул коедан китерә, чөнки аның суы бик тәмле һәм шифалы да диләр. Ел саен кое һәм чишмәләр чистартылып торыла. Бу эшне авыл өлкәннәре башлап йөри, яшьләр дә бик теләп кушыла.

Авылның икенче ягында Камай тавы урнашкан. Тауда изгеләр кабере һәм Изгеләр чишмәсе бар. Бу — Мулла Хаҗи чишмәсе. Ул авылдан шактый ерак, аралары 7-8 чакрым булыр. Ерак булуга карамастан, Кылачы авылы халкы анда суга бара. Бу чишмә суына Казаннан кайталар, тирә-юньнәрдәге авыллардан киләләр. Әлеге суны эчкән кешеләр хәтта авырулардан сихәтләнәләр икән. Изгеләр каберенә халык

*Дәвамы. Башы 2006 елның бнчы санында.*

сәдака куя. Камай тавын казыганда төрле борынгы әйберләр дә тапканнар. Басуда Габдери аланлыгы исеме әлегә кадәр сакланган.

1971 елда авылда 101 хуҗалык булган, хәзер анда утызлап йортта гына кеше яши.

## Апаз

Апаз авылы Арча районында, район үзәге һәм тимер юл станциясе Арча эшчеләр бистәсеннән 38 чакрымда, Казан шәһәреннән исә 103 чакрым ераклыкта урнашкан. Апаз авылы — жирле үзидарә советы.

Д.А.Корсаковның XVIII йөз мәгълүматларын туплаган җыентыгында Апаз авылында 190 керәшен татары яшәгәнлеге күрсәтелә. Бу чыганакта авыл исеме — Шушма суы буена утырган Рождествено. 1859 елдагы А.Артемьев мәгълүматларына караганда, Апаз (Рождествено) авылындагы 95 хуҗалыкта 409 ир-ат һәм 422 хатын-кыз яшәгән, анда православие чиркәве эшләгән. 1766-1861 елларда үткәрелгән генераль ызанлау мәгълүматларына караганда, Рождественское яисә Апаз авылында ясак түләүче керәшен татарлары яшәве күрсәтелгән.

Бу авылны И.А.Износков түбәндәгечә тасвирлый. Апаз, икенче атамасы Рождествено, Шушма һәм Сәрдә суы ярларына, Себер элемтә юлының сул ягына утырган. Авылда 136 хуҗалык булып, аларда электән үк чукындырылган татарлардан 503 ир-ат һәм 515 хатын-кыз яшәгән. Тормыш-көнкүрешләре уртача булган. Авыл халкы тегермәнчелек, тимерчелек, балта эше, тукымалар мануу һәм умартачылык белән шөгыльләнгән. 1898 елгы җыентыкта Апаз авылында татарлар яши дип искәртелә.

Аксакаллар сүзенә караганда, авыл оешканчы бирегә чирмешләр (марилар) яшәгән. Авыл янында иске зират бар. Авыл кешеләре аны керәшен зираты дип йөртә. Явыз Иван Казан ханлыгын яулап алганнан соң, Апаз халкы көчләп чукындырыла. Ләкин соңыннан халык, бик зур тырышлык һәм батырлык күрсәтеп, кире исламга кайткан.

Нажия апа Борһанова мәгълүматларына караганда, Апаз, Носы, Ишнарат, Үгез-Елга, Шушмабаш, Каратай, Миржәм, Пөшәнгәр, Шекә авыллары халкы июнь аеның икенче җомгасында Казак җыены бәйрәм иткән. Икенче төрле аны Носы җыены дип атаганнар.

Авылның атамасы турында халык хәтерендә төрле легендалар сакланган. Имештер, элеккеге заманнарда авыл тирәсендәге тау башыннан үтеп барганда ике кеше елгада йомычка акканын күреп авылга керә. Әле авылда бу вакытта халык аз булган, шуны күреп, болар: «Ап-аз икән халкы», — дип әйткәннәр, имеш. Әлбәттә, бу легенданың халык этимологиясенә нигезләнүе күренеп тора. Икенче риваять буенча авылны Габбас исемле кеше нигезләгән һәм вакытлар уза-уза авылның исеме Апаз булып үзгәргән.

Авыл урыны элек куе урман белән капланып алынган булган.

Апаз авылын урталай бүлеп Шушма елгасы ага. Элек бу елга мул сулы, балыклы булган. Авыллар янында элегрәк су тегермәннәре гөрләп эшләгән, елга ярларындагы чишмә-кизләүләр һәрдаим чистартылган. Шуңа күрә елганың суы көмештәй чиста һәм саф, ярларыннан ташып чыгардай ишле булган, хәзер исә елга бөтенләй саеккан.

Шушма елгасына Сәрдә суы, Яңа Авыл, Шом, Жишнарат (Өчнарат) сулары кушыла.

Апаз авылындагы чукындырылган татарларның исламга кире әйләнеп кайту хәрәкәте XIX гасыр ахырында башлана һәм 1907 елга кадәр дәвам итә. 1881-82 елларда авылда бер төркем кешеләр ислам диненә кире кайтырга омтылыш ясый. Апаз побы ялган шаһитлар ярдәмендә аларны православие динен хурлауда гаепләп сөргенгә җибәртә. Барысы 10 гаилә, 50ләп кеше сөрелгән.

Беренче рус (1905-07 еллар) революциясеннән соң исламга кире кайту хәрәкәте тагын да тизләнә. Бу елларда унлап кына гаилә православие динендә кала. Авыл побы куркуга төшә.

Ул чиркәүдән (хәзерге балалар бакчасы урыны) алтын-көмеш әйберләрне кичтән алып чыга һәм икенче көнне (урак өстендә) көндез чиркәүгә ут төртә. Ут чыгаруны ислам диненә күчәргә өндәп йөрүче Бәшир исемле кешегә сылтый. Ләкин тикшерү вакытында ул көнне Биби Бәширенең өйдә булмавы ачыклана, тикшерү туктатыла һәм эшне ябалар. Бу хәлгә халык зур ризасызлык күрсәтә. Халык ризасызлыгыннан куркып, попны авылдан алырга мәҗбүр булалар.

1916 елда Апазда Казан байлары 2 катлы мәһабәт мәчет салдыра. Апаз мәчетенә мәхәллә мулласы итеп 1917 елның язында ук Спас өязенең Яңа Камка авылы кешесе Габделрәүф Мөхәммәтсафа улы Хәмзин сайланган.

Авыл халкының исламга кире кайту хәрәкәте татар җәмәгатьчелегенең игътибар үзәгендә була. Шуна күрә, 1917 елның апрелендә Апаз крестьяннарының мәхәллә оештыру һәм ике катлы ярымташ мәчет төзү турында җыелыш кабул иткән карарларын милли-азатлык хәрәкәтенең күренекле вәкилләре хуплыйлар, бу ниятләрне тормышка ашыруны үз карамакларына алалар. Оренбургтагы Диния нәзарәте 1917 елның 15 маенда үзенең ризалыгын җиткерә. Эшләрнең болай унышлы башлануында һәм тиз баруында ул чакта Нәзарәт җитәкчелеге әгъзасы булган Хәсәнгата Габәшинең дә өлеше була. С.Ш.Алкин һәм Казан мөселман комитеты рәисе М.Ф.Туктаров, Апаз халкының үтенечен унай хәл итүне сорап, губерна идарәсенә мөрәҗәгатьләр юллыйлар. Нәтиҗәдә, Апаздагы мәхәллә рәсми рәвештә теркәлә. Ә төзелеш бүлеге, төзелеш уставының торак йортлардан 20 сажин ераклыкта дини бина-корылмалар төзүне тыйган маддәсенә ишарәләп, мәчетнең проектын раслаудан баш тарта.

Мәчетнең хәзерге вакытта сакланган ике катлы ярымташ бинасы 1917 елгы планнарга һәм сызымнарга туры килми. Ихтимал, гыйбадәтханә сонрак төзелгәндер. Аның аскы каты таштан, өскесе агачтан. Манарасын яманаты чыккан утызынчы елларда кискәннәр. Баштарак бу бинада тегү ательесы ачкан булганнар. Хәзер аның бер бүлмәсендә халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинаты урнашкан, икенче бүлмәсендә авыл халкы намаз укый. Шатлыклы хәбәрләр дә ишетелеп тора. 1996 елда иске мәчет бинасы тулысынча дин тотучылар карамагына тапшырыла. Мәчет бинасы 1682 номеры белән «Татарстан Республикасы: тарих һәм мәдәният һәйкәлләре» дигән китапка кертелгән.

XIX гасыр чикләрендә Апаз таза тормышлы авыл була. Анда тимерче утары, буяухана, базарда 29 сату мәйданы, кабак, харчәханә, су тегермәне эшләгән. Базар шимбә көн үткәрелгән. Монда тирә-юнь авыллардан, еректан да сәүдә итүчеләр һәм сатып алучылар җыела торган булган. Анда мал-туар, кием-салым, ашлык, печән һ.б. бик күп әйберләр белән сәүдә иткәннәр. Базарда күнел ачулар да оештырылган.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# ӘКИЯТЛӘР

## Ярамый

Яшәгән ди, булган ди Ярамый атлы бер малай. Ярамый икән — ярамый инде. Бер-бер яхшылык кылырга ниятләсә дә, шукланса, наянланса, тырбыкланса, тырышса-тырышмаса да, киреләнсә, тискәреләнсә, алай түгел, болай ул дип әйтелсә дә, моңа өстәп-өстәп, һаман-һаман:

— Ярамый! — дип кенә әйтәләр икән.

Моңа бармак белән төртеп, ишарәләп тә, йодрык күрсәтеп тә, нишләсә дә, нишләмәсә дә гел:

— Ярамый! — дип кенә торалар икән ди инде менә.

Өстәл астыннан рәхәтләнеп мүкәләп йөрергә тотынса — ярамый; манный боткасы ашарга теләмәсә — ярамый; ишегалдында туп тибә-тибә былчыракка, комга батып керергә ярамый; кәнфит суырырга, сагыз чәйнәргә, туңдырма, шоколад ашарга ярамый; текә таудан чаңгыда шуып төшәргә, каен агачы башына менәргә, болында тапкан какы, кузгалакны юмыйча ашарга ярамый; күрше Әхмәтҗан бабайның ни бер бөртек шомыртын, ни алмасын рәшәткә арасыннан үрелеп, урлап ашарга ярамый; яткан килеш китап укырга, телевизор карарга ярамый; чатыр-чотыр йөгереп барганда абынып киткәндә тезе авырткач еларга ерамый; күрше кызының чәч толымы очын тартып куярга ярамый — кыскасы, Ярамыйга нишләсә дә ярамый.

Ярамыйны мондый «ярамый» бер дә бер заманны туйдырып, гарык итеп бетергән дә, әйткән ди бу:

— Мин Ярамыйм икән, әнә, урам буйлап Ярый килә. Аңа бөтен нәрсә ярый. Шуның көен көйләп торыгыз инде, алайса, — дигәч, әллә кая киткән дә барган.

И эзләгәннәр Ярамыйны, и эзләгәннәр, ә таба алмаганнар.

Шуннан соң Ярамыйсыз бик тә, бик тә күңелсез булып киткән.

Ә Ярамый япа-ялгызы йөри дә йөри, йөри дә йөри икән. Кая барса да, кая керсә дә, нишләсә дә, нишләмәсә дә аңа гел:

— Ярамый! — дип кенә торалар икән.

Ә Ярыйга ярамыйга ярамаган бөтен нәрсә ярый ди.

Шул ярыймы икән?

## Мылтык

Яшәгән ди, булган ди бер Мылтык. Аны бик-бик матур итеп, кулга тотарга җайлы, төбәп атарга ипле булсын дип ясаганнар ди. Ул түтәсе, дисеңме, ул тәтесе, ул көпшәсе, ул төбәгече, ул очына утыртылган дүрт кырлы, очлы кадагычы — боларның һәммәсе әйтеп, сөйләп бетергесез, карап туймаслык хәйран да тамаша шоп-шома, әйбәт, матур ди инде менәтерә.

Шуңа күрә ул уңлы-суллы, аллы-артлы шарт та шорт ата-ата кәперәеп бик күп йөргән: әллә күпме илләр гизгән, әллә ничә дингез, дәрья кичкән.

Ул хәтле йөргән дигәч тә – Кеше җилкәсендә инде. Мылтык шунсыз кая китсен дә кая барсын?

– Мин – Мылтык, мин – Винтовка, мең дә сигез йөз туксан беренче елгы үрнәк, мине Мосин атлы урыс ясаган, мин үземә корылган ядрәне ике чакрымнан үтерерлек итеп тидерәм, миннән узганнар юк әле! – дип мактанырга, искиткеч шапырынырга, лаф орырга яраткан ди, имеш.

Бер дә бер чакны моның шулай йөрүеннән тәмам туеп бетеп, гарык булып, моны бер дә бер өй чормасындагы җыен ташландык, иске-москы әйберләр арасына – кеше-кара күз карашыннан ераккарак яшереп куйганнар ди.

Бу Мылтык шуннан бирле тып-тын гына ята да ята, ята да ята икән ди инде. Шулай кача-поса ятуы моны бер дә бер заман бөтенләй ардырып, талчыктырып, хәлдән тайдырып, әлсерәтеп, тинтерәтеп бетергән ди.

Көннәрдән бер көнне, төннәрдән бер төнне ул үзен төреп куйган майлы чүпрәк-чапракны шытыр-шытыр ертып ташлаган да, күзен уа-уа шуышып чыккач, үрә каткан килеш түтәсенә торып баскан ди. Баскан да ди, пыяласы чатнаган борынгы иске бер көзге каршысына чат-чат, шак-шок атлап, дөп-дөп килеп, үзенең түтәсе нык икәнен аңлаган, тәтесен барлаган, көпшәсендәге тузанны өреп туздырган, төбәгечен җайлаган, теге көзгедә елык-елык ялтыравына сөенгән.

– И! – дигән ул. – Миңа атасы да атасы, үтерәсе дә үтерәсе икән бит әле!

Айлы булса да, төн дөм караңгы икән ди. Әлеге дә баягы бу Мылтык урамга чыгып, юан гына бер имән агачы артына барып поскан да:

– Нәрсәне генә, кемне генә күрсәм дә атам да үтерәм! Миңа шулай кушылган, миңа шулай боерылган, – дигән.

Ул түтәсен ипләгән, чакмасын тарткан; көпшәсен турайтып, төзәгечен төп-төз төбәп, хәтәр үткен кадагычын ялт-йолт ялтыратып, колагын хәтәр торгызган килеш, үткән-киткәнне көтеп тора ди инде менә.

Шулай көтә икән, көтә икән, моның каршысына күзе тары бөртеге хәтле генә булган бер бәп-бәләкәй Сукыр Тычкан малае килеп чыккан. Шуннан соң бу Мылтык бөтен тәнен киереп китергән дә, бар куәтенә теге Сукыр Тычкан малаена төбәп аткан да җибәргән ди.

Тик әлеге мылтыкның төнге күктәге Айны да куркытырлык, Йолдызларны да сискәндерерлек, теге Сукыр Тычкан малаен да өркетерлек, һәммә нәрсәнең дә котларын очырырлык дөбер-шатыр ату тавышы чыкмаган ди.

Чөнки Мылтык үзенең ядрә белән корылган икәнлеген онытканикән.

Шуннан соң ул әлеге Сукыр Тычкан малае белән әйлән-бәйлән, бишташ, өй-өй, йөзек салыш, пәке кадаш, кузна чиртеш уеннары уйнаган, биегән, җырлаган – тагын әллә нишләп беткән.

Ә корылган булсамы? Нәрсәне, кемне генә күрсә дә, атасы да үтерәсе иде ич инде бу, әйеме?

Шуннан соң ул Мылтык нишләгән? Нишләсен ди инде тагын: әкертен-әкертен генә, ялт та йолт карана-карана чормасына кереп китеп, теге иске-москы чүпрәк-чапрагына төренгән дә бик тәмләп, бик тынычлап йокыга талган.

Ә татлы, тәмле төшендә ул бернәрсә дә, беркем дә атмаганын, бернәрсәне дә, беркемне дә үтермәгәнен күргән ди.

## Сугыш чукмары

Яшәгән ди, булган ди бер Сугыш. Моның исеме, ишетсәң, колагыңны торгызырлык, белмәсәң, төшеңә керерлек ди. Аны күргәннәр, күрмәгәннәр дә, белгәннәр, белмәгәннәр дә Сугыш Чукмары дип йөрткәннәр. Каргап. Чөнки ул, дөньяга килүе белән үк рогатка ясаган да, кош-кортларны

кырырга керешкән, песиләргә, этләргә көн күрсәтми башлаган, бөтен чүп-чарын урамнарга ташларга керешкән, ишегалдындагы балаларны, ап-ак яулык япкан әби-сәбиләрне, түбәтәй кигән бабайларны узып барышларында аяк чалып егарга тотынган. Аннары соң, үсәрәк төшкәч, чукмар ясаган да – унга-сулга, сулдан унга селтәнә дә селтәнергә, айкый да айкарга керешкән ди.

Моны һичкем тыя алмаган.

Беркем тыя алмагач, бу Сугыш Чукмары бөтен дөнья буйлап сәяхәткә чыгып киткән. Кая гына барып эләкмәсен, анда орыш, монда кырылыш башланып кына тора ди инде. Менә бу Сугыш Чукмары кая гына барып җитмәсен, бала-чаганың футбол, волейбол тупларын рогаткасыннан, мылтыктан, туптан атып чәлпәрәмә китерергә, шартлатырга тотынган; тәмле өчпочмакларын, итле бәлеш төпләрен, җир җиләге, каен җиләге, карлыган, сырганак кайнатмаларын ялмап кына алырга керешкән. Җирдән җиргә, илдән илгә, чишмәдән инешкә, елгадан дингезгә, чәчәктән күбәләккә, җилдән болытка, өйләрдән зиратларга – тагын әллә кайлардан әллә кайларга йөри-йөри дөбер-шатыр кыдыра, кыздыра да яндыра, бетерә дә... үтерә торгач, әлеге дә баягы Сугыш Чукмары арган-талган, алҗыган-талчыккан да Дию пәрие хәтле гәүдәсенең юан сабына таянган килеш бер-бер уйга килгән ди, имеш.

Уйга дигәч тә... арыган бит инде. Тын алырга туктаган. Чалгылап печән чапканда, ике куллы пычкы белән утын кискәндә дә бер кавым тын алу кирәк. Туктаган да – Күккә караса, анда бу Сугыш Чукмарын, һич кенә дә өнгә-санга сукмыйча, Салават күпере балкып тора икән; аяк астына караса, кырмыскалар тегендә-монда йөгерешә, карлыгачлар үз ояларындагы балаларына азык ташый, ул арада җир җиләге пешкән, чишмә челтери, күлдә балыклар йөзә, күбәләк белән энә карагы һавада әйлән-бәйлән уйный, әллә кайлардан бәбиләрнең әле елаганы, әле көлгәне, бала-чаганың үзләренчә уенындагы чыркылдашуы, бер-бер бозауның әнкәсе имиендәге сөтне сагынып мөэлдәве, ары таба тәмам өлгереп җиткән алмаларның көндез дә, төнлә белән дә тып-тын итеп җиргә өзелеп-өзелеп төшүләре, шунда бер малайның шулардан берсен үз учына тотып алып, каршысындагы ак яулыклы кызга сузуы, ә бер әнкә белән әткәнең бу Сугыш Чукмары һәлак иткән улларының әле генә гүргә индерелгән төштә үзара сүзсез генә юатышуларының үләннәргә иртәнге мул чык булып кунуын – тагын әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр Сугыш Чукмарының күз алдына яңгыр булып яуган да, кар бураннары булып бураган ди.

Шуннан соңмы? Шуннан соң Сугыш Чукмары күргән-белгәннәре хисеннән буыла-буыла чишмәләрдән, дингез, дәрьялардан да артыграк күз яшен агыза-агыза елаган да елаган ди, имеш тә, үзенең рогаткасын телемгә-телем теткәләп бетергән ди. Ә үзенең чукмарын... Чукмарынмы? Әллә күпме кисәкләренең берсенә яшереп куйган ди. Кирәге чыгар әле дип.

**Әхәт ГАФФАР**

## *Юбилеебыз тантанасы мизгелләре*



*Равил Фәйзуллин ЮНЕСКО каршындагы Европа-Азия халыкара гуманитар академиясенең «Роза мира» алтын медале белән бүләкләнде. Аның янәшәсендә академиклар, бертуган Индус һәм Энгель Таһировлар.*



*Буыннар эстафетасы. Аксакал әдип Айдар Хәлим һәм яшь язучы, «Идел» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин.*



*Безне Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов һәм «Агыйдел» журналының (Уфа) баш мөхәррир урынбасары Рамил Янбәк котлый.*



*Редакция хезмәткәрләре Марат Закиров һәм Гөлзадә Бәйрәмова «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек булдылар.*



*Гамәли хезмәткәр Флёра Сабирова Татарстан мәдәният министрлыгы медален кабул итә.*



*Журналның баш бухгалтеры Гөлнара Галиева һәм компьютер бүлеге мөхәррире Элеонора Җамалиева.*



*Сәхнәдә «Казан утлары» журналы редакциясе коллективы.*

# ТАТАР ОФЫГЫН КИҢӘЙТКӘН ӘДИП

МИРГАЗИЯН ЮНЫСКА 85 ЯШЬ

Нинди кимәлдәге вакыйга соң бу татар өчен?

«Өянке»дән башлыйк әле. Әдипнең «Безнең өй өянке астында иде» дигән хикәясен «Казан утлары» да, «Идел» журналы да икешәр тапкыр бастылар. Соңгысында (2001, № 12) «Идел» хикәянең автордан махсус сорап яздырган иҗат ителү тарихын да бирде әле.



Италиядә, Генуя шәһәрендәге зиратта совет диңгезчесе Габдрахманның (капитанның беренче ярдәмчесе), асылда авторның үзенең, туган ягын сагынып чит илдә интегепләр гомер кичергән татар карчыгы белән очрашуы турында укыганда тетрәнми калган кеше булды микән? Вакыйга иң әүвәл, әлбәттә, авторны тетрәндерә (моңа, бәлкем, Миргазиян абыйларның өйләре дә өянке астында булу да тәэсир иткәндер). Һәм бу тетрәнү безгә... татар язучысын бүләк итә! Паустовскийның 70 еллык юбилеена багышлап үткәрелгән конкурста «Железный слон» дигән хикәясе белән беренче урынны алган, хәтта энесе Вахитка да хатларын урысча гына язган Миргазиян Юнусов әлеге хикәяне, үзе дә һич көтмәгәндә, татарча яза. («Хикәяне укыганнан соң барлыкка килгән иң җитдие, минем язмышымда тирән эз калдырганы: «Җәмәгать, мин әле һаман татар икәнмен ләбаса!..»)

Бу хикәяне Финляндия татарлары елый-елый укыганнар. Карчыкның язмышы алар язмышына да аваздаш бит. Хикәя мине дә тетрәндерде. Бер милләттәшебез өчен ут йотудан тыш, гомумән татар язмышы турында да уйланырга мәҗбүр булдым чөнки. Миргазиян абыйның үз сүзләре белән әйтсәк, «Гасырларга сузылган таралу-таркалу кайларга гына олактырмаган татар кешесен. Меңләгән, миллионлаган татар сөякләре Җир шарының төрле кыйтгаларында күмелеп калган...» Исеме әйтелмәгән бу әбинең язмышында туган җиребездә дә килмешәк хәлендәрәк яшәп ятучыларның, ягъни үзебезнең хәл дә чагыла ләбаса. Әбинең өлкән баласы әле татарча белсә, бездә туган телләрен җуйган әниләр һәм хәтта әбиләр дә санап бетергесез бит!

Хикәя 1964 елны язылган. Миргазиян абый аны хат белән энесе Вахитка салган һәм... бу хакта оныткан. Шул елны ук (№ 8) «Совет әдәбияты» (хәзер «Казан утлары») журналында басылып чыгуы исә диңгезчене шаккатырган.

«Татар» сүзе матбугатка «теле», «китабы» кебек сүзләргә ияреп кенә керә алган ул заманда мондый әсәрнең басылып чыгуы мине дә гаҗәпкә салды. Хикәянең нәкъ менә «Совет әдәбияты»на бирелүе һәм тагын анда баш мөхәррир булып кыю-тәвәккәл Газиз Мөхәммәтшинның эшли башлавы гына юл ачкандыр инде аңа.

Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять»е (шул ук «Казан утлары»нда 1966 елның 1нче санында басыла) һәм алдарак чыккан «Өянке» тулаем диярлек совет «чынбарлыгын», ягъни үткән сугышны, колхоз, завод, төзелеш, нефть хәлләрен тәтиләндереп кәгазьгә төшерүдән гыйбарәт булган татар әдәбиятына милли гамьне

кайтарды. Әмирхан ага Акъәбине әсәрен бастыра алмаудан куркып башкорт итсә, биредә без тупырдап торган чын татар әбиен күрәбез.

Баулы районының Исергәп авылында 1927 елда туып та, Ватан сугышына ялганып өлгергән, 5 ел күктә очкан, 22 ел суда йөзгән Миргазиян агабызның шуннан соңгы бай иҗатында да (бу – «Дөнья гизү» трилогиясе, «Занзибар зәңгәр томаннар артында», «Табу һәм югалту» бәяннары, үткен-кыю публицистик мәкаләләре, күпләгән сәяхәтнамәләр...) үзәктә асылда туган халкының язмышы. Һәм бу, бәхәссез ки, олы талант, олы иҗат. «...Миргазиян әдәбият үрләренә эре адымнар белән бик тиз менеп тә житте. Һәм әдәбиятыбызның монарчы берәү кулы да тимәгән яңа чирәмен ачты...» – бу аның турында бөегебез Әмирхан Еники әйткән сүз. Мөхәммәт Мәһдиевнен «Шәмдәлләрдә генә утлар яна» турында әйткәннәренә дә колак салыйк: «Бу әсәр – сугышта яшьли үлеп калган егетләргә, сугыш авырлыгын сокланргыч сабырлык белән кичереп, дөньядан киткән безнең аналарыбызга гүзәл һәйкәл булырлык. Минем соңгы егерме биш ел эчендә бер генә татар язучысының да әсәреннән болай тәэсирләнгәнем һәм эчтән елаганым юк иде. Бу әсәр – Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять»еннән соң психологик прозаның яңа баскычы, күтәрелеше».

Безгә хәзер Италия зиратында очрап, шушы олуг шәхесне, олы талантны татар ягына борган өчен теге әбигәме, әллә язмышкамы, рәхмәт әйтәсе генә кала.

Язманы исә әдипнең иҗатын да, үзен дә бик шәп белгән Равил Рахманиның ун ел элек әйткән сүзе белән төгәлләргә булдым: «Холык-фигыль белән яшьләрчә дәртле, житез, хыялый; кешеләр белән мөнәсәбәтендә – сабыйларча эчкерсез, ихлас, беркатлы; бәхәс-фикердә - үсмерләрчә кызу, тәвәккәл, максималист; иҗатында – аксакалларча тирән, төгәл, саллы булган бу әдип үзен күңеле белән һаман әле яшь-жилкенчәк итеп тойса да, янып-яшәп узып киткән еллар саны инде аз түгел...»

Йөрәгенә авыр операцияне дә кичергән кеше әле агаебыз. Кадерен белик аның!

**Рафикъ ЮНЫС**

***

*Туган телемдә язылган беренче хикәям мине Казанга алып килде...*

*Ул чакта әдәби журналыбыз «Совет әдәбияты» атала иде. Мине журналның баш мөхәррире Газиз Мөхәммәтшин каршы алды. Кош теле зурлыгындагы сыңар хикәя авторына шундый хөрмәт күрсәтү? Мин моны аңлый алмыйм. Ул чакта газета-журнал редакцияләре Бауман урамы, 19да иделәр. Газиз мине редакторларның күбесе белән таныштырды. Минем бәхетемә каршы, «Совет әдәбияты»на Фатих ага Хөсни белән Габдрахман Әпсәләмов килгәннәр иде. Баш редактор алар белән дә таныштырды. Мине хәйран калдырган нәрсә - алар да минем хикәямне укыган булып чыктылар. Җылы сүзләр әйттеләр, киңәшләрен бирделәр...*

*«Безнең өй өянке астында иде...»гә булган җылы караш мине урыс телле язучы булып китүдән коткарып калды. Урысча язу миңа күпкә җиңелрәк иде. Өлкән абзыйлар телендә иҗат иткән булсам, мин бик күп китап чыгара алыр идем. Китапларым күп булыр иде, әмма бәгърьемне тырнап әрнеткән сүзләремне урыс телендә әйтеп бушана алыр идемме? Юктыр. Туган тел бит ул... Нишләп аңламыйлар икән шуны?! Туган телеңне югалту белән син бит инде әнкәңнең бишек җырларын, беренче мәхәббәтеңнең саф тойгыларын, туган телдә сөйләшеп яшәгән чорның алсу хыялларын югалтасың. Соңыннан бу югалтуларны никадәр тырышсаң да кайтара алмыйсың. Аянычлы югалту бу... Һәм... югалтуларыбызны татар үҗәтлеге белән дәвам итәбез!*

**Миргазиян ЮНЫС.**
*2001 ел.*

## İctimaği-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### ЯЗУЧЫЛАР ҖЫЕНЫ

18 май көнне Татарстан язучыларының XVII корылтае булып узды.

Җыен башланыр алдыннан ТР Президенты Рөстәм Миннеханов мәдәният министры Айрат Сибагатуллин һәм каләм әһелләре белән баштанаяк төзекләндерелгән Язучылар йортын карап йөрде. Бина архитектура истәлеге булып санала. Президент ике катлы бинаны карап чыкканнан соң, ремонт эше уңышлы башкарылган, дип бәяләде.

Корылтайны Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин ачты. Аннары «Казан» милли мәдәният үзәгендә корылтай башланып китте. Ике корылтай арасындагы әдәби процесс һем әдәбият алдында торган мәсьәләләр турында Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов доклад белән чыкты.

Корылтай эшендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады. Ул үзенең чыгышында язучыларны заман белән бергә атларга, яна казанышларга таянып иҗат итәргә, тәрҗемә мәсьәләләренә ныграк игътибар итәргә чакырды. «Республикада тыныч, толерант мөнәсәбәтләр саклану өчен мин язучыларга да рәхмәтле. Безгә мөнәсәбәт, халыкара җәмгыятьтәге урыныбыз сез иҗат иткән әсәрләргә дә таянып формалаша», — диде ул.

Язучылар җыенында төрле җанрлар буенча докладлар тыңланды, күпсанлы чыгышлар, бәхәсләр, тәкъдимнәр булды.

Корылтайның икенче өлешендә гамәлдәге Устав нигезендә берлеккә яңа рәис сайланды. Сайлауда күпчелек тавыш белән Рафис Корбан ТР Язучылар берлеге рәисе итеп сайланды. Аннан соң 25 кешедән торган идарә составы тәгаенләнде.

Татарстан Язучыларының XVII корылтае турында тулырак язма журналыбызның киләчәк санында биреләчәк.

### ГӨРЛӘП ҮТТЕ ЮБИЛЕЙ

17 май көнне Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театры бинасында «Казан утлары» журналының 90 еллыгы уңаеннан әдәби-музыкаль кичә булып узды. Иң элек журналның баш мөхәррире, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин сүз алды.

— Без әдәбиятыбызның мең еллык тарихы бар дип горурланып әйтәбез, — дип башлады ул чыгышын. — «Кыйссаи Йосыф» әсәренең иҗат ителүенә дә хәтсез гасырлар узган. Быел татар телендә басма китап чыга башлауга 400 ел тула. Безнең өчен зур истәлекле дата бу. Меңнәр димәктән, моннан 6 ел элек без элекке СССРда нәшер ителеп килгән журналлардан беренче булып «Казан утлары»ның меңенче санын чыгардык. Мең еллык тарихы булган әдәбият өчен 90 ел азрак түгелме, дияр кемдер. Әлбәттә, ХХ гасыр башында ук чыккан «Әлгасрелҗәдид», «Шура», «Аң» кебек әдәби-иҗтимагый басмаларны чишмә башы дип санасак, яшебез йөз елдан күпкә артып китәр иде. Әмма журналның 90 еллыгы да халкыбызның иҗтимагый-эстетик фикер үсеше, әдәбият-мәдәниятебезнең үткәне һәм бүгенгесе турында уйланып, киләчәкне анык күзаллап, бәйрәми хис белән билгеләп үтәрлек олы вакыйга.

Кичәдә «Казан утлары» журналы авторларын һәм укучыларын Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр җитәкчесе урынбасары Нурия Беломоина, «Татмедиа» ААҖ генераль директоры Айдар Сәлимгәрәев тәбрикләде. Шулай ук Татарстанның беренче Президенты М.Шәймиевнең котлау сүзләре укылды.

Кичәдә «Казан утлары» журналы Г.Тукайның 125 еллыгы уңаеннан үткәргән «Печән базары» дигән сатирик әсәрләр бәйгесенә йомгак та ясалды. 1 нче урынга драматург З.Хәким, 2 нче урынга Ф.Баттал һәм Л.Гатина, 3 нче урынга Р.Батулла, М.Әмирханов һәм Н.Әхмәдиев, ә кызыксындыру бүләгенә В.Нуриев һәм Р.Габделхакова лаек булды. Күренекле артистыбыз Р.Шәрәфи бәйгедә катнашкан әсәрләрнең берсен тамашачыларга да укып ирештерде. Ә танылган артистыбыз И.Әхмәтҗан һәм Г.Камал исемендәге театрның яшь актерлары кичәнең кунакларын классик шигърият үрнәкләрен укып сөендерде.

Редакция коллективын һәм язучыларны уртак бәйрәмнәре белән «Агыйдел» журналының баш мөхәррир урынбасары Рамил Янбәк, Татарстан Язучылар берлегенең ул вакыттагы рәисе И.Ибраһимов, тарих фәннәре докторлары Энгель һәм Индус Таһировлар тәбрикләде. Танылган җырчы-

лар З.Сөнгатуллина, Р.Маликов, И.Вәлиев, Г.Мурзиева һ.б. котлау сүзләрен жыр аша, ә Татар дәүләт жыр һәм бию ансамбленең биюче кызлары бию аша ирештерде.

### ИЗГЕ БОЛГАР КУНАКЛАР ЖЫЙДЫ

Бу атнада Изге Болгар жирендә Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми кабул итү көне зурлап билгеләп үтелде. Бу көнне тантаналы рәвештә берьюлы бернича тарихи һәйкәл ачылды. Мәсәлән, «Истәлек билгесе» дип аталган монументаль музей-күргәзмә корылмасы «Татарстанның мәдәни мирасы: Борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя шәһәр-утравы» комплексы проектының иң әһәмиятле объекты булып тора. Борынгы Болгар өслүбендә төзелгән әлеге бина 10 катлы йорт биеклегендә. Гөмбәзе һәм зур ярымае алтын белән йөгертелгән. Ул Идел елгасыннан да, жир өсте юлларыннан да күренеп тора. «Истәлек билгесе»нең проект авторы — «Акибанк» акционерлык жәмгыяте рәисе Илдар Галәветдинов. Узган ел Италиядә эшләтеп, Кол Шәриф мәчетенә кайтарылган иң зур Коръән дә бу көнне шушы мәгърур бинада урын алды.

Икмәк музее исә иң заманча музей буларак игътибарга лаек. «Изге Болгарда ният ителгән эшләр жиренә житкереп башкарылып килә», — диде Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев. Аннан соң Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм республика «Янарыш» фондының Попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиев «Акибанк»ның идарә рәисе Илдар Галәветдиновка фондның Рәхмәт хатын тапшырды.

### «БӘЛЛҮР КАЛӘМ» ЧЫНЫГА БАРА

19 майда ТР Матбугаты көне билгеләп үтелде. Шул көнне журналистлар арасында үткәрелә торган традицион «Бәллүр каләм — Хрустальное перо» бәйгесенә дә йомгак ясалды. Бәйге жиңүчеләрен «Пирамида» мәдәни-күнел ачу комплексында бүләкләделәр.

ТР Премьер-министры Илдар Халиков, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы житәкчесе Марат Моратов, министрлыктан ведомство башлыклары, Мәскәүдән килгән хөрмәтле кешеләр чараның мәртәбәле кунаклары булды.

Премьер-министр И.Халиков: «Үткән ел республикада бик күп вакыйгалар булды, шуның белән бергә, журналистларның «Бәллүр каләм»е тагын да үткенәйде, уңышка ирешергә заманча технологияләр, сәяси активлык та тәэсир итми калмагандыр», —диде.

«Конкурсны инде 15нче тапкыр үткәрүебез бик әйбәт, димәк, ул журналистларга ошый», — дип билгеләп үтте Р.Ратникова үз чыгышында. Шулай ук ул бәйгедә 175 кешенең жиңүче булырга дәгъва итүен һәм лаеклы эшләрнең күп булуын әйтте. М.Моратов исә, үз чыгышында, Татарстанда меңнән артык гаммәви мәгълүмат чарасы эшли, бу бик зур коллектив, дип билгеләп үтте. Аның сүзләре буенча, әлеге журналистлар конкурсында катнашырга теләк белдерүчеләр елдан-ел арта һәм аның чикләре дә киңәя бара.

«Бәллүр каләм — Хрустальное перо» бәйгесенең төп бүләге — «FIAT» машинасы исә бу юлы «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясенең радиотапшырулар хезмәте башлыгы Тәүфикъ Сәгыйтовка бирелде.

### ТЕАТР ТОРМЫШЫН САКЛАУ МӘСЛИХӘТ

Мәдәният һәм сәнгать әһелләреннән зурлыгына бер төркем Казанда театр һәм музыка мәдәнияте музее булдыруны үтенеп, республикабыз Президенты Р.Миңнехановка мөрәҗәгать итте. Мөрәҗәгатьтә музей өчен башкалабыздагы күп еллар тәрәзә, ишекләре кадакланган көе әрәм булып торган борынгы биналарның берсен, мәсәлән, Лобачевский урамы чатындагы 3нче йортны бирергә тәкъдим ителә. Бирелә 1897-99 елларда бөек актер В.Качалов яшәгән, кунакханә буларак хезмәт иткән бу йортта бик күп танылган актерлар тукталган. Хатка Татарстан Театр әһелләре берлеге рәисе, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры баш режиссеры Ф.Бикчәнтәев, Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәржани исемендәге Тарих институты директоры Р.Хәкимов, К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры баш режиссеры Р.Заһидуллин, Татарстан һәм Россиянең халык артистлары Н.Юлтыева, З.Сөнгатуллина, Р.Тажетдинов, В.Кешнер һ.б. кул куйган.

### МИЛЛӘТНЕ ШӘХЕСЛӘР КҮТӘРӘ

Мәскәү каласында «Зыялылар клубы»ның чираттагы кичәсе «Жыен» фонды чыгарган затлы китапларны — «Шәхесләребез» сериясен тәкъдим итүгә багышланды. Казаннан килгән мәртәбәле кунаклар — Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев, Татарстанның халык язучысы Гәрәй Рәхим, «Жыен» фондының башкаручы директоры Фуат Рафиков, жырчылар Рамил Миндияр, Наилә Фатыйхова, Рөстәм Асаев, Мәликә, һ.б. катнашында узган бу кичә бик тә эчталекле һәм югары сәнгати дәрәжәдә булды.

«Жыен» фонды халкыбызның күренекле шәхесләренә багышлап, инде 30дан артык фәнни-популяр китап бастырып чыгарды. Ул шәхесләрнең байтагы үз чорының корбаны булып, онытылырга дучар ителгән иде. Аларның тормыш һәм

ижат юлын җентекләп өйрәнеп, архив материаллары, тарихи документлар белән нығытып эшләнгән бу уникаль басмалар, һичшиксез, халкыбызның хәтер сандыгын баетуга, милләтебезнең куәтен арттыруга хезмәт итә.

### ОСТАЛАРГА УРМАНЧЕ БҮЛӘГЕ

«Хәзинә» милли сәнгать галереясендә бөек остабыз Б.Урманченың 115 еллыгы уңаеннан күргәзмәсе ачылды. Шул ук көнне Б.Урманче премиясенең быелгы лауреатларын бүләкләделәр. Быел нәкыш төрендә әлеге бүләккә «Алтынчәч», «Бәйрәм коймаклары», «Кыз карау» картиналар шәлкеме өчен Рабис Сәлахов, графика төрендә «Хатын-кыз образлары» шәлкеменнән бер триптих өчен Рият Мөхәммәтдинов, декоратив-бизәү сәнгате төрендә «Алтын Урда» композициясе өчен Зөфәр Низаметдинов, сәнгать белеме төрендә мәкалә һәм очерклар шәлкеме, «Рифкат Вахитов» альбомына әзерләгән мәкаләсе өчен Рауза Солтанова лаек булды. Ә «Милли мон» триптихы өчен Сәгыйдә Сиражиевага, «Җырчы» картинасы өчен Павел Бердниковка, «Татар халык әкиятләре» шәлкеме иллюстрацияләре өчен Зифа Мөхәммәтҗановага кызыксындыру бүләкләре тапшырылды.

### ЗУР ТЕАТРНЫҢ ОЛУГ ШӘХЕСЕ

Дәүләт академия Зур театры генераль директоры Анатолий Иксановка Татарстан Республикасы Президенты Рәхмәте белдерелде. Таныкнамәне Анатолий Геннадьевичка (Таһир Гаделҗан улына) Татарстанның РФдәге Тулы хокуклы вәкиле Равил Әхмәтшин Зур театр бинасында тапшырды.

Таһир Гаделҗан улына Президент Рәхмәте 60 яшь тулу уңаеннан, шулай ук Татарстан Республикасы белән элемтәләрне ныгыту һәм үстерүгә керткән шәхси өлеше һәм уңышлы хезмәттәшлек өчен белдерелде. Югары бүләккә рәхмәт әйтеп, Зур театрның генераль директоры Татарстан проектларын һәрвакыт якларга әзер булуын җиткерде.

Зур театрның генераль директоры итеп ул 2000 елда РФ Хөкүмәте Рәисе карары нигезендә билгеләнгән иде. Соңгы 10 елда Иксанов һәм аның командасы төп бинаны яңартып коруда, яңа сәхнә ачуда, труппаны күчерүдә зур хезмәт куйды. Таһир Гаделҗан улы җитәкчелегендә Зур театрның Попечительләр советы төзелде, финанслау җайланды, халыкара бәйләнешләр активлашты, җырчылар өчен яшьләр программасы ачылды, афишаны хәзерге заман хореографлары, композиторлары, режиссерларының исемнәре тулыландырды.

***

Уфада күренекле милләттәшебез, «Азатлык» радиосының татар-башкорт редакциясенә байтак еллар җитәкчелек иткән Гариф Солтанны искә алу чаралары булып үтте. Мәрхүм рухына багышлап Коръән укылды һәм искә алу мәҗлесе оештырылды. Гариф Солтан узган елның ноябрь аенда Мюнхен шәһәрендә 88 яшендә вафат булды. Гариф Солтанның бай китапханәсе һәм архив материаллары туган илгә кайтарылды һәм Татарстан Фәннәр академиясенә тапшырылды.

***

Күпьеллык иҗади эшчәнлеге, әдәбиятны һәм сәнгатьне үстерүгә зур өлеш керткәне өчен профессиональ язучы **Хәмидуллин Ризван Мирхәбибулла улы** (Ризван Хәмид) Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар халкы, Урта Идел һәм Урал буе халыклары тарихын һәм мәдәниятен пропагандалау эшенә зур өлеш керткәне өчен Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең «Фән» нәшрияты баш мөхәррире **Хәмидуллин Булат Лирон улына** «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, әдәбият һәм мәдәният үсешенә зур өлеш керткәне өчен «Татмедиа» ААҖ филиалы «Мәгариф» журналы редакциясе бүлек мөдире **Әхмәтҗанова Сания Юныс кызына** «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Татар халкы, республика җәмәгатьчелеге чиксез зур югалту кичерә. 2012 елның 2 маенда 77нче яшендә Татарстанның Халык язучысы, мәшһүр драматург, публицист, ТР Дәүләт Советы депутаты һәм җәмәгать эшлеклесе **Туфан Габдулла улы МИҢНУЛЛИН** кинәт вафат булды.

Туфан Миңнуллин 1935 елның 25 августында Татарстан АССРның Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылында игенче гаиләсендә туа. 1952 елда, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Олы Кариле һәм Кама Тамагы авылларында хисапчы булып эшли, аннан соң, Казанда бухгалтерлар курсын тәмамлап, комсомол юлламасы буенча Казахстанның Кустанай өлкәсенә чирәм җирләрне күтәрергә китә. Анда совхозларның берсендә баш бухгалтер вазыйфаларын башкара. 1956-61 елларда Мәскәүдә М.С.Щепкин исемендәге театр училищесында укый. Училищены тәмамлаганнан соң беркадәр Минзәлә драма театрында, аннан соң Казанда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында актер булып эшли. 1964-67 елларда Казан телевидение студиясендә баш мөхәррир вазыйфаларын башкара һәм «Чаян» журналы редакциясендә бүлек мөхәррире була. 1968 елдан башлап, һөнәри төстә әдәби эшчәнлек белән шөгыльләнә. 1975-77 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларда укый.

Т.Г.Миңнуллин әдәбият мәйданына узган гасырның 60нчы елларында юмористик хикәяләр һәм кечкенә пьесалар белән килеп керә. Аннан соң ул иҗатын зур драматик формаларда дәвам итә. 1962 елда яшь авторның ике пьесасы сәхнәгә куела, алар шунда ук тамашачылар игътибарын җәлеп итә. Минзәлә драма театры сәхнәсендә өч пәрдәлек «Безнен авыл кешеләре» комедиясе күрсәтелә, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында балалар өчен «Азат» пьесасы сәхнәләштерелә. 1967-69 елларда Әлмәт дәүләт театрында «Күрше кызы» спектакле, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында «Миләүшәнең туган көне», Татарстанның республика Күчмә театрында (хәзерге К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) «Нигез ташлары» һәм «Йөрәк янарга тиеш» дигән яңа пьесалары сәхнәләштерелгәннән соң, Туфан Миңнуллин әдәби тәнкыйть тарафыннан өлгереп житкән драматург буларак телгә алына.

Узган гасырның житмешенче-сиксәненче елларын Туфан Миңнуллинның табигый сәләте бөтен тулылыгы белән ачылган чор дип әйтергә мөмкин. Аның үткен каләменнән илледән артык драма һәм комедия, балалар өчен дисталәгән пьеса һәм әкият туа. 1963 елдан алып 1999 елга кадәре чорда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә генә дә Т.Миңнуллинның 26 пьесасы куела. Әлеге спектакльләрнең барысы да диярлек тамашачыларда зур кызыксыну тудыра һәм озын гомерле була. Т.Миңнуллин әсәрләре бүген дә К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Әлмәт, Минзәлә, Чаллы һөнәри театрлары репертуарында үзәк урынны алып тора.

Авторның аерым әсәрләре, бигрәк тә «Әлдермештән Әлмәндәр» фәлсәфи комедиясе, «Ай булмаса, йолдыз бар» драмасы, «Диләфрүзгә дүрт кияү» водевиле Башкортстан, Мари Иле, Удмуртия, Бурятия, Дагыстан, Казахстан, Кырызстан,

Таҗикстан милли театрлары, шулай ук Омск, Воронеж, Әстерхан, Мурманск, Мичурин, Түбән Новгород, Новокузнецк рус театрлары сәхнәләрендә зур уныш белән бара.

Туфан Миңнуллин татар балалар драматургиясен үстерүгә зур өлеш кертте. Аның «Азат», «Гафият турында әкият», «Айга сәяхәт», «Айбулат», «Авыл эте Акбай» һәм башка әкияти пьесалар сериясе, «Иптәш командир!» һәм «Кайда хаклык, кайда дөреслек?» комедияләрен берничә буын яшь тамашачы яратты.

1974 елда Туфан Миңнуллин «Нигез ташлары» комедиясе һәм «Үзебез сайлаган язмыш» драматик повесте өчен М.Җәлил исемендәге Республика бүләгенә, 1979 елда «Ай булмаса, йолдыз бар» спектакле өчен Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. 1979 елда «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакле өчен Туфан Миңнуллин, режиссер Марсель Сәлимҗанов һәм төп рольне башкаручы Шәүкәт Биктимеров Россиянең К.Станиславский исемендәге Дәүләт бүләген алдылар. Театр сәнгатен үстерүдәге аеруча зур өлеше өчен Т.Миңнуллинга 1978 елда «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе», 1984 елда «Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе», ә 2005 елда - «Башкортстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемнәр бирелде. 1984 елда ул «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнде. 2005 елда Т.Миңнуллинга «Татарстан Республикасының Халык язучысы» исеме бирелде. Шул елда ук ул «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләнде. Т.Миңнуллин - Казан шәһәренең мактаулы гражданы.

1984 елдан алып 1989 елга кадәр Т.Миңнуллин Татарстан Республикасы Язучылар берлегенә җитәкчелек итте. 1997 - 2008 елларда ул Халыкара ПЕН-клубның Татар ПЕН-үзәге рәисе вазыйфаларын башкарды.

Т.Миңнуллин СССР халык депутаты (1989-91), берничә чакырылыш Татарстан парламенты депутаты булып сайланды.

Бөтен тормышын һәм иҗатын үз халкына багышлаган, гомеренең соңгы минутларына кадәр намуслы граждан позициясеннән тайпылмаган талантлы язучы һәм кеше арабыздан китте. Туфан Габдулла улы Миңнуллин турындагы якты истәлек йөрәкләребездә мәңге сакланыр.

**Р.Н.Миңнеханов, М.Ш.Шәймиев, Ф.Х.Мөхәммәтшин, И.Ш.Халиков, З.Камалтынов, З.Р.Вәлиева, А.М.Сибагатуллин, И.Р.Метшин, З.Г.Гарәфиев, И.М.Ибраһимов, Ф.Р.Бикчәнтәев, Р.М.Заһидуллин.**

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Җәйнең бер мизгеле.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Булат Хәмидуллин**.

# Конкурс төгәлләнде, әмма «базар» ябылмый

Г.Тукайның тууына 125 ел тулу уңаеннан «Казан утлары» журналы сатирик әсәрләргә «Печән базары» исемле конкурс игълан иткән иде. Бәйгедә йөздән артык автор катнашты. Аларның күбесе журналда басылып чыкты. Кырыклап әсәр «Яңа базар» дигән китабыбызга керде. Мөхтәрәм язучылардан торган жюри конкурска йомгак ясады.

*I урын (50 мең сум):* «Бармы ришвәткә дәва?» пьесасы өчен **Зөлфәт ХӘКИМ**гә бирелде.

*II урыннарда(30ар мең сум):* **Фәнзаман БАТТАЛ** — «Җәһәннәмдә дәҗҗал» хикәясе.
**Ләйсән ГАТИНА (Сәйләп)** — «Авыл мәктәбен япкач, мөгаллимнәре ни диләр?» Шигъри фельетон.


*III урыннарда(10ар мең сум):*
**Рабит БАТУЛЛА** — «Төнге мәҗлес» хикәясе.
**Марат ӘМИРХАН** — «Их, мать якасын, Черчилегезнең сатыйм анасын» хикәясе.
**Нур ӘХМӘДИЕВ** — «Алтын балык турында заманча әкият».

*Кызыксындыру премияләре (5әр мең сум):*
**Вакыйф НУРИЕВ** — «Казан күркәсе» хикәясе.
**Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА (Чулпан)** — «Хөкем» хикәясе.

Дипломнар «Казан утлары» журналының 90 еллыгына багышланган кичәдә тапшырылды (Камал театры, 17 май).

Конкурс тәмам. Әмма «Печән базары» ябылмый, журналның сатирик әсәрләр рубрикасы булып кала.
Яңа әсәрләр көтәбез!





Булат Хәмидуллин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)